# Казан утлары

10 . 1985



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

10

1985

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

КПССның XXVII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

М. ЗАРИПОВ, А. ПОДОЛЬСКИЙ. Алтын орлык . . . 3

Р. ГӘРӘЙ. Күңелемдә яфрак яралар. Шигырьләр . . . 15
В. НУРУЛЛИН. Ике урам арасы. Повесть . . . . . 20
К. ЛАТЫЙП. Уй сәяхәте. Шигырьләр . . . . . . 83
Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Тайга аланында. Шигырьләр . . . 85
Р. ХӘЛИУЛЛИНА. Чаң . . . . . . . . . . . 88
З. ФӘТХЕТДИНОВ. Кем — кемне... Повесть . . . 92
Г. САДӘ. Кура ярында. Шигырьләр . . . . . . 126

МӘГЪСҮМ НАСЫЙБУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

М. НАСЫЙБУЛЛИН. Шөбһә. Хикәя . . . . . 129

СЕРГЕЙ ЕСЕНИННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

С. ЕСЕНИН. Шигырьләр . . . . . . . . . . 141

САЛИХ БАТТАЛГА 80 ЯШЬ

С. БАТТАЛ. Яктырту. Шигырьләр . . . . . . . 143

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ХАҖИӘХМӘТОВ. Уральскида Тукай урыннары . . . 146
Я. АБДУЛЛИН, Р. ӘМИРХАНОВ. Революцион-демократик идеология һәм XX йөз башында әдәби хәрәкәт . . . . . . . . . . . . . . 147
Э. ГОБӘИДУЛЛИНА. Тукай исемендәге театр . . . 156

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Х. ХӘИРЕТДИНОВ. Гөлбакчада яшибез . . . . 158

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

Б. КАМАЛОВ. Төп һөнәрләре — өйрәнү. Очерк . . 161

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. МУСИН. Детектив турында . . . . . . . . 166

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*

**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

**ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ**

**Уйландыра, тәэсир итә** . . . . . . . . . . . 173

**БИБЛИОГРАФИЯ**

Җ. МИҢНУЛЛИН. **Азатлык җырчысы** . . . . . 176

**ЮБИЛЕЙЛАР**

М. ГАИНУЛЛИН, Җ. ВӘҖИЕВА. **Заһидә Бурнашева** . . . . . . . . . . . . . . . 179

Р. ИСХАКОВА-ВАМБА. **Үз аһәңе бар** . . . . . 182

**СӘНГАТЬ**

Ф. ӘҺЛИУЛЛИНА. **Чынлыкка омтылу** . . . . . 183

**Кызыклы хәлләр** . . . . . . . . . . . . . 188

**Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары** . . . . . . . . . . . . 189

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . 190

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Окончание автобиографической повести В. НУРУЛЛИНА «Друзья-товарищи». Детективная повесть З. ФАТХУТДИНОВА «Кто — кого...»
Рассказ М. НАСИБУЛЛИНА «Подозрение».
Стихи С. БАТТАЛА, Р. ГАРАЯ, К. ЛАТЫЙПОВА, Б. СУЛЕЙМАНОВА, Р. ХАЛИУЛЛИНОЙ, Г. САДЭ.
К 90-летию С. Есенина: стихи С. ЕСЕНИНА.
Навстречу XXVII съезду партии: очерк М. ЗАРИПОВА, А. ПОДОЛЬСКОГО об опыте выращивания люцерны.
К 100-летию Тукая: рисунок Т. ХАЗИАХМЕТОВА из серии «Тукаевские места в Уральске», статьи Я. АБДУЛЛИНА, Р. АМИРХАНОВА, А. ГУБАЙДУЛЛИНОЙ.
В рубрике «Татарстан — родной мой край». Статья первого секретаря Зеленодольского ГК КПСС Х. ХАЙРУТДИНОВА.
«АЭС — литературный пост». Очерк Б. КАМАЛОВА о строителях АЭС.
В разделе «Литературная критика» статья Ф. МУСИНА «Детектив», письма читателей о романе Г. Кашапова.
В номере отмечаются юбилеи З. Бурнашевой, Х. Якупова.
В рубрике «Искусство» статья Ф. АХЛИУЛЛИНОЙ о народном артисте СССР Ш. Биктимерове.
Дневник культуры
На наших обложках.

Техник редактор Р. Сөләйманова. Корректорлар А. Садыйкова, Г. Салихҗанова.

Производствога бирелде 02.08. 1985 ел. Басарга кул куелды 08.10. 1985 ел. ПФ 05296 Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 X 108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8)
Тираж 64049. Заказ Ф-347. Бәясе 90 тиен

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1985 ел.

Марсель Заркипов,
Анатолий Подольский

# АЛТЫН ОРЛЫК

Ярты миллионлаган үсемлекнең күбесе орлыктан үрчи. Орлык бөртеге — яңа тормыш яралгысы. Бу хакыйкать безгә яхшы таныш. Шулай да менә «люцерна орлыгы» дигән сүз сәеррәк яңгырый. Бу төшенчә нинди күренешләрне күзалларга ярдәм итә соң? Моңа тәгаен генә җавап бирү дә кыен. Чынбарлыгыбызда исә люцерна басуларын киңәйтү, шуңа бәйләнешле рәвештә, аның орлыгын күпләп җитештерү ихтыяҗы арта бара.

1965 елда Россия Федерациясендә берьеллык үлән терлек азыгы чәчелгән барлык мәйданның өчтән бер өлешен диярлек, ә күпьеллык үлән биштән бер өлешен генә тәшкил иткән. Бүгенге көндә берьеллык үләннәргә барлык азык культуралары мәйданының дүрттән бер өлеше туры килә. Соңгы вакытта күпьеллык үләннәр — бигрәк тә кузаклылар төркеменә керә торган люцерна, клевер, эспарцет кебек үсемлекләр чәчүгә күбрәк игътибар бирелә башлады.

Безнең игътибарны, барыннан да элек, мәсьәләнең практик ягы — люцернаның кара туфраклы Кубань җирендә дә, Урта Азиянең эссе үзәнлекләрендә дә, Уралда, Себердә һәм Ерак Көнчыгышта да гөрләп үсүе үзенә тартты.

Төп йортыбыз булган Җирне һәр җәй саен яшел келәмгә төрә торган йөз меңнәрчә үсемлекнең азык чыганагы буларак төп сыйфатлары әлегә чагыштырмача бик аз өйрәнелгән. Галимнәр нибары биш мең чамасы үләнне тикшергәннәр. Алар арасыннан туклыклылыгы, файдалылыгы ягыннан алдагы урыннарның берсе люцернага туры килә.

Көтүче-терлекчеләр мондый үлән үскән көтүлекләрдә йөргән терлекләрнең ите-сөте тәмлерәк, туклыклырак булуына элек-электән игътибар итә килгәннәр. Фәнни трактатларда да бу мәсьәлә шактый киң яктыртыла. Шулай да әле ахырынача хәл ителеп бетмәгән, хәтта, беренче карашка, бәхәссез хакыйкать булып күренгән нәрсәләргә тагын мөрәҗәгать итик әле.

* * *

Люцернаның көчле тамырлары дымны биш метр тирәнлектән ала. Шуңа күрә ул корылыктан курыкмый. Ә аның үзе шытып чыккан җир мәйданыннан сиксән алты мәртәбә зуррак яфраклары туклыклы матдәләр запасын шул ук зурлыктагы мәйданны тәэмин итәрлек күләмдә тупларга, кояш энергиясен мулрак җыеп калырга, шулар аркасында салкын якларда да үсәргә мөмкинлек бирә. Язын ул иң алдан җирне яшел келәм белән каплап өлгерә һәм иң каты кыраууларга кадәр үсә дә үсә. Бер кат чабып алганнан соң, иренмичә, өстәмә ашламалар кертсәң һәм кирәгенчә сугарсаң, люцернадан көньякта елына биш-алты, ә Россиянең кара туфраксыз өлкәләрендә ике-өч тапкыр уңыш алырга мөмкин. Люцернаның һәр гектарыннан 100—150 центнер азык берәмлеге алына. Туклыклылыгы ягыннан һәр азык берәмлеге исә бер килограмм солыны алыштыра.

Тормышта бик күп төрле үлчәү берәмлекләре бар. Арада азык берәмлеге дигән эталоннан да шартлырак тагын берәр үлчәм бармы икән?! Азыкның кыйммәте аның составында протеин, каротин кебек аминокислоталар, төрле витаминнар, ягъни организмга кирәкле матдәләрнең күпме булуы белән билге-

ләнә. Тәҗрибәле крестьян утлыкка арыш, бодай кебек бөртеклеләрне түгел, ә туклыклылыгы югарырак булган солы, арпа, вика ише азык салуны хуп күрә. Һәр азыкның үз урыны, үз өстенлеге бар. Арыш һәм бодай ипи-күмәч салырга кирәкле булса, үсемлек-үләннәрдән әзерләнгән терлек азыгы ит, сөт һәм май җитештерү өчен яхшы. Бу аермалык аларның җир һәм кояш биргән хәзинәне ризыкка әйләндерүче махсус аксымнарга — аминокислоталарга ни дәрәҗәдә бай булуына бәйле.

Хуҗалыкларда люцернаның күпме чәчелүе зоотехникларның агрономнардан бу культураны арттыруны таләп итүенә барып тоташа. Люцерна үзенә башка үсемлекләрдә булмаган туклыклы матдәләр запасын күпләп туплый. Бодайны без гадәттә бөртекле ашлыклар патшасы дип йөртәбез. Әмма анда лизин бик аз. Баһадир үсемлек саналган кукуруз гектарыннан йөзәр центнер уңыш бирә. Ләкин ул да организм өчен чиктән тыш кирәкле лизинга һәм триптофанга бик ярлы. Ә бит аның дүрттән өч өлеше фермаларга һәм катнаш азык хәзерләүгә китә.

Чәчеп үстерелә торган үләннәрдән люцернадан да туклыклырак азык юк. Аның бер килограммында утыз алты грамм протеин исәпләнә. Организм тарафыннан ул бик тиз эшкәртелә һәм җиңел үзләштерелә. Аннан соңгы урыннарны, эспарцет, борчак, клевер, арыш, солы белән катыштырылган вика, көнбагыш алып тора. Люцернаның төп өстенлеге аның лизин, метионин, триптофан, аргинин, гистидин, лейцин, изолейцин кебек алыштыргысыз аминокислоталарга бай булуында. Бу матдәләрне организм үзе эшләп чыгара алмый. Өстәвенә люцернада тимер, цинк, бакыр, марганец, кобальт кебек микроэлементлар бар.

Люцерна — басуларның уңыш бирүчәнлеген арттыру ягыннан да отышлы үсемлек. Бодай, арыш, кукуруз, арпа кебек культураларның мул уңышы туфрактагы матдәләрнең, барыннан да элек җирнең төп кыйммәте булган азотның кимүенә китерә. Агрономнар инде ничәмә-ничә йөз еллардан бирле хәл итәргә омтылган иң мөһим бурычларның берсе чәчүлекләрнең потенциаль мөмкинлекләрен саклаудан, аның уңыш үстерү һәм кешеләр өчен сарыф иткән көчен кире кайтарудан гыйбарәт. Бу — программа-минимум. Ләкин безнең көннәрдә моның белән генә чикләнмичә, алга тагын да зуррак бурыч куела. Җирнең куәтен элеккегә караганда да арттырырга тырышалар. Моның өчен һәркайсыбызның үз-үзен аямыйча, җиң сызганып эшләве сорала. Алдыбызга заман үзе куйган бу олы бурычны үтәүдә игенчеләр белән бергә басуларга «икмәк» бирүче химиклар, тимер юлчылар һәм башка бик күп төрле һөнәр ияләре катнаша. Кешеләр күп көч һәм чыгымнар түгеп башкара торган шул ук эшне исә люцерна табигый рәвештә үти: азотны һавадан суырып ала да аларны тамыр бүлбеләренә җыя. Бер гектар люцерна үстерү — җиргә алтмыш тонна черемә кертү белән бер. Кызганычка каршы, ил буенча бу сан биш тоннадан артмый. Начармыни: бер гектарга чәчелгән унбиш-егерме килограмм люцерна орлыгы йөз центнер ләззәтле азык өстенә тагын ярты центнер азот та калдыра!

Люцернаның һәм башка төрле күпьеллык үләннәрнең абруе көннән-көн үсә, кара туфраксыз басуларда алар үлән чәчелә торган мәйданның җитмеш процентын тәшкил итәчәк, дигән сүзләр дә ишетелгәли. Бу үләннәрнең орлыгын каян табарга мөмкин икәнлеген шыпырт кына әйт, аны сатып алырга теләүче хуҗалыкларның саны-хисабы булмаячак. Кырымнан да, Новосибирскидан да, Уралдан да, Украинадан да, Балтик буендагы совет республикаларыннан да, Белоруссиядән дә бик күп заказлар явачак.

Орлыкчылык белән шөгыльләнүче дәүләт оешмаларының үлән орлыкларын кирәк кадәр туплауга ирешә алганнары юк әле. Базарда исә люцерна орлыгы, дәүләт бәясенә караганда, ике-өч мәртәбә кыйммәтрәк тора. Эш акчада гына да түгел. Орлык хуҗалары металл, урман, яхшы токымлы терлек, трактор яки комбайн кебек «эквивалентлар» телендә сөйләшергә яраталар.

Безнең республикабыздагы «Корноухово» совхозының уңган директоры иптәш Крутилин 1983 елны «Советская Татария» газетасында, хуҗалык люцерна орлыгы сата, дигән белдерү бастырды. Бу якларда рәтле-башлы юл да юк, тимер юл станциясенә йөз чакрымлап. Ә сатып алучылар каян гына килмиләр: республикабызның барлык районнарыннан, күршедәге кара туфраксыз төбәкләрдән, Днепропетровскидан, Белоруссиядән... килүчеләр дә эзләп таптылар.

Элек-электән арыш, бодай, бәрәңге игү, ит һәм сөт җитештерү белән шөгыльләнгән гап-гади бу хуҗалыкка сату өчен дә артып калырлык люцерна орлыгы каян килгән соң? Җавап бик кыска: үзләре өлгерткән. Монда терлек

күп авырыйлар. Савым сыерлар гына да мең баштан артып китә. Шул чаклы малны ашатырга ике мең гектар җирдә люцерна чәчелә. Һәр ел саен ул мәйданның ике йөз гектары орлыкка калдырыла. Моның өчен урманга, әлегәчә сабан төрәне кагылмаган үләнле чокырларга якын участоклар сайлап алына. Андый урыннар үсемлекләрне серкәләндерүче төрле-төрле бөҗәкләргә бай була. Шулар өстенә алты йөз илле баш умарталары бар. Бер гектар люцерна җиренә өч баш умарта туры килә. Шушы чараларның нәтиҗәсе буларак, җыеп алынган орлык хуҗалыкның үзенә дә җитә, сатарга да кала.

Дөресен әйткәндә, «Корноухово» совхозының бу үтемле товары хәзергә әле авыз тутырып мактарлык дәрәҗәгә ирешмәгән. Аның кайчандыр һәм кайдандыр сатып алган беренчел орлыгы шушы көнгәчә бер тапкыр да үзгәртелмәгән, югары кондицияле орлык белән алыштырылмаган яки шул хәлгә китерелмәгән. Ләкин, бу очракта сату-алу хәрәмләшүсез, һәр ике якның да ризалыгы, үзара килешүе нигезендә алып барыла. Паспортланган яхшы сортлы чәчү материалына заказ бирер җирләре булмагач, агрономнар нишләргә, кая барырга тиеш? Бу сорауга җавап бирүе җиңел түгел.

Күпьеллык үләннәр орлыгына шундый ихтыяҗ, үлән басулы чәчү әйләнешенә мондый игътибар нәрсә белән аңлатыла? Барыннан да элек — җитмәүчелек, азыкка мохтаҗлык белән. Хуҗалыкларда терлекләрнең баш саны һәм шуңа бәйләнешле рәвештә ит-сөт, йомырка җитештерү арткannан-арта. Илебезнең Азык-төлек программасы туклану структурасын тагын да камилләштерүне күздә тота. Сугышка кадәрге 1940 ел белән чагыштырганда мөгезле эре терлекләрнең саны ике тапкырдан күбрәккә артты һәм йөз егерме миллион башка җитте. Шул ук чор эчендә дүрт тапкырдан артыграк ит, утыз өч миллион тонна сөт, унике миллион урынына җитмеш биш миллион данә йомырка җитештерелде. Бу үсеш бүгенге көндә тагын да кызурак темплар белән дәвам итә.

Хәзер авыл хуҗалыгы продукциясенең зуррак өлешен кырлар да, җиләк-җимеш бакчалары да түгел, фермалар һәм комплекслар бирә. Йөзләрчә, меңнәрчә яңа совхозлар үсеп чыккан кырык миллион гектар чирәм җирләр тулысынча диярлек фермаларга, ит, сөт, йомырка фабрикаларына хезмәт итә башлады. Сугышка кадәр терлек азыгы бөтен ил буенча унсигез миллион гектарда игелгән. Хәзер кукуруз, берьеллык һәм күпьеллык үләннәр, тамыразыклар игелә торган җир мәйданы алтмыш алты миллион гектар мәйданны били. Моннан тыш миллионнарча гектар табигый болыннар, печәнлекләр һәм көтүлекләр бар. Аларның барысын да карарга, тәрбияләргә, ашлама белән тәэмин итәргә, эшкәртеп-яңартып торырга кирәк. Терлекчелектә меңәрләгән, миллионлаган механизаторлар эшли. Алар иртә яздан алып көзге карлы яңгырларга кадәр сенаж, силос, печән, үлән оны, салам, тамыразыклар хәзерлиләр.

Бу зур, катлаулы һәм, әйтергә кирәк, гаять четерекле системада иң нечкә урын — орлыкчылык. Орлыкка кытлык күпьеллык үләннәр чәчү мәйданын теләгәнчә киңәйтергә мөмкинлек бирми, алар терлек азыгы игелә торган басуларның яртысын да тәшкил итә алмый. Ә белгечләрнең фикеренчә, күпьеллык үләннәр терлек азыгы игү өчен билгеләнгән җир мәйданының җитмеш процентын биләргә тиеш. Монда шулай ук чәчүлек җирнең нинди сыйфатка ия булуын да истән чыгарырга ярамый. Россия Федерациясе колхозларында һәм совхозларында һәр ике гектар клеверның бер гектары ике яшьтән артык. Инде май аенда ук һәм азык бигрәк тә күп кирәк булган салкын көз көннәрендә сусыл ризыкны мул бирә торган люцерна җирләренең кырык сигез проценты иске, карт үләннәрдән тора. Моннан да күңелсезрәк нәрсәнең булуы мөмкинме икән?! Яшь үлән чабылган җирдә кибәннәр зуррак һәм биегрәк. Үләне картайган мәйданнардан җыеп алынган печән исә чүмәлә куярга да җитми.

Люцерна—катнаш азыкларның туклыклылыгын яхшыртуда алыштыргысыз. Концентратларда яшел витаминнар ике-өч проценттан артмый. Зоотехниклар исә аны ун-унбиш процентка җиткерү ягында. Елына утлыкларга салына торган йөз утыз миллион тонна катнаш азыкның ун-унбиш процентын яшел үлән массасы белән алыштырганда күпме икмәк янга калачак! Өстәвенә, мондый азык белән туенган маллар ит, сөт һәм йомырканы да күбрәк бирәчәк.

В. Р. Вильямс исемендәге Бөтенсоюз азык институты директоры, ВАСХНИИЛның член-корреспонденты Митрофан Андреевич Смурыгин миңа мондый саннар китерде:

— Илдә терлекчелекне тәэмин итү өчен дүрт йөз илле миллион тонна азык берәмлеге җитештерелә. 1990 елга аны биш йөз егерме — биш йөз кырык миллион тоннага җиткерү бурычы куела. Хикмәт тонналарда гына түгел. Төп максат азыкның продукция бирү сәләтен күтәрүдән гыйбарәт. Кызганычка каршы, фермаларда рационнарга баланс ясалмаган. Бу исә «чимал»ның кирәгеннән артык тотылуына, әрәм-шәрәм ителүенә китерә. Яхшы сыердан, мәсәлән, бер килограмм азык ашатып, шул ук күләмдә сөт савып алырга мөмкин. Бүгенге көндә азык ярты килограммга артыграк тотыла...

Исәпләп караган идек: 1983 елда ил буенча «артык яндырылган ягулык» кырык сигез миллион тонна булган. Ит җитештерүгә дә азык шул ук бер ярым норма киткән. Җилгә очкан чыгымнарны бергә кушып исәпләсәң, үлчәү йөз миллион тоннага тарта. Зур сан! Бу мәгълүмат уйландырып кына калмый, хәлне төзәтү өчен кичекмәс чаралар күрүне дә сорый.

* * *

Гомумән, рационның туклыклылыгын күтәрү ысуллары күп. Терлек һәм кош-корт азыгына аксымга бай соя, борчак, химик тәмләткечләр, балык оны кушарга мөмкин. Әмма шулкадәр балыкны каян, кайсы диңгездән, нинди океаннан алырга? Ул бит алтын бәясенә төшәчәк. Шулай булгач, һәркем үстерә ала торган күпьеллык үләннәргә — люцернага, клевер һәм эспарцетка исәп тоту отышлырак.

Тиешенчә эшкәртелгән яшел үлән басулары, болыннары һәм көтүлекләре булган хуҗалыкларның эшләре дә әйбәт бара. Әгәр әнә шулар юк икән, анда терлекчелек тармагы акрын үсә. Мәсәлән, Кабарда-Балкария, Дон һәм Кубань — РСФСР күләмендә бөртеклеләрдән иң югары уңыш алучы төбәкләр, ләкин бу өлкәләрдә терлекләрне кышлату үзе бер проблема булып кала бирә, фермаларда җәйне җиткерә алмый йөдәп бетәләр.

Люцернага бәйләнешле мәсьәләләргә җавап эзләп йөргәндә без күршедәш ике районга — Татарстанның Балтач һәм Киров өлкәсенең Малмыж районына да барып чыктык. Алар икесе дә бер үк шартларда, әмма төрлечә хуҗалык итәләр. Балтачлылар, сигез мең баш савым сыер өчен, яртысыннан артыграгы сугарулы алты мең гектар җиргә күпьеллык үләннәр, нигездә люцерна чәчәләр. Дөрес, аларның да үз орлыклары җитми, бер өлешен сатып алалар. Хәзер биредә һәр сыерга ясалма яңгыр яудырылган ярты гектар яшел участок туры килә. Һәр сыердан уртача савып алынган сөт өч мең биш йөз килограмм тәшкил итә.

Малмыж районы хуҗалыкларының яртысы исә терлекләргә берьеллык үлән ашаталар, шул сәбәпле сөтне һәр сыердан күршеләрнекенә караганда нәкъ бер тоннага кимрәк савалар. Алга таба ничегрәк эшләү турында сүз чыккач, КПСС райкомы секретаре Виктор Леонтьевич Колупаев терлекчелекне үстерү өчен бөртеклеләр мәйданын киметергә мәҗбүр булуларыннан зарланды. Ә бит заманында, мәсәлән, 1967 елда монда ике мең гектар мәйданның һәр гектарыннан 1,2 центнер люцерна орлыгы җыеп алынган. Көньякта алына торган уңыштан һич тә ким түгел бу!

Чувашстанның Батыр районындагы «Гвардеец» колхозы люцерна орлыгын Үзбәкстаннан бәрәңгегә алыштырып ала. Ә Ядринск районының «Ленинская искра» колхозы председателе Аркадий Павлович Айдек орлыкларны, люцерна орлыгын да, үзләрендә җитештерә. Хуҗалык ел саен дәүләткә җитмешәр тонна орлык сата һәм шактый зур файда ала. Бу колхоз өчләтә ота: акча туплый, малларын тук асрый, басуларның уңыш бирүчәнлеген тәэмин итә. «Гвардеец» колхозында исә терлекчелек зыян гына китерә. «Ленинская искра»да фермалар табышлы, һәр сыер елына уртача дүртәр мең килограмм сөт бирә. Ядринск районы 1983 елда чәчүлек гектарыннан егерме ике центнер уңыш алган, ә «Ленинская искра»да уңыш районныкына караганда ун центнерга артык. Бер үк җир, бер үк һава шартлары, хуҗалык итү ысуллары гына төрле.

Кешеләргә гасырлар буена файда китерүче люцерна орлыгына кайчаннан бирле һәм ни өчен кытлык соң?

Люцерна орлыгының ни өчен аз җитештерелүен аңлатып бирергә мөмкин. Табигать, люцерна бүләк итеп, кешегә олы игелек кылу белән бергә, бу байлыктан файдалану өчен аның ачкычын — күзгә күренмәгән зәңгәр таҗ яф-

ракчыклары арасына яшеренгән орлыгын табу бурычын да йөкләгән. Легенда һәм риваять-әкиятләрдәге пәһлеван егетләр шундый тылсымлы ачкычларны эзләп җиде җир читенә, җиде диңгез артына чыгып киткәннәр һәм аны саклаучы явыз сихерчеләрне, һәртөрле аждаһаларны, иң куәтле дию пәриләрен җиңгәннәр. Тормышта әкияттәге киртәләр юк, әмма люцерна орлыгын өлгертүнең серенә төшенү җиңел түгел.

Иң зур кыенлыкларның берсе — люцернаның үзәнчәлекле якларында. Ул орлыклансын өчен аның чәчәген бөҗәкләр серкәләндерергә тиеш. Шулай булмаганда иң әйбәт җәйдә дә люцерна чәчәгенең җимшәнсез калуы мөмкин. Әгәр дә һәр чәчәк үзеннән орлык калдыра икән, ул чагында люцернаның һәр гектары егерме-утыз центнер чәчүлек материалы бирә ала. Чәчү нормасын гектарына биш-ун килограммнан исәпләнгәндә, бер участоктан җыеп алынган әйбәт уңыш очы-кырые күренмәгән зур мәйданны яшел басуга әйләндерергә җитә.

Тырыш, уңган хуҗалар арасында аерым участокларда һәр гектардан дүртәр-бишәр центнер уңыш алучылар да юк түгел. Гомумән, бөтен ил буенча люцерна орлыгының уртача уңышы гектарына бер центнердан чак кына артыграк.

Люцерна орлыгы уңышының түбән булуының икенче бер сәбәбе — хезмәтне дөрес оештырмау. Илебездә орлыкчылык белән генә шөгыльләнүче махсус хуҗалыкларның шактый киң челтәре булса да, һәр колхоз-совхоз үзе турында үзе кайгыртырга мәҗбүр.

Бөтенсоюз азык институты галимнәре орлык уңдырышлылыгының формуласын да беләләр: Россиянең урта өлешендә, бигрәк тә кара туфраксыз зонаның төньягында, һәм Ерак Көнчыгышта люцерна ун елга бер генә ярыйсы уңыш бирә. Ә мондый бик үк күңелле булмаган нәтиҗәнең сәбәбе исә объектив шартларда гына түгел, ә кайбер кешеләрнең ваемсызлыкларында, искелеккә ябышып ятуларында. Куелган көчнең, чыгымнарның нәтиҗәлелеген әнә шулар кимәтә.

* * *

Авыл хуҗалыгы — искиткеч зур тәвәккәллек сорый торган тармак. Табигый кыенлыкларга кешенең үзенә бәйле авырлыклар да килеп өстәлсә, гади генә мәсьәләләр дә атлап чыга алмаслык киртәгә әверелә.

Табышны аз бирә торган орлыкчылык хуҗалыкларына нигә әле шулкадәр көч түгәргә, дип уйлаучылар юкмыни?! Массакүләм фәнни-техник революция заманында люцерна игү өчен бер генә махсус машина да иҗат ителмәүне дә бары тик шуның белән генә аңлатырга кирәк. Аяныч күренеш. Механизаторлар люцерна чәчкәндә бөтенләй башка машиналар кулланалар. Үстерелгән уңышны җыеп алу тагын да катлаулырак. Үләнне суктырганда «Сибиряк», «Нива», «Колос» комбайннарының искереп, ертылып беткән иләкләреннән файдаланалар. Ул иләкләрдән хәтта эре бөртекләрнең дә яртысы коелып бетә. Әнә күзенә сыешлы люцерна орлыгы турында әйтеп тә торасы юк.

Безнең илнең авыл хуҗалыгы фәнни тәэмин ителүе ягыннан дөньяда беренче урынны алып тора, дисәк, сүзебез ялган булмас. В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы Академиясе системасында гына да йөз егерме җиде махсус фәнни-тикшеренү институты бар. Аларда унсигез меңләп галим эшли. Авылларга барлыгы дүрт йөздән артык фәнни-тикшеренү институты, йөз дә унҗиде югары уку йорты хезмәт күрсәтә.

Тугызынчы бишьеллыкта селекционерлар төрле культураларның — бер мең сигез йөз илле сигез, унынчы бишьеллыкта ике мең туксан җиде сортын уйлап тапканнар. Әмма бу зур саннар арасында күпьеллык үләннәр, аеруча кузаклылар өстендә эшләүче белгечләрнең күрсәткечләре бик тыйнак. Ил буенча, мәсәлән, люцернаның нибары сиксән алты сорты, соңгы ун елда шуларның унсигезе районлаштырылган. Балтик буеннан алып Тын океангача сузылган чиксез зур территория өчен бу, әлбәттә, бик аз.

Бездә уйлап табылган һәм күп кенә илләрнең, континентларның басуларында дәрәҗәле урын яулап алган бодай сортлары үзләренең чыгышлары, дан тотулары белән Лукьяненко, Ремесло, Неттевич кебек сәләтле селекционерларның талантына гына түгел, идарә итүнең, оешканлыкның тиешле югарылыкта торуына да бурычлы. Ә менә терлек азыгы культуралары селекциясе башкача оештырылган. Дөрес, яңа сортлар тудыру белән шөгыльләнүче

учрежденеиләрнең саны аз түгел. В. Р. Вильямс исемендәге Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы азык фәнни-тикшеренү институты инде алтмыш елдан бирле яшәп килә. Аның утыз алты бүлеге һәм лабораториясе бар, биредә сигез йөздән артык фәнни-техник хезмәткәр эшли. Аларның һәр дүртесенең берсе — доктор яки кандидат. Институт, фәнни тәҗрибә базасыннан тыш, Мәскәү, Киров, Тамбов, Брянск өлкәләрендә сигез тәҗрибә станциясе һәм тәҗрибә хуҗалыгы тота. Аларга утыз мең гектар җир мәйданы беркетелгән. Институтның фәнни уңышы азык культураларының йөзгә якын сортын тудырудан, җитмеш биш уйлап табу һәм оригиналь ачыш ясаудан, соңгы ун елда йөзләгән китап һәм брошюра, меңләгән мәкаләләр бастырудан гыйбарәт. Ләкин азык җитештерү өлкәсендә кичектергесез проблемаларны хәл итәргә бурычлы бу институтта да люцерна селекциясенә җитди игътибар бирелми.

Институтның селекция үзәге белән авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, профессор Анна Сергеевна Новоселова җитәкчелек итә. Зур коллективның иң тәҗрибәле хезмәткәрләреннән саналган бу галим үзенең фәнгә булган мәхәббәтенә беркайчан да хыянәт итмәгән, үлән игүчеләр ләгънәтләнгән аграр буталышлар һәм көтелмәгән үзгәрешләр чорын сабыр гына үткәргән. Аның тормышы — саф, намуслы тормыш. Галимнәр башкарган эшнең нәтиҗәләре, аларның бүгенге мәшәкатьләре, алда торган проблемалары турында сөйләгәндә ул миңа мондый фикер әйтте:

— Яңа сортлар булдыру, аларны кулланышка кертү ялгыз энтузиастлардан гына тормый. Тикшеренүләр, үсемлекләрнең яңа төрләрен ачу, аларны һәлакәттән саклау ысулларын табу — барысы да эре комплекслы лабораторияләр тарафыннан башкарылырга тиеш. Бөртекләләр белән нәкъ шулай эшлиләр. Терлек азыгына килгәндә исә хәл башка. Безнең институтта, мәсәлән, клевер орлыгы белән шөгыльләнергә бер, ә люцернаныкы белән ике хезмәткәр белгечлеккә өйрәнә. Башка селекция үзәкләрендә дә шул ук хәл. Яңа уйлап табылган сортларның да күбесе басуларга юл яра алмыйча, уч төбедәй кишәрлекләрдә искерә. Әйдәгез, иренмик, миллионнарча гектар мәйданны биләгән люцерна басулары буйлап узыйк, аларга нинди сортлы орлыклар чәчелгәнлеген күрик. 1983 елда чәчелгән сортлар арасында беренче урында Зайкевич люцернасы тора. Бу орлык 1932 елда ук иҗат ителгән. «Семиречинский», «хивинский» сортларының игелә башлавына иллешәр елдан артык вакыт үткән. Ә алар әле дә булса кулланылышта. Бу сортлар чирек миллион гектар мәйданда чәчелә.

Яңа сортлар уйлап табу өлкәсендә сугышка кадәрге елларда зур эш башкарылган. Колхозлар һәм совхозларга бер-бер артлы «манычская», «славянская», «узгенская», «токмакская», «ташкентская», «ленинская», «казанская-36», «марусинская-425» сортлары тәкъдим ителгән һәм шулар әле һаман алыштырылмаган. Унынчы һәм унберенче бишьеллыклар дәвамында уйлап табылып, бик җитди конкурслардан соң, дәүләт паспортларына соңгы эталон итеп «яхшы» билгесе куелган күпме яңа сортлар чират көтә! Аларга нибары утыз мең гектар мәйдан бирелгән.

Халыкның, ни чәчсәң, шуны урырсың, дигән сүзләрен тормыш инде миллион тапкырлар раслагандыр. Тик игенчене бәхетле итәр өчен яңа сортлы орлык аерым бер кишәрлеккә генә түгел, миллионнарча гектар мәйданга җитәрлек булырга тиеш. Абруйлы фәннең бүлекләре әнә шул аз күләмдәге чәчү материалын ишәйтергә, кулланышка кергән яңа сорт орлыкны җитештерәчәк махсус хуҗалыкларны аның белән тиешенчә тәэмин итәргә бурычлы. Кызганычка каршы, алар әле зәгыйфь һәм көчсез, аларга таянырлык та, ышанырлык та түгел. Әйтик, яңа сортны табалар, дәүләт комиссиясенә тапшыралар, ә аны ишәйтү чарасын күрмиләр — төп бурычларны үтәмиләр. Биш мең тонна чамасы люцерна орлыгы урынына аның чиреге генә җитештерелә. Елның-елында шул ук хәл кабатлана. Нәтиҗәдә фәнни бүлекләр орлыкчылык белән шөгыльләнүче махсус хуҗалыкларны уңайсыз хәлгә куялар, соңгылары исә үз чиратларында колхозларны һәм совхозларны җитәр-җитмәс өлеш белән калдыралар. Кыяклы үләннәргә орлык табу мәсьәләсе кыен түгел, кузаклыларга килгәндә исә ник шунда каравыл кычкырмыйсың! 1982 елда Россия Федерациясендә план буенча утыз бер мең өч йөз тонна үлән орлыгын сатып алу каралган булса, ул егерме сигез мең бер йөз егерме җиде тонна гына җитештерелгән. Шуның дүрт йөз сиксән дүрт тоннасын клевер, ике мең тугыз йөз кырык өч тоннасын — эспарцет, ике мең ике йөз сигез тоннасын люцерна орлыгы тәшкил иткән. Боларның барысы бергә орлык запасының унбиш процентын алып тора. Ә кузаклылар чәчүлек мәйданнарының илле процентын били...

Бәс шулай икән, игенчеләргә күпме файда вәгъдә иткән кузаклы культуралар орлыгының җитмәвенә нигә гаҗәпләнергә?!

Азык институты исәпләп чыгарган саннардан күренгәнчә, «искерген» басуларда ил күләмендә ел саен ун миллион тонна азык бирәмлеге алып җиткерелми. Бу — кояшлы Кубаньның еллык уңышы дигән сүз.

* * *

Люцернаны барлык басуларга, табигый болыннарга, көтүлекләргә чәчү өчен ел саен җитмеш мең тонна орлык кирәк. Елына ил күләмендә җитештерелә торган ике йөз миллион тоннадан күбрәк ашлык, колхозлар һәм совхозлар үстергән тау-тау азык, яшелчә һәм җиләк-җимеш белән чагыштырганда, бу — күккә үрләгән биек кыяның бер кечкенә ташы гына югыйсә. Ә менә шуны атлап чыгып та, әйләнеп узып та булмый. Унынчы бишьеллыкта люцерна орлыгы илле мең тоннадан аз гына артыграк әзерләнде. Алда эшләнәсе эшләрнең очы-кырые күренми.

Тик шулай да өметсезлеккә бирелергә ашыкмыйк. Юанычлы хәбәрләр дә бөтенләй үк юк түгел. Сиксәненче еллардан соң товарлыклы орлыкчылык һәр яктан отышлы була башлады. Тәрбиягә таләпчән люцерна Россиянең көньяк регионнарындагы сугарулы җирләргә күчте. Кояшка һәм гомумән җылыга мохтаҗ кара туфраксыз зонаның төньяк районнары, Себер һәм Ерак Көнчыгыш регионнары орлыкны читтән алачак. Мондый программа тормышка ничек ашырылачак һәм ул нәрсә бирәчәк?

Россиянең җылы көньягында люцерна буенча товарлыклы орлыкчылык зонасы оештырылды. Орлыклык үлән чәчеләчәк мәйданнарның күләме дүрт тапкырга арттырылды. Орлык өчен элек кырык өч мең гектар җир калдырылган булса, 1983 елда шул ук максат өчен махсус чәчелгән мәйданның күләме йөз алтмыш мең гектарга җитте. Ростов өлкәсендә, мәсәлән, орлыклык җир мәйданын егерме мең, Кубаньда — егерме алты мең, Ставрополь краенда ундүрт мең гектарга, Саратов өлкәсендә дүрт тапкырга, элеккеге елларда үзенең эчке ихтыяҗларын тәэмин итү өчен нибары бер мең ике йөз гектар орлыклык җир калдырган Чечен-Ингушиядә егерме тапкырга киңәйттеләр. Товарлыклы люцерна орлыгы җитештерү белән шөгыльләнүне башкалар өчен гади эш дип санарга мөмкин. Ә менә таулар арасына урнашкан кечкенә Чечен-Ингуш республикасында бу тармак әле яңа үзләштерелә. Республикада люцерна игү өчен аерым регионнар билгеләнде, һәр басуның төгәл агротехникасы эшләнде, махсус звенолар, бригадалар оештырылды, кешеләрне укытуөйрәтү чаралары күрелде, ындыр табакларында үлән суктыру пунктлары, орлык чистарту станцияләре төзелде, умарталарны кышлату урыннары әзерләнде. Болар алты миллион сумга төште.

— Авырга туры килде,— диде партиянең Чечен-Ингуш өлкә комитетының икенче секретаре Доку Гапурович Завгаев.— Хәзер агрономнар да чапкычларга элекке кебек ашыгып тотынмыйлар, киресенчә, чәчәкләрнең орлыкка төймәләнүен көтәләр. Шулай да төрле кыенлыклар туып кына тора.

— Гадәти күренеш. Яңа эштә һәрвакыт шулай була,— дип, без дә әңгәмәгә кушылабыз.

— Күз алдыгызга китерегез: кешеләр монда гомер-гомергә бодай иккәннәр, бу эшнең сере буыннан-буынга — ата-бабаларыннан уллрына, улларыннан оныкларына тапшырыла-күчә килгән, шул рәвешле алар зур уңыш үстерергә өйрәнгәннәр. Бу — аларның байлык чыганагы гына түгел, ә бәлки профессиональ горурлыгы, дан-шөһрәте, дәрәҗәсе- абруе! Инде һич көтмәгәндә аларга бөтенләй таныш булмаган яңа эш тәкъдим итәләр. Аннан нәрсә килеп чыгар бит әле? Люцерна орлыгының язмышы — кешеләр язмышы ул. Хәзер орлыклык люцерна игелә торган мәйдан егерме ике мең гектардан артып китә. Әмма гектарлар санын арттыру гына мәсьәләне хәл итми. Иң мөһиме — уңышны күтәрү, орлык сортларын ишәйтү һәм сыйфатын яхшырта бару. Республика өчен традицион булган яшелчә, ашлык, җиләк-җимеш, кукуруз җитештерүнең күләмен киметмәгән хәлдә, дәүләт фондына ел саен дүрт мең тонна люцерна орлыгы тапшырырга кирәк. Узган ел бер мең ике йөз тонна саттык. Быел ике тапкыр күбрәк сатарга исәп тотабыз...

Әйе, бурыч җиңелдән түгел! Чечен-Ингушия Россиянең көньягындагы тагын биш регион белән бергә илебезнең кара туфраксыз өлкәләрен, Урал төбәген, Себер һәм Ерак Көнчыгышны люцерна орлыгы белән тәэмин итәргә,

кукуруз орлыгын ничек җибәреп торса, моны да шундый ук төгәллек белән эшләргә тиеш.

Чәчүлек мәйданын арттыру — ул әле программаның беренче өлеше генә. Төп бурыч гектарның уңышын күтәрүдән, сугару системалары белән тәэмин ителгән басуларда гектарыннан икеләтә, өчләтә һәм аннан да артыграк уңыш җыеп алудан гыйбарәт. Бары тик шуңа ирешкәндә генә, һәр гектарында уртача утызар-кырыгар центнер бодай, алтмышар-җитмешәр центнер кукуруз бөртеге, дүртәр-бишәр йөз центнер азык чөгендере үстерелә торган басуларның бер өлеше люцерна орлыгына алынуы үз-үзен аклаячак. Халкыбызның көннән-көн үсә барган ихтыяҗларын тагын да тулырак канәгатьләндерүне күздә тотып, дәүләтебез кайберәүләр өчен бик кечкенә нәрсә булып күренгән люцерна орлыгы хакына әнә шундый байлыклардан баш тартып тора.

Кызганычка каршы, соңгы елларда көньяк регионнарның берсе дә үзенең йөкләмәсен үтәмәде. 1983 елда, мәсәлән, Кубань үзеннән читкә ике мең тонна орлык чыгарырга тиеш иде, дәүләткә җиде йөз сиксән тонна гына сатты. Ростов өлкәсе дә дәүләт заказының яртысын да үти алмады. Ставрополь крае җиде йөз тонна урынына — ике йөз, волгоградлылар биш йөз тонна урынына ике йөз илле тонна гына орлык тапшырдылар. Саратовлылар төньяк районнар хуҗалыкларын орлык белән тәэмин итүгә бөтенләй катнаша алмадылар. Кечкенә Чечен-Ингушия исә һич көтмәгәндә, дәүләткә бер мең ике йөз тонна люцерна орлыгы тапшырып, Россия Федерациясе буенча беренче урынга чыкты. Бөртекләләр игеп дан казанган осталар люцерна орлыгы җитештерүдә үзләрен күрсәтә алмадылар, өйрәнчекләр хәлендә калдылар. Хикмәт шунда ки, люцерна орлыгы җитештерү — ничек туры килде шулай башкарыла торган эш түгел. Бөек Бэконның: «Табигать белән аның законнарына буйсынып кына идарә итәргә мөмкин»,— дигән кисәтүен онытырга һич ярамый.

Без Чечен-Ингушиядә кешеләрнең яңа эшкә нинди омтылыш белән алынганлыкларын күрдек. Республикада орлыклык люцерна, кайбер урыннардагы шикелле, вак-вак кишәрлекләрдә түгел, зур уңыш бирә алырлык киң мәйданнарда игелә. Коминтерн исемендәге колхозда һәм «Озерный» совхозында люцерна орлыгы җитештерү өчен — меңәр гектар, «Червленский» колхозында өч йөз гектар җир бүленгән һәм бу хуҗалыкларда яңа эш гаять табышлы булып чыккан. Люцерна орлыгы кыска гына вакыт эчендә «Путь коммунизма» колхозы кассасына бер миллион сум, «Червленский» совхозынынкына ике йөз илле мең сум табыш керткән.

Коминтерн исемендәге колхозга без орлык хәзерләү эшләренең иң кызган вакытында килеп төштек һәм җиренә җиткереп көйләнгән урып-җыю конвейерының ничек эшләвен кызыксынып күзәттек. Җыйгыч-комбайннар кырда рәт-рәт булып чабылган үлән тезмнәрен җирдән иплән кенә күтәрәләр. Герметик арбаларга төялгән өемнәрне махсус сугу урынына ташыйлар. Анда ике «Нива» комбайны үләнне ике кат суктыра. Орлык шунда ук чистартылуга һәм калибрлауга, ә вакланган сабаклар сенажга, витаминлы үлән оны хәзерләүгә китә. Эштә тоткарлык сизелми, уңыш әйбәт чыга, димәк, табыш та аз булмаячак. Тик партиянең Шелково район комитеты беренче секретаре, Социалистик Хезмәт Герое Вера Табацкова һәм колхоз председателе Николай Юшков шатланырга ашыкмыйлар иде.

— Эш акчада гынамыни?— дип кашын җыерды председатель.— Без ике мең өч йөз баш мөгезле эре терлек, кырык ике мең сарык асрыйбыз. Аларга нәрсә ашатырга? Бүгенге орлыклык люцерна чәчелә торган мең гектар җирнең һәр гектарыннан без элек утыз биш-кырык центнер бодай ала идек. Чама белән бу шул ук күләмдәге азык берәмлеге массасы дигән сүз. Люцерна орлыгын дәүләт бергә — ун исәбеннән терлек азыгына, ягъни фуражга алмаштыра. Димәк, люцерна орлыгы мәйданының һәр гектары ун центнер концентрат бирәчәк, ә калган аерманы нәрсә белән тутырырга?— Ул райком секретарена карады.— Вера Георгиевна, район резервларына таянып, бәлки, Сез ярдәм итәрсез?

Вера Георгиевна Табацкова үзе дә Коминтерн исемендәге колхоздан. Монда ул башта агроном, соңыннан председатель булып эшләгән, колхоз тормышын яхшы белә. Ләкин ул председательнең хәленә керүдән, киңәш бирүдән башка нәрсә эшли ала соң?

— Андый резервлар юк, Николай Александрович, юк,— дип җавап кайтарды Табацкова туп-туры.— Орлыкны дүртәр, бишәр центнер сугарга тыры-

шыгыз. Шул чагында югалтуларны каплый алачаксыз, хәтта әле файда да калыр.

Тик гектарыннан дүртәр-бишәр центнер үлән орлыгы алу — бик зур проблема. Яңа продукцияне үзләштерү өчен технологик яктан хәтта иң әйбәт җиһазландырылган заводларга да ташлама ясала, вакытлыча җиңелрәк нормативлар билгеләнә. Люцерна өчен җиңеллек — хуҗалыкка катнаш азыкны ун тапкырга артыграк күләмдә сатып бирү. Бу — стандарт норма. Бөртеклеләрнең гектарыннан унбиш-егерме центнер гына уңыш алучы төньяк игенчеләре моңа бик риза, ә чәчүлек җирләре юмарт хуҗалыклар үзләренә бирелә торган фуражның аз булуына канәгать түгелләр. Кешеләрдән люцерна орлыгын тизрәк үзләштерүне, аннан мөмкин кадәр күбрәк уңыш алуны күтәргә һәм таләп итәргә мөмкин. Ләкин осталыкка команда биреп кенә, яки ашыктырып, төрле шелтә чаралары кулланып кына өйрәтеп булмый. Осталык һәм тәҗрибә акрынлап туплана.

Люцерна орлыгы җитештерүче энтузиастлар алдына куелган катлаулы мәсьәләләр байтак. Мәсәлән, чәчкечләргә мохтаҗлык. Рәт аралары ничаклы сирәгрәк булса, үсемлек җылыны шулкадәр күбрәк ала, нектар мулрак бүленеп чыга, чәчәкләргә бөҗәкләр килә һәм үсемлектә җимшән күп хасил була. Орлык бер гектар җиргә хәзерге кебек ун килограмм түгел, ә ун тапкыр кимрәк чәчелсә, ничаклы кадерле һәм кыйммәтле чимал янга калыр иде! Нәкъ әнә шундый чәчү машинасын уйлап чыгарырга конструкторларның кайсысы алыныр? Бөртеклеләрне суктыру да мең төрле мәшәкатьләргә бәйле. Болай да фәкыйрь уңыш күп кенә очракларда бункерларга түгел, җиргә ага. Ниһаять, азык институтында безнең алда шатлыклы телеграмма алдылар. Белгечләрне махсус агрегат карар өчен, Фрунзега чакыралар иде. Институтның өлкән фәнни хезмәткәре Владимир Кузьмич шул ук көнне Урта Азиягә очты. Тәҗрибә уздыру өчен үрнәк әзер, тик сынап караулар нәрсә күрсәтер?.. Азык үләннәренең әнә күзедәй орлыгын суктыру өчен махсус машиналар күрергә насыйп булырмы-юкмы?

Тагын бер бик мөһим мәсьәлә. Удмуртия, Мордовия, Татарстан, Чувашстан республикаларында, Владимир, Орел, Тула, Мәскәү, Липецк, Пенза өлкәләрендә, Уралда, Себердә, Ерак Көнчыгышта люцернаның «марусинская-425», «северная гибридная» сортларын чәчү отышлы. Әмма аларга «кизлярская», «славянская» кебек җылы ярата торган сортлар җибәрелә. Кубань, Дон, Төньяк Кавказ өчен алар, бәлки, әйбәттер дә. Кара туфраксыз районнарда бу сортлар белән нишләргә? Аяныч: соңгы биш ел дәвамында, матур теләкләр һәм тәкъдимнәрдән тыш, эшне җайга салуда артык бернинди алга китеш тә сизелми.

* * *

Бүгенге көндә люцернаның бөтен серләре диярлек ачылган. Бу культурадан уңыш алу аның чәчәкләрен серкәләндерүгә бәйле икәнлеген, бөҗәкләр ярдәменнән башка аның орлык бирмәгәнлеген һәр кеше белә. Димәк, иң беренче чиратта серкәләгечләр турында чын-чынлап кайгыртырга кирәк. Кызганычка каршы, алар белән табигатьнең төп таләпләрен санга сукмыйча эш итәләр.

Колхозларда һәм совхозларда авыл хуҗалыгын интенсивлаштыру елларында әйләнешкә йөз миллион гектардан артыграк яңа чәчүлек җирләр кертелде. Ләкин үткен төрәнле тимер сабан, игелекле эш башкару белән бергә, үсемлекләрнең уңышын күтәрүгә файда китерүче табигый серкәләгечләрнең ояларын да туздыра. Шуның аркасында никадәр басу-кырларның кысыр калуы турында берәү дә уйламый. Үлән игеләчәк мәйданнарны эшкәртү, аларга ашлама кертү, берөзлексез сугарып тору өчен никадәр көч куела, ә җитештерелгән орлыкның күләме элекке еллардагыча ук кала. Сабан төрәннәре, һәртөрле пестицид-гербицидлар күпме бөҗәкләрне һәлак итә. Болыннарда чикерткәләр сикерешеп уйнамагач, урман буйларындагы басуларда бал кортлары гөжләп очмагач, мул уңыш кайдан килсен?!

Сугышка кадәр илебездә ун миллион баш умарта булган. Бакчалар, җиләклек һәм күпьеллык үлән басулары, яшелчә-җимеш плантацияләре елдан-ел ишәя барганда, аларның тагын да күбрәк кирәклеге үзеннән-үзе аңлашыла кебек. Ләкин, ни хикмәт, бал кортларын үрчетүгә игътибар кими генә бара. Күп кенә урыннарда умартачыларга да специальләшү чире йокты. Яңгырдан соң борынлап чыккан гөмбәләр шикелле меңәр баш һәм аннан да артыграк

умартадан торган хуҗалыклар барлыкка килде. Кайбер җитәкчеләр, б е р м ә ш ә к а т ь  к и м ү е н ә  к у а н ы п, умарталыкларсыз хуҗалык итә башладылар. Бүгенге көндә Татарстанда йөз илле, ә Башкортстанда аннан да күбрәк колхоз һәм совхоз умарта тотмый. Россия Федерациясендә умартачылык белән уртача ике хуҗалыкның берсе шөгыльләнә. Бөтен ил буенча умарталар саны ике миллион башка кимеде. Авыл хуҗалыгы министрлыгында люцерна игү программасын төзегәндә орлык җитештерү тармагында эшләүче танылган белгечләр Канадага һәм Америка Кушма Штатларына махсус барып кайттылар. Бу илләрдә алар серкәләгеч-яфраккискечләрнең ничек эшләүләре белән якыннан таныштылар. Саранланып тормыйча, аларны сатып алдылар һәм үзләре белән алып кайтып, махсус билгеләнгән хуҗалыкларга урнаштырдылар. Ерактан күчеп килгән канатлы кунаклар өчен лабораторияләр — саклау урыннары төзелде, аларның бездәге һава шартларында, бигрәк тә салкыннарда исән калуын тәэмин итү чаралары күрелде. Җәй җитеп, кышкы йокыларыннан уянгач, билгеле бер вакытта бу яңа төр серкәләгеч бөҗәкләрне орлыклык басуларга очырдылар. Сүз дә юк, серкәләндерү индустриясен оештыру бик кыйммәткә, экономистлар исәпләвенчә, йөз илле миллион сумга төшәчәк. Тик... алга таба эшләр ничек китәр — хәзергә кунак бөҗәкләрдән файда күренми әле. Чечен-Ингушиядә алар, гомумән, бөтенләй үлеп беткән.

Бу урында без укучының: «Ә үзебезнең бал кортларын гына арттырсак, ни була соң? Аларга бит гап-гади бер оядан башка берни дә кирәкми»,— дип, каршы төшүен сизеп торабыз.— Серкәләндерү өчен ник алардан файдаланмаска?»

Берни дә әйтеп булмый, урынлы сорау, урынлы таләп. Серкәләгечләрнең үзебезнекеләренә дә, читтән кайтартылганнарына да эш җитәрлек. Ләкин менә Коминтерн исемендәге колхозның мең гектар мәйдандагы орлыклык җирендә бер генә баш умарта да юк. Көньякта була торып та, төньяк өлкәләрдәге шикелле үк, орлык уңышын стандарт центнерлардан арттыра алмый. «Червленский» колхозы председателе Александр Макарович Беляков та барлык умарталарын бал буенча специальләшкән совхозга тапшырган. Чәчәкләр серкәләнмәгәч, буш үләнне суктырып азапланудан ни мәгънә?! Кысыр сыердан бозау көткән кебек бу.

Бакчаларның, чәчеп үстерелә торган үсемлекләрнең, ягъни карабодайның, көнбагышның, эспарцет, клевер һәм люцернаның уңышы — эшчән бал кортларының канатларында, умартачылыкның ничек оештырылган булуында. Бал кортында җитезлек бар, тик аның канатларының көче өч кенә километрга очарлык. Әгәр умарталыклар басудан ерак булсалар, уңыш өчен моның бернинди файдасы да юк. Шуңа күрә бал кортларыннан эш көткәнче, агрономнар аларга тиешле бурычны бөтен шартын туры китереп бирергә өйрәнсеннәр иде!

— Без серкәләндерү белән шөгыльләнмибез,— дип мәсьәләгә шунда ук ачыклык кертте РСФСР Авыл хуҗалыгы министрлыгының умартачылык баш идарәсе начальнигы Евгений Михайлович Ульяничев, үлән орлыгы уңышын күтәрүгә умарталыкларның нинди хезмәт күрсәтүләре турында сүз чыккач.— Безне бал, балавыз, прополис кызыксындыра. Кырларның, бакчаларның һәм болыннарның уңдырышлылыгы турында кайгырту — РАПОлар бурычы.

Гаҗәп тә, сәер дә, буталчык та. Бер үк министрлык системасындагы специальләштерелгән өч идарәнең һәркайсы бары тик үзенең шәхси бурычы, шәхси эшен генә алга сөрә.

Умартачылык баш идарәсе, аның урындагы конторалары алда телгә алынган бурычны агрономнарга йөкләгәннәр. Алары исә умартачылар иңенә салынганнар. 1983 елда Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе социалистик ярыш алдынгылары арасында Куйбышев өлкәсе умартачыларының да исемен атады. Әле шушы өлкәдә дә агрономнар кирәкле басуларны серкәләндерү өчен бал кортларының өч мәртәбә кимрәк булуыннан зарланалар. Ул чагында умартачылыгы артта калган өлкәләрнең хәле нинди була инде?! Умарта кортларын автомобильләргә, трактор арбаларына, тиз очышлы самолет канатларына утыртып йөртә-йөртә бал җыючы хуҗалыклар да бар. Алар да бары тик нектар турында гына кайгырталар. Грозный шәһәре янындагы «Чечен-Ингушия» умартачылык совхозы директоры Габдерахман Гандалоев безне, тәме дә, төсе дә, исе дә үзгә булган бал белән сыйлады.

— Люцерна балы,— дидек без һәм, әлбәттә, ялгыштык.

— Юк, сөтле үлән балы бу,— дип аңлатты директор.— Умарталарны күршедәге Дагстан республикасына махсус илттек.

Чечен-Ингушия басуларында җәй буе люцерна күкселләнеп утыра. Серкәләгечләрне күтеп ала алмагач, аның кысыр чәчәктәге таҗ яфраклары җимшәнләнмичә коелырга мәҗбүр. Сүз уңаенда шуны да әйтеп китик. Чәчүлек үлән орлыгын күршесендәге Чечен-Ингушиядән алучы Төньяк Осетиянең йөз егерме умарталыгы, бал уңышыннан мәхрүм калмас өчен, люцерна кырына түгел, таулар арасындагы кыргый болыннарга күченә.

* * *

Люцерна орлыгы җитештерелә торган басулар буйлап сәяхәт кылу шактый озакка сузылды. Ләкин аларның берсендә дә кечкенә матур өйчекләр, фән өйрәткәнчә, аркылыга-буйга рәт-рәт тезелгән умарталыклар күрергә насыйп булмады. Люцерна чәчелгән участокларда нәкъ әнә шулай эшләнергә тиешлеген белеп тә орлыкчы-агрономнарның бу юнәлештә кыл да кыймылдатмаулары бик гаҗәп, әлбәттә. Акланыр өчен алар безгә җыен тузга язмаган дәлилләр китерәләр. Бал корты, имеш, люцерна белән дус түгел. Ул аның төсеннән курка имеш, шуңа күрә бал кортына исәп тоту файдасыз, бал да, орлык та булмаячак. Һай, бу үзеңнең ялкаулыгыңны аклау өчен, мең төрле сәбәп эзләп азаплану гадәте кайчан бетәр икән?!

Махсус мәсьәләләрдә каләм әһеле китергән кайбер дәлилләрне бик үк кабул итеп бетермәүләре ихтимал. Шуңа күрә биредә без мисал итеп белгеч фикеренә таянйык. Үзбәкстанның Хорезм умартачылык совхозы баш зоотехнигы О. Юнусов «Пчеловодство» журналының 1984 елгы алтынчы санында басылып чыккан мәкаләсендә үз күзәтүләре, шуларга нигезләнгән исәпләүләр белән таныштыра. «Элек,— дип яза ул,— «Коммунизм» совхозында бал кортларын люцерна басуына җибәрмиләр иде. Бал уңышы бик аз булды. 1982 елда совхоз люцернаны бал кортлары ярдәмендә серкәләндерү оештырды. Хорезм умартачылык совхозы, килешү нигезендә, аның 600 гектар люцерна җиренә 1965 баш умарта күчерде. Галимнәр фикеренчә, бер гектар җиргә өч баш умарта туры килергә тиеш. Нәтиҗәдә «Коммунизм» совхозы люцернаның һәр гектарыннан 2 центнер 18 килограмм, ягъни 1981 елдагыга караганда 92 килограммга артыграк орлык алды.

Люцерна орлыгының бер центнеры 600 сум тора. Өстәмә уңыштан алынган керем 331 мең 200 сум. Серкәләндерү өчен тотылган чыгымны чигергәннән соң совхоз кассасына 291 мең 900 сум өстәмә акча керде».

Кызганычка каршы, О. Юнусов умарта кортларының күпме бал җыюы турында бер сүз дә әйтмәгән, шунлыктан тагын бер мисалга мөрәҗәгать итмичә булмый.

1983 елның җәендә Чечен-Ингушия автономияле республикасы, Грозный районының Ленин исемендәге колхоз агрономы Федор Гаврилович Хрусталев үзенең умарталарын люцерна басуына урнаштыра. Ә калганнар тауларга, көнбагыш чәчүлекләренә китүне артыграк күрәләр. Федор Гаврилович, бал корты люцерна чәчәгеннән серкә һәм нектар алмый, дип фараз итүне тикшереп карарга уйлый. Аның бал кортлары унҗиде көн люцерна басуында кайнашалар һәм барлык кәрәзләрен нектар белән тутыралар. Балны, суырткач, үлчәп карыйлар. Бер баш умарта биргән бал «Чечен-Ингушия» совхозы таулы болыннарда алган уңыш белән бертигез чыга: егерме өч килограмм.

Бу урында яңа сорау туа. Меңнәрчә баш умартаны тәрбияләргә сәләтле Хрусталев кебек энтузиастлар ни өчен соң болыннарны серкәләндерү эшенә башкаларны да тартмыйлар? Бу уңайдан һәвәскәр умартачыларга министр приказы белән акча түләүнең законлаштырылган булуын да искә төшереп үтәргә кирәк. Безнеңчә, аңлатулар алып барганда, люцерна чәчәгенә ярдәм итүчеләр табылмый калмас иде. Әйе, министр приказы ачык һәм аңлаешлы. Ләкин колхозларда һәм совхозларда шәхси хуҗалык умарталарын басуларга чыгарып торган өчен акча түләү турында сүз чыккач, председательләр: «Ничек инде ул алай?— дип, аңламамышка салыналар.— Балын да безнең үләннәрдән алсыннар, өстәвенә тагын акча да түлә аларга?! Хәзер, имеш, авыл кешесе элекке кеше түгел, умарта кортлары белән азапланыр димә син аны. Техникадан, ферма һәм кырлардан соң ул телевизорга тартыла, гомумән тракторчыга, комбайнчыга, терлекчегә нindидер умарталар белән кайнашуның кирәге шул чаклы гына...»

Чувашстандагы «Ленинская искра» колхозы председателе Аркадий Павлович Айдак, хуҗалык үлән орлыгы җитештерүгә күчкәч, беренче эш итеп һәртөрле гербицид-пестицидлардан баш тарта, колхозга бөҗәкләр тормышын өйрәнүче белгеч кайтарта һәм шәхси хуҗалыклардагы һәр умарта өчен унар сум акча түләүне оештыра. Унике авылны берләштергән бу колхозда өч ел эчендә умарталар саны алты йөз башка арта. Аркадий Петрович үзе дә дүрт баш умарта асрый. Бал белән тәмләп чәй эчү өстенә ул кырык сум күләмендә акчалата бүләк ала.

Умарта тотучыларга карата председательнең мондый юмартлыгы үзен аклыймы соң? Әйе. «Ленинская искра» колхозы, районның уртак күрсәткечләре белән чагыштырганда, бөртеклеләрне гектарыннан ун центнерга, һәр сыердан сөтне мең килограммга артыграк җитештерә, аның кассасында өч миллион сум акча исәпләнә. Иң әһәмиятлесе — кешеләрнең үз җирләренә ябышып ятулары! «Әгәр кеше йорт сала, агач утырта, кое казый һәм умарта кортлары үрчетә икән,— ди председатель,— туган туфрагыннан, ата-бабасы нигезеннән аны берничә көч тә кузгата алмый».

СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгы коллегиясенең 1978 елда кабул иткән карарында: «Бал кортлары ярдәмендә серкәләндерүне әһәмиятле агрочаралардан санарга»,— дигән сүзләр бар. Ләкин бу җитди, бик кирәкле директива канцеляриеләрдән ары узмады. Умарта кортлары үрчетүне, умарталарны басуларга күчереп йөртүне беркем дә планлаштырмый. Үз агымына куелган бу эш «барып чыкса — яхшы, барып чыкмый икән — зыян юк» принцибына корылган.

Авыл хуҗалыгы алдындагы бурычлар күбәя бара. Аның бүгенге интенсив, киеренке темплары табигать серләренә карата нәзакатле булуны таләп итә.

Бер очракта, без орлыкның яңа сортларын санга сукмыйбыз, икенчесендә ышанычлы техник тәэмин ителешне карап җиткермибез, өченче урында, йогынтылы мораль һәм материаль стимуллар турында онытабыз, якын ярдәмчеләребез булырга тиешле серкәләгечләр белән дуслаша белмибез. Нәтиҗәдә йөзләрчә миллион гектар мәйдандагы кырларны, болын һәм көтүлекләрне орлык белән тәэмин итү авырлаша. Яшел хәзинәнең тылсымлы ачкычы булган люцерна орлыгы безнең кулга үзеннән-үзе генә килеп кермәячәк.

## Рәшит Гәрәй

### Күңелемдә яфрак яралар

Ык ярында басып тормас идем,
Сагынмаган булсам талларны.
Ник берсе дә чыкмый каршыларга,
Кем күчергән моннан аларны?

Шул талларга яшьли бүләк иткән
Хисләремә кемнәр кагылган?
— Бездән түгел, сора ул хакта син
Дулкыннары тынмас агымнан.

Хисләрең дә,— диләр,— дулкыннарда
Тирбәлмиме икән таңнарда...
Дулкыннаргамыни,— мин аларны
Сөйли идем бары талларга.

Ул таллар бит миңа иң-иң якын
Сердәш иде сабый чагымнан.
— Исәннәрме?— диеп сорый идем,
Җилләр иссә туган ягымнан.

Ә бер көнне җилләр әйтте миңа:
— Вакыт инде сиңа аңларга:
Ык сулары түгел, Чулман-дәрья
Үзе кага бүген ярларга.

Көймәләргә утырып, истәлекләр
Эзләп йөрмә инде үткәннән.
Талларыңны кочып, болынлыклар
Су астында калды күптәннән.

Вакыт кыла барыбер үзенекен,
Үтен-ялвар, теләтеләмә.
Бу тормышны алга илтим дисәң,
Кирәк аңа күпне түләргә.

Диңгезгә тиң олы су читендә
Кармак салып утыра балалар.
Ә талларым минем күңелемдә
Һаман әле яфрак яралар.

## Сүзләр эзләп чыгам

Чыклар төшкән яшел аланнарга
Чыгып китәм һәрбер иртәдә.
— Нәрсә югалттың соң анда,— диеп
Авылдашлар тия теңкәгә.

Ник әйтмисең... Без дә эзләшербез
Һәм табарбыз... энә түгелдер.
Зыян итәр димә: тыңла әле
Дусларыңның ихлас сүзен бер...

Сездән яшерен серем бармыни соң,
Дуслар һәрчак дуска сыенып.
Тик шулай да минем бу җавабым
Сезгә бераз гаҗәп тоелыр:

Юк, җыенмыйм, һич юк, аланнардан
Кем өчендер гөлләр өзәргә.
Мин бит чыгам анда яңа җырлар
Язар өчен сүзләр эзләргә.

Бер җырга да җитеп бетмәс кебек
Моңа кадәр ишетеп белгәнем.
Җиргә ятып тыңлыйм: колагыма
Яшь үләннәр сөйли серләрен.

Тояк тавышлары ишетелә,
Сабантуйда атлар узыша.
Җанга якын бер өн килер сыман,
Тузганаклар дәррәү тузгыса.

Гашыйк итәр өчен чишмәләр дә
Өйрәнгәннәр оста хәйләгә:
Челтер-челтер иткән тавышлары
Иң ягымлы сүзгә әйләнә.

Туган җирнең сулышы күңелегезгә
Иң якты җыр булып керсенгә,—
Шушы авазларны бергә кушып
Тыңлатырга телим мин сезгә.

## Яңгырларың белән куандыр

И чыланыйм әле яңгырыңа,
Миңа бүтән кирәк ни тагы...
И буялыйм әле тузаныңа,
Шул ук яңгыр юа бит аны.

Чәчәкләр дә әле кайчан гына
Күмелгәннәр иде тузанга.
Хәзер әнә ничек елмаялар,
Яңгырларың явып узганда.

Яңгыры да аның синеке шул,
Тузаны да аның синеке.
Ихлас сөенәм, ярый әле, димен,
Болар барысы туган җирнеке.

Ярый әле өлеш чыгарасың
Яңгырыңнан миңа, карыңнан.
Чит итмичә, шулай үз итүең
Кыйммәтрәк миңа барыннан.

Йөрәгемдә бер ут сүнми яна,
Син бит аны үзең дөрләткән.
Һичкайчан да сиңа үпкәләмәм,
Булсам да мин бер кат күлмәктән:

— Әй, бигрәк тә юка киенгән,— дип
Башкалардан мине аерма.
Ышыкланып тора алмас димә
Юл буенда үскән каенга.

Һаман шулай кинәт китереп яуган
Яңгырларың белән куандыр.
Синдә яуган нинди яңгырның да
Шифасызы булмый торгандыр.

## Арыш серкә очыра

Назлы җилләр йомшак үләннәрнең
Башларыннан сыйпап торганда,—
Арыш серкә очыра, карагызчы,
Арыш серкә очыра кырларда.

Арыш серкә очыра... Тирә-якның
Хозурлыгын гына күрсәнә:
Юлларыма минем, әйтерсең лә,
Куе ап-ак тетен түшәлә.

Игенче бит шушы мизгелләрне
Ел буена көтә зарыгып.
Кереп китсәм басу эчләренә,
Эзем калыр инде ярылып.

Якташларым тиргәр:— Әйтче, нишләп
Игеннәрнең кадерен белмисең?
Сизмисеңме әллә, үзеңнең бит
Ризыгыңны таптап йөрисең.

Тик бер башак кына өзеп алам —
Кырдан ядкарь булып калсынга.
Арышларым гафу итсен мине,
Гаебем булса алар каршында.

Юк ла, алар миңа рәнҗемәсләр,
Бер-бер гаеп табып узганнан.
Серләребез уртак... Тормыш юлыбыз
Башланган ич бер үк ызаннан.

Арыш серкә очыра... тагын күпме
Ямь өстәлә туган ягыма!
Әллә шуңа микән монда минем
Җырларым да җиңел языла.

## Авылым кызларына

Матурларның матурлары, димим,
Кемгә хаҗәт кысыр матурлык.
Болай да бит сезне күрер өчен
Атна саен йөгереп кайтырлык.

Әткәм нигезенә җиткәнче үк
Сезнең яныгызга тукталам.
Күз тимәсен берүк үзегезгә,
Эшегезне күреп сокланам.

Терлекләргә азык тураганда
Кулыгызга йокмый кулыгыз.
Авылым кызлары, сез, кемгә охшап,
Шундый җитез булып тудыгыз.

Гомерем буе сездәй тырышларга,
Сездәй уңганнарга табындым.
Карашларыгызда үзебезнең
Әбкәйләрнең күрәм чалымын.

Ял белмәгән алар... Таңнан торып
Ашыкканнар урак урырга.
Лаек алар үрдә — кыр түрендә
Һәйкәл булып басып торырга.

Сыер җигеп көлтә кертмәгәнме
Нурфигыл һәм Зифа җиңгиләр...
Хәзер генә никтер кайберәүләр
Күбесенең кадерен белмиләр.

Җылы сүзләр таба алмыйлармы
Шуларның соң күңелен эретерлек...
Безнең бу заманда аларны бит
Уч төбендә генә йөртерлек.

Йөзләренә карыйм текәлеп мин,
Күпме сагыш, күпме моң анда.
Теләкләре уртак һәркайсының,
Өметләре уртак булганга:

— Язмыш мине туган туфрагымнан
Аермасын соңгы сулышымда.
Балаларым,— диләр,— оныкларым
Үз бәхетен тапсын шушында.

Сеңелләрем, якты өметләре —
Оныклары сез бит аларның.
Сездә күрәм сабыр әбкәмнәрнең,
Әнкәмнәрнең гомер дәвамын.

Кешеләрдәге бөтен яхшылыкны
Сез алгансыз алар күңеленнән.
Хисләрегез, җырга әверелеп,
Киләчәккә күчә бүгеннән.

## Исемлектә кайда булсаң да

Бәхет саный идем Минзәләнең
Бер малае булып калуны.
Элеккеге Чаллы төбәгенә
Күчергәннәр безнең авылны.

Янәшәсен болай янәшә дә,
Юллары да таныш күптәннән...
Урталыкта яткан Калмаш аша
Тәпи-тәпи минме үтмәгән?!

Чишмәсеннән минме Гәрдәленең
Су эчмәгән эссе көннәрдә?!
«КамАЗ» сулышын минме тоймаган соң
Орловкага килеп кергәндә?!

Бер уйласаң, элек-электән үк
Бөтенесе якын җаныма.
Тик шулай да никтер күңелем һаман
Минзәләгә ныграк табына.

Малай чактан таныш урамнары
Ничек инде чыксын исеңнән...
Әйтә күрмәгез сез:— Бүгеннән,— дип,—
Ул тарафка юлың киселгән.

Юккамыни, күңел шайтан, диләр,
Аңласаң да нихәл итәсең:
Минзәләнең такыр юлларыннан
Килә һаман җәяү үтәсем.

Шул юлларда туган тәүге җырым,
Шул юлларда булган дәвамы.
Юксынулы йөрәк үзенә соң
Башка җирдә дәва табамы?!

Йөрәкне бит күчереп куеп булмый,
Бер үк төштә аның урыны...
Яңа җирдә яңа кешеләргә
Күнегүе җиңел булырмы...

Туган авылым, мондый чакта тагын
Сиңа дәшми, кемгә дәшәсең.
Карталарда чигең үзгәрсә дә,
Әүвәлгечә матур яшә син!

Исемлектә кайда булсаң да бул,
Җырсыз гына мине тилмертмә.
Минзәләме, Тукай районымы —
Җырым минем бер үк җирлектә.

..................

## Вакыйф Нуруллин

# ИКЕ УРАМ АРАСЫ

ПОВЕСТЬ

### Бүреләр, үгез һәм без...



Тор инде, улым, тор, соңга каласың бит!

Бу — әни тавышы. Мин инде күптән уяу. Торырга кирәк икәнен бик беләм. Иртәрәк уятырсың дип, кичтән үзем әйтеп куйган идем. Таш яуса да мәктәпкә соңарырга ярамый миңа. Чөнки узган атнада бик хәтәр буран булды да ике көн дәресем калды. Ә өченче көнендә беренче дәрескә соңардым. Һаман шул буран аркасында инде: ике көн йокым туйганчы йоклап, йокы чүлмәгенә әйләнеп китә язганмын. Мәктәпкә беренче дәрес бетәргә ун минут кала гына барып кердем. Ярый әле рус теле, Габдулла абый дәресе иде. Әгәр Нәби Зарипович дәресе булган булса — харап иде эшләр. Ниндидер бик зур җинаятьчене тоткандай җилтерәтеп, шундук директор янына алып керер иде. Ә минем өчен директор янына керү — үлемгә бару белән бер. Чөнки узган көз үземне укырга алганда мин аңа сәбәпсез дәрес калдырмаска, тәртипле булырга, яхшы укырга һәм мәктәпкә бер кубометр утын китереп бирергә вәгъдә иткән кеше.

Тәртип бозганым юк анысы. Чамасыз нык буранлы көннәрдән тыш, дәрес калдырганым да булмады. Ә утын мәсьәләсендә эшләр шәптән түгел: кубометр дип әйтмим, хәтта бер пүлән утын да илткәнем юк әле. Бик илтер идем, ләкин утын дигән нәрсә үзебездә дә бик чамалы: салам-солам, куак-чыбык ягып кына көн күрәбез. Урман ерак түгел түгелен: булыр-булмас бер чакрым чамасы гына. Ләкин аның исеме генә урман: бары өч йөз гектар гына. Җитмәсә урманның икенче ягында тагын бер авыл — Ильиновка. Ильиновкалыларның да мичләре бар, аларга да утын кирәк. Аннары килеп, урман аша юл үтә: узгынчылар да аны туктаусыз кымтырыклап тора. Бөтенләй бетмәсен өчен, урманны бик нык саклыйлар. Дәүләт тарафыннан куелган сакчысы — Сафа абый. Кече Әшнәкнеке ул. Безгә атнага бер-ике мәртәбә, акт төзегән булып, агач кискән кешеләрне куркытып, шуларда ашап-эчеп кайту өчен генә килә. Югыйсә елына ике-өч кенә килсә дә булыр иде. Чөнки безнең авылда аның ышанычлы кешесе Каңсыз Әхмәт бар. Әхмәт исән булган чагында

Ахыры. Башы 9 нчы санда.

урман өчен борчыласы юк ана. Бер бәйләм коры ботак күтәреп кайтучыны да күреп-белеп, исәпкә алып бара Әхмәт абый.

Авыл халкын җәберләп кенә калмый, Ильиновка кешеләрен дә дер селкетеп тора. Бигрәк тә хатын-кызларын. Әле күптән түгел генә колхоз идарәсендә, идарә тулы ир-ат алдында, авызын ерып, мактанып утырганын үз колакларым белән ишеттем:

— Узган җәйдә шулай,— ди.— Илиныфкыдан әйбәт кенә кайтып киләдерием, ишетәм: юлдан ерак та түгел, берәү чыш-чыш агач кисеп ята. Киттем мин моның янына. Ну эләктерәм хәзер, мин әйтәм. Тавыш килгән җиргә барып җиттем. Пычкы чыжлавы прәме янда гына ишетелә. Ә кешесе күренми. Бу ни тамаша бу, дип аптырап торганда, имән ботаклары арасыннан пычкы чүбе коелуын шәйләп алдым. Күтәрелеп карасам — бер куллы пычкы белән шактый юан имәннең бер тармагын кисеп утыра берәү. Кем диген әле син аны: шалкан күк түгәрәк тыгыз ботлы, утыз-утыз биш тирәләрендәге чибәр генә хатын-кыз! Карыйм, Илиныфкыныкы түгел. Кем икән бу фәрештә, кайдан килеп чыкты икән, ничек итеп «рәтенә» төшим моның дип, шаккатып авыз ачып, карап торам тегеңә. Ә аның үз эше эш: мине күрми дә, сизми дә! Никадәр уйлап та башка юньле уй килмәгәч, тоттым да: «Һайт, шту там делаеш? Давай, слизай чичасже!»— дип кычкырдым мин моңа. «Ой!»— дип чыелдап куйды. Кулындагы пычкысы төшеп китте, аннары үзе төшә башлады. Ләкин кулы ычкынды да ике метр чамасы биеклектән лап итеп җиргә егылды. «Ой, умираю, ой больно!»— дип ачыргаланырга тотынды. Ә мин күреп торам: берни булмаган, болай гына, миннән куркудан гына чырылдый теге. «Канчай!— мин әйтәм,— дурака вәләйт! Ставай и атвичай: зачем деловой дуб пилишь? Давай, пошли, акт писайт будем!» — дим. Хәзер инде акттан куркып, чынлап ук җылый башлады бу.

«— Ой, мамочка! Ой, отец, нинады акт писать. Пажалысты ни надо. Чава хош дилай, ну акт ни пиши»,— ди. Ә миңа шул гына кирәк тә: «Латны. Акт писат ни буду тогда. Ну любит буду»,— дидем дә...

Идарәдәге ир-атлар хәйран калып, бер кавым тын тордылар. Аннары әлеге шул Әхмәтгали абый телгә килде:

— Мин синең кансыз адәм икәнеңне беләдерием, Әхмәт. Әмма мондый ук әшәкелеккә барырсың дип уйламаганыем. Хәтта кыргый җанварлар да эшләми бит бу кабахәтлекне! Алар да бер-берен аңлашкач кына, ике якның да теләге булганда гына сөешәләр. Ә син хатын-кызның чарасызлыгыннан файдаланып... Ничек җир күтәреп тора, ничек йотмый икән ул сине?!

Кансыз Әхмәт урынында башка берәү булса, Гали абыйның бу сүзләреннән соң һич югы азрак кызарыр иде. Ләкин төге дә селкенмәде тегенең.

— Син, Гали дус,— диде ул,— алай тиз генә нәтиҗә ясарга ашыкма. Син башта нинди хатын иде ул, аның белән эшегез ничек-ничек булып бетте дип сора, акыллы адәм булсаң.

Гали абый кулын селкеп куйды:

— Кем булса да адәм баласы бит инде ул. Һәм ул сине гомере буена каргап яшәячәк.

— Втумты и делы, шту ул мине каргамаячак, исенә төшергән саен, рәхмәт укыячак ул миңа. Казаннан Илиныфкыга кунакка кайткан тол хатын булып чыкты ул. «Рәхмәт сиңа, абый җаным!»— дип рәхмәт укып калды.

Ул үзенең шушы «тапкырлыгыннан» канәгать булып, кычкырып көлеп куйды. Ләкин идарәдәгеләрнең берсе дә аңа кушылмады. Әгәр көчем җитә торган булса, мин аны буып ыргытырга әзер идем. Шул кадәр үк кансыз һәм оятсыз булырга кирәк бит, ә? Хәер, анда кешене кызгану хисе булмавын моңарчы да белә идем. Үз баласын үзе, бака тоткан шикелле итеп, ботыннан тотып, кем күтәреп йөри ала? Ә менә аңа

үзенең ике яшьлек Әнвәрен ботыннан эләктереп алып селкеп тору — берни түгел.

Һәй, ул гынамы соң? Минем үземә дә бик күп җәбер эләкте аннан. Безнең әнинең фермада эшләгәнен әйтеп киткән идем инде. Әхмәт абый шунда төнге каравылчы иде. Кыш көннәрендә, бигрәк тә сыерлар бозаулый, сарыклар бәрәнли торган чорларда, фермада эшләүчеләр чиратлап каравылчы янына төнге дежурга бара. Безнең әни дежур буласы төннәрдә без я икәү барабыз яки әни үземне генә җибәрә торган иде.

Дежур торучыга төн буе йокысыз утырырга димәгән. Сыерлар бозауласа, сарыклар бәрәнләсә, каравылчыга бозау-бәрәннәрне җылыга алып керергә ярдәм итешүдән һәм имидән аерылган яшь терлекләргә эчертү өчен бер казан су җылытып куюдан гына гыйбарәт аның вазифасы. Башка чакта аңа йокларга да, китап укып утырырга да була. Дежурда чакта мин гадәттә дәресләремне әзерли торган идем. Аннары салам тутырып ясалган матрацны каравыл өе сәкесенә җәям дә йокларга ятам.

Ләкин Әхмәт абыйга бу бер дә ошамый. Йокыга китеп өлгермим, әйдә, сарыкларны карап керик әле, әйдә, сыерларны карыйк, берәрсе бозаулап ятмасын дип, кулыма фонарь тоттырып, мине үзе белән утарга алып чыга. Анысына да түзәр идем әле. Иң кыены шул: мин йоклап киткәч бишмәтемнең итәген һәм күлмәгемне муеныма тикле кире кайтарып һәм чалбарны тезгә кадәр төшереп, бөтен тәнне ачып куя да мин дер калтырап, туңып уянам. Я, шуннан соң кабих димичә ни дип әйтергә инде аңа? Минемчә, кабихнең дә иң кабихе генә эшләр иде мондый эшне...

Әнә шул явыз бәндә каршына утын сорап ничек барасың ди? Үлсәм дә барачак түгел мин аның янына. Барсам да бирмәячәк. Чөнки мин аның үзенә үк: «Эттән дә хужырак икән син, Әхмәт абый!»— дип әйткәнем бар.

Анысы узган кыш булган иде. Бүрәнәләр шартлап ярыла торган ачы суык төнне кулыма фонарь тоттырып, атлар абзарына алып чыкты бу мине. Фонарьны абзар баганасы ботагына элеп куйды да, каравыл өенә мине кире алып кереп, мичкә ягарга дип әзерләгән биш-алты утын агачы күтәртте. Бер арыш капчыгы алып, тагын атлар янына чыктык. Капчыгын тоткан килеш, баганадагы фонарь янына барып басты да миңа теге утын агачларын абзар түбәсенә ата башларга кушты. «Күгәрчен тотабыз!»— диде ул, нигә атарга кирәк соң аларны түбәгә дип сорагач.

Күгәрчен итен ашарга яраганын беләм, минем үземә дә кызык булып китте бу. Ләкин нибары бер фонарь белән генә яктыртылган, зур һәм биек абзарда ничек итеп ул күгәрченнәрне тотып булыр икән? Шулай да, теге кушкач, ыргыттым утын агачларының берсен. Ыргытуым булды, төнгелеккә кунаклаган җирләреннән дәррәү кубып, егермеләп күгәрчен фонарь яктысына килеп Әхмәт абыйга да, миңа да бәргәләнеп очып йөри башлады. Әхмәт абый шул арада дүрт күгәрченне эләктереп капчыкка тыгарга да өлгергән иде инде. «Ә син нәрсә карап торасың, малай актыгы. Нигә тәре шикелле катып торасың?»— дип мине тиргәргә тотынды бу. Мин, чыннан да, бер күгәрчен дә тотмаган идем.

— Давай, тагын бер-ике пүлән ыргыт. Тагын дүрт-бишне тотарга кирәк. Туйганчы бер ашарлык булсын!— диде Әхмәт абый.

Ләкин ул мине сүгеп ташлаганга, бу эштән гайрәтем кайткан иде инде. Күгәрченнәр дә безнең хәйләне сизенеп өлгергән иде булса кирәк: яктыга килмәделәр һәм без ул төнне бүтән бер күгәрчен дә тота алмадык.

Бичара күгәрченнәрне кызганудан күземә яшьләр килде. Әхмәт абый, киресенчә, бик шат һәм канәгать иде. Ул мыгырданып-җырлап торды.

Дүрт-биш көн үткәч ул тагын мине күгәрчен ауларга алып чыкмакчы булды. Аның теләгенә каршы килү яхшылык белән бетмәячәген белсәм дә, бу юлы мин кырт кисеп әйттем:

— Юк, Әхмәт абый, булмый.

— Теге көнне күгәрчен ите ашатмаганга үпкәләдеңмени? Курыкма, тота алсак, бу юлы сиңа да булыр.

— Аннан түгел. Ул көнне аша дисәң дә ашамый идем мин аны.
— Алай булгач, нигә кәҗәләнәсең?
— Күгәрченнәр кызганыч!
— Ә сарык, үрдәк, каз итләрен ашыйсың бит!
— Әйе, ашыйм. Чөнки аларны кешеләр хәләл көчләрен куеп, үзләре тәрбияләп үстерә.

Минем бу сүзләрнең мәгънәсен аңлап бетермәдеме, әллә җавап таба алмадымы, Әхмәт абый бүтән әгъвәләп тормады. Таянып йөри торган кәкре таягы белән күкрәгемә төртте дә:

— Бу кадәр дә атаңа ошарсың икән!— дип күгәрчен ауларга үзе генә чыгып китте.

Ләкин кеше кыйнап уңышка кем ирешсен? Бер күгәрчен дә тота алмыйча керде ул. Фонарь яктысына ул төнне күгәрченнәр түгел, нигәдер көтүе белән чыпчыклар гына җыйналган. Җиде-сигез чыпчык тотып алып керде теге. «Ашарга ярамый бит аларны, нигә апкердең?» дигәч: «Туңганнар бит. Хәзер җылытам мин аларны»,— дип кайнап торган казанга чыпчыкларны тереләй салды. Шул гөнаһсыз җаннарның пешеп үлгәннәрен ләззәтләнеп, күлә-күлә карап тора...

Әнә шул чакта әйттем мин аңа: «Эттән дә хуҗырак икәнсең син, Әхмәт абый!»— дип.

Әнә шул чакта кыйнап кайтарды ул мине.

Әнә шул чактан бирле мин — аны, ул — мине дошман күреп йөрибез.

Шулай булгач, ничек итеп, мәктәпкә илтергә утын сорап барыйм ди мин аның катына?..

Ләкин мәктәпкә утынсыз барырга да ярамый. Кичә мәктәп директоры Асия апа үз кабинетына чакыртып әйтеп җибәрде: «Утын алып килмәсәң — мәктәпкә бүтән килеп тә йөрмә, Нәҗимов».

Дөрес, утынны бер мин генә китерергә тиеш түгел. Әшнәктә без авылдан өч малай укыйбыз. Мәхмүт, Гәрәй һәм мин. Ләкин Асия апа аларга түгел, нәкъ миңа миңа әйтте. Чөнки Мәхмүтнең әтисе белән Гәрәйнең Миңниса апасы үткән айда ук инде мәктәпкә берәр йөк утын илтеп бирделәр. Ә минем минем әле бер утын агачы да илткәнем юк. Чөнки бу зур эшне үзем генә булдыра алмыйм. Әни...

— Ни уйлап болай тормыйча ятасың, малай? Әнә, иптәшләрең китте бит инде. Тор, улым, тор әйдә. Тизрәк юын да киенә башла. Бик тәмле итеп тәгәрәткән бәрәңге пешергәнием. Җылы чагында ашап алсаң әйбәт булыр иде да, хәзер өлгерә алмыйсың инде. Сумкаңа тыгам. Мәктәпкә баргач ашарсың. Тор, әйдә, тор! Гомердә булмаганны ялкауланып ятма!

Әй, әни-әни, ялкаулыктан ятуым түгел ләбаса! Мәктәпкә барып директор күзенә күренергә куркудан ятуым. Утынсыз барсам, барыбер кире борып кайтарачаклар. Әйткән сүзеннән кайта торган гадәте юк Асия апаның. Беләм, ул да усаллыктан түгел, кирәк булганга таләп итә торгандыр. Амбар хәтле мәктәпне җылыту өчен бер көнгә дә күпме утын кирәк! Зур-зур сигез мич бит анда. Ләкин, шулай булса да, миңа бер нәрсә бик үк аңлашылып җитми: Гәрәй, Мәхмүт һәм минем кебек малайлар һәм кызлар безнең класста гына да утыз алты кеше. Әмма Асия апа алардан утын таләп итми. Шуңа таләп итми, чөнки Олы Әшнәк балаларына тиешле утынны, имеш, авыл советы китерткән.

Ә без, имеш, бүтән авыл советына карый торган Зәңгәрле малайлары. Әйтерсең, Зәңгәрледә туган булуыбыз өчен без үзебез яки безнең эти-әниләр гаепле!

Әйтерсең, Әшнәк мәктәбенең бишенче «Б» классын җылытырга без өч малай өчен өстәмә ягарга кирәк?

Яхшылабрак уйлаганда, безнең анда салкын һава сулап утыруыбыз кире сенчә, классны җылытырга ярдәм генә итә ләбаса!

Ләкин юк, шуны аңламый Асия апа. Син аңа әбизәтелне утын китереп бир. Ә кайдан алыйм һәм ничек илтим мин ул утынны? Әхмәт абый-

дан сорарга ярамавын инде әйттем. Мәктәпкә утын илтәсе бар дип, әнигә әйтеп торасы да юк. Ярдәм итмәячәк. Киресенчә, бик әйбәт булган, ярар, бүтән барып йөрмәссең, дип сөенәчәк кенә. Чөнки ул Әшнәктә укуыма башта ук каршы иде. Чак кына берәр нәрсә булса: «Йөрмә интегеп, ташла шул укуыңны! Безнең нәселдә укып мулла булган кеше юк,»— дип кенә җибәрә.

Ләкин, инде укый башлагач, дәрес калдырганны яратмый үзе. Әнә хәзер дә:

— Иптәшләрең аръяк тауга менеп җитте инде, ни уйлап ятасың син, малай?— дип тагын яныма килде.

Әй, әнием-бәгырем, белсәң икән син минем ник болай тормыйча ятканымны? Ләкин сәбәбен сиңа әйтә алмыйм шул.

— Бүген укырга бармыйм мин, әни: башым авыртып тора.

Ул, хәвефләнеп, кулын маңгаема куеп карый. Аның кулы шундый йомшак, шундый җылы — җаннар рәхәтләнеп китә.

— Алай зыянлы шикелле түгел бит, улым,— ди әни, тынычлана төшеп.— Әллә барып карыйсыңмы мәктәбеңә. Юлда барганда каның таралып, җиңеләеп тә китәриең шунда.

Әни кеше сизмиме соң баласының чын хәләтен? Миңа оят булып китә, колакларым кызышып чыкканын үзем үк тоям. Авырмаган килеш көн буе урын өстендә ничек ятмак кирәк, дип уйлап алам. Бүген, ярый, ятып та булыр, ләкин бит иртәгә дә, берсекөнгә дә көннәр булачак, аларын ничек үткәрермен, дигән хәвефле фикер килә башка. Юк, болай ятып эш чыкмаячак: утын үзеннән-үзе килмәячәк, ә дәрес калачак. Ни булса да булыр, барып карарга кирәк.

Бер дәреска соңарам инде соңаруын. Нәби Зарипович сизсә, директор янына алып керәчәк — анысы көн кебек ачык. Ләкин бит мине, нигә утын алып килмәдең дип, Асия апа үзе дә чакыртырга тиеш. Онытыр дип уйлама, андый нәрсәне оныта торган гадәте юк аның. Ә соңга калуымның сәбәбен мин аңа урман каравылчысы янына барып, утын сорап йөрдем, дип аңлатырмын. Бәлки әле соңга да калмам: кызулабрак барсам, Мәхмүт белән Гәрәйне куып та җитәрмен...

Юк, никадәр генә тырышсам да, куып җитеп булмады иптәшләрне. Җан-тиргә төшеп, каш-керфекләрем бозланып мәктәп ишеге төбенә килеп җиткәндә, дәрес инде башланган иде. Бәхетсезгә-вакытсыз дигәннәре шушыдыр: бүген мәктәптә дежур укытучы — Нәби Зарипович икән ләбаса! Чаңгыларымны салып, дәрес беткәнче укытучылар күзенә күренми генә кайда торып торырга дип баш ваткан арада Нәби Зарипович шалт итеп үзе килеп чыкты. Пальтосын өстенә салып, тартырга дип чыгуы иде. Шырпысы кулында, кабызып җибәрәсе генә калган иде. Нәкъ менә шул чагында күреп алды ул мине. Җилтерәтеп директор янына алып керде.

— Менә, Асия ханым, рәхим итегез: бу «чибәр» егет дәреска соңга калган!

Ә үзе, чик бозучы дошман шпионын тотып алып кайткан кешедәй, бик горур һәм канәгать иде. Гел шулай ул: берәр укучы чак кына шаярганын күрсә, хәзер аны директор янына алып керергә тора. Ир кеше бит югыйсә, үзе дә хәл итә алырга тиеш иде мондый вак-төяк нәрсәләрне. Ә бу — юк! Моңа әбизәтелне директор янына алып керү кирәк.

Асия апа аңа җәелергә ирек бирмәде:

— Ярый, Нәби Зарипович, сезне тоткарламыйм, Нәҗимов белән мин үзем сөйләшермен,— диде.

Кәефе әйбәт чак туры килдеме, әллә кыяфәтем кызганыч булгандырмы, ул көнне Асия апа минем белән җитди, әмма рәхимле сөйләште.

— Нигә дәреска соңга калдың, Нәҗимов?

— Утын юллап йөргән идем, апа.

— Алып килдеңме соң?

— Булмады шул, апа: каравылчы Әхмәт абый, урманчылыктан рөхсәт язуың булмаса, бер агач та кистертмим, ди.

Болай дип әйтүем алдашу иде, әлбәттә. Шул ук вакытта дөреслеккә дә якын иде бу. Чөнки бик яхшы белеп торам: сорасам да нәкъ шулай дип җавап бирәчәк иде миңа Әхмәт абый. Ихтимал, шуңа өстәп сүгеп тә җибәрер иде әле...

Әхмәт абый «әйткән» сүзләр әллә ни тәэсир итмәде директорга.

— Ә утын алып килергә барыбер кирәк булачак, энем,— диде ул, тавышын күтәрмичә генә.

— Кирәк икәнен үзем дә беләм, апа. Ләкин каян алып китерим?

— Мин бит сиңа үзең алып кил дип әйтмим, әниең китерсен!

— Утын илтергә кирәк икәнен белсә, әни мине бөтенләй укытмаячак шул, апа!

— Ничек инде укытмаячак?

— Кызгана ул мине. «Юньле өс-башың юк, ашарга рәтле ризыгыбыз юк, интегеп йөрмә, калхузда гына эшлә. Калхузда эшләсәң, миңа да файдаң тияр, үземә генә авыр тормыш аппаруы»,— ди.

Асия апа беркавым аптырап торды. Ул моңарчы укыйсы килмәгән балаларны һәм балаларын укытасы килгән ата-аналарны гына күргән, ә баласын укытасы килмәгән ана турында беренче ишетүе иде булса кирәк. Ләкин ата-аналары мәҗбүр иткәнгә генә укып йөргән балаларга караганда үзләре теләп укыган балалар якынрак иде бугай аңар.

— Ә син укып кем булырга телисең соң?

Бу мәсьәлә минем өчен күптән хәл ителгән: милиционер булмакчы идем мин. Бер гаепсезгә кешеләрне җәберләп интектерә торган Әхмәт абый, Зәки абыйларны акылга утыртасым килә иде.

— Анысы ярый икән,— диде Асия апа, минем ул ниятемне хуплап.— Гаделлекне саклаучылар сафында эшләргә теләвең бик шәп. Тик менә утын мәсьәләсен ничек хәл итәрсең икән соң?

Инде миңа артык тәкәллефләнеп торасы юк, мәсьәлә кабыргасы белән куелган: тегеләйме-болаймы, аны нәкъ менә хәзер хәл итеп калырга кирәк иде.

— Таш ярырга кушсагыз да риза, апа. Тик мәктәптән генә чыгармагыз. Ә утын китерә алмыйм. Ярдәм итәр беркемем юк минем.

Асия апа тагын беркавым уйланып торды да әйтте:

— Ә киселгән утынны алып кайтырга председательгездән ат сорап ала алырсыңмы соң?

— Кайдан алып кайтасы ул утынны?

— Корноухово урманыннан.

Корноухово урманы — Әшнәккә җиде чакрымнар тирәсе. Шуңа тагын безнең авыл белән Әшнәк арасындагы алты километрны китереп кушсаң, ул буладыр унөч чакрым. Бер көндә иркенләп әйләнеп кайтып була икән булуын. Ләкин председатель Мөбин абый ат бирер микән? Үзе болай хәлгә керә торган ипле кеше ул. Безгә бераз чыбык очы да тиешле. Мин Әшнәктә укый башлаганны белгәч: «Молодец-молодец, әйбәт иткәнсең, укуның зыяны юк аның!»— дип үзе дә хуплаган иде. Ат сорап баргач нишләр — анысын белгән юк. Ярый, һәрхәлдә, бөтенләй үк этеп екмас әле.

— Председательдән сорап карармын, апа. Бәлки, бирер.

— Бәлки түгел, бирергә тиеш ул!— диде Асия апа.

— Тиеш нәрсәләр бар инде ул, апа. Ләкин колхозның да эше бик күп шул. Дүрт кибән сугылмаган игене бар. Алты ат Чистайдан Казанга спирт ташый. Урман ташу өчен Берсутка биш олау җибәрергә кушып, әле өченче көн генә районнан кәгазь килде.

— Син боларны кайдан беләсең, Нәҗимов?

— Безнең авылда клуб юк. Электр да, радио да юк. Тик колхоз идарәсендә генә батарея белән эшли торган радиоалгыч бар. Авыл халкы радио тыңларга кичен идарәгә җыела. Өченче көн председатель Мөбин

абый идарәгә җыелганнарга үзе шулай дип зарланып утырды. Шулай да мин аннан сорап карармын, апа. Бәлки, берәр җаен табып, ат биреп торыр.

Һәм менә без — Мәхмүт, Гәрәй һәм мин — Корноух урманында! Кубатурага салынган утынны чанага төяп азапланабыз. Әшебез бик авырлык белән бара. Чөнки агачлар юан. Төп буеннан салган юан агачлар гына калган. Нечкәрәк агачларын алып кайтып бетергәннәр.

Без төйи башлаган кубада нибары биш агач иде. Шуларның дүртесен төядек инде. Төявен төядек, әмма вакытны һәм безнең көчне дә бик күп алды бу. Урманга иртәнге уннарда килгән идек. Хәзер кичке эңгер төшеп килә. Ә безнең соңгы агачны һаман чанага сала алганыбыз юк. Чөнки анысы — иң юаны. Тәгәрәтеп булмый — ботагы комачаулый.

Без инде тәмам хәлдән тайдык. Кичке ашка әйләнеп кайтырбыз дип, икмәкне дә өчебезгә бер ашарлык кына алган идем. Анысы да чын арыш икмәге түгел, азрак он кушып салган бәрәңге ипие генә иде. Без аны урманга килү белән сыптырып куйдык. Хәзер берәр кабым гына булса бик ярап куяр иде дә...

Ә вакыт уза тора. Инде күз дә бәйләнә башлады. Ярый әле Мәхмүт белән Гәрәй әйбәт. Безнең утын илтелгән, син үзеңнекен үзең кара, димәделәр. Миңа ярдәм итәргә икесе дә берсүзсез риза булды. Чын дуслык менә шушыдыр инде ул.

Беләм: Гәрәй белән Мәхмүтнең дә карыннары ач. Ләкин берсе дә зарланмый. Бездән инде тир дә чыкмый. Чыгасы тир беренче түмәркәләрне төягәндә үк чыгып бетте. Өстән җепшек кар явып торуга карамастан, бишмәтләребез агач ботагына элеп куелган. Бүрекләребез белән бияләйләребез дә шунда. Безгә тамчы да суык түгел. Гаҗәп: карыннарыбыз ач булса да, нигәдер үтереп эчәсе килә.

— Берәр стакан гына су эчсәк тә әзрәк хәл булып китәр иде. Якынтирәдә чишмәсе дә юк ичмаса!— ди Мәхмүт.

Хәл керер идеме, юкмы — белмим. Әмма туйганчы бер эчкәндә начар булмас иде. Учлап-учлап кар ашап карыйбыз, ләкин ул сусауны басмый, киресенчә, арттыра гына икән.

Соңгы бүрәнәне чана янына әллә кайчан китереп куйдык. Әмма чанага салып кына булмый бит каһәрне! Тәгәрәтеп менгерергә ботагы ирек бирми, ә рычаг белән күтәртеп салырга безнең көч җитеп бетми. Инде салдык дигәндә генә шуып төшә дә китә!

— Әллә монысын калдырып кына китикме, малайлар? Бер ботаклы түмәркәне калдырганнан дөнья харап булмас. Апкайтсак та барыбер яра алмыйлар аны. Мәшәкате генә булыр.

Моны Гәрәй әйтте. Мәхмүт тә аңа кушылды.

Дөресен генә әйткәндә, бу уй минем башка алдан ук та килгән иде. Ләкин утын өчен мин җаваплы бит. Мәктәпнең завхозы кайсы кубада күпме агач барын белмидер дисеңме әллә? Кайткач алай-болай безнең алдашуны фаш итсәләр, директор алдында ничек җавап бирермен?

— Юк, малайлар, алай итмик. Бер агачны калдырып кайтканны белсәләр, кубагыз тулмый дип, я тагын урманга барырга кушарлар. Әйдәгез, килгән җирдә эшне бетереп кайтыйк инде!

Шулай дидем дә, иптәшләремне дә, үземне дә рухландырмак булып, кулларыма төкереп, тагын теге хәерсез имәнгә тотындым. Малайлар да миңа булыша башлады. Әмма...

Чукынып кына китсен бу үгез дигән хайван! Агачны инде чанага салдык дигәндә генә кинәт дуамалланып кузгалды да китте бит, хәерсез! «НАТИ» тракторы урынына сөйри чананы: дилбегәгә өчәүләп асылынып, көчкә туктаттык. «Баһадир» дип тикмәгә генә атамаганнар икән үзен! Күзләре калайланган, борын тишекләре футбол тубы сыярлык булып киңәйгән, үзе мыш-мыш сулый. Бер-ике тапкыр мөгезен чайкап, ямьсез итеп мөгрәп тә куйды. Ә бит колхозның иң тыңлаулы, юаш үгезе иде үзе. Бервакыт, өченче елның җаендә, шушы Баһадирны җигеп, өч ху-

жалыкның ашлыгын төяп, күршеләргә ияреп Бәтке тегермәненә барган идем. Ашлыгыбызны тартырга чират көтеп, ике тәүлек яттык тегермән болынында. Кигәвен, черки вакыты булуга карамастан, шунда да үзен бик сабыр тоткан иде: барлы-юклы юкә дилбегә арканын ник бер тапкыр өзеп карасын ичмаса! Ашый-ашый да, буадан су эчеп, күшәп тик ята. Кайтып китү турында уйламаган да иде... Бүген дә моңарчы тынычсызланмады. Килеп туктаган шәпкә, бияләй-бияләй кабып, ләкин ашыкмыйча гына, алдына салынган печәнне ашады. Олы һәм кече хаҗәтләрен үтәп, тәртә арасында килеш кенә ятып, шактый гомер ял итеп алды. Аннары торып тагын ашарга кереште. Әле алдында печәне җитәрлек: «Ерак юлга чыгасыз, дөнья эшен белеп булмый, балалар»,— дип ат караучы Галим абый печәнне мул итеп биреп җибәргән иде. Ләкин менә хәзер тыныч кына ашап торган җиреннән кинәт җенләнде дә китте...

Инде түмәркә янына кире килү турында уйларга да ярамый, чөнки кар бик тирән, йөкле чана белән борылу мөмкин түгел. Ә безнең теге хәерсез агачыбыз егерме-утыз метрлап артта калган иде.

Башта өчебез дә бергәләп Баһадирны тиргәдек. Аннары кинәт тынып, бер-беребезгә карап, ни эшләргә белмичә аптырашып калдык. Һәм менә шул чакта «и-ююююу», «и-ююүу» дип сузып кына бала елаган тавыш ишетелде. Тавыш юлның сул ягыннан, урман эченнән килә иде.

— И-ююүуу!

— Бүре бит бу, малайлар!— диде Гәрәй, кинәт куркып-агарынып китеп. Аның хәтта чәчләре үрә торган иде.

Минем дә котым алынды. Бүренең нинди әшәке ерткыч икәнен мин инде үз күзләрем белән күреп беләм. Мин икенче класста укыган кышта бер бүре уңъяк күршебез Мәһисәрвәр апаларның лапас ишекләрен каерып, кәҗәләрен алып чыгып, күз алдыбызда, урам уртасында ашап киткән иде.

Кешегә әйтеп, кеше ышанмас хәл булды ул. Безнең капка төбендә әни мич капкачы кагып, үз капкалары төбендә Мәһисәрвәр апа чиләк кагып, бүрене куркытмакчы булып, кычкыралар. Аларга кушылып без, балалар, кычкырышабыз. Ә бүренең гамендә дә юк: әле җаны да чыгып бетмәгән кәҗәне күз алдыбызда умырып-умырып ашавын белә. Ай-һай, андагы көч-куәт, ай-һай, аның тешләре! Чәйнәп тә тормый икән ул корбанының итен: өзеп ала да шул килеш йота, өзеп ала да йота икән.

Элек, китаплардагы рәсемнәрдә бүренең тешләре сирәк булуын күргәч, бу кадәр сирәк теш белән азыкны ничек чәйни икән ул дип уйлый идем мин. Теге көнне аңладым: чәйнәп торуның бөтенләй кирәге юк икән аңа!

Шул вакыйгадан соң бүренең үзен күрү түгел, исемен ишетсәм дә, куркып, бала йоннарым кабарып китә торган булып калдым.

Ул арада «И-ююүуу!» дигән коточкыч нечкә тавыш бу юлы тагын да якынрак ишетелде. Нинди сабыр Баһадир да ул тавышка түзә алмыйча, «Ыммо!» дип үкереп куйды һәм тагын кузгалып китәргә талпынды.

Хәзер аңлашылды: бая хәвеф барын сизеп кузгалып киткән икән ул!

Ярый әле, шундый хәл буласын алдан белгәндәй, дилбегәне юл буендагы имәнгә бәйләп куйган идем. Баһадир талпынса да китә алмады.

«И-ююүуу» тагын кабатланды. Ул тавышның бүре улавы икәненә инде беребезнең дә шиге юк иде.

— Нишлибез хәзер, малайлар?— диде Гәрәй. Куркудан аның тавышы пышылдап кына чыкты.— Безнең киемнәр утын төягән җирдә калды бит?

Ялан баш, бишмәтсез басып торуымны абайлап алгач, минем эчне тагын да ныграк бора башлады. Ни эшләгәнемне үзем дә белештермичә кар өстенә чүгәләдем.

Әгәр Мәхмүт тә безнең шикелле курыккан булса, эш юньле булып бетмәс: өс киемнәребезне барып алырга куркып, я катып үләр идек, я бүреләр тотып ашар иде безне.

Арабызда буйга иң кечкенәбез — Мәхмүт. Гәрәй белән без буйга икебез бер чама һәм яшьтәшләребез арасында бәләкәйләрдән санал-

мыйбыз. Ә Мәхмүт безнең күкрәктән генә. Дөрес, яшькә дә бездән ике яшькә кече ул.

Карап торышка бәләкәй һәм ябык булса да, Мәхмүтнең батырлыгы һәм тәвәккәллеге — биш кешелек. Шуның өстенә башы да бик шәп эшли. «Уртача» дигән билгенең нәрсә икәнен дә белми, «яхшы»ларны да бик сирәк, анда да, шаярып утырган чакларда гына ала. Аларны да чирек ахырына «биш»кә төзәтеп, гел отличник булып килә. Ә телгә осталыгы хакында әйткән дә юк инде. Ак сакаллы карт акыллары бар аңарда. Бүсеренә операция ясатып район больницасында ике-өч атна ятып кайткан иде, шунда русчасын да өйрәнеп өлгергән. Рус теле дәресендә укытучы Габделхак абый белән русча гына сыптыра. Габделхак абый сөенеп бетә алмый: «Вот как надо, ребята, учиться!» — дип безгә Мәхмүтне үрнәк итеп куя. Һәм бик дөрес итә: чыннан да, шәп белә Мәхмүт русчаны. Чөнки аның хәтер яхшы. Гәрәй белән без унар-унбишәр кат укып та авырлык белән генә ятлый торган шигырьләрне ул бер-ике кат укып чыгуга сүзен-сүзгә хәтерендә калдыра һәм җиде төн уртасында уятып сора — чатнатып сөйләп бирә.

Ронодан инспектор килгән вакытларда, директор яисә завуч класска кереп утырган чакларда укытучылар һәрвакыт дәресне Мәхмүттән сорыйлар. Ә ул беркайчан да тегеләрнең йөзенә кызыллык китерми: андый чакларда чабыш аты шикелле аеруча дәртләнеп җавап бирә. Укытучылар гына түгел, хәтта без — укучылар да сокланабыз аның шул зирәклегенә.

Менә хәзер, Гәрәй белән мин бүре улаганга коелып төшеп, баш югалтып торган чакта да, Мәхмүт безне айнытып, күңелебезгә рух кертеп җибәрде: бүредән куркып котыбыз алынудан кычкырып көлде дә:

— Тыңлагыз әле, малайлар, әнә ничек матур итеп улый бит! — дип бүренең чираттагы улавын тыңлап тора башлады. Аннары: — Оһо, берәү генә дә түгел ахры. Ишетәсезме, әнә тагын берсе калынрак тавыш белән улый башлады! Әйдәгез, алар яныбызга ук килеп җиткәнче, киемнәрне апкилеп калыйк! — дип без утын төягән җиргә китеп барды.

Бераз икеләнеп торганнан соң, курка-курка гына Гәрәй дә аның артыннан атлады. Миңа берүзем калу оят иде. Ләкин курку оятны җиңде: күңелем теләсә дә, аякларым атламады. Алар артыннан бара башласам, агач арасыннан килеп чыгып, өстемә бүре сикерер кебек тоелды. Ә Баһадир янында ничектер ышанычлырак: аның янына килергә бүреләрнең йөрәге җитмәс, килә калсалар да, ул аларга ирек бирмәс шикелле иде.

— Малайлар, минем бишмәт белән бүрекне дә алып килегез әле! Мин дә барсам, үгез китеп баруы бар! — дигән булдым.

Ләкин Мәхмүт андый гына хәйләне сизмиме инде!

— Ичмаса дөресен әйт: куян йөрәк мин, бүредән куркам диген! Ярар, килеп йөрмә, апкилербез,— ди ул. Аннары: — Һәйй, бүреләр, йөрмәгез безнең тирәдә! Без бит барыбер сездән курыкмыйбыз! — дип кычкырды һәм ачы итеп сызгырып җибәрде.

Шүрләп калдылар булса кирәк: Гәрәй белән Мәхмүт безнең киемнәрне алып килгәнче бүреләрнең улавы тынып торды.

Гәрәй дә шактый тынычланган, ләкин мин һаман калтырана идем әле.

— Курыкма инде шул хәтле! — диде Мәхмүт, тагын миннән көлеп.— Әгәр котырган ук булмаса, бүре кешегә тими ул. Хәтта икәүдән-икәү кара-каршы очрашканда да кешегә юл биреп үтә. Ә без монда өч кеше һәм амбар хәтле бер үгез! Шулай булгач, икәү генә түгел, хәтта унау уласалар да тимәячәк алар безгә. Аңладыңмы шуны?

— Аңлавын аңладым да бит, шулай да куркыныч. Кем белә аларның ни уйлаганын. Әгәр чамасыз нык ачыккан булсалар...

— Һе, кызык икән син. Алай уйлый башласаң, бу дөньяда куркынычның бетәсе юк. Менә шушы безнең Баһадир да куркыныч: йөгән кидергәндә мөгезен бер айкап җибәрсә, бөтен эчеңне актарып чыгара ала бит ул! Яки менә бая үгез тартылып киткәндә берәребезнең чана

табаны астында кысылып калуы мөмкин түгел идемени? Яки сугышны ал. Анда бит солдатны һәр секунд саен үлем сагалап тора. Ә шулай да сугыша солдатлар. Гадәттә үлем турында түгел, җиңү, яшәү турында уйлаганнар җиңеп чыга. Һәй, тапкан икәнсең куркыр нәрсә: бүреләр улый, имеш! Уласыннар! Рәхәтләнеп улый бирсеннәр, югыйсә кайда ишетер идек әле бүре концертын? Ә хәзер ичмаса үз колагың белән тыңлап торасың. Әйдә, чиш үгезнең дилбегәсен дә киттек кайтып!

Мәхмүтнең шулай олыларча акыллы сөйләшүе һәм батырлыгы минем эчкә дә җылы кертеп җибәрде. Хәзер теге хәерсез имән түмәркәсе турында уйлаган да юк. Хәтта төягән утыннарның да кирәге калмаган, тик исән-имин кайтып җитү турында гына уйлый идем. Дөресрәге, үзем ул кадәр курыкмыйм. Ахыр чиктә, Мәхмүт әйтмешли, барыбер бер үләсе. Барыннан да бигрәк, әни өчен курка идем. Әгәр шушында мине бүре ашаса, минем өчен кайгырып, акылыннан язуы бар аның. Әле кырыгынчы яше белән генә барса да, болай да чәчләре агара башлаган инде. 1938 елда, нибары егерме дүрт яшендә әти үлеп киткәч агарган аның чәчләре. Берсенә өч, берсенең яше дә тулмаган ике малай белән бер ялгызың тол калуны җиңел дип беләсезме әллә сез? Инде менә мине дә бүре ашаса — акылдан язмыйча нишләсен ди ул?!

Ә мин аны бер дә рәнҗетергә теләмим, кимендә йөзгә кадәр яшәтергә тиеш мин аны. Әтием өчен дә яшәргә тиеш ул. Шуңа күрә, әйбәтләп укып чыгып, милиционер булырга һәм дөньяда тәртип, гаделлек урнаштырырга телим. Шуңа күрә менә шушы Корноух урманында үземне дә, иптәшләремне дә интектереп йөрим бит инде. Әлбәттә, мин аларга бурычлы булып калмам, үзләренә дә ярдәм итешермен. Моңарчы да гел булышкалап килдем. Әле күптән түгел генә Мәхмүткә тиресләрен түгештем. Ә Гәрәйләргә узган ял көнендә генә утын кисешкән идем. авыл җирендә эш дигән нәрсә гел чыгып тора, тагын булышырмын. Эштән курыккан юк анысы. Тик бүре генә ашамасын да исән-имин кайтып кына җитик. Югыйсә...

— Кадалып китсен, әллә утынны бушатып кына калдырыйкмы, малайлар? Бүредән куркып ташлап калдырдык дисәк, Асия апа да әллә ни әйтмәс!— дидем мин.

— Әйе шул. Кайтасы юл да бик ерак,— дип Гәрәй дә минем фикерне күтәреп алды.

Ләкин Мәхмүт бу юлы да Мәхмүт булып калды.

— Сез нәрсә, җегетләр,— диде ул, әле миңа, әле Гәрәйгә аптыраулы карап.— Акылыгыздан яздыгызмы әллә? Көне буе чиләнеп, кәҗә майларыбызны чыгарып төягән утынны ташлап кайталар димени? Әнә,— диде ул, тагын улый башлаган бүреләр ягына ымлап,— бүреләр дә көлә сезнең бу ахмак сүзләрегездән!

Агачка бәйләп куелган дилбегәне чишеп алып, чанага менеп утырды да:

— Әйдәле, Баһадир-җаным, кайтып карыйк әле!— дип ачы итеп сызгырып җибәрде.

Чана артыннан барсак, бүреләр килеп эләктереп алудан куркып, Гәрәй белән без дә йөк өстенә менеп утырдык.

Көнозын җигүле торып, кайтырга бик зарыккан идеме, әллә ул да бүреләрдән куркып микән — Баһадир юыртып диярлек алып китте.

Көн буе буранлап торганлыктан, юлны кар күмеп бетерә язган иде.

Минем күңелдә һаман шул бер уй: бүреләр! Менә-менә артыбыздан куып җитәрләр дә безне йөк өстеннән йолкып алып, ботарлый башларлар шикелле иде. Ул-бу була калса дип, балтаны кулыма тотып барган булам да бит, аның белән ике бүрене хәл итү бик шикле шул. Яралап кына калдырсаң — харап инде аннары! Яралы бүредән дә яман ерткыч юк диләр җир йөзендә.

Шуларны уйлап, котым алынып, як-ягыма каранып бара идем, юл-



Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.

ның сул ягында, бездән ерак та түгел, агач арасында, ике яшькелт ут ялтырап киткән шикелле булды!

— Гәрәй, Мәхмүт, карагыз әле малайлар: әнә анда, агач арасында, ниндидер ут бар! Сез күрәсезме?

— Ут түгел ул, бүре күзләре шулай ялтырый!— диде Мәхмүт.— Мин инде аны кузгалып киткәннән бирле күреп киләм. Әнә теге якка карагыз әле, анда да ялтырый дүрт «ут». Ләкин курыкмагыз: безгә тими алар. Безнең янга килү түгел, әнә, чана эзе артына төшәргә дә курка алар. Урман эчләтеп, кар ерып килсәләр киләләр, юлга төшмиләр. Юлга төшсәләр, капкынга яки тозакка эләгүдән куркалар. Ә безгә тими алар. Мылтыгыбыз бар дип беләләр.

— Алай бик батырайма, Мәхмүт, тфү диген! Өстебезгә ташлансалар ни эшләрбез? Мылтык юк бит безнең!— диде Гәрәй һәм миңа тагын да ныграк елышып утырды.

— Бөтен хикмәт тә шунда, алар безнең мылтык юк икәнен белми! — диде Мәхмүт, бик ышанычлы итеп.— Шуңа якын килергә куркалар. Менә сез җаныгыз өчен дер калтырап, тын алырга куркып киләсез бит. Аларның шулай ук үз җаннары үзләренә кадерле. Аларның да үләсе килми. Әйдә, Баһадир! Тибешрәк атла әле, җанкай!..

Ләкин Баһадир кузгалгандагы шикелле үк тиз бара алмый, жепшек кар чана башына тыгылып, йөкне бик нык авырайта иде.

Ә бүреләр яшькелт-зәңгәр «фонарьларын» яктыртып, һаман бездән арттан киләләр. Ләкин арабыз мин беренче тапкыр күргәндә ничек булса, хәзер дә шулай: утыз-утыз биш метрлар чамасыннан артмый да, кимеми дә. Шуны абайлап алгач, Мәхмүт сүзе дөрестер ахрысы дип, күңелем бераз җылынып китте...

Анысы шулаен шулай да, ләкин ул бүреләр чамадан тыш ач булса һәм ачлык аларның куркуыннан көчлерәк булып чыкса? Я, раббем, алай була гына күрмәсен инде!?

— Син нәрсә өнсез калдың? Телеңне йоттыңмы әллә?— дип Мәхмүт минем янтыкка төртте. Болай да котым чыгып кына бара иде, бу миңа бик житә калды: сискәнеп китеп, чанадан чак кына егылып төшмәдем. Бүтән вакыт булса, моның өчен мин Мәхмүтне чәчрәтеп кенә җибәрер идем. Ләкин хәзер кая ул аңа каршы сүз әйтү!

Хәзер мин ул ни кушса, шуны эшләргә торам. Ул ни әйтсә, шуңа ышанам. Ул хәзер минем өчен алла да, мулла да иде. Теләсә ни дип әйтсен, теләсә ничек көлсен, тик шушы бүреләрдән исән-имин котылуыма өметемне генә өзмәсен! Исән-имин шушы бәладән котылып өйгә кайтып керә алсам, киләсе көздә чебеш суйгач үземә тигән өлешне Гайнетдин бабайларның Актырнагына бирер идем...

Тыны-тавышы булмагач, нишли икән дип, Гәрәйгә күз салдым. Ул да минем шикелле белгәннәрен укып килә булса кирәк: иреннәре туктаусыз кыймылдый, ә үзе изгеләрчә мөкиббән китеп, күзләрен үк йомган иде.

Тик Мәхмүт кенә бер дә аптырамый.

— Әйдә, Баһадир-жаный, түз!.. Әйдә, урманны чыккач җиңеләер. Кырда карны бу кадәр үк салмагандыр әле,— дип тыныч кына сөйләнеп утыра.

Инде урман авызына җитәргә дә күп калмаган, ике-өч йөз метрдан артык түгел. Баһадир кинәт туктап калды. Борын тишекләреннән көлтәкөлтә пар чыга, бөтен гәүдәсе шыбыр су, бот аралары тирләп, күбекләнеп үк чыккан иде.

Без туктагач, бүреләр дә туктап, арт аякларына утырдылар. Безнең ара хәзер отыры якынайган, шуңа күрә аларның күзләре генә түгел, үзләре дә аерым-ачык күренә: өчәү иде алар. Икесе уртача, гадәти бүреләр. Ә берсе тана хәтле. Безнең арттан килгәндә улаулары тынып торган иде, хәзер тагын чиратлашып уларга тотындылар. Алар миңа үзара сөйләшәләр: «Башта син ташлан шул малайларга!» «Юк, башта син ташлан!»— дип сатулашалар шикелле. Аларның ул бәхәсе озакка бармас,

берәрсе тәвәккәлләр дә, минут эчендә безне өзгәләп бетерерләр сыман.

Гәрәй дә шул рәвешлерәк уйлый иде булса кирәк.

— Әллә үгезне шушында калдырып, үзебез агач башына менеп утырыйкмы, малайлар?— диде ул. Шул тәкъдименә хуплау эзләп, бер миңа, бер Мәхмүткә карап алды.

Яшермичә генә әйткәндә, аның бу тәкъдименә мин үзем дә риза. Алай гына да түгел, безнең хәзер җаныбызны саклап калу өчен башка чара да юк кебек иде.

— Ә үгез нишли?— диде Мәхмүт, безнең дүртенче иптәшебез турында сүз баргандай җитди итеп.— Аны агач башына ничек алып менәбез?

Фәлсәфи яктан килеп караганда, Мәхмүт, әлбәттә, хаклы: үгез дә безнең шикелле үк җан иясе. Без адәм балаларына хезмәт итеп килә торган, хезмәте өчен бер тиен эш хакы да сорамый торган игелекле җан иясе. Ләкин, шул ук вакытта, үгезне саклыйм дип, күрә торып бүре авызына кереп тә булмый бит инде.

— Нигә аны агач башына алып менәргә?— дидем мин, Мәхмүтнең шулай җиңел уйлавына гаҗәпләнеп.— Ул шушында кала. Аның безгә нәкъ менә шушында калуы кирәк. Өч бүрегә бер үгез ите, шәт, җитәр. Ашарлар да, тамаклары туйгач, китеп барырлар.

Хәленнән килсә бәреп егардай булып, Мәхмүт миңа ямьсез итеп карап куйды:

— Ай-яй, Вакыйф, мин сине шундый да куркак җан дип уйламаган идем! Сугыш кырында иптәшеңне дошманга калдырып китү берни дә тормый икән синә, болай булгач! Әйдәгез, икегез дә төшегез әле чанадан. Күрәсез бит, үгезгә болай да авыр!

Гәрәй, коты алынып, Мәхмүткә текәлде:

— Син нәрсә? Бүреләр килеп эләктереп алсын дисеңме әллә?

Минем дә чанадан төшәргә исәп юк иде:

— Әйдә, төшеп тормыйк ла, Мәхмүт. Көн буе ашап ятты ич, безне тартырлык кына көч җыйгандыр әле. На, Баһадир! Әйдә, ялкауланып торма!

Чана башына бөялгән җепшек кар без туктап торган арада ныгыпоешып өлгергән иде: талпынып-талпынып караса да, Баһадир чананы алып китә алмады.

— Их, корт чаккырлары. Их, куян йөрәкләр!— дип Мәхмүт сикереп төште дә, йөккә кыстырган көрәкне алып, чана башындагы карны көри башлады.

Ул төшүгә бүреләр аңа килеп ябышырлар төсле иде. Киресенчә булып чыкты: Мәхмүт чанадан сикергәнне күргәч, өч бүренең өчесе дә, команда бирелгән шикелле итеп, берничә метр арырак китеп утырдылар.

Мәхмүтнең бездә бөтенләй гаме юк: бияләен салып ташлап, чана башын чистартуын белә иде. Әйтерсең, бу утынны алып кайту миңа түгел, аңа кирәк. Чанада бөкшәеп утыруым өчен миңа оят булып китте. Әнә шул оялу хисе куркуны җиңеп, мин дә йөк өстеннән төштем:

— Син азрак ял ит, Мәхмүт. Кая, мин бераз көрим әле.

— Әһә, оятыңа көч килдемени? Мә инде алайса. Тик курыкмыйча эшлә. Безгә тими ул бүреләр дип әйттем бит инде!

Ул арада Гәрәй дә чанадан төшеп, шыпырт кына минем янга килеп баскан иде...

Чана башын чистарткач, Баһадир бер азапсыз кузгалып китте.

Гәрәй белән без, чана артыннан барырга куркып, тиз генә йөк өстенә менеп кунаклаган идек, Мәхмүт үгезне туктатты да:

— Оятыгыз бармы сезнең, малайлар? Нужәли хайванны кызганмыйсыз? Болай да авыр бит аңа! Давай, төшегез хәзер үк тә чананы арттан этеп барыгыз!— диде.

Атарга дип күкрәгемә мылтык терәсәләр дә, чана артында калырга риза булмас идем мин.

— Юк-юк, Мәхмүт малай, мин лутчы менә болай итәм!— дип янга чыктым да, карга бата-чума тәртәдән этеп бара башладым.

Мине күреп Гәрәй дә икенче як тәртәгә барып тотынды.

— Соң, ахмаклар, кар ерып, яннан сөйрәлеп, үгезгә комачаулап барганчы, арттан этсәгез ни була?— дип Мәхмүт безне күпме генә орышып караса да, чана артына чыгарга йөрәгебез җитмәде.

Ә бүреләр, һаман бер араны саклап, безгә ияреп килә иде. Гәрәй бу хәлгә аптырап:

— Нигә калмый икән инде болар? Әллә тәки безне ашарга җыеналар инде!— дигән иде, Мәхмүт анда да безне юату җаен тапты:

— Нигә калдырасың аларны? Килсеннәр! Йөккә авыр итеп, синең кебек тәртәгә сөйрәлеп килми ич алар. Үз аяклары белән килә. Бәлки алар безне озатырга телиләрдер. Бәлки шулай кызыктыр аларга!

Ә үзе йөк артына чыгып, юри арткарак калып, кычкырып җырлап җибәрде:

Шахтер егет күмер чаба
Вак-вак итеп кисәген шул.
Гомерем бетеп, таш басмаса,
Ташламам җанкисәгем...

Ике йөрәкледер бу Мәхмүт, билләһи! Карап торырга йодрыктан чак кына зуррак бит. Ә үзе, әнә, артыбыздан өч бүре эзәрлекләп килүгә карамастан, уйлап та бирмичә рәхәтләнеп җырлап бара! Бүреләрен дә әйт әле син аның! Мин шулай берүзем артка калган булсам, миңа шундук ташланырлар иде. Ә Мәхмүт калгач, киресенчә, тагы да ераграк калып киләләр. Әйтерсең, ниндидер күзгә күренми торган җепләр аша Мәхмүт алар белән шулай идарә итеп тора! Әйтерсең, ул аларны гипнозлаган!

Урман авызына килеп җиткәч, Баһадир тагын туктады. Урман эчендә генә сизелмәгән, кары гына түгел, җиле дә шәп булган икән: урман буена шундый көртләр өеп киткән, юлның эзе дә калмаган. Шул көрткә килеп терәлгән идек.

— Әллә чананы шушында тугарып калдырыйк та үгезне җитәкләп кенә кайтыйкмы? Иртәгә колхоздан ат бирерләр әле утынны апкайтырга,— диде Гәрәй.

Шушы урман авызын үтсәк, безнең эшләр көйләнә: дүрт чакрымнар чамасы юл гел түбән таба төшә. Баһадирга авыр булмаячак иде. Монысы бер. Икенчедән, иртәгә ат белән килеп алу турында уйларга да ярамый. «Сугу машинасында эшләүче алты аттан һәм салам тарттыручы бер кырыкмыш тайдан башка, җигәр ат калмады. Барысы да читтә: урман эшендә, спирт ташуда, наным. Шуңа күрә үгездән башка нәрсә бирә алмыйм сиңа. Анысын да үзең әйбәт булганга, җәйге каникул вакытында колхозга булышкан өчен генә бирәм»,— дип Мөбин абый кичә нәрәт биргәндә өзеп әйтте. Шулай булгач, иртәгә ат түгел, үгез дә бирә алмаячак ул. Колхозда җигелә торган нибары биш баш үгез бар. Ә аларга эш — муеннан! Аннары килеп, бүреләр дә өскә сикерергә тормый. Без тукталгач, әнә, алар да туктап, сабыр гына утырып торалар. Әллә арыдылар, әллә барыбер безне өркетә алмауларын аңладылар — улаудан да туктадылар хәзер. Шулай булгач...

— Көн буе салган тырышлыгыбызны әрәм итеп калдырганчы, юлны көрәп карыйкмы әллә, малайлар?— дидем мин.

— Кәнишне көрибез!— диде Мәхмүт, һич икеләнеп тормыйча.

— Ыы шул. Мин дә шулай дип әйтмәкче идем. Күп ара түгел бит, дүрт-биш метр гына көрисе. Шушы урман авызыннан чыксак, әнә, юлга әллә ни салмаган,— дип Гәрәй дә ризалыгын белдерде.

Без, чиратлашып, юлыбыздагы көртне таратырга тотындык. Яңа яуган кар әллә ни авыр түгел иде, без аны кул-кулдан бик тиз көрәп ыргыттык.

Ул арада Баһадир да ял иткән: юлны арчуга, дәшкәнне дә көтмичә, үзе кузгалып китте.

Ә бүреләр Әшнәкнең басу капкасына җитә башлагач туктап, моңаешып улап калдылар.

Без мәктәп ишегалдына кайтып кергәндә кичке тугыз тулып килә иде. Мәктәп каравылчысы Гыйльметдин агайдан сорап, ач карынга берәр чүмеч салкын су эчтек тә, исән-имин котылуыбызга һәм ният иткән эшебезне җиренә җиткерүебезгә куанып, өчебез дә бергәләп җырлый-җырлый, үзебезнең Зәңгәрлегә кайтып киттек.

Хәзер инде, утын китерергә кушар дип, Асия ападан куркасы юк. Мәктәптә күкрәк киереп укып йөрергә була иде.

## Мин көзге имтиханга калам

Моннан сигез ел элек, мине нәшриятның баш редакторы итеп эшкә билгеләү хакында сүз барганда җитәкче иптәшләрнең берсе:

— Синең бу эшне алып бара алуыңа без ышанабыз. Ләкин анда эшләү сиңа җиңел булмаячак: кешеләр белән мөгамәләдә гибкость җитеп бетми сиңа, Вакыйф. Артыгын турыдан ярасың да үзеңә карата кешеләрдә тискәре фикер тудырасың. Киләчәктә дипломатия саклабрак эш итәргә кирәк булыр. Шуны искә ал әле, пожалуйста, яме!— дигән иде.

Рәхмәт ул иптәшкә. Мин аның бу акыллы сүзен һәрдаим исемдә тотарга тырышам. Ләкин, никадәр генә тырышсам да, теге яки бу мәсьәләне дипломатларча шома, соңыннан үземә авырлык китерми торган итеп хәл итәсе урында, еш кына берәр туры сүз әйтеп куям да, шуның аркасында дус дип йөргән иптәш кешеләрем белән үпкәләшүгә, дус булмаганнары белән бөтенләй ара бозылуга кадәр барып җитә.

Менә хәзер, шул турыда уйланып, шушы юлларны язып утырганда аңладым: инде күптән, бала чактан килә икән минем бу «кирелегем». Һәм ул миңа бик күп өстәмә авырлыклар китергән икән. Мәсәлән, җиденче классны тәмамлыйсы елны көзге сынауга калуым да әлеге шул «гибкий» була алмавым нәтиҗәсендә килеп чыкты.

Ул елны кышкы каникулдан соң математикадан безне Нәбиева Эльмира дигән яшь кенә бер укытучы укыта башлады. Үз укытучыбыз декретка чыккан иде,шуның урынына Әшнәккә Корноухтан (Корноухово ул чакта район үзәге иде) килеп йөри иде ул. Ире Корноухта эшли, район масштабындагы башлыкларның берсе иде. Шуңа күрә Нәбиева апаның килеп-китеп йөрү өчен кайгысы юк: иртән иренең аты белән аны мәктәп ишеге төбенә китереп куялар, кич килеп алып китәләр иде.

Корноухка барган чакларда район башлыклары хатыннарын күргәләгән бар. Үзләрен башлыклардан да болайрак «важный» тоталар. Аларның атлап йөрешләре үк бүтән. Әмма безнең Эльмира апабыз ул яктан тегеләргә һич охшамаган. Хәтта, мин әйтер идем, аларның киресе иде. Кечесен-олысын аерып тормый, кешеләр белән һәрвакыт башлап үзе исәнләшә. Аның чырае беркайчан да караңгылана белмидер шикелле иде миңа. Тутырып бер караса, күңелләрне тетрәтеп, җаннарны рәхәтләндереп җибәрә торган зур кара күзле, кыйгач кара кашлы, сөрмә тарткан озын кара керфекле, өске иренендә бәләкәй генә чем-кара миңле, һәр нәрсәсе үз урынында һәм үзенә тап-таман булган искиткеч зифа гәүдәле, бик тере һәм искиткеч ягымлы хатын иде ул. Ул чакта миңа дөньяда аннан да чибәр хатын-кыз юктыр, булырга тиеш тә түгелдер шикелле иде. Миңа аның һәр хәрәкәте, һәр кыланышы кадерле. Безнең класска дәрескә керүен түземсезлек белән көтеп алам. Бездә дәресе булмаган көннәрдә, аны күрер өчен, тәнәфес вакытларында укытучылар бүлмәсе тирәсенә барып, көтеп тора идем. Болайлар итеп әрсезләнеп йөрү миңа оят: кешеләр сизәр дип куркам. Ләкин берни эшли алмыйм, аны күрергә теләү хисе ояттан көчлерәк иде. Турысын гына әйткәндә, ул миңа бик ошый иде. Ул үзе дә бик яшь. Узган ел гына педучилище тәмамлаган. Ә мин яшем буенча инде тугызынчыда булырга тиеш. Дүртне бетергәч, Әшнәккә йөрергә иптәш булмаганга ике ел укымый тору аркасында гына җиден-

чедә йөри идем. Димәк, ул миннән нибары ике-өч яшькә генә олырак.

Анысы шулаен шулай, ләкин бит ул, бердән, минем укытучым, икенчедән, кияүдәге кеше. Димәк, нинди дә хыял-өметләр багларга һич нигез юк. Мин моның шулай икәнен беләм. Ләкин, ни хәл итмәк кирәк, беренче күрүдән үк ошаттым бит шуны!

Әлек математикага әллә ни исем китми: «биш»леләргә караганда «дүрт»леләрем күбрәк була, кайчакларда «өч»ләр дә эләктергәли торган идем. Нәбиева апа килгәч, хәлләр үзгәрде: башка фәнне әзерләми калсам калам, ләкин математиканы әзерләмичә мәктәпкә бармыйм. Өйдә эшләргә биреп җибәргән мәсьәләләрне генә түгел, киләсе дәрестә эшләргә тиешлеләрен дә эшләп куям. Әгәр ул, теманы кем сөйләргә тели, яки такта янына кем чыгарга тели?— дип сораса — иң элек мин кул күтәрәм! Класста эшләргә бирелгән мәсьәләләрне мин инде өйдә үк чишеп киләм. Ә дәрес вакытында, үзенә сиздермәскә тырышып, гел аңа карап, чибәрлегенә сокланып утырам. Әгәр шул минутларда ул миңа үл дип әйтсә, мин хәтта үләргә дә әзер!..

Ләкин ул... Кая анда үл дип әйтү, мине бөтенләй сизми дә. Аның үзе эше эш: мәсьәләне кем ничек чишкәнен караштырып, парта араларында йөри, тукталып, кайбер укучыларга сораулар бирә, кайберәүләренә мәсьәләне чишкәндә нинди формулага нигезләнеп чишәргә икәнен искәртә. Ә минем янга тукталып та тормый: мәсьәләне чишеп куйганны ерактан ук күреп ала да бер сүз әйтмичә үтә дә китә. Әллә бар мин аның өчен, әллә юк. Мактасын дип әйтмим, һич югы, янымда биш кенә секунд басып торсын иде ичмаса! Неужели шулай бөтенләй үк игътибарга торгысыз пүчтәк малай икән мин аның өчен?..

Нәбиева апаның игътибарын башкача берничек тә җәлеп итә алмагач, бер көнне өйдә дә эшләп килмәдем мәсьәләләрне, класста да чишмичә утырып карарга булдым. Бармак калынлыгы боз каткан мәктәп тәрәзәсенә текәлдем дә, өннән чыккан кеше шикелле, тик утырам. Сизәрме икән? Сизсә ни әйтер икән? Әгәр сизмичә үтеп китсә, бик шәп: апа, мин мәсьәләне чишмәдем бит, ә сез шуны күрмәдегез, дип сүз кушарга мөмкин булачак...

Ләкин ул мин уйлаганча ук игътибарсыз түгел икән, сизде. Дәрес бетәргә ике-өч минут кала дежур укучыдан дәфтәрләрне җыйдырып алдыртты да, звонок булгач, миңа класста калып торырга кушты. Ни әйтүендә, ни өчен алып калуында эшем юк, миңа аның менә шушы игътибар итүе һәм үземне генә класста алып калуы кыйммәт, шунысына бик куанган идем. Куанычымнан авызны ерып бардым мин моның янына.

— Нәрсә әйтмәкче идегез, апа?

Аның йөзе һәрчак балкып торадыр дип уйлап ялгышканмын икән: кирәк чагында хәтта куркытырлык дәрәҗәдә җитди дә була белә икән ләбаса ул!

— Син нигә шулай кыланасың, Нәҗимов?— диде ул, мин аның өстәле янына килгәч.— Син нәрсә, укытучы апа юләр, ә үзем акыллы дип уйлыйсыңмыни?

Мондый хәлдә берни аңламауга сабышудан да хәерлесе юк иде.

— Сез нәрсә, апа? Кем алай уйлаган? Кайдан чыгып әйтәсез моны?

— Беренчедән, синең апаң булганым юк минем. Мин — Эльмира Хәлиловна. Икенчедән, син мине юләргә санама, яме! Үзең дә акыллы башыңны ахмакка чыгарып утырма. Бик яхшы белеп торасың ни өчен икәнен. Ә хәзер менә болай эшлибез. Бүген дәрестә кыланып утырганың өчен, мин сиңа менә шушы дүрт мәсьәләне өеңә биреп җибәрәм. Алдагы дәрескә шуларны эшләп киләсең! Монысы — бер. Икенчедән, шул: киләчәктә беркайчан да мондый кыланышыңны бүтән кабатламыйсың! Аңладыңмы?

Менә монысы ярый. Монысы нәкъ мин теләгәнчә иде. Миңа бит аның менә шушылай игътибар итүе генә кирәк. Минем берниндн явыз ниятем юк! Ләкин аның үзенә моны әйтеп булмый бит инде.

— Алай ук зурга алмагыз инде, Эльмира Хәлиловна. Башым бик авыртып тора, шуңа гына чишмәдем мин ул мәсьәләне. Гафу итегез, бүтән алай итмәм, яме.

— Башың авырткач, нигә алдан ук әйтмәдең соң аны?— Ул тагын элеккечә мөлаемланган иде:— Каяле, кил әле,— дип, яныма ук килеп, башымны тотып карады.

Аның кулының йомшаклыгыннан, бөтен гәүдәсеннән бөркелеп торган хуш исле кайнарлыктан миңа шул тикле рәхәт иде, һушымны җыеп.авып китүдән чак кына тыелып калдым. Тагын шунысы гаҗәп: белмим, үземнең артык нык куану-каушаудан шулай булдымы, әллә аның кулы аша үз кайнарлыгы миңа, минем маңгайга күчкән идеме — ул мине чыннан да авыру дип тапты:

— О-о!— диде ул, борчуга калып.— Температураң бар икән бит. Болай булгач, дәресләр беткәнче утырырга ярамый сиңа. Бар, класс җитәкчегезгә әйт тә өегезгә кайтып ят!

— Юк, апа, моның өчен генә кайтып тормыйм, үтәр әле. Аннары иптәшләрдән башка үзем генә кайтуы да күңелсез,— дидем мин.

Шатлыгымнан кая басканымны да белмичә, йөгереп класстан чыгып киттем.

Шул көннән мин аерата канатланып укый башладым. Алгебра белән физикадан бигрәк тә нык тырышам. Физика дәресе буласы сәгатьләрдә тәнәфес вакытында ук әзерләнеп, Эльмира Хәлиловнага приборларны класска алып керергә булышам. Минем бу эшем һәр нәрсәдән көләргә генә торган кайбер малайларга ошамый, «куштан» дип үртиләр. Ләкин аларның сүзләрен колагыма да элмим. Сөйли бирсеннәр. Ә миңа Эльмира Хәлиловнага булышудан, аның рәхмәтле елмаюын күрүдән кадерле нәрсә юк. Аның якын итеп бер елмаюын күрер өчен әлләниләр эшләргә әзермен. Арабызда булган теге көнге сөйләшүдән соң ул үзе дә миңа якын итебрәк карый башлады.

Берәр йомышы булса — миңа куша.

Класс чишәргә тиешле мәсьәләнең шартларын тактага язып куярга булса — мине дәшә.

Кара тактаны сөртә торган чүпрәк кипкән булса, аны юешләп керергә — мине чыгара.

Мин моңа сөенеп бетә алмыйм, очынып йөрим. Элек, ул безнең мәктәпкә килгәнче, көн әллә ни суык булмаган чакларда да: «Бик салкын бит, малайлар. Әйдәгез бүген барып йөрмик укуга, я катып үләрбез»,— дип, Гәрәй белән Мәхмүтне мин котыртып алып кала торган идем. Ә ул килгәч бик суык көннәрдә дә: «Әй, җылы бит. Берни дә булмый. Әйдәгез, барабыз»,— дип тегеләрне үзем әйдәп мәктәпкә алып бара торган булдым.

Белмим, ник алай булгандыр, тора-бара Эльмира Хәлиловна мине бөтенләй үк якын итә башлады. Физика приборларын төзәтергә булышырсың дип, янсә, күргәзмә материаллар сызарга ярдәм итәрсең дип, дәрестән соң ул мине үзе белән алып кала. Бергәләп приборларны рәткә китерәбез, сызымнар сызабыз. Миңа аның янында булып, аның якты елмаюын, ерактан ук бәреп торган җан җылысын тоеп тору бик-бик рәхәт. Үзебез эшлибез, ә ул шунда, эш арасында, педучилищеда укыганда булган хәлләрне сөйли. Минем тормыш хәлләрен сораштыра.

Ул үзе Мөслим районыннан икән. Ирен Корноухка эшкә билгеләгәннәр дә, шуңа бу якларга килеп чыккан. Ә ире белән Казанда училищеның соңгы курсында укыганда танышкан. Тегесе инде институт бетереп, Казанда комсомол райкомында эшләгән булган. Мин моңа гаҗәпләнеп: «Алай булгач, ничек соң ул болай тиз генә хәзерге зур урынга килеп эләкте?»— дип сораган идем: «Әтисе аркасында. Әтисе зур урында эшли аның,— дип җавап бирде.— Ә минә синең, кызганычка каршы, әтиең бөтенләй юк икән шул»,— дип мине кызганып куйды.

Ләкин минем кызганыч булып күренәсем килми иде. «Ә миңа беркемнең дә ярдәме кирәкми, Эльмира Хәлиловна. Мин барысына да фә-

кать үз көчем, үз тырышлыгым белән генә ирешергә телим!»— дип җавап бирдем.
Эльмира Хәлиловна кычкырып көлеп куйды:
— Мо-ло-дец, Нәҗимов! Болай фикерләвең ошый миңа!— диде.
Мондый әчкерсез һәм дустанә сөйләшүләр минем үземә дә бик ошый. Шуңа мин хәзер мәктәпкә һәркөн бәйрәмгә барган шикелле ашкынып, куанып йөри идем.
Ә вакыт үз җае белән акты да акты. Сизелмичә генә диярлек март, апрель айлары үтте. Май керде. Язгы сулар китеп, җирләр кибеп, юллар төшкәч, безнең сөйләшүләрне дәвам итәр өчен Эльмира Хәлиловна тагын бер әмәл уйлап тапты. Аны эшкә һәркөн китереп куялар, килеп алып китәләр, дип әйткән идем инде. Әнә шул үзең алмага килүчене, минем әле эшләрем бетмәгән, эшем беткәч тә һава сулап болын юлыннан җәяү кайтасым килә, дип кире кайтарып җибәрә дә:
— Әйдә әле, Нәҗимов, юлың ике-өч чакрымга әйләнеч булса булыр, бергә кайтыйк бүген!— дип. Корноухка кадәр минем белән кайта торган иде.
Укытучы тикле укытучы, аннан да бигрәк, үзем яраткан кеше шулай иярттеп йөргәч, мин, әлбәттә, биш куллап риза. Ләкин тар гына болын сукмагыннан, таллар арасыннан аның белән икәүдән-икәү генә бару миңа ничектер уңайсыз да. Безнең шулай шаяра-көлә сөйләшеп барганны Эльмира Хәлиловнаның ире күреп алса, яки берәрсе күреп аңа әйтсә, әллә нинди күңелсезлекләр килеп чыгар дип борчылам. Күңелемдә мең төрле сораулар булса да, аның белән алай бик күп сөйләшмәскә, бернichә адым арткарак калып барырга тырышам. Ә ул, киресенчә:
— Әйдә инде, якынрак кил инде! Тотып ашамыйм бит мин сине!— дип туктап көтеп тора...
Бер көнне, инде имтиханнар башлангач, консультациядән кайтып барышлый кинәт кенә сорап куйды бу миннән:
— Нәҗимов, сигезенче класска кая бармакчы буласың: Солтангамы, Корноухкамы?
Минем инде планым үзгәргән: Казанга педучилищега китәргә исәп! Мәктәп директоры Асия апа, рус теле укытучысы Габделхак абый һәм минем өчен иң чибәр, иң изге булып күренгән менә шушы Нәбиева апалар шикелле укытучы буласым килә иде. Гомумән, укытучы булудан да әйбәт һөнәр юктыр шикелле иде миңа. Класста утыз-кырык бала. Шуларның барысы синең күзеңә карап, син ни әйтсәң — шуны эшләргә әзер булып утыра. Аларның язмышы тулысы белән синең кулда: син ничек укытсаң — аларның белеме шулай булачак. Хәтта холыкларын да үзең теләгәнчә итеп тәрбияләргә мөмкин аларның. Шулай булгач, моннан да зуррак, моннан да мөһимрәк тагын нинди һөнәр булсын ди?
— Ә мин Солтанга да, Корноухка да бармыйм!
Эльмира Хәлиловна шаккатып, туктап калды:
— Ничек инде ул бармыйсың? Син нәрсә, укуыңны бөтенләй ташларга җыенмыйсыңдыр бит?
— Юк. Мин Казанга педучилищега барам!
Ул бик хәтәр итеп башын селкеп куйды:
— Юк, Нәҗимов, син анда бармыйсың! Беркая да җибәрмим мин сине!
— Нишләп алай дисез, апа?
Күрәсең, үзенең дә бу мәсьәләдә тәгаен генә дәлиле юк иде булса кирәк, ул бераз уйланып торды. Аннары әйтте:
— Сиңа унны бетерергә кирәк, Нәҗимов. Мин синең унны бетереп, урта белем алып чыгуыңны телим.
— Ә минем сезнең кебек укытучы буласым килә!
— Бик әйбәт, булырсың.
— Укымыйчамы?
— Юк, укып. Педагогия институтын тәмамлап.

— Институтка хәтле училищесын тәмамларга кирәк ич әле аның.
— Унны бетергәч тә кереп була анда.
— Юк, минем ише авыл малаена училище да бик җиткән. Башта өч ел урта мәктәптә, аннары дүрт ел институтта укып йөрергә минем мөмкинлегем дә, теләгем дә юк. Менә сез үзегез дә педучилище бетергәнсез ич. Ә шулай да бик әйбәт итеп укытып йөрисез.
— Мин быел обязательно институтка укырга керәм.
— Белмим шул, ирегез җибәрер микән?
— Мин бит читтән торып укырга.
— Менә-менә, дөрес әйтәсез: мин дә башта педучилище тәмамлыйм. Аннары читтән торып институтта укырмын.
— Юк, Нәҗимов. Әшнәктә мин вакытлыча, узган ел без күчеп килгәндә инде укулар башланган, Корноух мәктәбендә сәгатьләр бүленеп беткән булганга гына укытып йөрдем. Быел Корноухта укытачакмын. Синең дә шунда укырга килүеңне телим!
— Нигә кирәк соң, апа, минем анда уку?
— Әйттем бит инде, мин синең ун класс бетерүеңне телим дип! Һәм мин моны синең язмышны кайгыртып, сиңа яхшылык теләгәннән әйтәм.
— Корноухта русча укыйсы бит, Эльмира Хәлиловна. Анда мине тик алтынчы класска гына алачаклар. Ә мин бер елымны югалтырга теләмим! Болай да үземнән ике яшькә кечеләр белән укып йөрим.
— Анысы өчен борчылма, мин сине сигезенче класска алдыртам!
— Тыңларлар микән соң сезнең сүзне?
— Тыңларлар. Мине тыңламасалар, Радик абыегыз аша тыңлатырбыз! Ә синең анда укый алачагыңа минем тамчы да шигем юк. Математика белән физиканы син әйбәт беләсең, аларның формулалары татарча да, русча да — бер үк. Кагыйдәләрен, теоремаларын гына ятларга кирәк булачак. Хәер, ник боларны сөйләп торам соң: хәзер дә әйбәт кенә беләсең бит русчаны.
— Анда сөйләшәсе генә түгел бит. Рус телендә диктантлар, сочинениеләр язасы да була.
— Анысы бар инде барын. Ләкин күңел биреп тотынсаң, аларын да бик тиз үзләштерәсең син аның.
— Юк инде, Эльмира Хәлиловна, алайлар итеп, үзегез дә мәшәкатьләнеп, мине дә мәшәкатьләп интекмәгез. Көн саен уникe километр йөреп уку болай да бик туйдырды. Ният иткәнмен икән, педучилищега барыйм инде. Анда стипендия дә бирәләр икән. Әни дә минем шунда баруымны тели.
Шулай иплəп кенә сөйләшеп барган җиреннән кырт туктапып, ник бу кадәр кире беткән кеше син, ахмак түгелдерсең бит, дигән шикелле итеп, Эльмира Хәлиловна миңа исе китеп карап алды да, чын-чыннан ачуланып:
— Өченче һәм соңгы кабат әйтәм, Нәҗимов: мин сине училищега җибәрмим!— диде.
Инде минем дә йон кабарган иде:
— Ничек инде ул җибәрмисез? Сез бит мине тоткарлый алмыйсыз. Һәм тоткарларга тиеш тә түгелсез!
— Ярый алайса, менә шушы сүзеңне онытма, Нәҗимов! Һәм соңыннан миңа үпкәлисе булма!
Шулай диде дә, бик горур атлап, саубуллашып та тормыйча китеп барды.
Аның ул кыланышына артык исем китмәде. Гадәттәгечә, хатын-кыз кылтаюы гынадыр, иртәгә үк онытыр да элеккечә дустанә мөгамәләдә булыр, миңа үпкәләргә бернинди сәбәбе юк бит аның, дип уйлаган идем.
Ләкин алай булып чыкмады. Шул көннән соң ул миңа карата бөтенләй битарафка әйләнеп, күргәндә дә күрмәмешкә сабышып йөрде. Аннары алгебрадан мине «батырып», көзге имтиханга калдырды.
Ә бит алгебраны мин әйбәт белә идем. Имтихан мәсьәләсен классыбызда беренчеләрдән булып чиштем. Аны ничек чишәргә икәнен белми-

чә утырган иптәшләргә дә язып бирдем. Кулдан-кулга йөртеп, җидесигез кеше шуннан күчереп эшләгәннәр иде. Аларның кайсы «дүрт»ле, кайсы «биш»ле алды. Ә миңа — шул мәсьәләне беренче булып эшләп чыгарган кешегә! — «ике»ле куйганнар.

— Менә күрдеңме инде, энем?— диде миңа Эльмира Хәлиловна, билгеләрен әйтеп, классташларны кайтарып җибәргәннән соң, үземне генә алып калып.— Әйткән идемме мин сиңа, училищега бармыйсың дип!

— Әйтүен әйттегез анысы. Ләкин мин сезне бу кадәр үк каты күңелле булырсыз дип уйламаган идем.

— Белмәсәң, моннан соң белерсең инде менә: хатын-кыз үз дигәнен итәр өчен теләсә нәрсәгә бара ул, егетем!

— Сез күрә торып гаделсезлек эшләдегез, апа. Мин сезнең өстән завуч Кадыйр абыйга керәчәкмен. Мәсьәләне мин дөрес чишкән идем. Тикшерсеннәр яңадан!

— Һии, Нәҗимов, Нәҗимов, юкка мәшәкатьләнеп йөрмә! Мин — Радик абыегыз хатыны. Кем минем өстән тикшеренеп йөрергә батырчылык итсен? Кадыйр абыең үз хәлен үзе белә ул: җиде класс белем белән завуч булып утыра. Үзенә тимәсәләр, миңа, начальник хатынына, кагылырга башы икемени аның?

Шуннан мин сөмсерем коелып кайтып киттем дә үзебезнең колхозда көндез бригадир ярдәмчесе, ягъни кырда эшләүче колхозчыларның кайсы күпме җир сөргәнен, кайсы ничә сотый урак урганын, кайсы ничә йөк көлтә алып кайтканын, кайсы ничә олау тирес чыгарганын исәпләп баручы булып эшли башладым. Ә төнлә болында ат көтәм. Ат көтүен инде майның егермеләреннән, болында үлән борный башлаганнан бирле үк көтә идем. Әлбәттә, болай эшләү миңа җиңел түгел. Аннары килеп, кичен яшьләр-кызлар янына чыгып булмый, ә чыгасы килә, бик килә. Ләкин шулай ике эштә эшләмичә чарам юк. Чөнки әни көзен педучилищега китәргә ниятләвемне белгәч, җәйге каникул вакытында кышын үзеңә ашау белән кием алырга җитәрлек хезмәт көне эшләмәсәң, уку турында уйлама да, улым, Равил әле, бердән, кечкенә, икенчедән, аның үзенең дә быел Әшнәккә йөреп укыйсы бар, дип кистереп әйтеп куйган иде. Шуңа күрә, ничек кенә кыен булса да, түзәргә туры килә иде.

Шул ук вакытта көзен имтихан бирәсе булуы да гел истә, күңелне борчып тора. Эльмира Хәлиловнага ышаныч юк, бик хәтәр катлаулы мәсьәлә биреп куюы да мөмкин имтихан вакытында. Шундый хәл булган тәкъдирдә, мәсьәләне чишә алмыйча оятка калмас өчен, математиканы да караштыргаларга, мәсьәләләрен дә чишәргә туры килә.

Ә шулай да имтихан өчен артык курыкмыйм, тизрәк август җитсен дип түземсезлек белән көтәм.

Егерме тугызынчы августта Эльмира Хәлиловна мәктәпкә мине үзе чакыртып алды.

Тагын берәр төрле хикмәт уйлап чыгармаса ярый инде бу хатын дип, бик нык кына шикләнеп барган идем. Ләкин Эльмира Хәлиловна мине берни дә булмагандай якты йөзе белән каршылады.

— Карале, кара-кара: бер җәй эчендә бөтенләй танымаслык булып үсеп-олыгаеп киткәнсең бит, Нәҗимов!— дип мактап алган булды.

Эльмира Хәлиловна мине үзебезнең 7 «Б» бүлмәсенә алып керде. Ул инде андагы кара тактага мин чишәргә тиешле мәсьәләне язып куйган икән. Мин мәсьәләне үз кәгаземә күчереп алганчы Эльмира Хәлиловна чибәрләнү белән мәшгуль булды.

Ун минут та үтмәгәндер, чишеп бирдем теге мәсьәләне.

— Китми тор, билге куеп, хәзер таныклыгыңны биреп җибәрәм,— дип минем эшне тикшерә башлады. Никадәр эзләп тә, хатасын таба алмагач:

— Почеркың ямьсез, цифрларны аннан-моннан гына язгансың, «дүрт»ле куям мин сиңа,— диде.

— Юк, Эльмира Хәлиловна, «дүрт»ле түгел, «биш»ле куясыз!

— Син нәрсә, минем белән бәхәсләшмәкче буласыңмыни?
— Мин мәсьәләне дөрес чишкәнмен! Миңа сез «биш»ле куярга тиеш.
— Нигә соң сиңа ул «биш»ле?
— Миңа «биш»ле түгел, миңа гаделлек кирәк! Математикадан мин ел буена нибары өч кенә «дүрт»ле алдым, калганнары барысы да «биш»ле иде, үзегез дә беләсез. Гел мактап килдегез бит.
— Анысы шулай. Ләкин эшенең шапшаклыгы өчен билгене бер балл га төшерергә минем хакым бар. Ну, ярый, алайса болай сөйләшәбез: «биш»ле куюын куям, ләкин син укырга Корноухка киләсең!

Бу мәсьәләне дә күптән хәл итеп куйган идем инде: педучилищега китеп булмагач, бер ел вакытны әрәм итмәскә, сигезенче класска Солтан мәктәбенә барырга иде минем план. Корноухка барсам, Эльмира Хәлиловна әллә нинди хикмәтләр уйлап чыгарып, теңкәгә тияр дип курка идем. Яратуын мин аны әле һаман яратам. Ләкин, ни хәл итәсең, үкенечле мәхәббәт бер миңа гына килгән нәрсә түгел, миннән болайраклар башыннан да үткән хәл ул. Яратам дип, бөтенләй үк баш югалтып, кеше ни әйтсә шуны эшләп йөрергә ярамый бит инде егет булган кешегә.

— Алайга киткәч, әйдә куегыз «дүрт». Ләкин мин Корноухка бармыйм!

Эльмира Хәлиловна башта минем имтихан эшенә, аннары җидене тәмамлаганга бирелә торган таныклыкка калын иттереп «дүрт» куйды да, таныклыкны миңа сузып:

— Мә, Нәҗимов. Ә шулай да укырга Корноухка килмичә син бик нык ялгышасың. Мин сиңа чын-чынлап ярдәм итмәкче идем,— диде.

— Сез миңа болай да бик «зур» ярдәм иттегез инде, рәхмәт! Ә башкасын мин үзем карармын. Хушыгыз, апа, бәхетле булыгыз.

Шулай дидем дә класстан чыгып киттем.

## «Әгәр синең белән вәгъдәләшсәк...»

Солтан мәктәбенә сигезенче класска барырга булдым. Мәхмүт баштан ук унны бетерергә ниятләп куйган иде. Аның белән икәү укый башладык.

Солтан — безнең авылга сигез чакрым. Көн саен кайта-килә йөрибез. Көзге пычракларда һәм кышкы бураннарда торып укыйбыз. Мәхмүт — үзләренә туган тиешлерәк Исмәгыйль абыйларда, мин — үземнең Солтан бабайларда.

Солтан бабай да, Солтан әби дә, аларның төпчек кызлары Минсара апа да минем өчен үлеп торалар. Кыш буе авылга кайтмый яшәсәм дә — сүз әйтмәячәкләр. Ләкин дөньяның мәшәкатьләре күп шул аның. Әйтик, авылда әни белән Равил бар бит әле. Мичкә ягарга утын кисәсе, малтуарны карыйсы, ишегалдын себерәсе, тирес түгәсе, кар көрисе, су алып менәсе бар. Биш километрдагы Кече Әшнәккә йөреп бишенчедә укыганлыктан, Равил энем берүзе генә боларны эшли алмый. Әни, гадәттәгечә, фермада. Миннән ике яшькә кечкенә булса да, Равилгә сүзем юк: кулына ни тотса — шуны коеп куя. Итеккә олтан салу, иске чалгыдан пычак ясау, агач көрәк ясау дисеңме — барысын да булдыра. Әле күптән түгел генә өрәңгедән үзенә шундый шәп чаңгы ясаган — кибет чаңгыларың бер якта торсын!

Белмим, ничек шулай һәр нәрсәгә кулы ятып торадыр бу Равилнең. Узган җәй Качкалак авылы кибетенә керосин алырга барган җиреннән бер рус агае чыгарып ташлаган иске велосипед күтәреп кайтты бу. Камералары тишелеп беткән, арткы тәгәрмәч спицләренең яртысы гына калган, руленең бер җәбе сынык, хәтта рамына хәтле кәкрәеп беткән иде. Әни дә, мин дә, нигә юләрләнеп күтәреп кайттың бу тимер ватыкларын, чыгарып ташла тизрәк, кеше көлдереп йөрмә, дигән идек, исе

китмәде. Алып кайтканына ике ай дигәндә велосипедны менә дигән итеп төзәтеп, мәктәпкә шуның белән йөри башлады...

Шундый катлаулы нәрсәләрне эшләргә һәвәс булса да, утын кисү, терлек асларын җыештыру кебек эшләрне бик үк өнәп бетерми ул: «Аларын, әнә, олы кеше — абый эшләсен!»— дип кенә җибәрә... Аннары, дөресен генә әйткәндә, ике көн күрми торсам да, әни белән Равилне сагына башлыйм. Шуңа күрә, чамадан тыш каты буран булмаганда, Мәхмүт кайтмый калган чакларда да авылга кайтып йөрим.

Авылыбыз кечкенә (нибары егерме җиде генә йорт) булганга, бездә клуб-фәлән юк. Җыелган акчасы юл расхутын акламый дип, кино да алып килмиләр. Елына бер-ике мәртәбә (сайлау булса, сайлау көнендә, я авыл советы күләмендә үткәрелә торган берәр тантана уңае белән) халыкны атларга төяп, Әшнәккә алып төшеп, бушлай кино күрсәтәләр дә — вәссәлам. Дөрес, колхозның идарә бинасы бар барын. Һәр көнне төнге унберләргә, уникеләргә тикле ачык була. Кем кереп утырса да, сүз әйтүче юк. Председатель Мөбин абый белән хисапчы Рәүф абый үзләре дә көн саен кичке сәгать уннарга кадәр утыралар. Чөнки идарәдә радиоалгыч бар. Телисең икән — Казан тапшыруларын, телисең икән — Мәскәүне тыңларга була. Зур дөнья белән тик шул радио аша гына бәйләнеш тота безнең авыл. Шуңа ир-атлар идарәгә җыела. Татарча тапшырулар тәмамлангач, семьялы агайлар:

— Ярый, егетләр, безгә кайта башларга да вакыттыр. Анда безне сандугач оялары көтәдер...— диешеп, өйләренә таралышалар.

Ә яшь-җилкенчәк егетләр нишли, алар кая бара, дигән сорау туарга мөмкин. Бер дә борчылмагыз, аларның да барыр урыны бар һәм клублы зур авыл егетләренекеннән бер дә ким түгел.

Кышкы озын кичләрдә безнең авыл кызлары көн саен диярлек аулак өй оештыралар. Чиратлап эшләнә бу: бүген бер кызның өендә, икенче көнне — икенчесенекендә. Һәм бу нәрсә бездә шул кадәр гадәти хәлгә әверелгән, аулак өй буласы кызларның әти-әниләре, әби-бабайлары һәм балачагалары — барысы да ул кичтә күршеләренә кереп яисә туган-тумачаларына барып, яшьләр таралышканчы шунда сабыр гына көтеп утыралар.

Ә яшьләр рәхәтләнә аулак өйдә: йөзек салыш, күз бәйләп качышлы уйнау, арка сугыш, тагын әллә нинди уеннар уйнап, тәмам кайнарланып бетәләр.

Инде алтынчы класстан бирле ул аулак өйләргә мин дә йөрим. Үзем бармасам — килеп алалар. Чөнки мин — гармунчы. Дөрес, гармун уйный белүче егетләр авылда миннән башка да дүртәү. Шуларның икесе миңа караганда бик күпкә яхшы уйный. Бигрәк тә Галәү абый. Ләкин аларның үз гармуннары юк. Ә минем теге «көмеш» телле гармун сиптерә генә! Шуңа аулак өйгә дәшәләр мине. Баштарак, әле борынга кызлар исе кермәгән чакта, мин ул аулак өйләргә үземнән олы кызлар һәм егетләр сүзен тыңлап, гармун хуҗасы буларак кына бара идем. Гармунны олырак егетләр уйный. Ә үзем аулак өйнең я мич башына, я кече яктагы сәкеләренә менеп ятам да яшьләр таралганчы рәхәтләнеп шунда йоклыйм. Аннары берәр олырак егет мине өйгә озатып куя торган иде.

Ләкин узган елгы Сабан туеннан соң хәлләр үзгәрде. Кичке уеннарга чыгарга, аулак өйләргә барырга хәзер мин үзем атлыгып торам. Көн саен диярлек Солтаннан авылга кайтып йөрүем дә — аулак өйгә бару өчен. Чөнки мин Халисә исемле кызны ярата башлаган идем.

Халисә — Кече Әшнәк кызы. Алсу түгәрәк битле, тип-тигез ап-ак тешле, юка иренле, саргылт сирәк кашлы, сизелер-сизелмәс кенә сипкелле бәләкәй борынлы, йомры гәүдәле, сөйкемле генә бер кыз ул. Беренче тапкыр мин аны узган ел үзебезнең авыл Сабан туенда күрдем. Кашаф абыйларның туганнары икән, шуларга килгән иде. Күрү белән күңелем төште аңа. Безнең авыл кызлары-егетләре белән түгәрәк уен уйнаган чагында гармун уйнап биеттем дә үзен. Шәп бии икән, чукынмыш! Безнең авыл кызларының барысыннан да җиңелрәк, хислерәк һәм дәртлерәк итеп биеде. Биеп бетергәч, янымнан үтеп барышлый:

— Рәхмәт, егет, әйбәт уйныйсың икән!— дип мактап та китте хәтта. Шулай булгач, кем буласыз соң, кайдан килдегез, дигән булып, соңыннан сүз катып карарга да җае бар иде. Юк, сүз әйтү түгел, янына барырга да йөрәгем җитмәде.

Бер генә кич кунды да ул кыз үзенең Әшнәгенә кайтып китте. Китүен китте, ләкин аның бөтен килеш-килбәте, йөреше-торышы, бигрәк тә сыек зәңгәр күзләре күңелемә кереп калган һәм гел күз алдымда тора иде.

Аннары мин, шул кызны күрер өчен, кичләрен Әшнәккә төшкәләп йөри башладым. Башта — җәяүләп, Равил теге велосипедын караштыргач — велосипед белән. Велосипедны безгә туган тиешле, минем белән бер елгы Рафикларда калдырам да аның белән икәүләп клубка китәбез. Барып керү белән яшьләр арасыннан Халисәне эзли башлыйм. Ул клубта булса — миннән дә бәхетле кеше юк! Аның иптәш кызлары белән сөйләшкәнен, көлгәнен рәхәтләнеп күзәтеп торам. Көлүен минем өчен генә көлә, сүзләрен минем өчен генә сөйли шикелле тоела.

Биюле уенда берәр егет белән бии башласа, теге егеттән көнләшеп, ярылыр чиккә җитәм. Ә үзем бии белмим. Белсәм дә, яшь кенә башымнан чит авылда биеп йөрү килешмәс иде.

Кичке уеннар беткәннән соң Халисәне Әшнәкнең Габдулла исемле таза гына бер егете озата кайта. Шул Габдулланы чәйнәп өзәрлек булам. Ләкин берни эшли алмыйм. Чөнки Габдулла миңа караганда өч яшькә олы, буйга бер башка озын, төп күк таза егет. Әмма хикмәт анда гына да түгел. Рафик дустымның әйтүенә караганда, алар инде Халисә белән елдан артык йөриләр икән. Һәм яратышып йөриләр икән. Бигрәк тә Габдулла өзгәләнеп, күзенә генә карап тора икән Халисәнең. Шулай булгач, миңа — чит авыл егетенә, шуның өстенә тагын укучы кешегә, алар арасына ничек барып кермәк кирәк? Кереп тә ни файда? Габдулласы әйбәтләп ишеп кайтарып җибәрсә...

Аннары килеп, Халисә үзе дә миннән ике яшькә олы. Егет кеше үзеннән олырак кыз белән түгел, үз яшьтәше яисә бер-ике яшькә кечерәк кыз белән йөрергә тиеш икәнен беләм. Ләкин ни эшләтәсең аны: йөрәк акылны тыңламый бит. Халисә, бары тик Халисә генә, ди. Шуннан башка беркемне белми дә, күрми дә, теләми дә.

Әмма мин яратуымны Халисәнең үзенә сиздергәнем юк. Сиздерсәм, ахмакланып йөрмә, малай, күрәсең бит, минем сөйгән егетем бар, дип бөтен өметемне чәлпәрәмә китерүеннән куркам. Шуңа үзенә әйтмичә генә сөеп йөрим. Күңелемнән аның белән үзем теләгәнчә сөйләшәм. Ул беркайчан да чытлыкланмый. Мин кая алып барсам — шунда бара, ни әйтсәм — шуңа риза. Ә үзе белән чынлап торып сөйләшә башласаң, әллә нинди күңелсезлекләр булып бетәр иде...

Шулай да хыялда гына түгел, чынлап торып сөйләшеп карыйсы килә бер, шайтан алгырысы! Белдерәсе килә күңелдәге саф һәм пакь хисләрне. Ай-һай, читен икән ул гашыйк кешенең хәлләре! Кирәк бит шулай булырга, ә: башта Эльмира Хәлиловнага мөкиббән китеп гашыйк булып йөрдем, хәзер менә Халисәгә. Йөргән егете булган һәм үземнән ике яшькә олы кыздан башка кызлар беткәнме инде миңа дөнья йөзендә? Бардыр, әлбәттә. Аннан чибәррәкләре һәм акыллыраклары да бардыр. Әмма мин аларның берсен дә белмим дә, күрмим дә. Хәзер минем өчен дөньяда иң чибәр, иң акыллы кыз — Халисә!

Ә Халисә, аның өчен йөрәк майларым сыздыруымны бөтенләй белмичә-сизмичә, рәхәтләнеп Габдулла белән йөри бирә.

Ләкин ул бик нык ялгыша. Габдулла белән ул бәхетле була алмаячак. Чөнки Габдулла аны беркайчан да мин яраткан шикелле көчле ярату белән ярата алмаячак. Габдулла аңа беркайчан да минем шикелле игътибарлы-ярдәмле булмаячак. Киресенчә, ул аны кимсетеп, кысып торачак. Әнә, әле хәзердән үк Халисә янында ничек кукраеп, алланың кашка тәкәсе кебек тора. Ә Халисә, бичара, шуны аңламый. Тегенең янында гел елмаеп.

авызына гына карап тора. Их, ничек кенә итеп аңлатырга аңа бу ялгышын? Ичмаса шигырь дә яза белмим. Яза белсәм, үзәкләрен өздереплек итеп, барысын да аңлатып шигырь язып бирер идем дә шуннан соң, бәлки, акылына килер иде...

Җәй дә үтте, көз дә узды, кыш та җитте. Ләкин минем әле Халисә белән сөйләшеп карый алганым юк. Солтанда укыгач, Әшнәккә дә гел барып йөреп булмый. Шимбә яки якшәмбе көннәрдә барып кайткалаудан ни файда? Габдулла козгын шикелле карап кына тора Халисәне: сөйләшергә бер дә җай калдырмый...

Инде хезмәткә барыр яше җиткән, көзен армиягә алырлар шул Габдулланы дип өметләнеп йөргән идем. Анысы да булмады: колакка катырак дип, ак билет биреп кайтарганнар үзенә. Габдулла үзе моны ничек кабул иткәндер, анысын әйтә алмыйм. Ләкин үземә ак билет биреп кайтарсалар, минем өчен аннан да зур бәхетсезлек булмас иде кебек.

Әйе, хәзер инде Халисәгә әллә ни зур исәп тотып булмый иде. Ләкин һич югы бер тапкыр гына булса да сөйләшеп карыйсы килә иде шул кыз белән. Кышкы бураннарда көн саен диярлек авылга кайтып йөрүем дә шуның өчен. Халисә безнең авылга туганнарына килгән булыр да шунда күреп сөйләшермен дип өметләнәм.

Ниһаять, без очраштык. Мәктәптән кайтып, капка төбендә чаңгыларны сала башлаган идем, Зәки абый малае Габделгазиз килде минем янга. Миннән бер яшькә олы ул. Бик ярдәмчел, иплe егет. Әмма укырга һәвәс түгел. Артык тырышмый да. Дүртне бетергәч тә бүтән укырга теләмәде, атлы эшне сайлады. Алтышар потлы капчыкларны уйнатып кына йөртә, кая кушсалар — шунда бара, тик атлы эш кенә булсын аңа. Ат дигәндә — җаны фида. «Чулпан» исемле атны җигеп йөри һәм аны шул тикле ярата, ерак юлга чыкканда үзе ашарга дип алган икмәгенә хәтле шуңа ашата. Өйләрендәге ашлы сулар, бәрәңге кабыклары да «Чулпан»га китеп бара. Үзеннән башка кешегә «Чулпан»ын җиктерми дә хәтта. Әгәр председатель Мөбин абый «Чулпан»ны берәрсенә тегермәнгә яки утын алып кайтырга җигеп торырга кушса, бернинди хезмәт көне алмыйча, Габделгазиз үзе дә хуҗага ияреп бара. «Чулпан»га камыт суктырмагайлары, кирәгеннән артык төяп интектермәгәйләре дип курка. Чит авылдан кунак аласы яки үзләре кунакка барасы булганда авыл халкы әлеге шул Габделгазизнең «Чулпан»ы белән барырга тырыша. Чөнки аның йөгәншлеялары җиз тәңкәләр белән бизәлгән. Ул тәңкәләрне Габделгазиз көн аралаш көл белән чистартып, алтындай ялтыратып тота. Дугасы гади карама дуга түгел, дүрт кырлы һәм дүрт кыры дүрт төрле итеп бизәкләп эшләнгән борынгы байлар дугасы. Хәтта чанасының тәртә-урчәләренә тикле елкылдап тора торган кара буяуга буялган. «Запорожец» машиналары арасында яңа «Волга» машинасы ничек аерылып торса, бүтән кешеләрнең сбруй-чаналары арасында Габделгазизнеке дә әллә кайдан аерылып, күңелне тартып тора. Сабан туена барасы булганда авыл кызлары Габделгазиз атына утырып барыр өчен берәр ай алдан аңа ярарга тырышып, куштанланып йөриләр.

Шундый тырыш егет ул Габделгазиз. Тик миңа бик үк ошап бетми торган бер ягы бар: аз сөйләшә. Һәр сүзен келәшчә белән алгандай тартып кына алырга туры килә. Менә хәзер дә, яныма килеп туктады да телен йоткан кешедәй, карап тик тора. Ә без инде өч көн күрешмәгән кешеләр, һич, югы, исәнме, Вакыйф, дип кенә булса да әйтергә ярый торгандыр. Җиде яшьлек юлдан кайтса, җитмеш яшьлек хәл белергә керер, дигән картлар сүзе аңа, әйтерсең, бөтенләй кагылмый. Ярар, ул дәшми дип, мин дә сүз әйтмичә кереп китә алмыйм бит инде.

— Нихәл, Габделгазиз.
— Ару гына болай.
— Авылданиләр бар?
— Әллә нәрсә юк шикелле болай.
— Бүген кайда эшләдең?

— Фермага салам ташуда.
— Кая барышың иде әле?
— Болай гына. Сине күргәч, хәлеңне белергә дип кенә чыгу иде.
— Рәхмәт инде алай булгач. Ярый, мин өйгә кереп карыйм әле. Әни белән Равил көтә торганнардыр анда.
— Ыы шул. Карале, Вакыйф малай, бүген кич урамга чыгасыңдыр бит болай?
Халисәгә гашыйк булганнан бирле, авылда чагымда кич чыкмый калганым юк. Моның шулай икәнен Габделгазиз үзе дә белә иде. Аның болай соравы миңа сәер тоелып, сагайтып җибәрде. Өзеп кенә җавап бирмәскә булдым.
— Әйтә алмыйм шул әле, малай.
— Бик арып кайттыңмыни?
— Аруын әллә ни армадым да...
— Чык инде, малай Вакыйф. Гармуныңны да алып чык.
— Нәрсә булды сиңа, Габделгазиз? Моңарчы гармунга да, җырбиюгә дә бер дә шаккатмый торган идең.
— Мужыт шулай булгандыр, ну хәзер алай түгел. Алып чык инде, малай, яме?
— Нигә кирәк икәнен әйтсәң, алып чыгам, әйтмәсәң — юк!
Ул шикләнеп як-ягына каранып алды. Аннары яныма ук килеп, пышылдап кына:
— Әйтсәм, кешегә сөйләмәссеңме соң?— диде.
— Син нәрсә, хатын-кыз дип белдеңме әллә мине?
— Бер бик шәп кунак кыз килгән анда. Шуны сөйләштереп карарга исәп.
— Ә гармунсыз гына сөйләштереп булмыймы?
— Булырые булуын болай. Мин аның биегәнен дә күреп карыйсым килә малай.
— Оһо, авызын ачтырып, тешләрен дә санап карыйсың килмиме тагын?
— Я инде, Вакыйф малай, көлкегә алма инде. Апчыгасыңмы гармуныңны?
— Алай бик кирәк булгач, алып чыкмый булмас инде. Ләкин алдан ук әйтеп куям: кунак кыз миңа да ошаса, таяк тотышабыз. Кем өскә чыкса — кызны шул озата.
— Юк, малай Вакыйф, арага төшмә инде син. Мин ул кызны ике көн озаттым инде.
— Кит аннан!— дидем мин, исем китеп. Чөнки Габделгазизнең моңарчы беркайчан кызлар дип исе киткәнен күргәнем юк иде әле.— Ничек соң, бик кыргый түгелме? Кулга килер сыман күренәме?
— Катырак тора шул әле болай. Бераз йомшарды инде йомшаруын. Ну бөтенләй ук күндереп булмады әле болай.
— Ә син әйбәтләбрәк сөйләш. Тәмле телеңне җәлләмә! — дидем мин, тәҗрибәле кешедәй кылынып. Ә үземнең гомеремдә бер тапкыр кыз озатып, кыз күндереп караганым юк бит әле.
— Кулдан килгәнчә тырышкан булам да болай. Телгә осталык бик әллә ни түгел шул, малай. Алайса гармуныңны алып чыгасың инде, җәме. Бүген аулак өй — Мәгышияләрдә.
Ул куанып китеп барды. Мин кичне түземсезләнеп көтеп алдым. Габделгазизгә генә түгел, минем өчен дә ниндидер зур бер яңалык булыр шикелле иде. Күңелем дөрес сизенгән икән. Капкабыздан чыккач, һәйбәтләп авыл көен сузып җибәрим әле дип гармун каешын иңемә элә генә башлаган идем, чырык-чырык көлешеп, безнең турыдан үтеп баручы ике кыз күренде. Берсен шундук танып алдым: председатель Мөбин абый кызы Зәкия иде.
— Нихәл, малай Вакыйф, кайттыңмы?— диде ул, туганнарча якын итеп.— Хәлләр изге. Тик менә кызлар миннән бизде.
— Бизсәләр дә гаҗәп түгел: укудан кайтып кермисең бит! Ичмаса бүген аулак өйгә барасыңмы?

— Алып барсагыз, барырмын дигән идем.
— Алайса ни карап торасың? Әйдә, киттек!
— Ә син кем белән әле анда?
— Танымыйсың син аны, кунак кыз ул. Кашаф абыйларга утырмага килгән.
Йөрәгем дерт итеп китте:
— Халисәме әллә?
— Әйе. Син аны каян беләсең?
Көтелмәгән куану-каушаудан аяк буыннарыма хәтле хәлсезләнеп калды. Шулай да җавабын таптым:
— Без белмәгән аз булыр, Бохарадагы таз булыр!
Кызлар икесе дә көлеп куйды. Шунда көлүеннән танып алдым: кунак кыз дигәне, чыннан да, Халисә иде.
Солтаннан кайтканда бүген гел шушы Халисә күз алдымда булды. Әгәр алай-болай үзен очрата калсам, сөйләшеп сүзем бетмәс, сандугачлар булып сайрармын шикелле иде. Ә хәзер, ул нибары ун-унбиш метрда гына басып торганда һәм аның янына тизрәк барып сүз кушар чакта, коелдым да төштем. Ярый әле Зәкия коткарды:
— Әйдә инде, күтәреп аппарганны көтәсеңмени?
Юк, барыбер яннарына барырга кыюлыгым җитмәде:
— Сез бара торыгыз. Мин үз җаем белән килермен,— дидем дә, күңелемдәге хисләрне гармун теле белән әйтеп бирмәкче булып, «Шомыртым»ны сыздырып җибәрдем...
Халисәнең күңеленә барып житә алгандырмы минем ул хисләр, юктырмы — әйтә алмыйм. Ләкин шунысын сиздем: мин аулак өйгә килеп кергәч, кызлар белән күрешкәндә ул миңа якын итеп, елмаеп кул бирде. Аның кулы, әлбәттә, безнең авыл кызларыныкыннан бик күпкә җылырак та, йомшаграк та иде.
Бармакларым талса талды, ул көнне кичнең кич буена гармунымны бүтән беркемгә бирмәдем: аларның миннән яхшырак уйнаганнарын күрсәтеп, Халисә алдында дәрәҗәне төшерәсе килмәде.
Ләкин болай эшләүнең уңайсыз ягы да бар иде минем өчен. Гел гармун тотып утыргач, кызлар-егетләр бергәләп уйный торган күмәк уеннарда катнашып та, «кәҗә ябарга» яки «йолдыз санарга» чыгып та булмады. Хәер, мин Халисәне читтән карап утыру белән дә чиксез бәхетле идем...
Ә Габделгазиз читтән генә карап утырмады. «Җәзалы уен» уйнаганда Халисә белән бер тапкыр «сандугач туйдырды» (бер бөртек шырпының яртысын, күкертсез ягын сындырып алып, шуның бер башын егет үзе каба, ә икенче башын кыз каба һәм егеттән тартып алырга тырышырга тиеш була). Бер тапкыр, шактый озак торып, «кәҗә ябып»[1] керделәр. Халисә аңа үптергәндер үк дип әйтә алмыйм, әмма Габделгазиз омтылыш ясаган булса кирәк: килеп кергәндә кызның ике бите мәрҗән шикелле кызарган, Габделгазизнең хәтта маңгаена тир бәреп чыккан иде.
Юк, миңа болай авыз ачып торып булмас, ни дә булса берәр нәрсә эшләп карарга кирәк иде. Уйладым-уйладым да, гармунны култыкка кыстырган килеш кенә Габделгазизне өйалдына алып чыктым.
— Шушымы инде кунак кыз дигәнең?
— Шушы инде болай.
— Ну ничек, күндерә алдыңмы соң?
— Бөтенләй үк түгел әле болай.
— Ә син беләсеңме соң мин инде аны җәйдән бирле күзләп йөргәнне.
— Сизмәдем үзе болай.
— Сизмәсәң, сиз инде менә: бүген мин озатам аны!
— Ничек инде озатасың? Ә мин? Мин пачти күндердем бит инде аны!
— «Пачти» — булды дигән сүз түгел әле ул.

[1] Бу «җәза»га дучар булган егет үзе теләгән кызны өйалдына алып чыга, кызга әйтергә теләгән сүзләрен әйтеп булдыра алса, һәйбәтләп бер үбеп керә.

— Юк инде, малай Вакыйф, син безнең арага кермә, дус булсаң Әйдә, җегетләрчә сөйләшик: бүген дә мин озатып карыйм әле үзен болай.

— Шуннан ни була ди?

— Ни булсын? Әгәр күндерә алсам — миңа, күндерә алмасам — син сөйләшеп карарсың аннары.

Аның бу тәкъдиме, чыннан да, егетләрчә иде. Яхшылабрак уйлаганда, хаклык күбрәк аның ягында. Ләкин бит мондый эштә хаклык белән генә бара башласаң, гомер буе кыз сөя алмый калуың мөмкин! Халисә иртәгә авылларына кайтып китмәс дип кем әйтә ала? Ә анда аны Габдулла көтеп тора. Димәк, мәсьәләне ничек тә бүген хәл итәргә кирәк.

— Ярар, синеңчә булыр инде алайса!— дидем Габделгазизгә. Ә үзем күңелдән аңа каршы хәйләкәр план кордым.— Үчти, дуслык хакына гына юл куям! Бар, кер дә хәзер, Зәкияне чыгар әле минем янга. Йомыш бар иде дип әйтә, диген.

Зәкия шундук килеп чыкты:

— Нәрсә, Вакыйф, үз туганыңа күңелең төшмәгәндер ич?

— Ярар, Зәкия, шаяруны куеп торыйк. Сиңа бер зур үтенеч бар иде, малай.

— Нәрсә, кунак кызы ошадымы әллә?

— Шулайрак иде шул.

— Шуннан?

— Аны Габделгазиз озатып йөри икән.

— Беләм. Ә мин ни эшләргә тиеш инде?

— Синме?.. Әйт әле шул кызга, Зәкия: Вакыйфның сиңа күзе төшкән икән, биш кенә минут булса да сөйләшәсем килә дип әйтә диген.

— Ярар, әйтермен, ә аяк ялына нәрсә бирәсең?

— Туктале, куеп тор әле шул шаяруларыңны, Зәкия! Башта син мине тыңлап бетер: әгәр мин әйткәнгә риза булса, Габделгазизне я бөтенләй озаттырмасын, яки Кашаф абыйларның капка төбенә җиткәч тизрәк кайтарып җибәрсен дә, ишегалларына кереп, мине шунда көтеп торсын...

Болай кистереп кую — артык зур тәвәккәллек иде минем тарафтан. Мәсьәләне чишә башлаганчы ук бозып ташларга да бик мөмкин иде. Ләкин ул чакта минем бүтән чарам юк: һаман шушылай билгесезлектә йөргәнче, ичмаса кызның миңа ничегрәк караганын ачыкларга кирәк иде.

Өйалдыннан кердем дә, «Кая Вакыйф? Кая гармун?» дип инде юксына да башлаган кызларны тагын җырлата башладым. Ә күңелдә һаман Халисә. Күзем — гел шул кызда һәм Зәкиядә. Кайчан әйтер икән Халисәгә? Тегесе ничек карар икән?..

Ләкин Зәкиянең әйтергә атлыгып торганы бер дә сизелми. Башка кызларга кушылып, рәхәтләнеп җырлый бирә. Аптырагач, ник әйтмисең инде дигәнне аңлатып, Зәкиягә ым кактым. Әллә онытып торган булган: дерт итеп китте дә, хәзер әйтәм дигәнне белдереп, каш сикертеп куйды. Һәм күмәк җырның көчәйгән җирендә кинәт кенә туктап, үзе белән рәттән утырган Халисәнең колагына үрелде. Әлбәттә, минем гозерне әйтүе иде. Җырыннан бүленеп, Халисә тыңлый башлады. Җиңелчә генә кызарды, елмаюлы йөзе җитдиләнеп китте. Аннары ялт итеп кенә минем якка күз ташлап алды. Ләкин Зәкия әйткән сүзләргә җавап бирмәде, ярар, бимазалама, шушының өчен кешене бүлдереп торалармыни дигәндәй, бүтәннәргә кушылып, җырын дәвам итте.

Туган — туган инде: Зәкия тегенең бер җырны җырлап бетергәнен генә көтеп торды да, тагын колагына үрелеп, бу юлы шактый җитди итеп, нидер әйтте. Тегесе, сиңнән котылып булмас инде, дигән шикеллерәк елмайды һәм бер сүз белән генә җавап бирде дә, якын итеп, Зәкиянең иңенә сыенып куйды. Аның бу кыланышын ике төрле: «Ярар, синең сүзеңне тыңлап кына ризалык бирәм инде»,— дип тә, «Син бит минем иптәш кызым, нигә шушындый тузга язмаган сүзләр сөйләп торасың, минем аны күрәсем килми»,— дип тә аңларга була иде.

Мин шулай әүле-тәүле булып торган арада Халисәгә сиздермичә генә Зәкия миңа каш сикертеп һәм баш бармагын күрсәтеп, «була!» дигәнне аңлатты.

Ниһаять, эчемә җан кереп китте. Ул кичтә болай да бик тырышып уйнаган гармунымны тагын да моңлырак, тагын да тәэсирлерәк итеп уйный башладым.

Тик Габделгазиз белән ике арабызда тартыш килеп чыкмас микән дип борчыла идем. Ни әйтсәң дә, бала чактан бергә уйнап үскән дус кеше белән низаглашу әйбәт түгел бит инде.

Ләкин мәсьәлә мин уйлаганга караганда күпкә ансат һәм акыллы хәл ителде. Күрәсең, Зәкиянең башына килгән уй булгандыр һәм ул Халисә белән алдан ук килешеп куйгандыр: Габделгазиз, Халисә, Зәкия үзе һәм мин дүртәүләп аулак өйдән кайтырга чыккач, Зәкия мине арткарак алып калды да:

— Халисәне мин, бездә генә кунарсың дип, үзебезгә алып кереп киткән булам. Ул сине ишегалдында көтеп торыр. Габделгазиз кайтып киткәч шунда керерсең, яме! — диде.

Зәкияләрнең өе урамның безгә каршы ягында гына. Шунда килеп җиткәч кызлар кинәт кенә борылдылар да:

— Ярый, егетләр, тыныч йокы сезгә! — дип Зәкияләр капкасыннан кереп киттеләр. Ни булганын сизми дә калды Габделгазиз. Ул аңына килеп:

— Халисә, Зәкия, туктап торыгыз әле! — дип кызлар артыннан ыргылганда, тегеләр капканы эчтән бикләп тә өлгергәннәр иде.

— Бер генә сүз әйтәсем барые үзе болай, чык әле, Халисә! — дип Габделгазиз сырпаланып караса да, файдасы булмады. Халисә аңа:

— Сөйләшәсен сөйләшеп бетердек бит инде. Көтмә, егет, барыбер чыкмыйм!— дигәч, аңа өстәп Зәкия дә:

— Әйе, чынлап әйтә, бездә куна ул бүген! — дигәч, ашыга-кабалана папирос кабызып капты да, үзалдына нидер мыгырдана-мыгырдана, өйләренә кайтып китте.

Габделгазиз алай-болай шикләнмәсен дип, ул әле Зәкияләр турында аптырап торган чакта ук мин, өйгә кереп киткән атлы булып, капка ярыгыннан карап тора идем.

Дүрт-биш минуттан әкрен генә капка төбенә чыктым: Габделгазиз инде күренми, өйләренә кереп киткән иде. «Бу кызлар шаяртып кына чакырмадылар микән? Халисә мине көтеп тора микән? Көтеп торса, ничек итеп сүз башларга икән? Сөйләшә башласам, Зәкия безне тыңлап тормас микән?»— дип, эшне нидән башларга белмичә торган арада тегеләрнең капкасы ачылды. Аннан бер баш күренде. «Әһә, көтеп тора икән, кереп китмәсен тагы»,— дип, секунд эчендә Зәкияләр капка төбенә барып җиттем һәм, пышылдап кына:

— Халисә, син андамы?

Ул да шулай әкрен генә җавап бирде:

— Монда.

— Чык әле?

— Ник үзең кермисең?

— Анда караңгы бит.

— Курыкма, тотып ашамам!

— Мин аннан түгел. Сине күреп торасы килә!

— Ә Габделгазиз әйләнеп килсә?

Аның башына шул акыллы фикер килгәнгә исем китте:

— Әәә, анысы бар икән шул!

Капканы шыгырдатмаска тырышып, сак кына эчкә кердем. Ишегалларының төз әвеслекләре тын да кермәслек итеп капланган, дөм караңгы иде.

— Кайда син, Халисә?

Кулларымны канат итеп җәеп бара башлаган идем, бер кулым кинәт аның күкрәгенә орынды. Ни эшләвемне үзем дә белештермичә, мин аны кысып кочаклап алдым. Я рабби, ул аның йомшак кына итеп сулу алулары, ул аннан бөркелеп торган хуш исләр! Ә кайнарлыгы хәтта мамык шәле аша да бәреп чыккан һәм магнит шикелле үзенә тартып тора иде!..

Икебез дә сүзсез калган идек. Ләкин гел шушылай мокыт булып торып булмый, нидер әйтергә кирәк. Тик ни әйтергә икәнен үзем дә белмим.

— Халисә,— дидем аптырагач,— ник бер сүз дә эндәшмисең?

— Үзең дә берни әйтмисең бит әле.

— Әйтсәм, ачуланмассыңмы соң?

— Белмим шул, нәрсә әйтерсең бит.

— Әйдә, танышабыз, Халисә?

Ул пырхылдап көлеп җибәрде:

— Соң без бүген аулак өйгә барышлый ук таныштык ич инде.

— Мин андый танышу турында әйтмим, Халисә! Дуслашып йөри башлыйк димәкче идем мин. Мин сине инде узган Сабан туеннан бирле яратып йөрим, Халисә!

— Беләм, Вакыйф. Ләкин минем йөргән егетем бар шул.

— Габдулланы әйтәсеңме?

— Әйе.

— Мин сине аңа караганда мең мәртәбә күбрәк яратам.

— Ул бит инде минем арттан ике елга якын йөри.

— Йөрсә соң! Дүртәр-бишәр ел йөреп тә ташлашкан кешеләр бар. Гел бер кеше белән генә йөрергә димәгән.

— Син бит укуда. Атнага бер-ике генә кайтып йөрисең.

— Әгәр синең белән вәгъдәләшсәк, көн дә кайтып йөрер идем.

— Хәзер генә шулай дисең син аны. Аннары фикерең үзгәрәчәк. Үзең шикелле укыган кызларга күзең төшәчәк.

— Кемнең, минемме? Һәй, әйтер идем инде!

— Нәрсә әйтер идең?

— Телисеңме, укуны бөтенләй ташлыйм!

Уен өчен генә әйтелгән сүз түгел иде бу.

Әгәр Халисә ташла дисә, эһ тә итмичә ташларга әзер идем укуны. Әмма Халисә үзен генә ярата торган вак җанлы кеше түгел, бүтәннәр турында да адәмчә уйлый белә торган рәхимле кыз булып чыкты.

— Кирәкми, Вакыйф, нигә минем өчен уку ташлап йөрергә, укы! Син миңа нәкъ менә шул укыганга күрә ошыйсыңдыр да әле,— дип миңа сыена төште. Ничектер үзеннән-үзе шулай килеп чыкты, безнең иреннәребез очрашып, бер-беренә тартылды һәм бик озак аерыла алмыйча тордылар...

Бу минем сөйгән кыз белән үз гомеремдә беренче үбешүем иде...

Халисә минем каникул беткәнче безнең авылда торып китте.

Без аның белән көн дә очрашып йөрдек.

Ул киткәндә мәңге ташлашмаска сүз куешкан идек. Каникулдан соң көннәр бик ямьсезләнеп китте дә, мин дүрт көн Солтаннан кайта алмадым.

Бишенче көнне кайтып, өйгә сумканы кертеп калдырдым да энигә: «Мәктәп директоры бик ашыгыч йомыш кушып җибәрде»,— дип алдашып, Әшнәккә киттем.

Ләкин Халисәне күреп кенә калдым.

Авыл җирендә синең кем белән кайчан һәм ни сөйләшкәнеңне генә түгел, нәрсә уйлаганыңа хәтле белеп торалар. Минем Халисәне озатып йөргәнне дә Габдуллага ишеттергәннәр икән. Рафик дустым белән Әшнәк клубына барып биш минут утырырга өлгермәдем, Габдулла мине клуб артына алып чыкты да, уңачемнән каптырып алып:

— Исемең ничек әле синең, энем? — диде.

— Шуны сорар өчен клуб артына чыгып тору кирәк идеме икән? — дидем, берни дә аңламаганга сабышып.

— Анысын мин үзем беләм,— диде ул, үңәчне тагын да ныграк кыса төшеп: — Син сорауга җавап бир!

— Синең белергә теләгәнең бу түгел бит! Нигә читләтеп маташасың?

Ул мине селкеп куйды:

— Нәрсә, Халисә янына дип килдеңме?

— Әйе.

Бу җавапны көтмәгән иде булса кирәк: ни әйтергә белмичә, телсез калып торды. Аннары каптырып тоткан килеш үзенә таба тартып һәм бүлдыра алса күземә керердәй булып:

— Ничек, ничек? Яле, кабатла әйткән сүзеңне?— диде.

— Кат-кат сөйләргә мин сиңа хатын-кыз түгел. Әйдә, сүзең булса, әйт тә, керик!

— Кая керик? Ничек инде ул «керик»! Юк, егет, беркая да кермисең син хәзер. Менә болай итәбез дә!..— дип ул минем яңакка китереп сукты.— Хәзер син беркая да тукталмыйча, үзегезнең Зәңгәрлегезгә кайтып китәсең. И бүтән беркайчан да — әйбәтләп ишетеп кал: беркайчан да! — Халисә янына якын килмисең! Әгәр килсәң — миңа үпкәлисе булма! Мин синнән кәтлит ясыйм ул чакта. Ишеттеңме?

Ишетүен ишеттем, ләкин җавап бирмәдем. Чөнки авыз-борынымнан кан киткән, күз алдымда очкыннар уйнаклый иде.

Шушы хәлдә клубка керүдән мәгънә юк, Халисә алдында адәм хурлыгына калу гына булыр иде.

Салкын кар куеп торып,борын канавын туктаттым да, шул Габдулланы селкеп салырлык көчем булмаганга уфтанып, бөтен дөньясын каргап, хәтта клубта калган Рафикка да әйтеп тормыйча, үзебезнең авылга кайтып киттем.

Ул кичне дөньяда миннән дә бәхетсез кеше булды микән?

Халисә белән ул кичне Габдулла нилөр сөйләшкәндер, араларында нилөр булгандыр — белмим. Ләкин шунысын тәгаен әйтә алам: минем белән әнә шул «сөйләшүдән» соң ике көн үтүгә, Габдулла Халисәне урлап алып кайткан, һәм алар, языльшып, бергә тора башлаганнар иде.

## Кортикка кызыгып...

1954 елның март аенда безне, унынчы класста укучы малайларны, военкоматка дәшеп комиссия үткәрделәр. Шунда кемнең кайсы төр гаскәрдә хезмәт итәргә теләве белән дә кызыксындылар. Мин, әгәр сәламәтлегем ягыннан туры килә торган булсам, хәрби диңгез училищесына укырга китәргә теләвемне әйттем.

Моңарчы минем диңгезче, бигрәк тә диңгез офицеры булу турында уйлаганым да юк иде. Киресенчә, семьяларыннан, бала-чагаларыннан, дус-иш, туган-тумачаларыннан аерым хәлдә ничек инде еллар буе гел диңгез өстендә яшәргә мөмкин икән, дип гаҗәпсенеп карый идем. Ә менә хәзер, ике дә уйлап тормыйча, диңгезче-офицер булырга язылып кайттым. Ник алай?

Хикмәт менә нәрсәдә. Әлеге комиссиягә барудан бер-ике ай гына элек Солтанга, туганнарына кунакка, хәрби-диңгез флотында хезмәт итүче бер офицер кайткан иде. Шул чакта, комсорг буларак, мин ул лейтенантны үзебезнең класс укучылары белән очрашырга чакырдым. Чөнки нәкъ шул айда безнең эш планында «Минем профессиям» дигән көн тәртибе белән комсомол җыелышы үткәрү каралган иде. Килде теге лейтенант (кызганычка каршы, мин инде аның исемен хәтерләмим). Башта рус диңгез флотының искиткеч бай тарихын тасвирлап үтте. Аннары СССР хәрби-диңгез флотының хәзерге уңышлары, диңгезчеләр тормышы турында сөйләде. Аның сөйләвенә караганда, илнең кораллы

көчләре арасында иң әһәмиятлесе — хәрби-диңгез флоты иде. «Ә киләчәктә аның роле тагын да үсәчәк, — диде ул.— Куәте артачак. Чөнки коры җир гаскәрләренә караганда, диңгез флоты гаскәрләренең маневр ясау мөмкинлеге зур. Алар тиз арада бер урыннан икенче урынга күчә, шулай итеп, дошманга көтмәгәндә удар ясый алалар...»

Аның үз һөнәрен шулай яратып, мактап сөйләве бер миңа гына түгел, классташ егетләргә дә ошады. Хәтта безнең кызлар да сокланып, авызларын ачып тыңладылар. Халисәдән колак какканнан соң мин классташым Р.га гашыйк булган идем. Ул аеруча мөкиббән китеп, күзен дә алмыйча карап утырды аңа. Әгәр теге лейтенант, әйдә, киттек минем белән, дип ым гына какса да, укуын бетерми торып та шуңа ияреп китәргә әзер иде ул, минемчә.

Лейтенантның үзенә мин әллә ни шаккатмадым. Ә менә киемнәре миңа (унтугыз яшькә җитеп, өстенә юньле кием кигәне булмаган авыл егетенә) искиткеч нык ошады. Бигрәк тә бил каешына таккан кортигына кызыктым мин аның. Бер генә дә җыерылган яисә бөкләнгән җире булмаган, үзенә тап-таман итеп тегелгән шул лейтенант киемнәрен киеп, аның әллә кайдан күренеп һәм ниндидер серлелек биреп торган кортигын тагып, Р. каршына килеп бассам — җир йөзендә миннән дә бәхетле кеше булмас шикелле иде. Өстемдә юньле киемем булмаганга гына мәхәббәтемне аңлатырга куркып йөрим бит мин Р.га. Аның әтисе — авыл советы председателе. Әнисе — укытучы. Р. — аларның бердәнбер баласы. Аңа әйбәттән әйбәтне генә кидереп йөртәләр. Минем генә түгел, миннән шәбрәк егетләр дә сүз каткалап караганнары бар, ләкин берсенә дә исе китми. Дөрес, без аның белән болай әйбәт кенә сөйләшеп, дус булып йөрибез. Ләкин яратышу хакында аның берни дә сиздергәне юк. Мин бик сиздерәсе дә — куркам. Ә менә теге диңгезче шикелле лейтенант булып кайтсам, ул чакта сөйләшеп карарга булыр иде! Ә болай... Бер төндә бишәр тапкыр төшләремә керсә дә, яратам, дип үзенә әйтергә йөрәгем җитми. Төннәр буе утырып хатлар язам мин аңа. Иртән мәктәпкә баргач, һичнигә карамыйча, хатымны Р.га бирәм дип әзерләнеп куям. Ләкин мәктәпкә барып, шул кызны күрү белән, әллә нишләп коелам да төшәм. Мәгънәсез, юләр сүзләр язганмындыр шикелле тоела. Мәктәптән кайткач ул хатны ертып учакка ягам да тагын, бу юлы инде шәбрәген язарга дип тотынам. Икенче көнне тагын ертып ташлыйм. Илле-алтмыш хат язып ерткanмындыр инде шулай...

Ә менә диңгез офицеры булсам, болайлар итеп интегеп йөрүенең һич кирәге калмас, бер күреп сөйләшү бик җитәр иде. Хәер, нигә «булсам» дип аһ орып утырырга? «Тырышканда мин дә шул лейтенант укыган училищеда укып чыга алам лабаса! Һәм, бернигә карамыйча, «Укыячакмын да!» — дигән нәтиҗәгә килдем мин шул очрашу вакытында. Лейтенант укыган училищеның адресын юри бөтен класс алдында сорап, язып алдым. Чөнки бу ниятемә Р. ничегрәк каравын беләсем килгән иде. Класс кызларының кайберләре, дөрес итәсең, Нәҗимов, дип сүз белән, кайберләре елмаюлары, күз карашлары белән минем теләгемне хуплауларын белдерсәләр дә, Р. бу мәсьәләне бөтенләй игътибарсыз калдырды. Чөнки ул, дөньясын онытып, лейтенантка карап тора, аның бүтән беркемдә эше юк иде.

«Ярар, бик әллә кем булган булып торма әле. Мин менә шушы егет шикелле укып, лейтенант булып кайткач карарбыз: ул чакта ничегрәк бөтерелерсең икән минем тирәдә! — дидем мин күңелемнән.— Без дә бөтенләй үк төшеп калганнардан түгел. Лейтенантка авыз суыңны корытып утырасың да бит, ләкин аның сиңа шаккатканы сизелми әле. Синең ишеләрне генә күргәне бардыр шул аның...»

Әмма мин уйлаганча булып чыкмады. Лейтенант та игътибар иткән икән Р.га.

Очрашудан соң ул Р. янына махсус килеп, берәр минут чамасы аның белән сөйләшеп торды. Аннары мәктәп ишегалдындагы интернатка ка-

дәр озатып куйды. Дөрес, берүзен генә түгел, Р.ның иптәш кызлары белән бергә. Ләкин, мин бик яхшы сизеп торам: Р. булмаган булса, ул башкалар өчен алай вакланып йөрисе кеше түгел иде.

...Комиссия үткәндә миннән:

— Унны тәмамлагач кая бармакчы буласың?— дип сорагач, бер дә икеләнмичә:

— Хәрби-диңгез училищесына! Диңгез офицеры буласым килә,— дип җавап бирүем әнә шул вакыйгаларга бәйләнгән иде.

Военком минем бу теләгемне бик хуп күреп:

— Вот молодец! Нам именно такие добровольцы нужны,— диде. Аннары кемне кая билгеләгәнне теркәп баручы секретарь кызга әйтте:— Зоя, запишите парня в военно-морское училище.



## Университетка!

Ә имтиханнарны тапшырып, кулыма өлгергәнлек аттестаты алганда минем план тагын үзгәргән иде. Университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керергә дигән ныклы карарга килдем.

Моңарчы әдәбиятка алай ук исем киткән кеше түгел идем. Программага кергән әсәрләрне, дөрес, укып барырга тырышам. Әмма шуннан артыгына, кайта-кайта-килә йөргәнлектән, вакыт та калмый. Аннары безнең авылда китапханә булмавы да минем матур әдәбият белән кызыксынып китүемә шактый зур тоткарлык ясаган булса кирәк.

Ләкин чыгарылыш имтиханнары якынайган көннәрдә ныклап торып әдәбият белән кызыксына башладым. Моның үзенә күрә сәбәбе дә бар иде. Классташларым Роберт Әхмәтҗанов белән Мидхәт Миншиннар (8—10 классларда бергә укыдык без) көн-төн шигырь язалар. Мәктәп газетасының һәр санында, район газетасы битләрендә инде сигезенче класстан бирле шигырьләре басылып килә. Роберт Әхмәтҗанов шигырьләре исә «Ялкын» журналында һәм «Яшь ленинчы» газетасында да басылып чыкканы бар. Мидхәт — Солтан малае, Роберт — Искеарышныкы. Искеарыш — Солтанга ун чакрым чамасы. Шуңа күрә Искеарышныкылар безнең кебек көн саен авылларына кайтып йөрми, торып укыйлар. Роберт Мидхәтләрнең күршесендә үк тора. Алар үзара ярышып, көнне төнгә ялгап шигырь язалар. Язган әйберләрен көн саен бер-беренә укыйлар. Үзара фикер алышалар: мактанышалар, бәхәсләшәләр, якалашырга җитеп тәнкыйтьләшәләр.

Яңгыр явып аяк астын бик нык пычраткан көннәрдә мин Солтан бабайларда куна калам. Үзем шигырь язу белән мавыкмасам да, шундый чакларда Мидхәтләргә барып, аларның Роберт белән шигырь укуын, әдәбият турында барысын да белеп, зурдан кубып сөйләшүләрен шаккатып тыңлап утырам. Кави Нәҗми, Ибраһим Гази, Шәриф Камал, Фатих Кәрим, Һади Такташ, Сибгат Хәким, Гали Хуҗи кебек язучылар турында алар шундый итеп сөйлиләр, әйтерсең, әле кичә генә шулар белән бер табында утырып чәй эчкәннәр! Хәтта шуңа барып җитәләр, кайбер күренекле генә әдипләрнең әсәрләрен бөтенләй сүтеп, юкка чыгарып ташлыйлар. Аларның шулай барысын белеп, кыю кылануларына исләрем китеп утырам. Мин дә шушындый акыллы кешеләр белән укып йөргән булам бит, юләр, дип үземне үзем орышып куям.

Мидхәт аеруча күп һәм шома яза. Без, гади укучылар, башыбызны күтәрмичә имтиханнарга әзерләнгән көннәрдә Александр Невский турында ике калын дәфтәр тутырып шигъри повесть язган. Миңа аны укып чыгар өчен генә сәгатьтән артык вакыт кирәк булды. Ә бит ул әлеге поэманы кайдандыр күчереп түгел, үз башыннан чыгарып язган! Һәм ничек кенә язган әле! Ритмы да, рифмасы да коеп куйган шикелле: бернинди кытыршылык юк, су урынына агып, юлы-юлга бәйләнеп кенә

бара. Дөрес, эчтәлеге ягыннан әллә ни яңалык күренми күренүен. Тарих дәреслегендәге мәгълүматларга нигезләнеп кенә язылган. Ләкин бит алай язар өчен дә никадәр зур сәләт, тырышлык һәм түзем булу кирәк.

Шаклар катам Мидхәтнең шул кадәр зиһенле булуына. Мин тәүлегенә унсигезәр сәгать әзерләнеп тә, имтиханда тарихтан нибары «дүрт»ле алдым. Ә ул, шул көннәрдә шигъри повесть язу белән җенләнеп йөреп тә, «биш»ле алып чыкты.

— Молодец, Миншин!— дип, тарих укытучысы Габдулла абый мактап калган әле үзен.

Ә бит Габдулла абыйдан мактау сүзе ишетү — абага чәчәк атканын күрү белән бер: бик бәхетле кешеләр генә лаек була аның мактавына. Мин үзем, мәсәлән, өч ел уку дәверендә бер тапкыр да аннан шул сүзне ишетә алмадым.

Роберт күп язмый. Аның язганнары Мидхәтнеке кебек үк шома да булмый: ритм-рифмаларында аксап-аксап киткән урыннары, бер үлчәү белән язып килгәндә кинәт икенче үлчәүгә күчеп куйган чаклары шактый еш очрый.

Нәкъ менә шул ритм-рифма мәсьәләсендә Роберт белән Мидхәт үзара бәхәсләшеп алгалыйлар. Мидхәт шигырь ансат укылырга, су урынына агып барырга тиеш дип саный. Үзе дә шулай язарга тырыша.

Роберт — шигырь шома укылырга, бер уку белән укучы күңеленә сеңеп калырга тиеш икәнен шулай ук инкарь итми. Ләкин ул беренче урынга шигырьнең формасын (безнеңчә әйтсәк, киемен) түгел, бәлки эчтәлеген — ягъни шигъри фикерне куя. Әгәр синең әсәреңдә укучы өчен яңа шигъри фикер юк икән, ничек кенә шома язсаң да, ул чын мәгънәсендә әйбәт әсәр була алмый, матур кием киендереп куйган җансыз курчак шикелле булып кына кала, ди. Үзенең шул сүзләренә мисал итеп, бик шома яза торган, ләкин әсәрләре җанга барып җитми, күңелне дулкынландырмый торган берничә шагыйрьнең шигырьләрен укып күрсәтә. Ә фикерле, укучы күңелендә хис уята торган шигырьләргә мисал итеп, укылышы ягыннан бик алай шома булмаган, әмма шигъри фикере ягыннан тәэсирле, уйланырга мәҗбүр итә торган Тукай, Дәрдмәнд, Такташ шигырьләрен яттан сөйләп китә. Ул үзе дә, аңлы рәвештә, беренче урынга шигъри фикерне чыгарып, шул фикергә муафыйк форма табу юнәлешендә эш итә.

Миңа Мидхәт тә, Роберт та якын. Алар минем өчен әдәбият укытучысы Хәнифә Вәлиулловна кебек үк зур авторитет. Өстәвенә, Хәнифә Вәлиулловна мәктәп директоры да. Үзе өчен генә түгел, мәктәптәге барлык укучылар һәм укытучылар өчен дә җаваплы бит ул! Утызлап укытучы, алты йөзгә якын укучы бар мәктәптә. Аннары килеп, мәктәпнең бар хуҗалыгы аның өстендә. Җәйгә чыкса — утын, ремонт артыннан йөрисе. Кышка керсә — өлгереш, йөреш, колхозда кар тоту һәм тагын шуныңише нәрсәләр санап бетергесез бит ул.

Әдәбиятка җитди итеп карау һәм аның һәр темасын укып, үзләштереп барырга тырышуым да, фәннең үзен яратудан бигрәк, Хәнифә Вәлиулловнаны хөрмәт итүгә бәйләнгән иде. Шуның өстенә миңа гаҗәеп талантлы һәм бәхетле булып күренгән, җитмәсә әле мине үзләренә иш итеп йөргән классташларым Мидхәт белән Роберт та, әйдә, Вакыйф, университетның татар теле бүлегенә керәбез, безнең татар халкына язучылар гына түгел, язучылар... язган әсәрләрне укытырга әдәбият укытучылары да кирәк, дип әгъвәләп тә торгач, мин хәрби-диңгез училищесына бармаска, университетка кереп карарга булдым.

Болай эшләвемнең тагын бер сәбәбе бар. Теге лейтенант киткәннән соң, Р. аның белән хат алыша икән, дип сөйли башлаганнар иде. Болай булгач, офицерлыкка укып йөрүдән мәгънә юк, барыбер минем укып чыкканны көтеп тормас ул кызый. Училищега керүдән гайрәтем шуңа да чиккән иде.

Югары уку йортларына укырга керергә гаризалар кабул итслә баш-

лау белән, Мидхәткә иярен барып, Казан университетына гаризамны биреп кайттым. Һи, җүләр, әгәр алай-болай имтиханнарны әйбәт кенә тапшырып, шунда укырга кереп булса, училище ише генә булачакмы соң? Ленин тикле Ленин укыган университет бит ул!

Аннары шунысы да бар: моңарчы безнең авылның бер генә кешесе дә укыганы юк иде әле ул университетта. Аягына чабата, өстенә бишмәт киеп үскән һәм Зәңгәрле авылының тар гына урамыннан чыккан ятим бер малай бер дә бер көнне кесәсенә университет студенты билетын тыгып, Ленин урамындагы Ленин университетында укый башласа — начар булыр идемени?!

Искә алырга да куркыныч: кемнәрне генә күрмәгән ул университетның диварлары! Бер Лобачевский үзе генә дә ни тора!..

Дөрес, университетта конкурс зур була диләр. Укырга алганда имтихан нәтиҗәләрен генә түгел, моңарчы берәр җирдә эшләү-эшләмәвеңне дә исәпкә алалар икән. Беренче чиратта әтиләре сугышта үлгән, үзләре заводта яки колхозда эшләп килгән, армиядә хезмәт итеп кайткан кешеләрне алалар, ди.

Ул яктан караганда, минем укырга эләгә алу ихтималы бик чамалы. Әтием сугышка кадәр үлгән. Эш стажым юк. Дүртенче классны бетергәч ике ел колхозда эшләдем дә бит, ләкин ул стажга теркәлмәгән. Аттестатымдагы билгеләр дә Мидхәтнекеннән кайтышрак.

Шулай да өметемне өзмим әле. Ныклап торып имтиханга әзерләнә башладым. Казанга, Ленин укыган җиргә укырга керәм дигәч, әни дә:

— Тырышып кара инде алай бик ашкынгач,— дип гомерендә беренче тапкыр фатиха бирде.

Ул елны июльнең унбишләрендә уракка төштеләр. Авылның балачагасыннан алып карт-корысына тикле иген эшендә. Ә мин, әзмәвердәй егет, өйдә ятам. Миңа оят, миңа бик уңайсыз. Шуңа кеше күзенә бик күренмәскә тырышам. Өйалдындагы сәкебезгә сузылып ятам да көннәр буе укыйм да укыйм. Ярый әле өйалдыбызның идәне — җир идән. Көн ничек кенә кызу булганда да тирләтми-оетмый; җир салкыны бәреп тора.

Председатель Мөбин абый башка чакта минем укуыма каршы түгел, киресенчә: «Укы, энем! Укысаң, әрәм булмассың»,— дип хуплап тора иде. Инде мена аның белән дә сүзләнеп алдык. Берәр атнага гына булса да, кырдан ындырга көлтә ташырга кушмакчы иде, бара алмыйм дигәч, чынлап ук үпкәләп, хәтәр орышып чыгып китте.

Мин аның хәлен аңлыйм: бер кешене бишкә бүлә торган чак. Ләкин әзерләнмичә дә булмый. Университет диләр бит аны!..

Шул ук вакытта, әзерләнеп-әзерләнеп тә, керә алмыйча кайтсам, нишләрмен дип тә куркам. Әллә кем булып, колхоз эшенә дә чыкмыйча яткан иде, барыбер шайтанына да китә алмады, дип көләрләр шикелле тоела.

Университет белән, булачак укытучылар белән таныша торыйк дип, Мидхәт белән июльнең егерме җидесендә үк Казанга киттек.

## Юк, булмады!

Алты фәннән имтихан бирәсе иде. Университетка эләгер өчен егерме сигез балл җитә, бер-ике кеше егерме җиде балл белән дә үтәчәк икән, дип сөйлиләр. Мин инде биш имтихан бирдем. Ике айга якын тырышып әзерләнү үзенекен иткән: куркыбрак кына башласам да, алган билгеләрем зарланырлык түгел. Рәхмәт инде имтихан алучы укытучыларга: өс-башың сәләмә, авыл малае дип тормыйлар, җавабыңны әйбәт биргәч, белгәнне кызганмыйлар икән. Шулай ук шәп киенгәнгә дә артык исләре китми. Әнә, берәүгә, өр-яңа костюм кигән, муенына артистларча бантик таккан, ялык-йолык итеп торган кара лаклы ботинка кигән булса да, татар теленнән «дүрт»ле, ә язмасыннан гел «өч»ле үк куеп чыгарганнар.

Минем, шөкер, рус телендәге сочинениедән башка «дүрт»ле алганым юк әлегә. Хәтта мәктәптә укыганда «дүрт»ледән югары билге алмаган тарихтан да «биш»ле куеп чыгардылар. Имтихан алучылары кемнәр диген әле син: берсе — профессор Данилов, икенчесе — доцент Мөхәммәдьяров! Минем өчен иң куанычлысы шул булды: «биш»лене нәкъ менә профессор Данилов куйдыртты миңа. Югыйсә «дүрт»ле куярга чамалап торалар иде. Профессорның әйткән сүзләре әле дә хәтеремдә:

— Парень кажется надежным. Думаю, не подведет,— диде ул.

Ә бит шул ук профессор тәкъдиме белән унбиш кешегә «ике»ле куеп чыгардылар ул көнне.

Шулай итеп, биш фәннән егерме дүрт балл миндә. Тагын бер имтиханым гына калды. География. Географияне мин мәктәптә дә ярата идем. Дөньяда нинди илләр, нинди җирләр, нинди кешеләр барын белү, минемчә, һәркем өчен кызыклы булырга тиеш.

Соңгы имтихан булгач, һич югы «дүрт»ле алырга кирәк дип, географиядән аеруча тырышып әзерләнергә тотындым. «Дүрт»ле алсам — утыз мөмкинлектән егерме сигез балл җыячакмын. Ә егерме сигез балл җыйган кешеләр беренче чиратта кабул ителә, дип сөйлиләр.

Имтихан бирә башлаганда йөз утызлап кеше идек, соңгы имтиханга нибары утыз тугыз калдык. Ләкин утыз тугызы да аз түгел: шуларның ундүрте төшеп калырга тиеш, группага нибары егерме биш кеше генә алалар. Дөрес, ул утыз тугыз арасында егерме өч, егерме ике, хәтта егерме бер баллылар да бар. Шулай булгач, бер яктан ышаныч бар кебек минем.

Ләкин күңел нигәдер бик нык борчыла. География дәреслеген инде тоташтан «ятлап» бетердем диярлек. Өстәмә материаллар да байтак укыдым. Имтихан буласы көнне төнге сәгать өчтән торып, тагын бер кат дәреслекне күздән кичереп чыктым.

Мидхәт, гадәтенчә, беренче төркем белән керде имтиханга һәм икенче кеше булып тапшырып та чыкты.

— Ничек соң, Мидхәт? Имтихан алучы бик каты тинтерәтмиме?

Мидхәт иреннәрен киң җәеп, рәхәтләнеп көлеп куйды:

— Ничек дип, шул инде, җавабыңны яхшылап бирсәң, берни түгел. Миңа, мәсәлән, өч сорауның берсенә дә ахырына кадәр сөйләттермәде: сөйли башлау белән туктата килде дә «отлично» куеп чыгарды. Ә менә миннән алда җавап биргән Флүсне, сораулар биреп, байтак талкыды. Минемчә, кыю булганны ярата ул. Беләсеңме-юкмы, каушап калмаска, ышанычлы итеп сөйли башларга кирәк. Ничава, Вакыйф, курыкма, кыю тот үзеңне. «Дүрт»тән дә кимгә бирмисең инде син аны. Мин сине беләм бит. Бар кер инде, бар!

Ул шулай дигәч, әллә тәвәккәллим микән дип талпынып та куйган идем. Ләкин күңел түрендә нинди дер үзем дә белми торган курку, өметсезлек бар, шуны һич җиңеп булмый иде. Шуңа сабыр итәргә булдым. Чөнки иптәшләрнең нинди билгеләр алып чыкканын беләсем килә иде.

Ләкин бик соңга калырга да ярамый: имтихан алучының арып, кәефе китүе, аннан-моннан гына тыңлап, «өч»ле куеп чыгаруы да бик ихтимал! Нинди билге куйса да, беркем бер сүз әйтә алмый аңа.

Тәвәккәлләп, утыз дүртенче кеше булып, мин дә кердем. Кайсы билетны алырга белмичә, каушап калдым. Ничә имтихан тапшырып, бер тапкыр да болай булганым юк иде: бизгәк тоткан кешенеке шикелле, бөтен гәүдәм калтырый. Минем куркып торуымны профессор Булыгин да сизеп алды һәм, ризасызлык белән:

— Берите, берите билет! Не дрожите как осиновый лист!— дип куйды.

Шуннан соң мин бөтенләй коелып төштем: «Бетте баш, болай булгач: әзерләнмичә килгән имтиханга, шуңа шушылай калтырый бу малай, дип уйлады инде бу!»

Билет алып, әзерләнү өстәле артына барып утыргач, күңелгә азрак җылы кереп китте. Калтырануым да туктады. Унсигезенче билет эләккән иде. Билеттагы сорауларның өчесе дә таныш, өчесенә дә әзерләнеп тормыйча да җавап бирә алырлык иде.

— Следующий? — диде профессор, әзерләнеп утыручыларга ваемсыз гына карап.

Аудиториядә миннән алдан кергән дүрт кеше бар иде. Берсе дә чыгарга ашыкмады: Булыгинның соравын ишетмәгән атлы булып, башларын аска иеп, өнсезләнеп утыралар. Ә миңа әзерләнеп торырга кирәкми: барысын да беләм. Соңгы сорауга бирәсе җавап исә, нәкъ дәреслектә язылганча, бөтен тексты белән күз алдымда тора иде. Тик шуны русчага күчереп сөйләп кенә бирәсе.

Кирәк бит шулай булырга: әле имтиханга керер алдыннан гына дәреслекне актарып утырганда «Пассатлар һәм муссоннар» дигән темага күзем төшеп, шуны тагын бер тапкыр укып чыккан идем. Билеттагы сорауның берсе — шул.

Шуңа күрә, һич икеләнеп тормыйча, кулымны күтәрдем дә:

— Җавап бирергә мөмкинме? — дидем.

Профессор миннән моны көтмәгән иде булса кирәк: күзлеген бер салып, бер киеп, гаҗәпсенеп карап торды да әйтте:

— Нәрсә, әзерләнмичә генәме?

«Нигә әзерләнмичә булсын, мин өйдә әзерләндем!»— дип әйтәсе булгандыр миңа. Ә мин, юләр, алдын-артын уйлап тормадым:

— Миңа әзерләнеп тору кирәкми, болай да беләм!— дип ычкындырдым.

Профессор миңа ышанычсыз итеп, мыек астыннан елмайды:

— Ну үзеңә алай бик ышанасың икән, әйдә, сөйләп кара.

Чыктым. Ышанып чыктым. Курку-каушау дигән нәрсәнең әзе дә юк. Чөнки, бердән, һәр өч сорауга да җавап бирә алам. Икенчедән, имтихан алучының миңа нигәдер шикләнеп каравына җенем кузгалып, шуңа батыраеп киткән идем: «Тыңлап кара алай булгач. Башың булса, үзең чамаларсың шуннан минем ничек белгәнне!»

Кыю гына итеп тотындым беренче сорауга җавап бирергә. Утыра профессор Булыгин тыңлап. Ләкин йөзенә карап берни белеп булмый: канәгатьме ул минем җавап бирүдән, юкмы? Әйтерсең, мин аның өчен түгел, имтиханга әзерләнүче иптәшләрем өчен сөйлим...

Әмма, тыштан шулай битараф күренсә дә, тыңлап утыра икән үзе. Мин әле беренче сорауга җавапның яртысын да сөйләп бетермәгән идем, икенче сорауга күчәргә кушты. Анысында Грузия ССРның файдалы казылмалары һәм промышленность үзәкләре хакында сөйләргә диелгән иде. Монысы да минем өчен авыр сорау түгел: ул елларда Чиатура, Тквибили, Ткварчили кебек чимал һәм промышленность үзәкләре турында газеталарда да күп сөйләнелә, дәреслектә дә шактый тулы язылган иде. Тик менә русча сөйләве генә читенрәк. Шулай да, кулымнан килгәнчә тырышып, бу сорауга да җавап бирә башладым. Берәр минут сөйләгәч, Булыгин минем сөйләүне бүлеп:

— Ә хәзер әйтегез әле, Чувашстанның Комсомол районында төзелеп ята торган ГЭСның җегәре күпме? — диде.

Тигез юлдан чабып барганда, кинәт упкын буена килеп чыккандай, шып тукталып каушап калдым. Ул сораган ГЭСның җегәрлеген генә түгел, андый электростанция төзелүен дә ишеткәнем юк иде.

Бәлки аңа шулай дип турыдан-туры әйтергә кирәк булгандыр. Ләкин мин, алай дип әйтсәм үземнең наданлыгымны күрсәтермен, Чувашстанда андый станция бардыр, дип уйладым да:

— Биш мең киловатт!— дип җавап бирдем.

Каптырдым бит үзеңне, дигән шикелле итеп, Булыгин канәгать елмаеп куйды:

— Ай-яй, шәп фантазер икәнсең син, егет! Ә бит Чувашиядә андый ГЭС бөтенләй юк.

Мөгаен, миңа шунда дәшми генә калырга да, башны иеп, тегенең ләззәтләнеп көлеп туйганын көтеп торырга кирәк булгандыр. Ә мин тоттым да:

— Булмагач, нигә бутап, кешенең башын катырып торасыз соң аны?— дип ычкындырдым.

Көлүеннән шундук туктап, профессор усал итеп карап куйды. Ләкин аны-моны әйтмәде. Әйбер тыгылган сыман, тамагын кырып кына куйды да:

— Ярый, өченче сорауга күч! — диде.

Инде әйткәнемчә, дәреслекнең пассат һәм муссон җилләре хакындагы тексты тулысы белән минем күз алдымда тора иде. Нәкъ шунда язылганча, чатнатып сөйләп алып киттем мин моңа. Әмма, яртысын да сөйләргә өлгермәдем, тагын бүлдерде теге:

— Юк, алай түгел. Теманы өйрәнмәгәнсең! — ди.

Бәлки ул юри, мине сынап карар өчен генә шулай дип әйткән булгандыр. Ихтимал, миңа: «Безгә шулай дип укытканнар иде мәктәптә»,— диярга кирәк булгандыр. Ләкин мин, юләр баш, аны-моны уйлап тормадым.

— Юк, мин теманы бик дөрес сөйлим! Ышанмасагыз, әнә, алдыгызда яткан дәреслектән укып карагыз! — дидем.

Мин, беркатлы авыл малае, «Каяле, карыйк әле алайса»,— дип китапны ачып карар дип көткән идем. Ләкин Булыгин минем сүзгә игътибар да итмәде. Нишләтергә икән бу үзсүзле мокытны, дип булса кирәк, беркавым миңа карап, уйланып торды да, тотынды сораулар яудырырга — чыда гына!

Әлбәттә, барысы да географиягә кагылышлы сораулар иде алар. Ләкин урта мәктәп бетереп килгән авыл малаен батыру профессор кешегә ни тора инде ул?

Шулай да бирешмәскә тырышам тегеңә. Сорауларының күбесенә җавап биреп барам. Ниһаять, ул да арыды булса кирәк: көн артык эссе булмаса да, кулъяулыгын чыгарып, бит-муен тирәләрен сөртте. Аннары өстәлдә яткан авторучкасын алды да:

— Әзерләнмичә генә сөйләргә тотынгач, мин сине бөтенләй укымыйча килгән бушкуык дип уйлаган идем. Шулай да «өч»лелек беләсең икән географияне,— дип билге куеп чыгарды.

Миңа хәзер университетка эләгү турында уйларга да ярамый, чөнки минеке кебек егерме җиде балл белән тик ике генә кеше кабул ителәчәк.

Мидхәт дустым киңәше белән пединститутка барып карауның да файдасы булмады. Анда үзләрендә егерме биш балл җыйган кешеләрне кабул итсәләр иттеләр, университеттан килүчеләрне алмадылар.

Роберт дустымның хәлләре ничек икәнен сорашмакчы булып, институтта эзләштергәләп карасам да табып булмады. Кабул ителгән студентлар исемлеге әле эленмәгәнлектән, аның укырга керә алу-алмавы шулай ук билгеле түгел иде.

Ә миңа, шырпы ящигыннан үзем ясаган фанер чемоданымны күтәреп, авылга кайтып китүдән башка чара калмады. Казанда берәр эшкә урнашып калыр өчен, торыр урыным да, танышым да юк. Аннары килеп, бер тиен акчам калмаган иде. Шуңа җәяү кайтырга булдым. Йөрмәгән юл түгел. Үгез җигеп тә, ат җигеп тә килгән бар Казанга.

Кузгалуын кузгалдым, ләкин Казанны чыгып җиткәнче үк туктап ял итәргә туры килде. Авырлыгы әллә ни булмаса да, чемодан бик уңайсызлый: кулга тотып барсаң — кул тала, иңгә куйсаң, бөкрәеп барып, муен авырта...

Мин Колай совхозына килеп җиткәндә, сәгать ун тулган иде инде. Ә бит Колайдан соң тагын кырык биш чакрым җир үтәсе бар әле. Дөрес, авылга кайтырга ашкынып тормыйм. Кайтып авыл халкы күзенә

күренүләре җиңел булмаячак. Минем кая киткәнне бөтен авыл белеп калды ич. Кайту белән «дупрусларга» тотыначаклар. Иң элек председатель Мөбин абый: «Ну, ничек, булдымы, энем?» — дип килеп житәчәк. Булмады дигәч, аның ни әйтәсен алдан ук белеп торам: «Әйттем бит мин сиңа, анда синең ише авыл малайларын бик үткәрмиләр, лутчы колхозда гына эшлә, дип! Имтиханга әзерләнәм дип, җәй буе колхоз эшенә чыкмыйча, бердән, күпме вакытыңны бушка үткәрдең. Икенчедән, никадәр хезмәт көне эшләүдән коры калдың. Быел икешәр килодан бүләргә торабыз, ким дигәндә дә тугыз-ун пот икмәк алган булырыең»,— диячәк ул.

«Безнең авылдан да берәр укымышлы кеше чыгар мәллә дип йөргәнием. Юк икән, син дә өметне аклый алмагансың икән, егет!» — дип, мыек астыннан гына елмаеп, аннары Әхмәтгали абый киләчәк...

Анысы шулаен шулай, ләкин барыбер кайтырга кирәк. Тамак тәмугъка кертә, ди. Ә минем кичә кичтән бирле авызга валчык та алганым юк иде. Қолайда берәр йортка кереп, берәр сынык икмәк сорап карыйм микән әллә дигән уй күңелемә килсә дә, тәвәккәллегем җитмәде. Бәлки, юл буенда сугылмаган борчак чүмәләсе очрар, шунда туктап борчак ашарга булыр дип өметләнеп килә идем. Әгәр инде очрамаса, алда Шәле авылы булачак, шунда барып җиткәч соранып карармын дигән идем...

## Юлдагы очрашу

Мишә күперен үтеп, күп тә китмәдем, арттан автомашина килгәне ишетелде. Утыртуына өметем әллә ни булмаса да, кулымны күтәрдем. Якынрак килгәч аның Қорноухка почта ташый торган машина икәнен абайладым. Ләкин бу мине куандырмады. Чөнки почта машинасының әрҗәсенә кеше утыртмыйлар. Ә шофер янында һәрвакыт кем дә булса утырган була. Бу юлы да шофер үзе генә түгел, аның янында бик чибәр бер кыз утыра иде.

Шулай да минем турга килеп җиткәч машина туктады. Сөенеп, кабинаның пассажир ягы ишегенә үрелгән идем, якын киләсе булма, дигәнне аңлатып, шофер йодрык күрсәтте. Аннары кинәт бик төче елмаеп, янында утырган кызга нидер әйтте. Тегесе бик җитди иде, шофер әйткәнгә риза булмавын белдереп һәм ачуланып баш какты. Шоферга бу хәл ошамады: секунд эчендә кызарып-бүртенеп чыкты да, пассажир ягы ишеген каерып ачып:

— Все, бетте! Бар, алайса, җәяү топай! — диде.

Ләкин чибәр кыз югалып калмады: кечкенә чемоданын тотып, кабинадан сикереп төште дә:

— Син идиот белән рәттән утырып кайтканчы, җәяү кайтуым мең артык! — дип горур атлап китеп барды.

Мин, болар арасында ни булганын аңларга теләп, ләкин һични аңлый алмыйча, шаккатып калган идем. Шул арада шофер кабинасыннан башын тыгып:

— Ә син, егет, әйдә, утыр! — диде.

Миңа теге кызның үзен генә калдырып китү кызганыч иде. Шофер аны минем аркада төшереп калдыргандыр, мин кул күтәрмәгән булсам, ул аны Корноухка кадәр алып кайтыр иде шикелле тоелды. Аннары килеп, шоферның кыяфәт тә бик үк иманлы түгел: җиз табак шикелле түгәрәк йөзле, җәлпәк борынлы, бәләкәй соргылт күзле һәм гәүдәсенә тоташып үскән муенсыз башлы, кырык яшьләрдәге бер ир иде ул. Шуңа мин башта аның машинасына утырырга теләмәгән идем. Ләкин чемоданым авыр һәм күтәреп барырга уңайсыз икәнен уйлап, аннары карыным да бик ачканга күрә, утырырга булдым. Мин утыргач, бәлки, кызны да утыртыр дип тә өметләнгән идем. Шуңа күрә:

— Хатын-кызның берүзен япан кырда калдырып китү ару түгел бит! — дип әйтеп караган идем...

— Шул кирәк аңар! — диде шофер, бик нык ачуланып. — Ә син, әгәр аны бик кызганасың икән, пажалысты, төшәсең дә каласың!

Рәхмәт ул усал кешегә! Әгәр шулай дип әйтмәсә, мин тәки аның белән китеп барган булыр идем. Биш-алты сәгатькә өйгә алданрак кайтыр идем. Ләкин шул мокытлыгым өчен әле хәзергәчә үкенеп, үземне-үзем орышып яшәр идем. Ярый әле, кимсетергә теләп, ул шофер миңа үземнең ялгышымны төзәтергә ярдәм итте.

— Әйе, кызганам мин аны! Туктат машинаңны! — дидем дә төшеп калып, теге кыз килеп җиткәнне көтә башладым.

— Рәхмәт сезгә,— диде ул, килеп җиткәч. — Әгәр шул хайванга утырып китсәгез, бу дөньядагы егетләр затына ышанычым калмый иде.

Без сөйләшеп киттек. Корноухтагы механизаторлар мәктәбенә укытучы булып эшкә килеше икән. Быел гына авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган.

«Димәк, миннән ике генә яшькә олы булып чыга икән»,— дип уйлап куйдым мин. — Үзе инде югары белемле һөнәр иясе. Минем ишеләрне укытачак. Ә мин менә укырга керә дә алмыйча кайтып килэм!»

Ләкин бу уйларымны аңа әйтергә ярамый иде.

Үземне егетләрчә тотарга, хәсрәтемне сиздермәскә кирәк иде.

— Корноух мәктәбендә егетләр генә түгел, икешәр-өчәр балалы ир-атлар да укый анда. Аларны тыңлата алырсызмы икән соң? — дидем, уенын-чынын бергә кушып.

— Ир-ат арасында эшләү кыз балага кайда да җиңел түгел ул. Ләкин өлешеңә тигән көмешең шул булгач ни эшләмәк кирәк? Түзәргә туры килер инде,— диде юлдашым, олыларча акыллы итеп.

— Шулай инде анысы. Гафу итегез, кайчаннан сөйләшеп киләбез, ә мин сезнең исемегезне дә белмим.

— Үзегез дә әйтмәдегез ич әле. Башта егетләр әйтә торган иде.

— Вакыйф дип йөриләр мине.

— Ә миңа Кифая дип эндәшә аласыз.

— Кызык, бер дә ишеткәнем юк иде мондый исемне. Кай якныкы сез, Кифая?

— Аксубай районыннан.

— Мишәр кызы икәнсез алайса. Ләкин сөйләшегездә мишәрлекнең исе дә юк!

— Каян беләсез бездә ничек сөйләшкәннәрен? Барганыгыз юктыр бит?

— Бездә Аксубай ягыннан бер укытучы бар иде. Узган ел пенсиягә чыкты. «Кабәм», «атәм» кебек мишәр сүзләрен иң аз дигәндә дә дәрес вакытында өч-дүрт тапкыр ычкындырмый калмас иде. Ә сез гел безненчә сөйләшәсез икән.

— Нигә, сезгә ошамыймы әллә?

— Аннан әйтүем түгел. Ошый, ник ошамасын. Ләкин, минемчә, кеше үзенең туган ягы сөйләшен онытырга тиеш түгел.

Кифая гаҗәпсенеп, чем-кара күзләрен текәп, миңа карап куйды.

— Сез гел шулай кешегә акыл өйрәтергә яратасызмы?

— Андый җитешсезлегем бар шул, кызганычка каршы,— дидем мин. Үземне хаклы санасам да, бәхәс ачып, араны бозасым килмәде.

Әле ун-унбиш минут элек кенә ничек кайтып җитәрмен дип борчылып килгән кеше, хәзер миндә ару дигән нәрсә дә, ашыйсы килү дә онытылган иде. Мин хәзер чемоданның авырлыгын бөтенләй тоймыйм да. Язмыш үземне менә шушы Кифая исемле кыз белән очраштырганга куанып бетә алмыйм һәм кайтасы юлыбызның утыз биш километр гына түгел, йөз утыз биш километр булуын тели идем. Чөнки миңа бу кыз белән рәттән атлап бару искиткеч рәхәт. Әгәр риза булса, мин аның үзен дә күтәреп кайта алыр шикелле идем. Киң итәкле, кыска җиңле, бизәкле

зәңгәр ситсы күлмәге дә, малайларныкы шикелле итеп кистерелгән, дулкынланып торган кара-бөдрә чәчләре дә, аягындагы зәңгәр брезент туфлиләре дә үзенә искиткеч килешеп тора иде аның. Ул шундый җиңел атлап бара, әгәр ныграк итеп талпынып куйса, кулларын канат итеп, очып үк китәр шикелле иде.

Мин аның очып китүен теләмим. Минем аның белән сөйләшеп рәттән барасым килә, ләкин нәрсә турында сөйләшергә икәнен белмим. Ни генә сөйләсәм дә, аңа ошамас, көлкегә калырмын дип курка идем.

— Карагыз әле, Кифая: үзегез Корноухка эшкә барам дигегез, ә үзегез бәләкәй чемодан белән генә киләсез. Кием-салым, урын-җир әйберләрен каян алырсыз икән соң? — дидем мин, ни тырышып та, шуннан әйбәтрәк фикер башыма килмәгәч.

— Ә миңа әле аларның кирәге юк. Башта барып, эш шартларын, торыр урын мәсьәләләрен белешәм. Ошаса — күз күрер анда.

— Ә ошамаса?

— Ул чакта борылып китәм дә барам. Без — агрономнарга бүтән районнарда да эш бетәсе түгел. Казанга якын булганга гына ризалаштым мин Корноухка.

— Ә сезгә Казанга якын булу нигә кирәк соң?

— Ирем Казанда.

Шушы яшь кенә кызның кияүдә булуы бик сәер иде.

«Нигә шул тикле ашыгып чыктың? Кыз булып үз иркеңдә яшәп калырга иде азрак»,— дип әйтергә дә теләгән идем. Кешегә акыл бирү килешмәс дип, кире уйладым.

— Ә нигә икегез бергә кайтмыйсыз соң Корноухка?

— Аны аспирантурада калдырдылар.

— Нинди уку йорты тәмамлаган иде?

— Университет.

«Ах, университет!»

— Аспирантурада да шунда укыймы?

— Әйе.

— Нинди фән буенча?

— Биология.

— Аспирантура тәмамлагач кем була инде ул?

— Диссертация яклый алса, я университетта укытыр, яки фәнни-тикшеренү институтында эшләр.

— Безнең кебек авыл малае түгелдер инде ул, алай булгач?

— Без аның белән икебез бер авылдан.

Бар бит дөньяда бәхетле кешеләр! Авылдан килеп аспирантурага эләккән диген, ә? Ә мин менә укырга да керә алмыйча кайтып киләм. Бик башлы, бик булдыклы кешедер инде ул. Югыйсә шушындый чибәр кызга өйләнә алмас иде. Чибәр кызлар бик сайланучан була бит алар. Әнә безнең классны тәмамлаган Р.ны гына ал. Кемнәр генә йөреп тә карамады артыннан. Ә ул берсенә дә шаккатмады. Теге диңгезче офицер белән хат алыша башлаган икән дип сөйләделәр сөйләвен. Анысы да ни белән бетәсен кем белгән? Р. үзе документларын Арча педучилищесына биргән диделәр. Мөгаен, шунда китеп баргандыр инде. Дөресен генә әйткәндә, миннән акыллырак булып чыккан ул. Югары уку йортына керәм дип хыялланып йөрмәгән: үз хәлен үзе чамалап, кулыннан килердәй, булдыра алырдай җиргә киткән. Училище тәмамлап та менә дигән итеп укытып йөриләр бит әле. Ә Р.ның укытучы булырга бөтен мөмкинлекләре бар: кирәк чакта матур итеп елмая да, кирәк булганда ачуланып, кешене тиешле урынына утырта да белә. Кыюлыгы да җитәрлек. Димәк укучыларның үзләре белән генә түгел, эти-әниләре белән дә аяк терәп сөйләшә алачак...

Әнә шулай уйланып, үземне-үзем тиргәп барганда, Кифая кинәт кенә сорау биреп, сискәндереп җибәрде:

— Сез миннән сорашасыз да сорашасыз, Вакыйф, ә үзегезнең кая барышыгыз соң?

— Авылга кайтып килүем.
— Кайдан?
— Казаннан,— дидем мин һәм, ник барган идең дип ул сораганчы, үзем әйтергә ашыктым.— Йомырка сатарга барган идем.
— Барганда да шушылай җәяү бардыгызмы?
— Юк, пароход белән.
— Нинди пристаньда утырасыз сез пароходка?
— Балык Бистәсендә.
— Еракмы ул сезгә?
— Егерме ике чакрым.
— Әллә ни ерак түгел икән. Ә нигә кайтканда да пароход белән генә кайтмадыгыз?
Билет алырга акчам булмады дип әйтә алмыйм бит инде мин аңа. «Йомырка сатып» кайтып киләм ич!
— Җәяү кайтасым килде. Файдалы диләр бит.
— Анысы шулай. Ләкин үзегез инде арыгансыз да.
— Кем арыган? Минме?
— Әйе, сез! Һәм бик нык ачыккансыз: күзләрегездән күренеп тора. Әйдә, әнә теге ялгыз карама янына барып җитәбез дә, шуның ышыгына утырып, бераз ял итәбез!
— Ә мин тамчы да арымадым!— дигән булдым сер бирмәскә тырышып.
— Ярый-ярый, сез арымагансыз. Ләкин мин бик арыдым. Мин ял иткәнче көтеп торырсыз бит?
—Хатын-кызны ташлап китеп булмас инде.
Ә үзем аягымда чак басып торам. Кифая әйтмәгән булса да, карама ышыгында туктап ял итәргә күптән ниятләп куйган идем. Чөнки аның белән сөйләшеп бара торгач без инде Шәле авылын күптән үткән, Никчүчтемгә якынлашып килә идек.
Без карама төбенә килеп утыргач:
— Ә хәзер, әйдәгез, тамак ялгап алабыз! — дип Кифая чемоданын ачты. Анда ярты бөтеннән артыграк икмәк белән ике таяк каклаган колбаса булган икән. Шуларны күргәч, авызыма сулар килде. Түземсезләнеп, Кифаянең мине ныграк кыставын көттем: никадәр генә ашыйсым килсә дә, бер әйтү белән ашый башлап булмый бит инде!
— Ой,— диде ул, икмәкне кулына алгач туктап калып.— Пычак алырга онытканмын бит.
— Ә минем пәкем бар! — дип чемоданыма үрелгәнемне сизми дә калдым.
«Минем дә андый нәрсәм юк шул, кая сындырып кына бирим!» — дип әйтәсе иде мин ахмак башка. Ләкин хәзер эш узган, чемоданны ачмыйча булмый иде. Ә анда, имтиханнар вакытында алмашка кияргә әни биреп җибәргән бер күлмәк, яңгырлап китеп, суытып җибәрә калса киярга дип алынган кыска брезент кожан белән бер пар итек һәм авылдан үзем белән алып килгән дәреслекләр иде. Кифая иң элек дәреслекләргә игътибар итте:
— Әһә, аңлашылды: Казанга берәр югары уку йортына укырга керергә барган булгансыз икән! Кайсы институтка барган идегез?
— Юк ла, бер институтка да бармадым.
Ул дәреслекләргә төртеп күрсәтте:
— Ә боларны нигә күтәреп йөрисез алай булгач?
— Мин быел унынчыда укыячакмын, сатып алдым.
— Алдашасыз бит! Унынчыда укыйсы булсагыз, сез аны инде күптән районыгыз кибетеннән алып куйган булыр идегез.
«Чукынган гына хатын икәнсең, билләһи!»
— Мин Казанда кулдан, арзанракка алдым!
— Ә бит аларны үз җилкәңдә күтәреп кайту кыйммәткәрәк төшә! Ул хаклы түгел иде бу очракта.

Университетка керә алмасам да, бөтенләй үк беткән бәндә түгел, минем дә азрак акылым бар. Киракләре булмаса, бу дәреслекләрне мин имтихан биреп бетергән көнне үк чыгарып аткан булыр идем. Мин аларны быел унынчыда укыячак Солтан малаена — үземнең туганнан туган энем Хатипка вәгъдә иткән идем. Ә ул миңа үзенең энесе Әдһәмнән калган сигезенче класс дәреслекләрен бирергә тиеш. Быел безнең Равил сигезенче класска Солтанга барырга җыена, дәреслекләр аңа кирәк булачак иде.

Ләкин бу хакта Кифаягә әйтеп, үземнең хәтта яңа дәреслекләр дә ала алмаслык дәрәҗәдә үк фәкыйрь икәнне сиздереп булмый бит инде. Әнә, чемоданның шырпы ящигыннан ясалганын күреп торуы да бик җиткән!

...Сынык чалгыдан үзем ясаган агач саплы пәкене алып биргәч, Кифая минем шул хәерсез чемоданны күтәреп карады да, исе китеп:

— Ай-яй-яй, пот ярым бардыр моның авырлыгы! Ничек күтәреп кайттың син моны шушыңарчы? — диде. Калын итеп бер телем икмәк кисеп бирде:

— Мәле! Хәзер колбаса кисеп бирәм дә әйбәтләп аша әле шушы икмәк белән. Югыйсә бу тамаша авыр чемоданны апкайтып җиткерә алмассың!..

Аннан соң инде байтак җирләрдә булырга, әллә нинди затлы ризыклар ашарга туры килде миңа. Ләкин әнә шул чактагы Кифая икмәгеннән дә тәмлерәк икмәкне очратканым юк әле. Ул мине кыстый-кыстый ашатты. Хәер, үзем дә артык кыстатып тормадым. Чөнки башта иркенрәк кыланып ташлаганлыктан, соңгы көннәрдә Казанда да юньләп ашаган юк, акча ягы бик саеккан, шуңа күрә ипи ашап, чәй урынына баллы су эчеп кенә торылган иде. Кифаянең ипие белән колбасасын ашагач, җаннар рәхәтләнеп, дөньялар матураеп китте. Хәзер инде мин алдымда торган егерме бер чакрымны гына түгел, йөз егерме бер чакрым җир үтәргә әзер идем!..

Кешеләрне үзара иң нык якынайта торган нәрсә — бер табыннан бергәләп тәгам җыю икән. Ул көнне әлеге ялгыз карама төбеннән купканда, Кифая белән без бертуганнардай дуслашкан идек. Бернинди хәйләяшерүсез, юл буе уй-фикерләребез белән уртаклашып кайттык. Кифаянең Казан тирәсенәрәк урнашырга теләвенең төп сәбәбе башта әйткәнчә гади генә түгел, шактый катлаулы һәм күңелсез хәлләр белән бәйләнгән булып чыкты. Аның әтисе — үги әти икән. Үгилеге бер хәл, бик нык эчә һәм Кифаянең әнисен кыерсыта икән. Шуңа күрә Казанга якынрак урнашып, ешрак өйләренә кайтып йөрергә һәм, шулай итеп, әнисенең хәлен җиңеләйтергә ниятли иде ул. Аспирант мәсьәләсен ул просто шыттырып, алайболай мин бәйләнә башламасын өчен генә уйлап чыгарган икән.

Ул шулай ачылып-чишелеп киткәч, мин дә аңа үземнең баштан үткән хәлләрнең дөресен сөйләп бирдем. Хатын-кызларга хас булганча, Кифая башта мине бик кызганды, аннары: «Ярар, Вакыйф, артык кайгырма. Дөнья булгач төрле хәлләр була ул, быел кермәсәң, киләсе елга керерсең университетка».— дип юатырга кереште.

Аның шулай үз итеп, хәлемә кереп сөйләшүен тыңлау миңа бик рәхәт иде билгеле. Ләкин:

— Бер ел вакытым әрәм була бит, Кифая. Менә шунысы кызганыч миңа!

— Вакытны әрәм итү яки аны файдалы итеп үткәрү кешенең үзеннән тора. Университет студенты булып та вакытны мәгънәсез үткәрергә була һәм авылда яшәп тә аны файдалы итеп үткәрергә мөмкин!

— Мәсәлән?

— Мәсәлән, әйдә, кил безнең Корноух училищесына.

— Комбайнчы булыргамы?

— Әйе.

— Мин бит алга таба укырга телим.

— Белгән эш беркайчан да зыян итми ул, Вакыйф.

Ул хаклы иде. Чыннан да, университет тәмамлап, укытучы яки журналист булып эшләгән тәкъдирдә дә комбайн йөртә белү миңа файдага гына: студент чагымда җәйге каникул айларында комбайнда эшләсәм, өстемә кием-салым алырлык, әни белән Равил энемә ярдәм итәрлек акча эшләргә мөмкин. Тагын шунысы бар: Корноухта укысам, мин шушы Кифаяне көн саен күреп, күреп кенә түгел, хәтта аның белән сөйләшеп тә йөри алачакмын.

Кыскасы шул: Корноух юлы чатында аерылышканда мин Кифаяга училищега укырга килергә вәгъдә биреп киттем. Бу теләгемне председатель Мөбин абый да бик хуп күреп:

— Маладис, наным Вакыйф, мин синнән күптән шушындый акыллы сүз көткәнием. Ничу анда, университет дип, булмастайны куып йөрергә. Җирдән аерылмаска кирәк. Менә комбайнчы булсаң, тамагың да тук, өстең дә бөтен, кеше арасында афтаритетың да булыр. Давай, укы, калхуз чутыннан укытабыз үзеңне! — дип тиешле кәгазьләрен дә әзерләп бирде, һәм мин инде училищеда укый да башлаган идем. Кифая дә сөенеп бетә алмаган иде. Әмма бу планым да барып чыкмады.

Сөйләргә онытып торганмын икән: әлеге 1954 елның җәендә, июнь аенда, хәрби-диңгез училищесына җибәрергә документлар әзерләү өчен, мине район хәрби комиссариатына чакырттылар. Ә ул чакта, үзегезгә мәгълүм, мин инде фикеремне үзгәртеп, университетка керергә карар кылган идем. Хәрби комиссариатта да шулай дидем. Югары уку йортына керергә теләгән кешеләргә тоткарлык булырга тиеш түгел икәнен мин инде белә идем. Шуңа военком белән батыр сөйләштем. Күкрәгенә алты рәт медаль һәм орден планкалары таккан, өстенә яшел китель, кесәләре бүлтәйтеп тегелгән куе зәңгәр диагональ чалбар кигән, корсак зур булганга бил каешының беренче тишегеннән генә эләктергән, төп күк таза, тәбәнәк буйлы бер майор иде ул. Диңгез училищесына бармаска булуымны белгәч, моңарчы көлеп торган чырае кинәт караңгыланып китсә дә, очып кунмады: — Вузга керәсе булгач, нигә училищега язылдың соң? — гына диде.— Без бит сиңа ышанып торган идек. Татвоенкоматка да хәбәр иткән идек.

— Гафу итегез инде, иптәш майор. Ашыгыбрак язылганмын. Әни һич тә риза түгел.

Майор урыныннан кубып, ишекле-түрле йөренеп алды.

Аннары әйтте:

— Ярый, вузга керергә теләвеңә без каршы килә алмыйбыз. Ну, бел аны: керә алмасаң, безнең карамакка кайтачаксың. Ул чакта инде училищега барырга соң булыр. Ул чакта без инде урта белемең бар дип тормаячакбыз. Башлангыч белемлеләр белән бергә хезмәт итәргә туры киләчәк сиңа.

— Ә миңа кем белән хезмәт итсәм дә барыбер! — дидем мин, аның болай сөйләнүен ошатмыйча.

Бу малай белән сүз көрәштерүнең файдасы барыбер булмас дип уйлады ахры, майор мине артык әгъвалап тормады:

— Алайса, бар, мин сине тоткарламыйм,— дип кайтарып җибәрде.

— Рәхмәт, иптәш майор. Сау булыгыз! — дип киткән идем мин аңа.

Аның белән бүтән очрашырга туры килер дип башыма да китермәгән идем.

Минем кайда булганны һәм ниләр эшләп йөргәнне махсус тикшереп торган диярсең: Корноух училищесында дүрт кенә көн укуга, военкоматка чакырып язу килде.

Бардым чакырган вакытка. Бүтән никрутлар белән бергә комиссия торырга чакырганнардыр дип уйлаган идем. Юк икән. Военкомның үзе янына керергә куштылар. Шундук танып алды бу мине. Никадәр җитди булырга тырышса да елмаеп куйды: — Менә, егет, тагын очраштык бит! — ди.— Хәтерлисеңме, моннан ике ай элек мин сиңа нәрсә әйткән идем?

Актан да, карадан да дәшмәдем. Нишлисең, бу очракта ул хаклы, аның сүзе дөрескә чыккан иде. Ул дәвам итте:

— Әә менә минем сүзне тыңлап, хәрби-диңгез училищесына киткән булсаң, инде курсант булып, дәүләт ризыгын ашап, дәүләт киемнәрен киеп, күкрәк киереп укып йөрер идең. Әйт әле дөресен генә: үкенәсеңме училищега китмәгәнеңә?

Әлбәттә, авыл хуҗалыгы механизаторлары училищесын хәрби училище белән тиңләп булмый. Ләкин «поезд киткән» иде шул инде.

— Юк! — дидем мин, сер бирергә теләмичә.— Үкенмим. Икенче елга барыбер керәчәкмен университетка.

Майор рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

— Юк инде, егет! Ул татлы хыялны онытып торырга туры килә сиңа. Кимендә өч елга онытып торырга туры килә. Синең укырга кергәнеңне көтеп торырга илнең вакыты юк. Башта аңа хезмәт итәргә кирәк булачак. Менә сиңа повестка. Кашык, кружка һәм бер атналык ризык алып, иртәгә иртәнге сәгать сигезгә военкоматка килеп җит. Соңга калма, тугыз туларга унбиш минутта пароход китә. Шуңарчы сезнең команда җыелып бетәргә тиеш,— диде.

Армиядә хезмәт итүгә мин инде күптән әзер идем:

— Илгә хезмәт итү — һәр яшь совет гражданинының изге бурычы. Була ул, иптәш майор, килермен! — дидем дә ишеккә юнәлдем.

Аның урынында бүтән бер акыллырак кеше булса, молодец, егет, мәсьәләне дөрес аңлыйсың, дип кул кысып, хезмәттә уңышлар теләп калыр иде. Күрәсең, теге чакта сүзен тыңламаган өчен каруы кайтмаган иде булса кирәк, майор тагын бер тапкыр чеметтереп аласы итте:

— Анда баргач башкачарак сайрарсың әле!

Военкомның миннән көлеп калуын теләми идем.

— Борчылмагыз, иптәш майор, анда да йөзгә кызыллык китермәм. Совет иленә кайда хезмәт итсәң дә оят түгел ул. Тик тугрылыклы хезмәт итәргә генә кирәк! — дидем мин аңа һәм ишекне юри каты итеп ябып, чыгып киттем...

## Солдат мәктәбе

Ләкин мин ул майорга армиядә хезмәт иткән елларымда да, соңыннан да үпкәләмәдем. Киресенчә, исемә төшкән саен рәхмәт укыйм үзенә. Армиядә хезмәт итү миңа бик күп нәрсә бирде.

Дөрес, аңарчы да ак перчатка киеп үскән иркә малай түгел идем. Үземне белә-белгәннән бирле урманнан күтәреп утын ташып, әнигә бакча казышып, бәрәңге утыртышып, бәрәңге алышып, печән чабып, печән ташып, тирес түгеп, ә соңгы биш елда җәй айларында төнлә ат көтеп, көндез бүтән эштә эшләп үскән егет идем. Армия миңа тагын да зуррак мәктәп булды.

Мин анда коллектив белән бергәләп эшләргә һәм үз эшең өчен генә түгел, гомуми эш нәтиҗәсе өчен куану ләззәтен татырга өйрәндем.

Мин анда сылау, буяу, ташчы, гранит эшкәртү һөнәрләренә һәм балта эшенә өйрәндем. Соңыннан үзебезнең дачаны нигезеннән алып түбәсенә хәтле үзем эшләдем. Шуларны үз кулым белән эшли алуыма чын күңелемнән куанып йөрим. Лев Николаевич Толстой — ун том әсәрләре басылып чыккан чорда үз кулы белән бер пар күн итек теккән дә шул итекләрне әлеге ун том китаплары янына киштәгә куеп:

— Менә минем хәзер унике том әсәрем бар! — дип куанып әйткән, имеш.

Мин аның ул чактагы халәтен бик яхшы аңлыйм. Күз белән күреп, кул белән тотып карарлык бирәр нәрсә эшләүнең куанычы — китап язудан туган куанычтан һич кенә дә ким түгел.

Рәхмәттән башка сүзем юк теге майорга. Аның шулай «үчләнүе» аркасында миңа Бөек Октябрь революциясе бишеге — Ленинград тирәсендә хезмәт итү бәхете насыйп булды. Безне еш кына Ленинградка увольнениегә җибәрәләр, ял көннәрендә төрле тарихи урыннарга экскурсияләргә, театрларга алып баралар иде.

Отрядыбызда күп кенә милләт егетләре хезмәт итте. Милләтләр дуслыгы, милли үзенчәлек дигән нәрсәләрне мин элек төшенчә буларак кына белгән булсам, шунда практик рәвештә үзем күреп белдем. Нык лап русча сөйләшергә дә шулай ук армиядә өйрәнеп кайттым.

Армия мине үземә кушылган эшне вакытында һәм җиренә җиткереп үтәргә дә өйрәтте.

Армиядән мин кулыма сәгать тагып, ике пар костюм, ике пар ботинка, җәйге һәм кышкы пальтолар алып кайттым. Ул чактагы белән тугыз йөз сум акчам да бар иде әле кесәмдә. Студент халкының дүрт айлык стипендиясе дигән сүз иде бу! Чөнки безгә эшләгән эшебез өчен түлиләр, ашау-эчү, кием-салым бушлай бирелә иде.

Ә иң мөһиме шул: армиядә хезмәт иткәндә мин беренче тапкыр яза башладым!

Яза башладым дигәч тә, алдыма шундый максат куеп эшләнгән эш түгел иде бу. Шимбә, якшәмбе көннәрендә безгә кино күрсәтәләр. Кайбер «герой» солдатлар кино барганда тәмәке тарта. Тәмәке төтене, киноаппараттан төшә торган яктылык нурына эләгеп, фильмны карарга комачаулый иде. Шуңа ачуым килеп бер көнне үзебезнең округ газетасына мәкалә язып җибәрдем. Бастырып чыгарырлар дип ышанып түгел. Шул мин язган буенча, полктан яисә дивизиядән килеп тикшерерләр дә тартучыларга бирәр чара күрерләр дигән өмет белән эшләгән эш кенә иде ул. Дежур солдатлар гына тартучыларны җиңә алмый, чөнки тәмәкечеләрнең бөтенесе дә диярлек мәскәүлеләр — хәерче шикәре шикелле шомарып беткән бик үткен һәм мут егетләр иде... Мәкаләне язып җибәргәнгә дүрт көн үтүгә, кичке ашка барырга торганда гына рота командиры капитан мине үз янына кәнсәләргә чакырып алды.

Калын кара кашлы, зур коңгырт күзле ул капитан безгә командир булып билгеләнгән көннән үк мине якын итте. Шахмат уйнарга ярата иде ул. Кәефе килгән чакларда, төнге сәгать уникеләрдә ротага килеп, мине йокыдан уята да, кәнсәләргә кереп, бирәр сәгать шахмат уйнап утырабыз. Уйнавын уйныйбыз, әмма ул үзен отканны бер дә яратмый. Ике генә партия уйныйбыз дип башлаган булса да, андый чакта дүртәрбишәр партия уйнамыйча кайтып китми. Тизрәк кайтып йокласын дип, юри оттыра башласаң да ошамый. «Син, давай, шаярып утырма минем белән. Чынлап уйна! Югыйсә гауптвахтага илтәм дә ябам!» — дип кызып ук китә. Шуңа күрә оттырганда да ул сизмәслек итеп, бик зур тырышлык куеп кына оттырырга туры килә. Ә үзе ота башласа, күңеле күтәрелеп, һаман бер җырны җырлый торган иде:

На пригорке у реки...

Җырның ахыргы юллары ничек булгандыр — әйтә алмыйм. Чөнки ул беркайчан аның ахырына кадәр җырламый, гел шул бер-ике юлны гына кабатлый иде.

Әлеге шул мине якын итүе аркасында булса кирәк, өченче взводның икенче отделениесе командиры гына булуыма карамастан, капитан мине взвод командиры ярдәмчесе итеп билгеләде. Старшина бирәр җиргә киткән чакларда ротаны тезеп ашханәгә алып бару һәм алып кайту, кичке барлауга тезү һәм йокларга яткыру вазифалары да миңа йөкләтелгән иде. Андый чакларда рядовой солдатлар гына түгел, хәтта бүтән взводларның сержантлары да барасы җирләре булганда миңа әйтеп китәргә

тиеш иделәр. Бу хәл миңа бер дә ошамый, уңайсызланам, чөнки башка роталарда старшиналарны взвод командиры ярдәмчеләре, гадәттә, өлкән сержантлар алыштыра иде. Устав буенча шулай тиеш. Ә безнең капитан аның ише нәрсәләр белән исәпләшеп тормый. Иң мөһиме — ротада яхшы тәртип булырга, рота үзенә тапшырылган боерыкларны төгәл итеп үтәп барырга тиеш, дип саный иде ул. Өлкән офицер Прохоренко каршында да авторитеты зур иде аның. Фронтта алар бер батальонда сугышканнар. Алай гына да түгел, безнең капитан (ул чакта әле лейтенант) Прохоренконы үлемнән коткарып калган. Чиннарында аерма булса да, алар очрашканда кул бирешеп исәнләшәләр. Прохоренко янына ул теләсә кайчан барып керә һәм үз тиңе белән сөйләшкәндәй сөйләшә иде.

Моның шулай икәнен бөтенебез дә белә, ләкин беркем күпсенми. Чөнки фронтташ дуслык — кан коеп ныгыган изге дуслык. Шуның өстенә капитан офицерлар янында гына түгел, хәтта солдатлар алдында да үзен бик гади, тыйнак тота. Кайбер яшь офицерларга хас булган кәпрәюнең исе дә юк анда. Вак-төяк нәрсәләргә бәйләнеп, солдатларга чираттан тыш наряд биреп вакланмый. Ниндидер җитешсезлегең бар икән, һәйбәтләп үткәзеп әйтә дә бетерә. Шуңа яраталар аны ротада. Ә командирың хөрмәт иткән солдат үзенә тапшырылган боерыкны үтәмичә калмый. Әнә шуңа күрә тәртип ягыннан булсын, эш ягыннан булсын — безнең рота һәрвакыт диярлек беренче урынны алып килә.

Безгә хәтта башка роталарның сержант-солдатлары да, сез бәхетлеләр, чөнки командирыгыз шәп кеше сезнең, дип кызыгып карыйлар иде.

Ләкин теге көнне капитан нигәдер мине бик кырыс каршылады. Килеп керүем булды, өстәлендә яткан «На страже Родины» газетасын тотып каршыма басты да, шундагы бер мәкаләгә бармагы белән төртеп:

— Моны син яздыңмы? — диде.

Мин аптырап калдым. Курка-курка гына ул күрсәткән мәкаләгә күз салдым. Мәкаләнең исеме «В облаках дыма» дип куелган иде. Я, хода! Мин җибәргән мәкаләнең исеме бит бу!

Капитанга ни дип әйтергә дә белмәдем. Мәкаләмнең газетада басылып чыгуы, бер яктан, күңелле хәл. Ләкин аның рота командирына нигәдер ошамавы да күренеп тора иде. Шуңа минеке дип әйтергә ашыкмадым.

— Ну, нәрсә? Синең мәкаләме бу? — диде капитан, түземсезләнеп.

Ул арада мин инде мәкаләнең баштагы берничә җөмләсен укырга да өлгердем: бер сүзе дә үзгәртелмәгән — нәкъ мин язганча иде. Мәкаләгә хәтта кечерәк кенә иллюстрация дә ясалган: бер төркем солдат тәмәке тарта-тарта, төтен болыты эченә күмелеп, кино карап утыралар.

— Кай арада басып чыгардылар икән соң? Мин аны болай гына язып җибәргән идем,— дидем мин, өзеп кенә җавап бирмичә.

— Димәк, чыннан да, син яздың моны? — диде капитан, әсәрләнеп. Аның зур коңгырт күзләре шарланган, ялт-йолт килә, ләкин ни өчен шулай икәнен аңлавы кыен иде.

— Шулай булып чыга инде, иптәш капитан,— дидем мин, ни эшләтерләр икән инде дип, котым алынып.

Капитан тиз генә бил каешын рәтләп алды һәм өстәлдә яткан фуражкасын киде дә, телефоннан кемгәдер шалтыратып:

— Ачыкладым, да, әйе, мәкаләне минем егет язган. Яхшы, яхшы, эшләрмен,— дип кем беләндер сөйләшеп алды.

Аннары мине штабка, Дерябин янына алып барды.

Эшнең зурга китәчәгенә шигем юк иде. Ләкин Дерябин безне бик тыныч, гадәтенчә елмаеп каршылады. Димәк, йомшак җәеп катыга утыртырга ниятли. Чөнки беләм: бу майор бүтәннәр белән дә гел шулай сабыр-ягымлы сөйләшә, ләкин мәсьәләне хәл иткәндә, кемнең кем булуына карамыйча, бик принципиаль хәл итә.

Бүтән офицерлар минемише сержант халкы белән алай тәкәллефләнеп тормый, аяк өсте тотып кына сөйләшәләр иде. Ә Дерябин минем белән кул биреп күреште һәм хәтта өстәле янындагы урындыкка утырырга кушты. Шуннан соң гына төп мәсьәләгә күчеп:

— Укыдым сезнең мәкаләне, сержант,— диде.— Начар язмагансыз. Фактны дөрес тотып алгансыз: әйе, кызганычка каршы, кино вакытында тәмәке тартучы тәрбиясезләр очраштыргалый әле бездә! Хуп, бик хуп мондый эшкә тотынуыгыз. Нәрсә, армиягә кадәр дә газетага язгалый идегезме әллә?

Колхозда кар тоту уңышлы баруын әйтеп, җиденче класста укыганда бер тапкыр район газетасына язган идем. Ләкин басмадылар. «Мәкаләгезне алдык. Каләмегез өметле генә күренә. Ләкин, кызганычка каршы, без аны укучыларыбызга тәкъдим итә алмыйбыз. Чөнки бу темага бездә материаллар басылды инде. Кабатланмаган тема табарга тырышыгыз»,— дип җавап бирделәр. Шуннан соң язганым юк иде. Ләкин майор Дерябинга:

— Булгалый иде инде шунда,— дип шыттырыбрак җавап бирдем. Янәсе, бу эш минем өчен яңа нәрсә түгел!

— Татарча яза идегезме, русчамы? — диде ул.

— Татарча.

— Менә, русча да әйбәт кенә булдыра аласыз икән бит, сержант. Язуыгызны киләчәктә дәвам итегез. Тик редакциягә җибәргәнче мәкаләләрегезне миңа күрсәтүегезне үтенер идем. Бергәләп киңәш-табыш итәр идек. Кайбер фактлар белән тулыландырырга үзем дә ярдәм итәр идем.

— Рәхмәт, иптәш майор, мин моны бик теләп эшләячәкмен,— дидем мин.

Аның шулай ачуланмыйча, хәтта дустанә сөйләшүенә бер яктан куансам да, икенче яктан, шикләнә идем: кем белә аның күңелендә ниләр барын?

— Тик бер үтенечем бар сезгә: безнең отрядта башкаларга да үрнәк булырдай яхшы эшләр кимчелекләргә караганда күбрәк. Шулар турында язарга тырышсагыз иде. Юк, мин тәнкыйтькә каршы түгел. Тәнкыйть, әлбәттә, бик кирәк һәм файдалы нәрсә. Ләкин үзебездәге житешсезлекләрне бөтен округ алдында фаш итү ничектер бик үк әйбәт түгел. Әгәр аерым кимчелекләргә юлыксагыз, сез алар хакында киләчәктә миңа җиткерә торыгыз. Без аларны бетерү чарасын үзебез күрербез. Аңлагансыздыр дип уйлыйм нәрсә әйтергә теләвемне?

— Бик яхшы аңладым, иптәш майор: отрядның патриоты булырга кирәк дип әйтүегез бу.

— Именно шулай, сержант. Димәк, килештек!

— Килештек, иптәш майор. Китәргә рөхсәт итегез?

— Барыгыз, сержант, уңыш телим сезгә!

Менә шул. Дер калтырап барган кеше, канат куйгандай рухланып кайттым мин ул көнне штабтан. Димәк, киләчәктә дә язарга була газетага! Әлбәттә, киләчәктә мин инде акыллырак булачакмын: хезмәт алдынгылары, политуку алдынгылары, спортчыларыбызның уңышлары турында язарга булыр. Майор Дерябин әйтмешли, бөтен округ солдатларына үрнәк булырлык эшләр турында язарга, үз частебызның чын патриоты булырга кирәк.

Бездә андый материаллар житәрлек. Мәсәлән, спорт мастерлары гына да дүртәү бездә. Икесе — штангачы, берсе городки уены буенча, ә берсе — йөгерешче. Городкичыбыз рядовой Никитинның хәтта бөтен округ күләмендә беренче урынны алып кайтканы бар. Үзенә житкерелгән эш планын батальон ай саен диярлек арттырып үтәп килә. Ташчыларыбыз арасында эш нормаларын йөз дә житмешәр процентка үтәүчеләр бар...

Мин әнә шул юнәлештә яза башладым. Шул ук айда тагын ике мәкаләм басылып чыкты. Алары өчен майор Дерябин үзе килеп, бөтен рота

каршында командование исеменнән рәхмәт белдереп китте. Юлда очраткан чакларында:

— Я, сержант, эшләрең ничек? Язасыңмы? Яз, яз, кулыңнан килә синең, әйбәт чыга язганың! — дип кул биреп исәнләшеп, аркамнан кагып үтә.

Егерме җиде йортлы бәләкәй генә авылда ятим үскән авыл малаена шуннан да куанычлырак тагын нәрсә булырга мөмкин инде?!

Өч-дүрт мәкаләм басылып чыккач, мине «На страже Родины» редакциясенә хәрби корреспондентлар киңәшмәсенә чакырдылар һәм штаттан тыш хәрби корреспондент таныкламасы биреп җибәрделәр. Ә мәкаләләрем сирәк булса да басылгалый килә.

Капитан хәзер миңа «мой корреспондент» дип кенә йөри. Шахмат уйнарга хәтта өйләренә дә алып баргалый. Үзебезнең рота солдатлары һәм үзем шикелле сержантлар да хөрмәт белән карый. Мин дә, үз чиратымда, шул ышанычны акларга — күбрәк аларның әйбәт эшләре хакында язарга тырышам.

Кыскасы, шул: газетада мәкаләләр бастыру миңа бик зур рухи канәгатьлек бирә, үземнең кешеләргә кирәкле икәнемне, алар алдында җаваплы булуымны аңларга ярдәм итә иде.

Газетага язуның тагын бер әйбәт ягы бар: мәкалә авторына гонорар да түлиләр булып чыкты! Дөрес, төзелештә эшләгәч һәм эшләгән эшебез өчен хезмәт хакы алып килгәч, бездә акчага кытлык юк. Ләкин мәкалә басылган өчен бирелә торган акча ничектер гел дә бушка килгән сыман тоела иде. Миңа калса, гонорарны мәкалә язган кешегә түгел, киресенчә, мәкаләсен бастырып чыгарганнары өчен автор редакциягә үзе түләргә тиештер шикелле иде.

Тора-бара мине үзем белгән, үзем күргән фактлар хакында язып бару гына канәгатьләндерми башлады. Үземне борчыган һәм дулкынландырган кайбер хәлләр турында киңрәк итеп, җәелебрәк язасы килә иде. Ләкин андый әйберләрне русча язарга ярамый. Чөнки андый әйберләр көн дә кулланыла торган гади һәм гадәти сүзләр белән түгел, бәлки күңел түреннән, йөрәк җылысы белән өртелгән һәм тик минем үземә генә хас сүзләр, үземә генә хас җөмләләр белән язылырга тиеш. Ә алай итеп бары үз ана телеңдә генә язарга мөмкин икәнен мин инде чамалаган идем. Казандагы берәр журналга җибәрер идең — анда минем шикелле генә язучылар аздыр дисеңме? Мин белгән атаклы язучылар гына да егермеләп бит анда!..

Ләкин, шулай икәнен белсәм дә, кечерәк кенә бер хикәя язып карау теләге кытыклап йөри башлады бит күңелне. Язарга материалым да бар. Әйтик, берсе менә болай. Армиядә хезмәт итә башлагач, бергә укыны бетергән Флера исемле кыз аркылы Р. ның адресын сорап алып, хат алыша башлаган идем мин. Р., чыннан да, педучилищеда укый булып чыкты. Солдат булгач мин дә үземне чын егет итеп саныйм, Р. га язган хатларымда күңелемдәге фикерләрне ачыктан-ачык әйтеп яза башлаган идем. Башта рядовой, аннары кече сержант формасы киеп төшкән фоторәсемнәремне дә җибәрдем. Ул да миңа студент булгач төшкән рәсемен җибәргән иде. Хатларын бик җылы итеп, шактый еш язып тора. Без аның белән бер-беребезне күтәргә сүз куешкан идек.

Шулай үзара серләшеп, ел ярым чамасы хат алыштык без аның белән. Ләкин кинәт аның хатлары өзелде. Аннары ул: «Син миңа бүтән хат язма. Мин кияүгә чыктым инде. Моңа артык борчылма. Сиңа да насыйбы булыр. Миннән дә әйбәтрәк кыз табарсың әле. Хуш!» — дип язып җибәрде.

Аның мәсьәләне әнә шулай ансат кына, нинди дер бик гадәти нәрсә шикелле итеп кенә хәл кылуы, шуның өстенә тагын акыл өйрәтеп язуы, башта мине берничә көнгә өнсез итте, аннары, җен ачуларымны чыгарып, күңелемдә нәфрәт уятты. Соң шулай булмыйча! Син, понимаешь, монда җаның-тәнең белән аңа тугрылыклы булып, дөньяда тынычлык саклап, илгә хезмәт итеп ят, ә ул, сине пешка урынына да күрмичә, икенче берәүгә кияүгә китеп барсын, имеш. Кая монда безнең татар кызларына

хас тугрылык? Кая аның биргән вәгъдәләре? Бу бит... йомшак кына итеп әйткәндә дә кешелексезлек дип атала. Бәлки әле хыянәт дип атарга да ярый торгандыр...

Менә шул вакыйганы тагын да куерта төшеп, Р. ны совет солдатының чын хисләрен аяк астына салып таптаучы итеп күрсәтеп хикәя язганда начар булмас иде. Янган йөрәк тә азрак басылыр, минем хикәяне укыса Р. да үрле-кырлы сикерер һәм гомере буена үкенеп яшәр сыман иде. Ләкин соңыннан бу уемнан кире кайттым: хыянәтчене әдәби герой итеп күрсәтәсем килмәде...

Шулай да күңелне кытыклап йөргән хикәя язып карау ниятен гамәлгә ашыру өчен җае килеп чыкты. Безнең ротаның беренче взвод командиры өлкән лейтенант Смирнов — сугышта катнашкан һәм Берлинга кадәр барып җиткән, сугыш беткәч ГДРда өч ел хезмәт иткән кеше. Ротада политзанятие үткәргән вакытларында ул фронтта үз башыннан үткән хәлләр турында да сөйли. Без аны бик кызыксынып тыңлый идек. Чираттагы әңгәмәләрнең берсендә ул безгә ГДРда хезмәт иткән чагында Карл исемле немец карты белән танышырга туры килгәнен һәм ул карт авызыннан ишеткән бик гыйбрәтле бер вакыйганы сөйләде.

... 1945 елның май башында булган ул хәл. Совет Армиясе гаскәрләре немец гаскәрләрен кысрыклап, Берлинга якынлашып килә. Сизенә немец карты Карл: никадәр генә каршылык күрсәтергә тырышсалар да, гитлерчылар җиңеләчәк. Мондый хәлдә сугышып азаплану — бер дә юкка кан коюы гына. Шулай булгач, русларга бирелергә дә, әле исән булган немец солдатларын үлемнән саклап калырга кирәк. Шуннан да яхшысы булмаячак, дип уйлый ул. Бу уен таныш-белешләренә дә әйтә. Һәм менә шул җитә кала: фюрерга каршы коткы таратуда гаепләп, Карлны хәрби трибунал судына бирәләр һәм атарга хөкем итәләр. Шул хөкем карарын җиренә җиткерү өчен алып барган чакта, бәхетенә туры килеп, бер совет разведчигы Карлны саклап баручы ике немецны атып ега. Ә Карлны үзебезнекеләр ягына алып чыга. Соңыннан алар танышып китәләр һәм безнең разведчик, истәлек итеп, Карлга фоторәсемен бүләк итә. Фотосының артына исемен дә язып бирә. Ләкин, кызганычка каршы, фамилиясе белән адресын разведчик үзе язмаган, ә Карлның сорап алырга башына килмәгән. Карл хәзер әнә шул солдатка — Фәрит исемле татар егете була ул — хат язарга бик тели, ләкин кая язарга белми икән. «Менә шушы кеше сиңа таныш түгелме? Аның кайда икәнен белмисеңме?» — дип, Карл безнең өлкән лейтенант Смирновка Фәритнең фотосын күрсәтә.

— Унсигез-егерме яшьләр тирәсендәге, түгәрәк кенә кара-тут йөзле, себер татарларыныкы сыман кысыграк күзле, текә маңгайлы ул солдат, нәкъ шул Карл күрсәткән рәсемендәгечә һаман күз алдымда тора да тора,— диде безгә өлкән лейтенант.— Очрамасмы шул егет дип карыштырып та йөрим. Аны табып, Карл картны куандырасым килә. Ләкин очрата алганым юк. Ә эзләтеп карарга — фамилиясе билгесез...

Шушы вакыйганы ишеткәннән соң, берничә көн бик нык дулкынланып, уйланып йөрдем. Фәритне табасым, таба алмасам, аны теге немец агае эзләгәнен ничек тә үзенә ирештерәсем килә иде. Шул теләк дүртенче көнне кулыма каләм алырга мәҗбүр итте: гомеремдә беренче тапкыр хикәя язарга утырдым.

Утыруын утырдым, ләкин ничек башлап китәргә? Әдәби әсәрдә вакыйганы сөйләп чыгу белән генә эш бетми бит. Анда вакыйганың урыны, вакыты күрсәтелергә, вакыйганы бәян итү табигать күренешләре белән бәйләп алып барылырга тиеш. Без укыган әдәбият дәреслегендә шулай дип әйтелгән. «Совет әдәбияты» журналында чыга торган тәнкыйть мәкаләләрендә әдәби әсәрләрне әнә шул җәһәттән чыгып тикшерәләр иде. Минем Герман җирендә беркайчан булганым юк. Ә ялганлап язарга булдыра алмыйм. Күпме тырышып та башлап китә алмагач, язуны ташлап торып, китапханәдән Германиягә кагылышлы китаплар алып, шуларны укырга тотындым. Мин хикәялисе вакыйга Берлиннан сиксән-йөз чакрымнар

көнчыгыштарак булган икән. Теге китаплардан Берлин тирәләренең табигатен сурәтләгән урыннарны табып укып-укып карыйм, ләкин анык кына бер картина күз алдыма килми, чөнки һәр китапта үзенчә сурәтләнгән. Юк, бөтәннәр язганны укып кына әллә кая китеп булмый икән. Белмәгәнне язып кеше көлкесенә калганчы, язмый калуың биш артык.

Шулай уйладым да ул хикәяне язмаска булдым.

Әмма лейтенант Смирнов сөйләгәннән күңелемдә туган Фәрит образы миңа һаман тынгылык бирми, ничек итеп булса да, аның хакында матбугат аша кешеләргә сөйләп бирәсе килә. Немец картына фоторәсемен калдырып киткән Фәрит әле үзе дә исәндер, мин язганны укыгач, кайда яшәвен әйтеп хәбәр бирер шикелле иде. Тик мәнә ничек кешеләрнең игътибарын җәлеп итәрлек итеп язарга соң?..

Шулай гаҗизләнеп йөргән көннәремдә «Известия» газетасында басылган бер мәкаләгә юлыктым. Безнең ил авыл хуҗалыгы белгечләреннән торган делегациянең ГДРга барып, андагы авыл хуҗалыгы эшләренең куелышы белән танышып кайтуы турында отчет рәвешендә язылган гап-гади мәкалә иде ул. Ләкин шул мәкаләдә нәкъ менә миңа кирәк булган Берлин тирәсендәге хуҗалыклар хакында сүз бара. Һәм әнә шул хәбәр инде булмый дип ташлаган хикәямә яңадан тотынырга этәргеч булды. Бәхеткә каршы дип әйтергә кирәктер, нәкъ шул көнне рота буенча дежур итеп билгеләнгән идем: отбойдан соң Ленин бүлмәсенә кереп утырдым да иртәнге подъемга кадәр яздым да яздым...

«Кайда син, Фәрит?» дигән беренче хикәям әнә шулай дөньяга килде.

Мин аны 1957 елның июнендә язган идем. Ләкин бер редакциягә дә җибәрмәдем: йөрәгем җитмәде. Газета өчен зур, ә «Совет әдәбияты»нда андыйлар болай да күптер, минекен укып та тормаслар, чүплеккә генә ташларлар да бөтенләй югалып калыр дип курыктым. Истәлек булыр дип, альбом эченә, фоторәсемнәр янына тыгып куйдым. Университетның өченче курсында укыганда гына искә алдым мин аны. Шул көннәрдә «Социалистик Татарстан» газетасы халыклар дуслыгы темасына язылган хикәяләргә ябык конкурс игълан иткән иде. Ачык конкурс булса, мөгаен, җибәрергә җөрьәт итмәс идем. Ә болай, үз фамилияң белән җибәрәсе булмагач, тәвәккәлләдем. Басылырына өметем әллә ни түгел. Чөнки минем хикәям, бердән, күләме белән конкурс шартларына туры килеп бетми: анда 10-12 биттән артык булмасын диелгән, ә минем хикәя унөч биттән дә артык иде. Икенчедән, язучылар һәм журналистлар арасында төрле конкурсларга катнашып, шомарып беткән тәҗрибәле кешеләр аздыр дисеңмени? Дөрес, хикәянең авторы билгеле булмау чак кына ышаныч уята уятуын. Ләкин, тозсызны күзсез дә таный дигәндәй, авторы күрсәтелмәсә дә, редакциядә утыручы кешеләр чамалый торгандыр. Күренекле әдипләр язган хикәяләрне берничә җөмләсен уку белән үк танныйдыр алар. Шулай булгач, минекен укый башлау белән, тәҗрибәсез кеше язганын аңлап алып, кәрзингә ташламаслар дип кем әйтә ала? Җитмәсә, кульязма авторына хат язып, нигә бастырмауларын аңлатып торасы да юк: «Конкурска килгән кульязмалар рецензияләнми, кире кайтарылмый»,— дип әйтелгән анда.

Шулай да хикәямне җибәргәннән соң «Социалистик Татарстан» газетасының һәр санын карап бара башладым. Конкурска килгән хикәяләр чыккалап тора. Укып карыйм, алай аһ итәрдәйләре күренми. Тәҗрибәле язучыларныкы булса кирәк, кайберләренең теле шундый шома — су кебек агып кына бара. Укый башласаң аерыла алмыйсың. Тик шунысы гаҗәп: укып чыккач ук онытылалар, күңелгә берни йогып калмый. Ә кайсыларының үзәккә алып сурәтләгән вакыйгалары ышандырмый, бармактан суырып язылганы әллә каян «бәреп» тора. Хәер, моның миңа гына шулай булып тоелуы да бик мөмкин, чөнки бу очракта миңа объектив фикер йөртү кыен булгандыр.

Ләкин, ничек кенә булмасын, басылган әйберләрдән чыгып фикер йөрткәндә, минеке дә бөтенләй буш булырга тиеш түгел. Әгәр гаделлек белән эш итсәләр, редакция хезмәткәрләре минем хикәягә дә газетада урын кызганмаска тиешләр...

Күңелем дөрес чамалаган икән: җибәрүемә ай ярымлап үткәч, минем хикәям газетада басылып чыкты. Шунысы бигрәк гаҗәп тоелды: аның бер сүзен дә үзгәртмәгәннәр, нәкъ мин язганча бастырып чыгарганнар иде.

Ул көнне ничек куанганымны сөйләп кенә аңлата торган түгел. Очраган бер кешегә газетаны күрсәтеп, менә бу мин язган хикәя, сез аның авторы Нурулла Вакыйфов[1] булганга карамагыз. Мин, Вакыйф Нуруллин язган әйбер бу! — дип кычкырып йөриселәрем килде. Кыскасы шул: дөньяда егерме биш ел яшәп, моның шикелле үк бәхетле булганым юк иде әле. Шулай булмыймы соң? Газетаның тиражы җитмеш сигез мең. Бер газетаны кимендә өч кеше укый да укый инде аны. Димәк, ике йөз меңнән артык кеше укыячак минем хикәяне! Ике йөз мең кешене җыйнап, рәт-рәт тезеп куйсаң, йөз чакрымга сузылачак лабаса аларның сафы. Нуҗәли шулар арасында Фәритне белә торган бер кеше дә булмас икән?..

Хикәя басылып чыкканга унбиш көн үтте, ай узды, ләкин Фәритне белүче кешеләрдән хат-хәбәр килмәде.

Аннары конкурска йомгак ясалып, аның нәтиҗәләрен газетада бастырып чыгардылар. Беренче премия бирәүгә дә бирелмәгән, икенче-өченче премияләр кемгә бирелгәнен хәтерләмим, ә минем хикәягә кызыксындыру премиясе бирелгән иде. Дөресен генә әйткәндә, бүләк үк алырмын дип башыма да китермәгән идем. Чөнки миңа хикәямнең басылып чыгуы да җитеп ашкан иде.

Шуннан соң мин инде ныклап торып, төннәр буе утырып хикәяләр язарга тотындым. Киногә йөрүләр, танцыга чыгулар гына түгел, хәтта дөньяда кызлар барлыгы да онытылды. Бүлмәдәш егетләрнең кызлар янына киткән чаклары — минем өчен иң кадерле минутлар: алар өйдә юкта рәхәтләнеп язып утырам.

Ләкин язу дигән нәрсәнең бер хикмәте бар: теләсәң кайчан язып булмый икән аны. Кайчак бүлмәдәш малайлар өйдә булмаганда да дүрт-биш сәгатькә юньле бер җөмлә дә язылмый. Ручка башын кимереп утырасың-утырасың да, җен ачуларың чыгып, койкага барып авасың. Ә күңелдә һаман шул язылачак хикәя. Анда сурәтләнәчәк вакыйгаларны, ул вакыйгаларда катнашачак кешеләрне син инде тере итеп күз алдыңа китерәсең, алар белән сөйләшәсең, бәхәсләшәсең. Алар — синең өчен җанлы, реаль кешеләр. Ләкин шуларны укучыга да җанлы булып күренерлек итеп сурәтләп бирергә җае, хуты табылмый. Хикәяне башлап китеп булмыйча интегелә. Яки язып утырган чакта бер җиргә килеп төртеләсең дә ары таба алып китә алмый интегәсең. Син шулай газапланып утырган арада, шау-гөр килеп, бүлмәдәш егетләр кайтып керә дә:

— Һоо! Бальзак! Һаман шулай яшь гомереңне әрәм итеп утырасыңмы?

— Юкка маташма, барыбер Галимҗан Ибраһимов була алмассың! Татарның классиклары болай да күп инде аның: укып бетерерлек түгел әсәрләрен. Киләчәк буын студентларны кызган: аларга тагын эш өстәмә! — дип авыз ерырга тотыналар.

Алар белән бәхәсләшүдән файда юк: барыбер җиңеп булмаячак, чөнки алар өчәү. Шуның өстенә, таш астыннан чыккандай, бик үткен малайлар. Алар синең менә шушылай газапланып иҗат итүнең бернинди киного, бернинди танцыга һәм дөньядагы иң чибәр кызларга да алыштырмаслык дәрәҗәдә татлы икәнен, әйтеп-аңлатып булмаслык рухи рәхәтлек бирүен аңлыйлармыни?

Андый чакта алар тынычланганчы коридорга чыгып торасың да, шыпырт кына кереп, койкаңа ятасың. Ләкин күзгә йокы керми. Күңелдә

[1] Хикәямне конкурска шул псевдоним белән җибәргән идем. (Автор)

гел бер уй: төртелеп калган хикәяне ничек дәвам итәргә? Иптәшләр инде күптән рәхәтләнеп, төш күрә-күрә, саташа-саташа йоклый. Ә син күңелеңдә үзең тудырган кешеләр белән мәш киләсең. Бүлмәдәш егетләр сизмәсен дип, сулышыңны яртылаш кына ала-ала торып утырып, яктысы дәфтәр бите турына төшәрлек итеп кенә калдырып, өстәл лампасына сөлге урыйсың һәм, дөньяңны онытып, хикәяңне дәвам итәсең. Әгәр инде теге «Газраил»ләрнең берәрсе уянып:

— Син тагын утны кабыздыңмыни әле? Сүндер хәзер үк! Югыйсә иртәгә студсовет алдында аңлатма бирергә туры киләчәк! — дип гауга күтәрә башласа, коридорга чыгып язуны шунда дәвам итәсең. Андый чакта кайда язуның әһәмияте юк. Андый чакта кайда язсаң да — күңелдәгечә, син теләгәнчә языла. Мине андый чакта бүлмәдәш егетләрнең көлүе дә, ачуланулары да, семинарларга, зачетларга әзерләнәсе булу да куркытмый. Ташла язуыңны, ташламасаң, университеттан чыгарабыз дисәләр дә, язуымны туктатачак кеше түгел мин...

Ә кай чакларда яза торган җиремдә төртелеп калып, аны дәвам итәргә җаен тапмыйча унбишәр көн, берәр ай йөрергә туры килә. Андый вакытларда, бердән, онытылып торып, үземне тынычландырыр өчен, икенчедән, гыйбрәт алу, тәҗрибә туплау өчен, Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимов, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники әсәрләрен укырга тотынам. Шәриф Камалның кыска гына (нибары өч-дүрт битлек) хикәяләрендә дә образларны җанлы һәм укучы хәтеренә сеңеп калырлык итеп сурәтләп бирә алуы; Галимҗан Ибраһимовның персонажларның эш-гамәлләрен һәм рухи халәтләрен табигать белән аерылгысыз бәйләп, вакыйгаларны романтика белән өртеп күрсәтеп бирә алу осталыгы; Ибраһим Газиның вакыйгаларны конкрет-кырыс һәм шул ук вакытта астыртын юмор белән сурәтләве, Әмирхан Еникинең бәләкәй генә вакыйганы да тәфсилләп, җелекләргә үткәреп «савып утыруы» мине хәйраннарга калдыра... Рус язучыларыннан Чехов, Бунин, Паустовский хикәяләре, чит ил язучыларыннан Эдгар По, О'Генри, Ги де Мопассан хикәяләрен кат-кат укыйм. Аларның сюжет-композиция төзү осталыгына, кешеләрне тере итеп, аларның уй-хисләрен бөтен нечкәлекләре белән ачып бирә алуларына исләрем китеп, уйланып йөрим... Ә күңелнең бер почмагында өзелеп калган хикәя һаман үзен искәртеп, тынгысызлап тора. Һәм, бер дә бер көнне, үзем дә сизмәстән, мин аны дәвам итү өчен кирәкле «хутын» табам да, тагын, дөньямны онытып, яза башлыйм...

Ләкин болары аның мин инде студент булып укый башлагач булган хәлләр. Мин бит әле кайчан һәм ничек студент булганымны сөйләмәкче идем...

Армиядә инде өченче елымны хезмәт итәм. Без инде «карт» солдатлар. Барыбызның күңелендә бер уй: хезмәтне тутырып, тизрәк «гражданка»га кайту. Армиядән соң кая бару, ни эшләү хакында да еш сөйләшәбез.

Минем әлегә анык фикерем юк. Әнием белән энем Равилне бик сагындым. Инде өченче ел аларны күргән юкка. Минем кебек сержантларның берничәсе инде икешәр тапкыр кунакка кайтып килде. Ә миңа хезмәтем тәмамланганчы кайтып килергә тәки насыйп булмас, ахры.

Хезмәтен яхшы башкарганы өчен яисә берәр якын туганы авырып китеп, военкомат имзасы куелган чакыру телеграммасы килгәндә бүтән солдат-сержантларны кайтара торалар. Хезмәтемне мин дә начар башкармыйм. Отделениемнең рота күләмендә генә түгел, зуррак ярышта да беренче урынны алган чаклары булды. Бу ел Май бәйрәмен лаеклы каршылауга багышланган ярышта да безнең отделение җиңеп чыкты. Шуның өчен бер солдат белән миңа ун көнлек ялга кайтып килергә приказ булган иде. Солдат кайтып килде. Ә мин ымсынып кына калдым. Үземнең гаеп аркасында түгел. Отделениенең бер солдаты (үзен генә ярата торган мәгънәсез бер егет иде ул) Май бәйрәменә каршы төнне «самоволка»га чыккан да комендатурага эләккән иде. Ә бу — бик зур ЧП дигән сүз. Шуның аркасында мине кунакка кайтар-

мадылар һәм инде алып куйган билетымны кире илтергә туры килде.

Ә узган ел чаңгыда йөгерү буенча дивизия беренчелегенә үткәрелгән ярышта икенче урынны алган идем. Шуның өчен кунакка кайтармакчылар иде.

Әмма кайта алмадым. Үзем гаепле булдым. Иртәгә кайтып китәсе дигән көнне, бар кирәк әйберләреңне алып куй, поездга барганда гына алып өлгерә алмассың, дип капитан миңа биш сәгатькә увольнение биргән иде. Солдат өчен биш сәгате түгел, бер сәгате дә бик кадерле ул увольнение дигән нәрсәнең. Шул шатлыктан башым әйләнеп киткән, күрәсең, увольнение кәгазен ротада онытып калдырганмын. Ленинградка барып керү белән, мине патрульләр эләктереп алды. «Бәйләнүләренең» сәбәбе шул: урамның икенче ягыннан миңа каршы килүче бер кече лейтенантка честь бирмичә үткәнмен икән. Ә бу инде уставны бозу дигән сүз. Увольнение кәгазем булган булса, әллә шуңа язып җибәрү белән дә чикләнгән булырлар иде. Ләкин кәгазем юк иде шул. Шуннан нәрсә: алып киттеләр комендатурага. Дежур торучы полковник кушуы буенча, бер капитан миннән уставның статьяларын сораштырырга тотынды да, мин барысын чатнатып сөйләп биргәч (строевой уставны яттан беләидем), артык бәйләнеп тормады. Дежур полковник янына алып барып:

— Сезнең боерыгыгызны үтәдем, иптәш полковник. Строевой уставны сержант яттан белә! — дигәч, хәзер үк частька кайтып комендатурага ни өчен эләгүемне рота командирына әйтергә кушып, чыгарып җибәрделәр.

Комендатурада йөреп, биш сәгатьнең ике сәгате инде үтеп тә киткән иде. Әгәр частька кире кайтып, рота командирына доложить итеп тә йөрсәм, (әллә туры килә эле ул, әллә юк!), күпме генә вакытым кала. Аннары килеп, кеше төсле йөри белмисең икән, үзеңә үпкәлә дип, капитанның мине кабат чыгармавы да бар иде. «Ничава, яна торган әйбер түгел, кайткач доложить итәргә дә өлгерермен әле»,— дидем дә кибетләргә кереп, әнигә күлмәклек бик матур чәчәкле ситсы, кызыл эчле галуш (әнинең гомер буе кызыккан нәрсәсе), плюш бишмәт, Равилгә якалы әйбәт пальто (күпме кызыгып та, армиягә кадәр үзем тәки тиенә алмаган нәрсә!), кер күтәрә торган коңгырт ситсы күлмәк, простой материалдан тегелгән һәм, арзан булса да, ул елларда модада булган киң балаклы бик шәп матрос чалбары алдым.

Ике култык астыма ике зур төенчек күтәреп частька кайтып кергәндә увольнением бетәргә ун минутлап вакыт бар иде әле. Әнигә конфет-шикәр, юлга азык-төлек шикелле нәрсәләр генә аласы калды, аларын китеп барышлый вокзал тирәсендәге кибетләрдән дә алырга булыр, дип, бүтән хәвеф-хәтәргә юлыкмыйча кайтып җитүемә бик сөенгән идем. Әйберләремне куйыйм да, комендатурага ни өчен алып барганнарын капитанга әйтермен дип, казарма ишегеннән кереп җитәргә дә өлгермәдем, дневальный:

— Иптәш сержант, срочно к командиру роты! — дип кычкырды.

Күрәсең, капитан мине шахмат уйнарга чакыргандыр дип уйладым. Шуңа бер дә хәвефләнмичә һәм ашыкмыйча гына кергән идем. Ләкин кәнсәләргә килеп керүем булды, капитан утырган җиреннән сикереп торды да:

— Эх, Наруллин![1] Наруллин! Нәрсә эшләдең син? Син нәрсә эшләдең, ә?! — диде.

— Юри эшләнгән эш түгел ул, иптәш капитан. Мин ул кече лейтенантны бөтенләй күрмәдем: урамның икенче ягында булган бит ул,— дидем мин, эшнең нәрсәдә икәнен шундук сизенеп һәм акланырга тырышып.

— Синең кайдан барган булуыңның хәзер инде һичнинди әһәмияте

[1] Ул минем фамилияне һигәдер гел шулай әйтә торган иде. (Автор).

юк. Соң инде! Комендатурадан чыгу белән туп-туры минем янга кайтырга иде сиңа. Ә хәзер эш зурга китте. Син чыгып киткәнгә ике сәгать үткәч, кайтып җиттеме әле дип, комендатурадан шалтыратканнар. Штаб дежурные рота дежурныена шалтыраткан. Ә син юк. Шуннан ун минут саен шалтыратып, сорап тора башлаганнар. Син һаман кайтмагач, инде менә мине өйдән чакырып алдылар. Башында мие булган кеше андый чакта шушылай эшлиме инде, ә?

— Увольнениедән кайткач доложить итәрмен дигән идем, иптәш капитан.

— Юк! Сиңа иң элек комендатура дежурныеның приказын үтәргә кирәк иде! Кадалып китсен иде увольнениесе. Кайтып доложить иткән булсаң, мин сине тагын чыгарыр идем. Ә хәзер... Билет алган идеңме кайтырга?

— Юк әле, кайтышлый алырмын дигән идем.

— Анысы ярый икән,— диде капитан, азрак тынычланып.— Югыйсә кире илтеп йөрергә туры килер иде.

— Нишләп, иптәш капитан?

— Ә син шуны аңламыйсыңмы?

Аңлый идем әлбәттә: приказны үтәмәгән өчен. Ләкин шул юк кына нәрсәдән башланган эш өчен кунакка кайтармыйча калдырырлар дип башыма да китерми идем. Капитан моны мине куркытыр өчен, юлда йөргәндә игътибарлырак булсын дип кенә әйтәдер дип уйлаган идем.

Соныннан аңлашылды: хикмәт капитанда түгел, хикмәт отряд дежурныенда булган икән. Минем хакта комендатурадан шалтыратуларын ул отряд командирына доложить иткән. Күрәсең, кәефе шундыйрак чакка туры килгәндер, командир мине кунакка кайтарырга дигән приказны юкка чыгарырга боерган икән.

Менә шул. Инде бөтенләй әзерләнеп беткәч кайта алмыйча калдым. Әни белән Равилгә алган бүләкләрне посылка белән җибәрергә туры килде.

Бу хәл минем өчен мәңге онытылмаслык сабак булды.

Шуннан соң мин үземә бирелгән боерыкларның барысын да вакытында һәм төгәл итеп үтәп бара торган булдым.

Ярый, сүз армиядән кая кайту хакында иде бит әле. Әйе, әнине, Равилне һәм гомумән, бөтен авыл халкын, безгә печәнен, утынын, чикләвеген, җиләген һәм чабата ясарга юкәсен биреп торган урманыбызны, Урманасты болынын, Зур һәм Кечкенә чишмәләрне бик сагынам. Андый чакларда: «Хезмәтем тулу белән туп-туры авылыбызга кайтып китәргә кирәк. Шоферлыкка яки трактор йөртергә укырмын да рәхәтләнеп колхозда эшләрмен. Тиздән авыл җирендә дә тормышлар арулана башларга тиеш. Эшләр шулай таба бара. Эшләгән кешенең кадере анда да булыр. Ә мин эштән курыкмыйм»,— дип уйлап куям. Иптәшләр чирәм җирләрдә эшләүче таныш-белешләреннән хат алгач, эшкә шунда китү хакында сөйләшә башласалар, әллә шунда китим микән дә, акча туплап, машина алып кайтып, бөтен авылны шаккаттырыйм микән, дип тә алгысып куям. Ленинградта калырга да ымсынгалыйм. Калырга мөмкинлеге бар: радиодан да, газета аша игъланнар биреп тә төрле завод-фабрикаларга эшкә чакырып торалар. Мәгъсүмәнең олы малае Ленинградның үзендә урнашып калган, фәлән хәтле акча алып эшли икән, дип тел шартлата-шартлата сөйләсеннәр иде бер авыл агайлары. Шул егет мине яратып йөргән иде бит, кадерен белмәдем, кадерен белеп әйбәт кенә йөргән булсам, мине дә үзе янына алдырыр иде, үзем юләр булдым шул дип, Р. дә үкенеченнән нишләргә белмәс иде...

Хыял гына булып калган университетка керергә тагын бер талпынып карыйсы да килә. Әгәр шул хыялыма ирешеп, университет студенты булып китсәм, Р. үкенеченнән үрле-кырлы сикерер иде аннары, дип тә уйлыйм. Шул ук вакытта куркыта да. Унны гына бетерүемә инде өч ел үтте. Өч ел буена дәреслек дип әйтмим, хәтта бер татар китабы укып караганым

юк. Ә бит имтихан бирә башласаң, урта мәктәпне быел гына укып бетергән һәм яхшылап әзерләнеп килгән кешеләр белән рәттән торып бирергә туры киләчәк. Өч ел буена гел русча сөйләшеп йөргәннән соң бернинди әзерлексез ничек татарча сочинение язмак кирәк. Коры теләк белән генә әллә кая барып булмас анда. Бер генә тыныш билгесен дөрес куймасаң да, бәяне бер баллга киметәләр ди бит... Тарихны, географияне табып укырга булыр анысы. Алары китап кибетләрендә бар. Русча булуларының зыяны юк кына түгел, киресенчә, татар баласы ул фәннәрдән имтихан тапшырганда русча сөйләшеп тапшыра алса, дәрәҗәләрәк санала. Ләкин, ничек кенә булмасын, төп фәннәрне — татар телен һәм татар әдәбиятын — ныклап торып белмәгәч, ерак китә алмассың. Йөреп-йөреп тә тагын университетка керә алмыйча калынса, ни эшләрсең? Әни күзенә, авыл халкы күзенә ничек күренерсең? Р. да куаначак кына. Минем арттан йөргән булды, ә үзе, әнә, провалить итеп кайткан имтиханнарын. Ярый әле булдыксыз кеше икәнен вакытында сизеп калганмын, дип борынын тагын югарырак чөячәк ул. Ә мин алай булуын теләмим!.. Дөрес, армия хезмәтеннән кайткач әзерләнергә вакыт булыр анысы. Ноябрьдә кайтсаң да имтиханнарга ун ай вакыт калачак. Ләкин инде өч ел укымый торганнан соң яңадан китапка тотынасы килер микән соң? Армиядән кайткач минем кебек егетләр өйләнеп тормыш корып җибәрә бит...

Мин әнә шулай әүле-тәүле булып, конкрет бер карарга килә алмыйча йөргәндә мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителде дә куйды. Өлкән буын кешеләре хәтерлидер, 1957 елның маенда хөкүмәтебезнең армиядә соңгы елларын хезмәт итә торган һәм югары уку йортларына укырга керергә теләгән урта белемле солдатларны һәм сержантларны хезмәттән гомуми демобилизациядән алданрак, вузларга кабул итү имтиханнарына өлгерерлек вакыт калдырып кайтарырга дигән карары чыкты. Капитан белән бер кичне икебез шахмат уйнап утырганда шул хакта сүз китте дә әйтте бу миңа:

— Әгәр вузга керергә теләсәң, сине дә җибәрергә мөмкин булыр, Наруллин. Исәбең ничек?

— Укырга ният барын бар да, әзерләнергә мөмкинлек юк бит, иптәш капитан.

— Ял көннәрендә, хезмәттән буш сәгатьләрдә әзерләнерсең.

— Хикмәт вакыт булмауда түгел. Дәреслекләр юк.

— Булачак: отряд китапханәсенә дәреслекләр алырга боерык бирелде.

— Миңа бит татар дәреслекләре кирәк.

— Ах, менә ничек! Алайса, берәр туганыңа хат язып, соратып ал!

— Рәхмәт, иптәш капитан. Чыннан да, шулай эшләргә кирәк булыр. Ә укырга керергә кайдан һәм кемнән рөхсәт аласы икән?

— Бик гади эшләнә ул: аттестатыңны җибәрүләрен сорап, иртәгә үк өегезгә хат яз. Кара аны, заказной итеп җибәрсеннәр, юлда югалырлык булмасын. Аттестатың килгәнче без монда синә хезмәтең турында характеристика язып куярбыз. Фоторәсемнәреңне әзерләп куярсың. Медицина белешмәсе кирәк булачак, аның да хәстәрен күрә башла. Өегездән аттестат килгәч, шул документларның барысын бергә үзең керергә теләгән институтка җибәрерсең дә имтиханга кайтырга чакырып язылган кәгазьне көтеп торырсың. Кәгазь килгәч, имтиханнарга ун-унбиш көн кала кайтарып җибәрәчәкләр.

— Ә конкурстан үтә алмаган яисә имтихан барышында төшеп калган кешеләр хезмәткә яңадан кайтырга тиеш буламы?

— Юк, бер-ике ай өчен кире чакырып тормаслар дип уйлыйм. Ну, ничек, тәвәккәллисеңме?

— Тырышып карарга кирәк, иптәш капитан.

Әнә шулай бер сөйләшүдә хәл ителде мәсьәлә. Укырга керә алсам — бик шәп! Керә алмасам да үкенеч зур булмый. Авылга имтиханнарны биргәч кенә кайтачакмын. Һәм анда минем белән ниләр булганын беркем

дә белми калачак. Ул елны Равил унынчыны бетереп йөри, аннан дәреслекләрен сорап алдырырга да була иде. Ләкин мин сорап тормаска уйладым. Сорасаң, ни өчен кирәк булуын әйтергә туры килә. Әйтсәң, авызында сүз әллә тора аның, әллә юк.

Ә аттестатны хезмәт буенча кирәк, штабтан сорыйлар дип алдырдым.

Документларымны әзерләп җибәрүгә ике атна да үтмәде, миңа имтихан тапшырырга рөхсәт ителүен әйтеп, беренче августка кайтып җитәргә чакырып, университеттан язу килде.

Имтиханнар башланырга әле айга якын вакыт бар иде. Буш минутларымда тарих белән география дәреслекләрен укый башладым.

Укырга керергә теләүчеләр безнең отрядта нигәдер бик аз — өч кенә кеше идек. Тула егете Николай Демидов, латыш егете Эдуардас Витаускас һәм мин. Эдуард — Риганың граждан авиациясе институтына, Демидов Крупская исемендәге Мәскәү techинститутына керергә җыеналар. Икесе дә белемле, төпле егетләр. Николай хәтта армиягә кадәр бер ел мәктәптә укытып та килгән. Эдуард да авиацияне бәләкәйдән ярата. Мәктәп елларында үзе ясаган авиамодельләр белән ярышларда катнашкан егет. Институтка кабул иткәндә болар барысы да исәпкә алыначак, әлбәттә. Тик минем генә бернинди «өстенлегем» юк. Үзебезнең округ газетасында басылган мәкаләләрем барын бар да, ләкин алар русча язылган шул. Ә миңа татар телен әйбәт белүемне раслый торган дәлилләр кирәк. Шуңа күрә Николай белән Эдуардка караганда мин күбрәк борчылам. Николай мине тынычландырырга тырыша: «Курыкма, андыйлар бер син генә булмассың. Мәкаләләрне русча әйбәт кенә язасың бит, татарча сочинениене генә ничек тә «дүрт»кә язарсың әле! Сиңа шулай язсаң бик җитәчәк»,— ди.

Июльнең егермеләреннән соң без, өч егет, көн саен очрашып, хәл белешеп тора башладык. Иштүебезгә караганда, кайбер частьлардан безнең ише укырга теләүчеләрне инде кайтара башлаганнар. Ә безгә беркемнең берни әйткәне юк әле.

Шул хәлгә борчылып, июльнең егерме алтысында өчебез бергәләп ул Дерябин янына штабка бардык.

— Болай булса, без беренче августка кайтып җитә алмыйбыз бит, иптәш майор. Әллә безне җибәрмәскә булдыгызмы? — диде Демидов.

Мин сездән нәкъ менә шул сорауны көткән идем, дигән шикелле итеп, замполит үзалдына елмаеп куйды:

— Эш миннән генә торса, инде күптән җибәргән булыр идем,— диде ул.— Приказ юк бит. Борчылмагыз, булыр. Приказ килү белән минут та тоткарламаячакбыз. Чемоданнарыгызны әзерләп куегыз һәм көтегез. Менә шул. Китәргә мөмкин.

Без штабтан чыгып аз гына киткән идек, дежурный артыбыздан чыгып:

— Товарищи сержанты, к майору! — дип кычкырды.

Без сөйләшеп торган арада югарыдан телефонограмма килгән. Анда Николай белән Эдуардны кайтарырга боерылган иде.

— Ә сиңа, иптәш Нуруллин, нигәдер приказ юк әлегә,— диде майор, миннән дә болайрак үзе борчылып.

Мин аптырап калдым. Нәрсә булган? Нигә минем үземне генә калдырганнар? Соңрак китсә дә өлгерер, дигәннәрдер дияр идең, Николайның да, Эдуардның да кайтыр җирләре минекеннән якынрак. Ә миңа аз дигәндә дә, юлга тәүлек ярым кирәк.

Тиз генә әйберләрен алып штабка килергә кушып, Дерябин Николай белән Эдуардны чыгарып җибәрде.

— Ә син утырып тор,— дип, мине үзе янына калдырды. Дивизия штабына шалтыратып, минем мәсьәләне ачыкламакчы иде ул. Ләкин безгә кирәкле кеше урынында юк, ә бүтәннәре өзеп кенә берни дә әйтә алмадылар.

Олы башын кече итеп, аның минем өчен шушылай тырышуына исем китеп утырдым. Мин бит аңа бөтенләй чит-ят гап-гади бер сержант. Әгәр мине бүген кайтарып җибәрәләр икән, без аның белән бүтән очраша алуыбыз да бик шикле. Ә ул, әнә, үз туганы шикелле итеп, чын күңеленнән миңа ярдәм итәргә тырышып йөри. Аның урынында башка берәү булса, мин берни эшли алмыйм, приказ юк бит, дияр иде дә кайтарып җибәрер иде.

— Ярар, сержант,— диде ул, шалтыратып-шалтыратып та мәсьәләнең очына чыга алмагач.— Бар, кайт һәм тыныч кына көт. Монда ниндидер аңлашылмау килеп чыккан булырга тиеш. Бер сине генә калдырмаслар дип уйлыйм. Иртәгә үзем барысын ачыкларга тырышырмын.

Ләкин иртәгә дә, аннан соң да боерык килмәде мине кайтарырга. Кемдер җибәрергә теләмәүдән түгел. Просто штабта утыручы писарь боерык язган вакытта минем фамилияне ялгыш төшереп калдырган.

Шуның аркасында мине хезмәттән азат итәргә дигән боерык бик соңга калып, тик өченче августта гына алынды. Ә имтиханнар беренче автустта башланган иде.

Барыбер өлгермәдем инде, минем үземнән генә кем кабаттан имтихан алып торсын, дип башта кайтмаска да уйлаган идем. Рәхмәт инде, капитан:

— Кайтасың — и никаких! Чөнки без синең укырга керәчәгеңә ышанабыз,— дигәч һәм «хезмәт вазифаларын үтәгәндә тоткарланды», дип белешмә язып биргәч, тәвәккәлләргә булдым.

## Казанга кайткач

Казанга алтынчы август көнне иртән кайтып төштем. Әйберләремне вокзалда гына калдырып, туп-туры университетка бардым. Безнең татар теле бүлегенә керүчеләр ул көнне төп корпусның беренче катында татар теленнән имтихан тапшыралар иде. Имтихан алучы ике укытучының берсен дәштертеп чыгарып, аңа үземнең хәлемне сөйләп бирдем. Чандыррак кына гәүдәле, урта буйлы, кысыграк күзле, шактый зур кылыч борынлы, көләч йөзле, утызлар тирәсендәге ул кеше сул кулы белән ияген тотып, гозеремне тыңлап торды да:

— Беләсезме нәрсә, егет: сезгә иң элек кабул итү комиссиясеннән имтиханга керергә рөхсәт язуы алып килергә кирәк. Шунсыз без сезне имтиханга кертә алмыйбыз. Чөнки сез гамәлдәге тәртипне бозгансыз: беренче, язма имтиханыгыз бирелмәгән,— диде.

— Ә кабул итү комиссиясе кайда соң, абый?

Ул өченче ишекне күрсәтте:

— Әнә, янәшәдә генә.

— Абый, әйдәгез икәү бергә кереп чыгыйк әле шунда, ә? Югыйсә мин анда беркемне дә белмим.

Көләч укытучым икеләнеп калды: аның миңа ярдәм итәсе килгәне күзләреннән күренеп тора, шул ук вакытта комиссия хозурына барып сөйләшергә тәвәккәллеге дә җитеп бетми иде.

— Әйдәгез инде, абый,— дидем мин, чын күңелдән ялварып.— Мәңге онытмас идем яхшылыгыгызны!

Юк, йөрәге җитмәде. Ташлап та китмәде үзе:

— Алайса без болай итик: сез шушында торып торыгыз, мин Ибраһим белән сөйләшеп карыйм әле. Бәлки ул берәр ничек ярдәм итәр,— дип имтихан бара торган аудиториягә кереп китте.

Ул арада имтихан тапшырырга торучылар мине сырып алды. Ара-

ларында минем кебек хәрби хезмәттән кайткан дүрт егет тә бар, берсе хәтта офицер-өлкән лейтенант иде.

— Нигә болай соңга калдың син, агайне?

Бу сорауны миңа кабарынкы калын иренле, яфраклары әле яңа гына чабыштан кайткан кешенеке кебек күпереп торган җәлпәграк борынлы, калын кара кашлы, бөдрәрәк кара чәчле кече сержант формасы кигән егет бирде.

— Шулай туры килде инде,— дидем мин шактый ук пошаманга калып.— Татар бүлегенә имтихан бирүчеләр барлыгы ничә кеше?

— Беренче экзаменда йөз дә егерме өч кеше иек. Шуларның алтысы коелып калды. Димәк, сине дә имтиханга кертсәләр, йөз унсигез булабыз,— диде әлеге кече сержант.

Ул үзен бик иркен, башлык шикеллерәк тота иде.

— Бер урынга биш кеше диярлек икән, ә? — дип көрсенеп куйганымны үзем дә сизмичә калдым.— Әллә рөхсәт сорап мәшәкатьләнеп тә йөрмәскә микән?

Бу юлы да шул ук кече сержант җавап бирде:

— Кара инде анысын, агайне. Бәлки, чыннан да, шулай итү хәерлерәктер.

Күрәсең, армиядә шулай өйрәнелгәндер инде, үзем кече сержант белән сөйләшсәм дә, күзем чины буенча бездән югары өлкән лейтенантта иде. Чәбәләнеп беткән җиз чыбык шикелле сары бөдрә чәчле, куе сипкел баскан озынча йөзле ул лейтенант моңарчы берни эндәшмичә, хәйләкәр елмаеп, читтә басып тора иде. Кече сержантның сүзләреннән соң лейтенант кинәт дерт итеп:

— Нәрсә сөйлисең син, Галимҗан! — дип безнең янга килде. Аннары миңа мөрәҗәгать итеп: — Ә сез аның сүзенә карамагыз, сержант,— диде.— Җыенып кайткан икәнсез, әлбәттә, имтихан биреп карарга кирәк. Тик менә рөхсәт итүләре генә инде. Тоткарлануыгыз хакында берәр белешмә алып кайтмадыгызмы соң?

— Анысы бар ла ул...

— Алай булгач, шәп инде!

Без шулай сөйләшеп торган арада имтихан бара торган аудиториядән ябык һәм каратут озынча йөзле, зур күзлекле, бәләкәй чандыр гәүдәле, кәкре таякка таянган бер кеше килеп чыкты да, ишек төбендә торучылар арасыннан кемнедер эзләгәндәй каранып, туктап калды. Ул чыгуга барысы да тынып калганнар иде.

Башлап һаман шул кече сержант Галимҗан телгә килде.

— Нәрсә, Ибраһим абый, берәр ярдәм кирәкме әллә?

«Эһем, эһем» итеп тамак кырды ул. Аннары:

— Армиядән кайткан җегетегез кайсы була соң монда? — дип сорады.

Бәлки мине соравыдыр дип уйласам да, хәрби киемлеләр бер мин генә булмагач, мин идем ул, дияргә кыюлыгым җитмәде.

Безнең арада хәрби диңгезче формасы кигән, төп кебек нык гәүдәле, түп-түгәрәк битле, дәү авызлы бер егет тә бар, ләкин ул моңарчы, бездә һичнинди галәкәсе булмаган кешедәй, тәрәз буенда басып, тәтенең граммын да әрәм итмичә тирән-тирән итеп эчкә суырып, тәмәке тартып тора иде. Әнә шул егет, үзалдына елмаеп куйды. Аннары акрын гына атлап укытучы янына килде:

— Армиядән кайтканнар бишәү без монда, Ибраһим ага. Сезгә кайсыбыз кирәк иде соң? — диде.

— Миңа хәзер генә армиядән кайтып төшкән бер егет бар дигәннәр иде.

Калын пыялалы күзлек кигән яшь кенә бер кыз, чөгендер шикелле кызарып, имтихан бүлмәсеннән килеп чыкты. Ишек төбендә торучылар барысы да аңа ябырылды.

— Ну, ничек?

— Нинди билет эләкте?
— Ничәле куйдылар?
Мине ул кызның ничәле алуы кызыксындырмый, үз хәлем — хәл иде. Кыяр-кыймас кына укытучы янына килдем:
— Мин ул, абый, әле кайтып төшкән кеше.
— Эһем, эһем, шулаймыни? Бик әйбәт, бик әйбәт,— диде ул. Кин итеп елмайды. Моның белән сөйләшеп торырга ярыймы икән соң, дип булса кирәк, бер мәл сынап карап торды. Күрәсәң, игътибарга лаек дип тапкандыр, кулын сузды да:
— Әйдә, энекәш, танышыйк алайса: мин Ибраһим абыең Нуруллин булам. Татар әдәбияты укытучысы,— диде.
Ул миңа шундук үз абыем шикелле якын булып китте:
— Минем дә фамилиям Нуруллин, абый!
Ләкин ул минем кебек үк сөенмәде.
— Шулаймы? Адашлар булабыз икән болай булгач. Кайсы районнан үзегез?
— Балык Бистәсеннән.
— Кайсы авыл?
— Югары Әшнәк. Халык телендә Зәңгәрле дип тә йөриләр.
— Югары Әшнәк, Югары Әшнәк...— диде ул, нидер хәтерләргә тырышып.— Юк, ишеткән авылым түгел.
— Шулайдыр шул. Кечкенә, нибары егерме җиде йортлы гына авыл ул.
— Ничава, кемнең кемлеген аның кайда тууы хәл итми. Габдулла Тукай да мәркәздә түгел, гади генә Кушлавычта туган...
Аннары кинәт кенә:
— Әйт әле, энекәш, дөресен генә: язасыңмы, басылган әйберләрең бармы? — диде.
Мин аптырап калдым: ни дип җавап бирергә? Язам дисәм дә әллә ни зур хилафлык булмаячак, язмыйм дисәм дә дөреслектән ерак китмәячәкмен. Ләкин аңа кайсы җавап кирәк икән соң?
— Юк,— дидем мин,— язмыйм, абый.
Язам дисәм, язган әйберләреңне күрсәт, дип төпченә башлавыннан курыктым. Чөнки минем мәкаләләр басылган газеталар вокзалда, чемоданда калган иде.
— Ә нигә безгә укырга кермәкче булдың соң?
— Укытучы булырга иде исәп.
— Анысы ярый икән,— диде Ибраһим абый, минем җаваптан күңеле булып.— Югыйсә безгә барысы да диярлек язу-сызу белән мавыгучылар килә. Һәркайсы Тукай да Галимҗан Ибраһимов булмакчы. Ә безгә башлыча әдәбиятны яратучы, аны әйбәт итеп укыта алырлык кадрлар әзерләргә кирәк.

Минем эчкә җылы кереп китте: «Ярый әле язам дип әйтмәдем!»
— Укытуын укытыр идем мин аның, ләкин имтиханга кертмисез бит әле! — дидем мин, сүз җае чыкканга сөенеп.
— Эһем, эһем... Әйе, шулай дигән иде шул Зәет абыең. Әйдәле, энекәш...
Ул папиросын бик җентекләп сүндерде, ташлар урын булмагач, аны кабына кире тыкты да мине «Кабул итү комиссиясе» дип язылган бүлмәгә алып керде.
Кыскасы, әлеге бүлмәдә миңа «Имтиханга керергә рөхсәт ителә»,— дип язып бирделәр.
— Ә бирмичә калган имтиханнарыгызны кайчан тапшыру мәсьәләсен деканат белән сөйләшеп хәл итәрсез,— дип тә өстәделәр.
Имтиханда нәрсә булачагын уйлау юк. Әлегә минем өчен иң кыйммәте — аның миңа шушы рөхсәте иде.
— Рәхмәт сезгә, бик зур рәхмәт!

Ә Ибраһим абыйга исә рәхмәтемнең чиге-чамасы юк иде. Комиссия председателе белән сөйләшеп, бирелмичә калган имтиханны (татар теленнән сочинение) да шул көнне бирергә рөхсәт алып чыкты ул!

— Әйдә, энекәш, киттек. Бәхетең бар икән! — дип Ибраһим абый мине үзе белән имтихан бүлмәсенә алып керде. Сочинение язар өчен миңа өч тема тәкъдим иттеләр. Кызганычка каршы, ул темаларның икесен инде оныткамын. Ә берсе хәтеремдә: «Советлар Союзы — тынычлык терәге» дигән ирекле тема иде ул. Мин шул темага яздым. Сочинениемне язып бетерү белән тикшерделәр һәм «дүрт»легә бәяләделәр. Шундук телдән имтихан билеты алырга да куштылар.

Бәхетемә каршы, бик җиңел билет эләкте. Беренче сорау «Туры һәм кыек сөйләм. Аларда тыныш билгеләре», икенче сорау «Гафур Коләхметовның «Ике фикер» пьесасының идея эчтәлеге» иде. Мин ул пьесаны армиягә кадәр университетка имтиханга әзерләнгәндә әйбәтләп һәм яратып укып чыккан идем. Ул сорауларга әзерләнеп тә тормыйча җавап бирдем. Күрәсең, шул тәвәккәллегемне искә алганнардыр, телдән миңа «биш»ле куйдылар.

Шулай итеп, ул көнне мин берьюлы ике имтихан тапшырып чыктым. Моның өчен үземә ярдәм иткән укытучыларым Ибраһим Нуруллин белән Зәет Мәҗитовка гомерем буе рәхмәтле булып калачакмын.

Соңгарып кайтып та имтиханга кертелү бик әйбәт.

Бер көндә ике имтихан тапшырып чыгу — аннан да шәбрәк. Ләкин бу мәсьәлә инде хәл ителде — мин университет студенты булдым дигән сүз түгел иде әле. Дөрес, тарихны «биш»легә тапшырдым: алдан әзерләнеп кайту үзенекен иткән иде.

Шулай итеп, дүрт имтиханның инде өчесе тапшырылган һәм мин унбиш мөмкинлектән ундүрт балл җыйган идем. Армиядә хезмәт итеп кайткан кеше өчен бу бер дә начар түгел. Мондый билгеләр белән теләсә нинди конкурстан үтәргә мөмкин. Тик менә дүртенче имтиханыбыз...

Анысы телдән иде. Безнең мәктәптә чит тел бөтенләй үк укытылмады дисәм, ялган булыр. Сигезенче-тугызынчы классларда инглиз теле укыдык без. Әмма өстән-өстән генә.

Мин армиядә хезмәт иткән арада кабул итү тәртипләре үзгәргән: тарих-филология факультетына керүчеләр өчен географиядән имтихан бетерелгән, аның урынына чит телдән имтихан гамәлгә кертелгән икән.

Шул хакта белгәч, чәчләрем үрә торды. Географиядән әзерләнеп йөрүемә үкенмим: булган белемнең зыяны тимәячәк! Ә менә чит тел белән ни эшләргә? Дүрт имтиханның өчесен әйбәт кенә биргәч, ташлап кайтып китү дә кызганыч. Унычы август иде бу. Уналтысында чит телдән имтихан булырга тиеш. Әзерләнергә биш көн вакыт бар. Ләкин биш көндә генә моңарчы бөтенләй диярлек укымаган фәнне өйрәнеп буламыни? Дөрес, читтән торып укучы бер студентның бер төн эчендә кытай телен өйрәнеп, иртәгәсен имтихан тапшыруы хакында сөйлиләр иде сөйләвен. Ләкин ул бит булган хәл түгел, ә анекдот кына!

Ни эшләргә дә белмичә, кара хәсрәткә батып, университетның төп бинасыннан чыгып килә идем, каршыма Солтан мәктәбендә укыган дустым һәм классташым Мидхәт Миншин очрады. Аның университетта укыганын беләм, ләкин теге елны мин конкурстан үтә алмыйча кайтып киткәннән бирле, күрешкәнебез дә, хат алышканыбыз да юк иде.

Без кочаклашып, бер-беребезгә карап, беркавым куанышып тордык. Очрашу куанычыннан икебез дә югалыбрак калган идек.

Башлап Мидхәт телгә килде.

— Карале, син монда каян килеп чыктың соң әле, малай?

— Әй, сорама инде, Мидхәт. Имтихан бирергә дип кайткан идем дә тагын барып чыкмады.

— Ничек барып чыкмады? «Ике»ле куйдылармыни?

— Куюын куймадылар да...

— Туктале, әйдә, конкрет кына итеп сөйләп бир әле: кая керәсең, ничә имтихан бирдең, нинди отметкалар алдың?

Түкми-чәчми генә вакыйгаларның асылын сөйләп бирдем.

— Минем эшнең хөрти икәнен инде белдең, үзеңнең тормышлар ничек соң, Мидхәт?

— Ничек булсын, шәәп! Университетның өч курсын бетердем. Быел менә дүртенче курста укыячакмын. Укуым әйбәт, повышенный стипендия алам. Ә монда укырга туры килә, малай! Күңел биреп укыганда, әллә ни авырлыгы юк икән аның. Хәтта инглизчә газеталарны инде сүзлексез дә укый алам. Укытучы кушкан текстларны гына түгел, артыгын да укыйм. Ник дисәң, югары белемгә ия булган кеше һич югы бер чит тел дә... Әһә, торып тор әле, малай Вакыйф...

Мидхәт университеттан чыгып барган бер ханым артыннан китте. «Күрәсең, авылдашы-фәләндер»,— дидем дә, үз уйларыма бирелеп, Мидхәт әйләнеп килгәнне көтә башладым. Ләкин күп тә үтмәде, кул изәп Мидхәт мине үзләре янына чакырды.

Мин кыяр-кыймас кына алар янына килгәндә, минем кем икәнне белергә теләгәндәй, теге ханым сыный карап торды. Челтәр якалы ак кофта, соры юбка кигән ул хатынның иң элек күзләренә игътибар иттем. Чөнки аның күзләре дә юбкасы белән пардан — яшькелт соры, һәм алардан әчке моң белән өртелгән рәхимле нур бөркелеп тора иде.

— Менә, Вакыйф, таныш бул: безнең инглиз теле укытучысы Зилә ханым Сабировна,— диде Мидхәт.

Зилә Сабировна тыйнак кына елмаеп:

— Исәнмесез? — диде.

— Исәнмесез!

Бер мәл киеренке тынлык булып торды.

— Миншин миңа сезнең турыда барысын да әйтте,— диде ул.— Сез классташлар икәнсез. Әгәр аның кебек әйбәт укыр булсагыз, берәр ничек ярдәм итәргә тырышырбыз. Сезнең группаның чит телдән имтиханы кайчан әле?

— Унсигезенче августта.

— Ике генә көн калган икән шул. Әйдәгез, алайса болай сөйләшик: сез имтиханга группагыз белән килмәгез. Минем соңгы имтихан егерме алтынчы августта, шул көнне килерсез. Ә аңарчы әле бер атна вакыт бар: әйбәтләп әзерләнә торыгыз!

...Егерме алтынчы август көнне имтиханга кергәндә (дустым өйрәткәнчә, иң соңгы кеше булып) «өчле» алуыма зур өмет белән кергән идем. Әмма...

Инде имтихан тәмамланып килә. Миннән алда нибары ике генә кеше калган иде. Нәкъ менә шул чакта, күктән иңгәндәй, Зилә Сабировна имтихан алып утырган аудиториядә ап-ак чәчле, дәү һәм юантык гәүдәле бер ханым пәйда булды. Әлбәттә, күктән иңмәгән, ишектән кергәндер ул. Ләкин, имтиханга әзерләнү белән мәшгуль булып, мин аның кайчан һәм ничек килеп кергәнен сизми калганмын. Мин аны күреп калганда ул инде Зилә Сабировна белән мыдыр-мыдыр нидер гәпләшә иде. Тик ни хакында сөйләшкәннәрен аңлап булмый, чөнки чит телдә сөйләшәләр. Димәк, ул да чит тел укытучысы! Бетте болай булгач баш! Дөбердәтеп «ике»ле куеп чыгаралар болар! Зилә ханым аның алдында ничек итеп миңа «өч»ле куйсын? Куймый, әлбәттә. Эх-эх-эх! Университетка быел да эләгә алмыйм икән болай булгач. Ә бит соңгы җиде тәүлек эчендә җитмеш тапкыр укып чыккан идем мин инглиз теленең грамматик кагыйдәләрен. Сүзлектән карап, әллә никадәр сүз ятлаган идем...

Ләкин гел аһ орып утырып кына да булмый, үземә эләккән билетка хәл кадәренчә җавап әзерләргә кирәк иде. Билетта ике сорау: берсе —

грамматикадан, икенчесе — инглизчә текстны русчага тәрҗемә. Әйтеп үткәнемчә, жиде көн буена бер генә минутымны да бушка әрәм итмичә, инглиз теле дәреслеген укыдым. Үземә калса, грамматик кагыйдәләрен дә хәйран гына үзләштереп, ул кагыйдәләргә мисаллар да китерә алырлык хәлгә килгән идем. Ләкин Акчәч килеп кергәч, бар белгәннәрем онытылды да китте. Барыбер рәт чыгара алмам дип, беренче сорауга әзерләнеп тә тормадым. Бөтен көчемне салып, үземә эләккән текстны русчага тәрҗемә итәргә керештем. Әле дә бик яхшы хәтеремдә: «Композитор Глинка һәм аның «Иван Сусанин» операсы дигән текст иде ул. Композиторның туган, үлгән еллары, укыган һәм яшәгән җирләре инглиз хәрефләре белән язылса да, русча атамалары белән бирелгән иде. Шуңа текстны тәрҗемә итү авыр булмады: сүзләрнең мәгънәсен сүзлектән эзләп азапланасы юк иде. Миннән алдагылар имтиханнарын тапшырып, нәүбәт үземә җиткәндә текстны тулысынча тәрҗемә иткән идем инде.

Мин такта янына чыгып, нидән башларга белмичә торган арада Зилә Сабировна Акчәч әбигә инглизчә нидер әйтә башлады. Аны тыңлап торганда Акчәч әбинең йөзе башта шикләнүле-җитди кыяфәткә керде. Аннары ул җиңелчә генә елмаеп куйды. Аның әнә шул сизелер-сизелмәс кенә, әмма карусыз елмаюы күңелемдәге өмет чаткысын тагын тергезеп җибәрде: «Бөтенләй үк этеп екмаска тиеш — йөзе иманлы күренә!» — дип уйлап куйдым. Белер-белмәс нидер сөйләп кәефләрен җибәргәнче, дәшми торуың артыграк дип, шул ук вакытта наданлыгым өчен җир тишегенә кереп китәрдәй оялып, тегеләрнең хөкемен көттем.

— Латин алфавитын яттан беләсеңме? — диде Акчәч әби.

Башкасын белмәсәм дә, анысын әйбәт беләм. Чөнки мәктәптә укыганда Гайшә апабыз безгә аны, ичмаса шул алфавитын гына булса да өйрәнеп калыгыз дип, кат-кат сөйләттерә өйрәткән иде. Имтиханга әзерләнгән көннәрдә дә берничә тапкыр кабатлап, хәтердә яңарткан идем мин аны. Менә хәзер ярап куйды: шартлатып яттан әйтеп бирдем. Акчәч әбинең болай да нурлы йөзе тагы яктырыбрак китте.

— Яхшы,— диде ул.— Инде хәзер икенче сорауга күчегез дә текстның русчага тәрҗемәсен укып карагыз!

Бу сорауны мин инде күптән көтә идем: шундук шатырдатып укып бирдем. Акчәч әбигә бу бик ошады: башта ул канәгатьләнеп һәм гаҗәпләнеп, кара син аны, булдыра бит, дигән шикелле итеп, Зилә Сабировнага карап алды. Аннары миңа борылды да:

— Молодец, тәрҗемәгез дөрес. Ләкин турысын гына әйтегез әле: үзегез тәрҗемә иттегезме, әсәрне укыдыгызмы? — диде.

— Солдат намусы белән ант итеп әйтәм: үзем тәрҗемә иттем!

— Алай булса, бик әйбәт. Инде хәзер инглизчә текстны укып карагыз.

Инглиз сүзләренең язылышы белән укылышы арасында аерма зур булуын белә идем. Ләкин кайсы сүз ничек укылганын, тәҗрибәм булмагач, каян белим? Шулай да, чит телдә сөйләшкәнгә охшатырга тырышып, текстны тиз-тиз укый башладым. Тиз укыганда минем ялгышны Акчәч әби белән Зилә ханым сизмичәрәк калырга тиешләр, дип уйлаган идем. Ләкин беренче җөмләне укып бетергәнне дә көтмәде тегеләр, икесе тиң кычкырып көлеп җибәрделәр.

— Булды, бүтән укыма, улыкаем, аңлашылды! — диде Акчәч әби, көлүеннән әле һаман туктый алмыйча.— Мәктәптә инглиз теле укымаганыгыз әллә кайдан күренеп тора! Ә университетта сезгә мәктәп программасын үткән кешеләр белән укырга туры киләчәк. Бу эш җиңел булмаячак. Хәтта бу тырышканда кулдан килмәслек эш түгел. Укуның беренче көннәреннән күңел биреп тотынганда, беренче семестрда ук иптәшләрегезне куып җитәргә мөмкин. Я, ничек, шулай эшли алырсызмы? Сезнең группаны Зилә Сабировна укытачак. Уку барышында өлгерә алмыйча аның йөзенә кызыллык китермәссезме?

— Кем? Минме? Әгәр университетка эләгә алсаммы? Һәй, әгәр сез мине ышанып укырга алсагыз!..

«Үлсәм үләм, лакин сезнең ышанычны акламыйкалмаячакмын!» — дип әйтергә теләгән идем. Әйтә алмадым: күңелем әллә нишләп китте дә күзләремнән кайнар яшь бөртекләре бәреп чыкты.

— Тынычланыгыз. Дулкынланмагыз,— диде Акчәч әби.— Белемегез өчен түгел, потенциаль мөмкинлегегезне искә алып, үзлегеңнән тырышып укып, кышкы сессиягә кадәр группадашларыгызны куып җитәрсез дип ышанып, аванс тәртибендә «өч»ле куябыз.

Миңа шуннан артык берни дә кирәк түгел иде! Куану-каушаудан юньләп рәхмәт тә әйтә алмыйча, очып кына университеттан чыктым да, хәзер инде аларга күренергә була, хәзер минем Казанда икәнемне авылга ишеттерсәләр дә ярый дип, теге чакта миңа ит сатышкан һәм бик шәп кирза итек алып биргән, безгә азрак туган тиешле Фатих абыйларга бармакчы идем башта. Ләкин, дөнья эшен белеп булмый, әле кулга студент билеты алмаган дип, соңыннан кире уйладым. Маяковский клубына барып, кино карау белән генә чикләндем.

Егерме сигезенче августта тарих-филология факультетының белдерүләр тактасына татар теле һәм әдәбияты бүлегенә кабул ителгән кешеләрнең исемлеге эленде. Анда минем фамилиям дә бар иде.

Шулай итеп, мин — егерме җиде йортлы, тар гына бер урамлы Зәңгәрле авылы малае — даны бөтен дөньяга билгеле булган, Казанның Ленин урамында балкып утырган һәм Ленин исемен йөрткән университетта укый башладым. Бер-берсеннән ерактагы ике урам арасында гомернең онытылмас бер өлеше теркәлеп калды...

Ул елны минем өчен тагын бер бик зур шатлык булды: урта мәктәпне көмеш медальгә тәмамлап, Равил энем дә Казанның химия-технология институтына укырга кергән иде.

1980—1984

## Кавк Латыйп

# УЙ СӘЯХӘТЕ

●

Киек казлар авазы ишетелә
чишмә җырында-моңында.
Көмеш чулпы чыңлый
кызлар толымында...
Сусау гына арта,—
йөрмә икән, йөрмә кызлар карап
чишмә юлында...

●

Күпме сулар аккан,
кошлар киткән, әйләнеп кайткан...
Кояш чыккан, баткан.
Сабан туйлары узган, атлар чапкан.
Кемнәр тапкан, югалткан...

Ә мин гел бер дога белән,
ә мин гел бер дуга бөгәм.
Әнкәм догасы белән
әткәм дугасын бөгәм.

Язу өстәлемдә таш кош тора.
Һавада карчыга кычкыра:
«Ни өчен ул таш?»— дигән сыман,
«Миңа кирәк аш»,— дигән сыман.

Ә ул таш кош минем кара савытым,
дөньяга шуннан тарала тавышым.

●

Ир-егет булмас ярасыз:
тәнемдә, җанымда табарсыз.
Яра сызыгыннан
гомер юлларымны,
гомер елларымны санарсыз.

Ир-егет булмас ярасыз.

●

Тормыш эзе минем йөземдә,
диңгез төсе минем күземдә,
кылыч үткенлеге сүземдә.
Минем түземлегем үземдә,
үземлегем — түземлелегемдә.

●

Сугыш узганга кырык ел,
Европа буйлап кайтып киләм:
Һәйкәлләр күп,
ә берсе генә дә — күрәм —
култык таяклы солдатка багышланмаган.
Үзем мин аяксыз.
Җир йөзендә ике миллион сугыш ветераны
йөри алмый таяксыз.

Сыңар аяк — сәнгатьчә түгел,
сәнгатьчә түгел — сыңар кул.

Тормыш белән сәнгать аермасы — бар шул!

................

**Булат Сөләйманов**

# ТАЙГА АЛАНЫНДА

## Серле яфрак

Син тугансың минем йөрәгемдә,
Мин туганчы газиз анамнан.
Себер! Себер! Бер син генә җирдә
Минем мәхәббәтем яулаган!

Җаным кебек бик кадерле миңа
Туган җирнең изге туфрагы...
Бу дөньяда Себер агачының
Мин бер серле, моңлы яфрагы.

## Гомер буе кеше юлда

Гомре буе кеше юлда,
Юлда икән — ул исән.
Юллар ага каннарымда,
Юлга юлдаш мин күптән:

Башта әнкәй җилкәсендә,
Аннан җәяү йөргәнмен.
Күрше авыл араларын
Үрмәкүчтәй үргәнмен.

Тупыр-тупыр атлар чаба,—
Үсмер бала чакларым.—
Авырттырма тоякларын,
Туган-үскән якларым!

Гомре буе кеше юлда,
Дөнья иркен, дөнья киң.
Самолетта, я поездда
Юл йөримен кемнән ким?

Төрле җирдә төрле халык,
Төрле авыл, калалар.
Я каршыңа килә алар,
Я озатып калалар.

«Инде менәм йолдызларга»,—
Дисәм, юләр санама:
Ай үтәсен бер сәгатьтә
Үтә торган замана.

Ләкин миңа Җир дә җиткән,
Җил булып җирдә исәм...
Гомре буе кеше юлда,
Юлда икән — ул исән!

●

Тормышта абынып
Йөрәгем канаттым.
Канатсам канаттым,
Тормышны барыбер яраттым.

## Үтеләсе юллар

Үтеләсе юллар үтелмәгән,
Хыял булган тормыш нибары.
Яшьлегемне узып китеп бара,
Гомеремнең сабантуйлары.

Үз учагым үзем кабыздым мин,
Киләчәктән чаткы-ут алып.
Чаптар аттай ярсу йөрәгемне
Ярты юлда кара туктатып.

Сикереп мендем тормыш-аргамакка,
Офыкларым иркен, чиге юк.
Әнә кояш миңа суза кулын,
Алда гүзәл дөнья — бите юк.

Үтеләсе юллар үтелмәгән,
Алкышларым булыр минем дә,
Күрәсезме! Күгем нинди аяз,
Зәңгәрлеген салган иңемә.

## Туй алдыннан

Авылыбызга кәләш төшкән,
Алма кебек матур, пешкән...
Истәлеге — гомергә!

Хуҗасының данын яклар
Әнә күпме чаптар атлар
Җыелганнар бергә...

Морҗалардан төтен ургый,
Кемдер өзеп гармун уйный,
Кояш тора биергә!

## Ана

Ник ышансын үлеменә,
Ана улын көтә һаман:
Кара күлмәк итәгенә
Тик бер өмет оялаган.

## Әй, көн аяз...

Әй, көн аяз!
Кошлар белән бергә,
Себер аша,
Очып үтте
Төньякка яз.

Әллә нәрсә булды җаныма...
«Бүтән читкә җибәрмибез»,—
дигән кебек, туган туфрак
Ябышты табаннарыма.

## Учак яктым

Учак яктым
Тайга аланында
Йөрәгемнән алып бер чаткы.
Күзлене дә
Сукыр иткән төннәр...
Канат җилпеп
Дөрли учак,—
Кайнар ул, якты.
Киң күңелле икән
Аланы да,
Каршыларга җәйгән кочагын.
Якты булсын
Килгән юлчыларга,—
Төн дөньясын
Теле белән ялый учагым.

Адашкан,
я юлдан язган булса —
Әгәр күреп минем учакны,
Дуслык белән килсә җылынырга,
Дустым, диеп
Эндәшермен аңа
Ул чакны.

Учак яктым
Тайга аланында,
Тиз сүрелмәс аның җылысы:
Кешеләргә булган сөюемнең
Учагымда түгел,
Йөрәгемдә яна олысы!

## Роза Хәлиуллина

### Чаң

Әле кайчан гына мин дә
Бер кайгысыз бала идем,
Бакырчыга — тимерчегә
Бер ваемсыз бара идем...
Алачыкта чаң — иң чын чаң,
Чын чаң эзләп ишек ачам:
Йөзкәй бабай, ямап бирче,
Безнең миски тишек ләса...—
Аннары чаң сугып дәшәм,
Бабай мине ишетмәсә.
Миңа монда чыңлау кыйбат!
(Мискидәге тишек — нәрсә!..)
Их, яз! Чыңлап сөйләп булса
Эчендәген — көч җиткәнчә!

Тимерче! Син кирәк безгә!
Кирәк синең сүзең безгә.
Кеше «язлар» диеп яши
Җәйдән кышка, яздан көзгә.
...Таңнан төнгә, яздан көзгә
Тимер сугар бу алачык:
Туктал, тимер йоласын яз!
Тап ачкычын яз көенең —
Алачыктан язларга чык!
Язларның көен ала чык!

Кур, тимерче алачыгын
Бала-чага алган урап...
Оланга бир сер ачкычын:
Ни ул сабан? Ни ул урак?
Ни ул илдә солдат булмак?
Ни ул җыру җырлап бирмәк?
Ни ул салкын сандал-тимер?
Ни ул туфрак, иген икмәк?
Ни ул бездә кайнар икмәк?
Идел җиле, ишет язны —
Таңда без бер җыру яздык —
Олыдан кубып уйлаучы,
Язлар өчен нур эзләүче —
Сабый җанлы, тимер канлы,
Олуг Йөзкәй бабакайны —
Тимерчебезне олылап.

Апрель, апрель, зәп-зәңгәр ай,
Син бит — ел туйдырачак ай,
— Чаң! — сабан кайрый чал агай.
Житен күлмәк киң иңбашта,
Түбәтәй береккән башка...
Тире тама тимер, ташка.
Йөзкәй изге чаңын суккач
Ындырда җан ыңгырашмас —
Сабый җанлы тимерченең
Сабанда шат җыры булгач:
— Корычымнан, тимеремнән,
Ал тимердән, гөл тимердән,
Чуенымнан-коенгымнан
Хасыйл булсын алтын сәгать! —
Дөрес суксын сәгатьләрне,
Минутларны — саф сәгадәт,
Башагыстан дәүләтенә
Алтын гомер итәм таләп!
Алтын көннәр, айлар, еллар,
Алтын язлар көтә йөрәк.
Үткенем бул, тутыкмас бул,
Тормыш тоткан корыч сабан!
Буразнаны сыздырып уз,
Чүп-чарны син туздырып уз.
Чүп үләннәр калкынмасын:
Чүбе-чары, чире-чоры
Арытмасын халкым башын!
Җирем дымга туена күрсен,
Зуратайлар тирләп-пешеп
Буразнага бодай чәчсен.
Төшкән орлык тизрәк үссен,
Чәчү көчле шытым бирсен!
Буразналар тирән булсын,
Алтын иген үсәр булсын.
Илнең-җирнең бәрәкәте
Алтын таулар өяр булсын.

Алачыкта — балалар ла.
Бала барын барлап бара.
Бәрә бабаң сандалларга —
Тел ачыла сабаннарда...
Ә куллары, кулларына
Ничек кенә күз иярсен!
Уйларына, хыялына
Йөгереп син иярерсең:
— Алтын язга! Олы язга! Чаң!!!

...Тимерчегә карагызчы:
Абыз-Иген бабабыз — шул.
Иңнәре тау, күкрәге кыр,
Аның тыны, чаңы — шау җыр!
Куанычы — янавычы;
Сабан кайрап канар учы
Эшли-эшли зурайгандыр...
Пакьләнгәндер, чаларгандыр,
Илдә булган бар батырлык,
Бар игелек аңардандыр.

Алачыктан, таңнан төнгә
Өзелмидер бер дә кеше.
Имән Ана нәселендә —
Хәбәрнең сөенечлесе:
— Жылы язда җиде килен малай тапкан!
— Җилкенеп, чал җилкәләрне
Горур киереп ал, тимерче!
— Таңда дога диеп килдек,
Агай, фатихаңны бирче.

Гел-гел изге дога өчен
Яралганмы бу дәү кеше?
Дәүдер Йөзкәйнең йөз эше,
Дәүдер фатиха әйтеше.
— Иген үссә, илең үсә,
Улың җитсә, килен төшсә,
Чибәр килен өйне җыйсын.
Сары-сары гәрәбәдәй
Идән-сәке көлеп торсын.
Сайгак саны утыз булсын,
Сайгак саны ул-кыз тусын,
Утыз булмаса ун булсын,
Ун булмаса сигез булсын.
Ким дигәндә, җиде булсын —
Һәрбересе Ил-җир өчен.
Җитмеш җиде сөенечем —
Жылы Инәй куенында
Тук кузактай олан үссен! Чаң!
«Ат-ат!» уйнап үсеп, алар
Атлы-тунлы ир-ат булсын:
Малайларның җидәве дә
Ардуандай батыр булсын!
Җирдән ике уңыш җыйсын. Чаң!
Даны илгә балкыр булсын!
Нур Баяндай шагыйрь булсын.
Аксакалдай — җирне белсен!
Чын ирләрчә гашыйк булып,
Гомерлеккә берне сөйсен!
Шундый теләк теләү үзе —
Бик газиз эш Йөзкәй өчен.
Һәр теләктән соң чаң суккач,
— Амин!— димичә, ни дисең:
Таңда туды җиде кеше!
Бел, моң арттыра җан көчен,
Бүген таңда туган кешем.
Таңда туган җиде көснең[1]
Тирән йөзсен һәрбересе.
Былбыл Акын Турай[2] төсле,
Саимә Зурнай[3] шикелле,
Сөякләрне эретердәй
Итеп, әргән уйный белсен! Чаң!
Бу җиде ул, җиде малай
Муллык яулап сөендерсен... Чаң!
Камылкайдан кыймыл-каймыл,

---

[1] Көс — маймыч (диалект).

[2, 3] Туган ягым кешеләре. (Автор)

Җиде колын атлап китсен.
Җылы яз аязлыгы өчен ир
Иленә аттай хезмәт итсен!!! Чаң! Чаң! Чаң!

Тимерчегә карагызчы,
Иген-Идел бабагыз шул.
Янында бер булу җитә
Мәңге бакый сабак өчен.
...Тимерче карт Йөзкәй бабай
Салып сабан телләренә —
Кереп сабый йөрәгенә
«Дога» укый алачыкта!

Ниләр ишетеп кайтмадым;
Алачык — гел җыру гына.
Шушы көйне кем дә белә
Имән-Ана җирлегендә:
— Көмеш Идел ярларында
Алтын иген дулкынланыр.
Кырык улым сал агызса,
Алтмыш улым урак алыр.
Агымсуның яры — басу,
Аргы яры — урманнардыр.
Алтын күзле игенчем бул!
Суда нарат, атлар куар
Көмеш күзле Иделчем бул!

Җиделәрем-җитмешләрем,
Җимешләре җитә торыр!
Җиделәрем җитмеш булып,
Җиңүләргә үтә торыр.
Таңда илнең милегенә
Ие, җиде малай туган!
...Йөзкәй бабай җиңе белән,
Җилкәдәге тире белән
Җирдә җитмеш сабан юган.
Җитен күлмәк киң иңбашта,
Түбәтәе бии башта.
Тире тама кайнар ташка:
Чаң кузгала — алачыктан,
Ашып безнең башлар аша!
Ташкынлый бураздаларда,
Агыйделдә боз кузгата.
Барып керә урманнарга...
Уралып һәр ябалдашка:
— Чаң! Чаң! Җирем, имин яшә!
— Кабул булсын теләгең! дип,
Дөнья үзе Илгә дәшә.

## Зөфәр Фәтхетдинов

# КЕМ — КЕМНЕ...

ПОВЕСТЬ

*...Шул каннар һәм яшьләр аркылы*
*Ил бөек җиңүгә иреште.*

Муса Җәлил

1

Йокымсырап утырган пассажирларны сискәндереп, моторларның тигез гөрелдәвенә эре калибрлы пулемет тавышы кушылды. Хәрби транспорт самолеты салонындагы гади киемле ике ир кеше, радист кыз һәм үзәк газета хәбәрчесе — барысы да атучыга таба борылдылар. Әйе, язмышның кем кулында икәнлеге бердән аңлашылды аларга.

Ул арада самолет кинәт уңга янтайды да, текә таудан шуган шикелле, атылып аска төшә башлады. Койрык өлешендә урнаштырылган йөк бер мәлгә һавада асылынып калгандай булды. Партизаннар өчен кирәк-яраклар тутырылган зур капчык пассажирларга таба шуышты. Әгәр вакытында аяклары белән тирәп калмаган булса, ул Зәки Нурмыевны, һичшиксез, очучылар кабинасы ишегенә китереп кыскан булыр иде.

Пулемет ничек ата башлаган булса, шулай кинәт туктап та калды. Самолет беравык тигез очканнан соң тизләгән кискен арттырып югарыга ыргылды. Тимер урындыкларга ябышып утырган пассажирлар бу борчуларның сәбәбен яхшы аңладылар — немецларның төнге истребительләре һөҗүм итүе ачык иде. Югыйсә, инде, фронт сызыгын үтеп, бераз тынычланырга өлгергән иделәр. Тирә-якта үлем чәчеп шартлаган зенит тубы снарядларыннан да, самолетны эләктереп алган көчле прожекторлардан да котыла алдылар бит.

Инде менә дошман истребительләре... Алар, әлбәттә, мондый табышны ычкындырырга теләмәячәкләр. Ә «корбанның» бөтен теләге — алда күренгән гаять зур кара болыт эченә кереп югалу. Әмма качып котылу өчен әле берничә километр очарга кирәк. Өстәвенә, болытлар арасыннан ай күренде, тирә-як яктырып китте.

Самолетны дерелдәтеп пулемет яңадан эшкә керешә. Шул ук минутта дошман уклары, калай түбәгә яуган боздай тып-тып бәрелеп,

самолетны «тешли» башладылар. Алар барлыкка китергән йодрык сыярлык тишекләрдән салонга сызгырып салкын һава керә башлады.

Эшләр болайга китсә, барып җитә алмавыбыз да бар,— дип уйлап куйды Нурмыев, парашютын төзәткәләп. — Ә бу — йөкләнгән бурычны үти алмау, дигән сүз. Тик аны ничек булса да үтәргә кирәк.

Язмыш аның белән гаҗәеп бер уен уйный кебек. Тикшерү органнарында эшләгән дәвердә ул катнашкан операцияләр никадәр авыр башланып китсәләр, ахыры шулкадәр җиңел була иде. Ә бу юлы алда торган бурыч аеруча катлаулы, мондый эш белән аның әле шөгыльләнгәне юк иде. Зур партизан отрядында оялаган дошман агентларын фаш итәргә кирәк. Гестапо шымчылары зур зыян китергәнлектән, отряд җитәкчеләре партизаннар хәрәкәте үзәк штабыннан ярдәм сорарга мәҗбүр булганнар.

Менә шуңа күрә лейтенант Зәки Нурмыев бүген фашист истребительләре эзәрлекләгән самолетта дошман тылына оча. Ике атна элек шунда ярдәмгә җибәрелгән хезмәттәше Алик Пепелин, партизаннар лагерен дошман бомбага тотканда, һәлак булган.

Үзәк штабта лагерьны бомбага тотуның очраклы хәл булмавы мөмкин, дигән фикер бар иде. Отряд күчеп килгәнгә дүрт кенә көн вакыт узуга карамастан, бомбаларның алар урнашкан җиргә генә сибелүе бик шикле. Дошман шымчылары лагерь координатларын хәбәр итеп өлгергән, күрәсең. Бәхеткә каршы, утызлап бомбардировщик лагерь өстенә үлем яудыра башлаганчы, отрядның корал тота алган бар кешесе, дошман һөҗүмен кире кагу өчен, аннан бераз читтәрәк тупланган булган һәм шулай очраклы рәвештә зур бәладән котылган.

Күптән түгел Пахомов отряды шундый ук хәлдә кешеләренең яртысын югалта. Командир үзе дә һәлак була. Аларның калдыгын үзенә кушкан икенче отряд исә, яңаларын үзенә сеңдергән көннән башлап, гел уңышсызлыкларга юлыгып тора...

Самолет, куркытылган кош кебек, әле уңга, әле сулга, әле аска, әле өскә ыргылды. Йөк самолетына немец козгыннарыннан котылу авыр шул — тегеләрнең тизлекләре зуррак. Самолет партизаннар «аэродромында» тукталырга тиеш булса да, пассажирларның барысына да парашют бирелгән. Гадәттә парашютларны «юлда» сикереп төшеп калучыларга гына бирәләр. Әмма бу очракта җитәкчеләр саклык чаралары күрде. Чөнки бүгенге һәр пассажир дошман тылындагы меңләгән язмышны кайгыртырга сәфәр чыккан иде.

Нурмыев юлдашларының кая, нинди максат белән очуларын белми иде. Ул аларны беренче тапкыр самолетка утыргач кына күрде. Немецлар кул астында калган берәр шәһәргә юл тоталардыр, мөгаен. Аларның эше тагын да авыррак. Зәки иптәшләренә, хәлләрен аңлаган шикелле, ихтирам белән карап куйды.

Шул чак, әзмәвер чукмары тидемени, самолет бик каты селкенде дә сулга янтая башлады. Очучылар кабинасы ишеге ачылуга, тәбәнәк гәүдәле штурманның:

— Карабиннарны эләктерергә! Сикерү өчен әзерләнергә! — дигән боерыгы яңгырады.

Һәркем үз йөген кулга алуга, штурман тагын кабинасына кереп югалды. Барысының да башында бер генә уй: нинди урынга төшәр дә, ничек барып җитәр. Борчылулы күзләр очучылар кабинасы ишегенә төбәлгән. Ә штурман юк та юк. Ул арада самолет тигезрәк оча башлады. Күңелләрдә тагын өмет чаткысы кабынды. Әллә котылдыкмы?! Нурмыев саклык белән генә рацияне идәнгә куйды. Отрядка ул радист булып бара. Зәки чынлап та рациядә ярыйсы гына эшли. Классташы Стась Могилевский белән бергә морзе әлифбасын өйрәнүе бушка китмәде. Соңрак — осоавиахим мәктәбе...

Штурман, бу юлы ишектән башын гына чыгарып, дәртле тавыш белән эндәште:

— Сикермибез! Өстерәлеп булса да барып җитәрбез.

Самолетның болытлар арасына качып котылуы, авыр яралар алуга карамастан, хәзер инде өметнең үсүе турында ул сөйләп тормады.

Партизаннар базасына таң алдыннан гына барып җиттеләр. Утыргандa самолет хәйран гына «кәҗәләнеп» алды — түмгәкләргә очрап сикергәләде һәм куе зирек куаклыгына терәлеп диярлек көчкә туктады.

Пассажирлар җиргә аяк баскач, ах иттеләр: шундый теткәләнгән самолет ничек оча алган!

Нурмыевны отряд командиры майор Журкин каршы алды. Аннары кызулап партизан аэродромыннан уникe чакрым көнчыгыштарак урнашкан лагерьга кайтырга чыктылар. Башка пассажирлар, атларга утырып, көнбатыштарак хәрәкәт итүче күрше отрядка китте.

Базага барып җиткәндә иртәнге аш вакыты иде. Бераздан отрядны сафларга тезеп, яңа радист белән таныштырдылар. Нурмыевның чынлыкта кем булуын отрядта бары командир һәм штаб начальнигы гына белергә тиеш иде.

Лейтенант, үзенә билгеләнгән «ояда» антенналарны көйләүгә, исәнсау килеп җитүе һәм эшкә тотынуы турында Мәскәүгә беренче радиограммасын тапшырды.

Аннары Зәки лагерьны әйләнеп чыгарга булды. Ул мәһабәт наратлар, каеннар һәм төрле вак куаклар каплаган калкулыкка урнашкан иде. Лагерьны урталай бүлеп торучы кипкән елганың ике ярында карлыгач оясын хәтерләткән ясалма мәгарәләр. Урыны җайлы, һава һөҗүме әллә ни зыян китерерлек түгел. Бәлки шуңа күрә дә немецлар лагерьны кабат бомбага тотмыйдыр. Дошман отрядның монда икәнен белергә тиеш бит. Шымчының партизаннар арасында булуына шик юк кебек. Яңа урынга күчеп килгәннән соң бер атна вакыт узган, хуҗалары белән бәйләнешкә керер өчен җитәрлек вакыт.

Лейтенант яңәшәдә генә урнашкан штаб куышына юнәлде.

Отряд командиры Журкин аны штаб башлыгы белән таныштырды. Нык гәүдәле, аксыл чәчле, кырыс йөзле ир-егет. Капитан Ковригин Михаил Анемподистович.

— Танышуыбызга мин бик шат,— диде Нурмыев, аның кулын кысып.— Әгәр каршы килмәсәгез, эшкә тотыныйк.

— Әйе, вакыт аз,— диде майор Журкин.— Җитмәсә, кичә тагын бер операция уңышсызлыкка очрады. Тимер юл күперен шартлатырга киткән тугыз кешенең дүртесе генә әйләнеп кайтты. Немецлар аларны нәкъ шул урында гына көтеп торган шикелле.

— Тимер юлда да эшләр начар,— дип башлады сүзен штаб башлыгы.— Ике атна эчендә бары бер генә хәрби эшелон шартлата алдык, тагын берсе — азык-төлек белән...

— Элек күбрәк була идеме? — дип сорады Нурмыев.

— Шактый ук. Югалтуларыбыз да кимрәк була иде.— Ковригин гамәл журналын ачып алдына куйды.— Отряд Пахомов партизаннары хисабына 152 кешегә артты. Алар безгә унҗиденче апрельдә килеп кушылды. Хәзерге көндә 435 кораллы кешебез бар. Сан ягыннан арттык артуын, эш нәтиҗәләре генә нык кимеде. Бөтен бәла-казалар шул апрель урталарыннан башланды да инде.

Капитан Ковригин хәвефле тәмамланган операцияләрне санап чыкты. Соңгы уңышсызлыкларның авыр тәэсире — отряд эшчәнлеген шактый сүлпәнәйтүе сизелә иде. Моннан ничек котылырга? Әлегә бу турыда берәү дә, шул исәптән хәрби тикшерүче Зәки Нурмыев та берни әйтә алмый иде. Алда гаять авыр, зур түгәллек таләп итәчәк эш торганын гына аңлый иде. Бу эшне уңышсыз төгәлләнгән һөҗүмнәрне өйрәнүдән башларга кирәк: анда кемнәр катнашкан, аңа әзерләнүне кем белгән? Лейтенант озак кына ул һөҗүмнәрнең төрле яклары белән кызыксынып утырды, Пахомов отрядының исән калган партизаннары исемлеген, мартапрель айларында отрядка кушылган яңа кешеләр исемлеген әзерләүләрен үтенде.

— Бу көннәрдә кайбер нәрсәләрне тикшереп карарга кирәк булыр. Шуңа күрә сезгә тагын бер үтенечем бар,— диде тикшерүче. — Миңа разведка взводыннан биш ышанычлы кеше бирсәгез иде.

— Була ул,— дип җавап бирде Журкин. — Тагын нинди ярдәм кирәк?

— Минем кем икәнлегемне әлегә белми торсалар яхшы булыр иде. Отряд тормышы элеккечә барсын. Дошман шымчыларын куркытмыйк диюем. Юкса аларны табу кыенлашыр. Шуңа күрә бөтен күрсәтмәләрне сез бирерсез.

— Ярый, Зәки Шәрипович, сезгә бу эштә Михаил Анемподистович та ярдәм итәр.

— Инде соңгы сорау. Әйтегез әле, сез үзегез эзләп карамадыгызмы ул кабахәтләрне? Миннән алда килгән капитан Пепелин нәрсәләр эшләргә өлгерде икән?

— Әлбәттә, тикшердек,— диде штаб башлыгы.— Бер взвод командирыннан шикләнә башлаган идек. Уңышсызлыкларның күбесе ул катнашкан эшләрдә очрады. Александр Повзнев турында әйтүем. Салгалап йөреп, тәртип ягын да аксаткач, командирлыктан азат итәргә туры килде үзен...

«Повзневның фашист шымчысы булуы бик шикле»,— дип уйлады Нурмыев. Тәҗрибәле кеше, андый эшләр эшләп, үзен-үзе шик астына куймас. Бу очракта бик оста һәм хәйләкәр дошман хәрәкәт итүе бәхәссез.

— Менә тагын берәү. — Ковригин, папкадан бөгәрләнеп беткән кәгазь кисәге чыгарып, лейтенантка сузды.— Укып карагыз.

Шифрорадиограмма

Левчукка — Ашыгыч

Красов Виктор Петрович турында белешүегезне сорыйм. 1915 елда Пермь шәһәрендә туган. Сугышка кадәр шәһәр автохуҗалыгында механик булып эшләгән. Хөкем ителгән булуы мөмкин. Портретын тасвирлап бирегез.

Пепелин

— Бу радиограмма җибәрелдеме? — дип сорады лейтенант, Ковригинга таба борылып.

— Бомбага тотканнан соң рациясез калдык. Ярдәм сорап күршеләргә мөрәҗәгать итәргә туры килде, әле биш көн элек кенә җибәрдек...

Нурмыев куыш буенча ишекле-түрле йөреп килде. Каен бүрәнәләреннән түшәлгән түшәм баш тияр дәрәҗәдә тәбәнәк иде.

— Ул сезгә кызыксынуының сәбәбен әйтмәгән идеме?

— Әйтте,— диде штаб начальнигы. — Красов төрмәдә утырып чыккандыр, ахры, диде. Бөтен тәне тулы рәсем икән. Тәндәге рәсемнәр төрмә билгесе бит инде. Үзеннән сораган идек, белмәгәнгә салыша. «Анда булган дуслардан күчкән нәрсә»,— ди. Иң әһәмиятлесе бу түгел әле. Пахомов отрядында ул 1942 елның икенче мартыннан гына сугыша башлаган. Ике солдат белән лагерьдан качкан булганнар. Тикшереп караган идек, расланды. Әмма отрядта бәла-казалар шул вакыттан башланган...

— Иптәшләре нинди кешеләр иде соң?

Ковригин кулын гына селтәде:

— Аянычка каршы, икесе дә сафтан чыкты. Берсе һәлак булды, икенчесе авыр яраланды. Әлегә лазаретта. Зур җиргә җибәрмәгез, дип ялына. Дөресен әйткәндә, бөтен яралыларны эвакуацияләргә мөмкинлегебез дә юк...

Лейтенант озак сораштырып утырды: Пахомов һәм Журкин отрядлары кайчан оештырылган, төп кешеләре кемнәр, элегрәк дошман ялчылары яки шикле кешеләр тотылмаганмы, лагерьны саклау ничек оештырылган, постлар штабтан еракмы, кайсы авылларда дошман гарнизоннары бар — боларның һәммәсен дә белергә кирәк иде аңа.

Төнлә дозорлар һәм постлар тирәсендә күренгән һәр партизан турын-

да үзенә хәбәр итүләрен дә үтенде. Посттагылардан башка беркемнең дә төнлә лагерь буйлап йөрергә хакы юклыгын, партизаннар базасына якын килгән һәр шикле кешене кулга алырга кирәклеген дә әйтте.

— Боларның барысын да эшләргә мөмкин. Тик ачлык кешеләрне кузгалак, кычыткан, дару үләннәре җыю өчен урманга йөрергә мәҗбүр итә. Без үзебез дә бу эш белән шөгыльләнәбез. Азык-төлек җитми. Авырулар, яралылар да бар бит әле.

— Аңлыйм. Барыбер мөмкин булган кадәр лагерьга керү-чыгу сукмакларын бикләргә кирәк. Бер атнага булса да. Агент үз юлыннан иркенләп йөри алмасын иде. Хуҗалары белән элемтәсен өзәргә, аны башка юллар эзләргә мәҗбүр итәргә кирәк. Шымчының элемтәгә керү өчен башка куркынычрак юллары да бардыр барын. Бәлки шул ачыкланыр.

— Зәки Шәрипович, бәлки аның рациясе бардыр, кайда да булса яшереп тотадыр? — диде Журкин.

— Минем уйлавымча, сез монда күчеп килгәнче ул рация ярдәмендә элемтәгә кермәгән.

— Нигә алай дип уйлыйсыз?

— Әйдәгез, болай фикер йөртик,— дип башлады Нурмыев, кесәсеннән карандаш чыгарып.— Базагыз бомбага тотылган уналтынчы майда отрядны сагать ничәдә күтәреп яңа урынга күчердегез?

Штаб башлыгы үзенең язуларына күз салганнан соң:

— Алты туларга егерме биш минутта,— диде.

— Ә бомбага кайчан тота башладылар?

— Җиденче ун минутта.

— Димәк, бу үзгәрешне рация аша хәбәр итү өчен шымчының вакыты җитәрлек булган. Гестапо шунда ук очышларны туктаткан булыр иде.

— Базада калган кешеләрне күздә тотсак, сез хаклы.— Журкин тәмәке кабызды.— Әгәр агент читкә җибәрелгән взводларда булса? Рация аша хәбәр итәргә мөмкинлек калмаса?

— Нигезле фикер, әмма мин андый очракларда элемтәгә керү өчен шымчының башка юллары бардыр дип уйлыйм. Шулай да сезнең фикер белән килешәм. Күзәтүләрне көчәйтү нәкъ шушы фаразны ачыклау өчен кирәк тә инде. Бигрәк тә төнлә. Кабатлап әйтәм, төнлә йөрүчеләргә аеруча игътибар итәргә кирәк. Тагын бер нәрсә: миңа барлык партизан элемтәчеләренең исемнәрен белү кирәк. Бомбага тоту вакытында базада калган кешеләр исемлеге дә кирәк булыр, дип уйлыйм.

— Сез аларны шикleләр арасыннан төшереп калдырырга уйлыйсызмы? — дип сорады Ковригин чигәләрен угалап.— Әйтик, мин үзем алардан шикләнмим. Гестапо агенты үзе булган җиргә әллә никадәр бомбардировщик һөҗүме оештырмас. Бу бит котылгысыз үлем дигән сүз.

— Михаил Анемподистович, кадерлем, агент тревога күтәрелсәсен, үзенең базадан читкәрәк китәсен дә белмәгәндер,— диде Нурмыев.— Һава һөҗүме буласын алдан белгән шымчы качар өчен урын әзерләгән булырга тиеш. Үзенең исән калачагына да нык ышанган. Ул газиз җанын куркыныч астына куймас иде.

## 2

Көн кичкә авышкач, көчле җил кузгалды. Тәбәнәк кара болытлар бөтерелә-бөтерелә урман өстеннән җете кызыл офыкка таба юнәлделәр. Нарат ябалдашлары җилдә әчпошыргыч бер төрле тавыш чыгарып шаулыйлар. Көчле җил куыш ишеген бер ача, бер ябa, мәгарәгә ылыс исе тулы саф һава бәреп керә.

Лейтенант Нурмыев төш күреп ята. Йокысыз ике төннең соңгысы — самолетта үткәне керде аның төшенә. Ишек шапылдавы зенит снарядлары шартлавы булып ишетелә. Ә землянкага кергән саф һава снаряд ярчыклары тишкән ярыклардан агыла сыман. Кинәт нәрсәдер бик каты дө-

дәде. Нәрсә бу!? Уянып китүгә ул бераз вакыт кайда икәнлеген дә аңламый торды. Ишек тагын ачылып китте, яңадан дөбердәү ишетелде. Күк күкриме, әллә бомбага тоталармы? Зәки урыныннан торып тышка чыкты. Якында гына ялтырап яшен яшьнәде, каты күк күкрәгән тавыш кайтаваз булып урманга таралды. Көчле яңгыр башланды.

Зәки сәгатенә карады да гаҗәпләнүдән сызгырып куйды. Хәйран йокланган! Эшкә тотынырга өлгермәгән — борчылам, уйланам, имеш. Үз көчеңә үзең ышанмау чире озак көттерми шул. Характерны ныгытырга кирәк, дустым, җитәкчең Левчукныкы кебек ихтыяр көче булдыру кирәк сиңа. Нинди генә авыр хәлләрдә калырга туры килмәгәндер аңа. Димәк, һәрвакыт нәрсә эшләргә кирәклеген төгәл белгән. Димәк, үз-үзенә ышанган. Ә Зәки... Нигәдер борынгы Рим философы Сенека исенә төште. Аның фикеренчә, үз-үзеңә ышанычсызлык эшсезлектән, мәгънәсез тормыш алып барудан килә. Ә Зәки эшли, булдырырга тырыша кебек бит. Нигә шулай? Бәлки тәҗрибәсе җитеп бетмәүдәндер. Сенека исә акыл туплаган, дөнья күргән ирләрне күздә тотып әйткәндер. Зәкигә әле егерме биш кенә яшь бит, акыл, зирәклек, тәҗрибә дөньясына аяк баскан вакыты гына. Яше утыз-утыз бишләргә җитмичә, анда үз кеше булып булмас.

Куыш ишеген саклык белән генә ачып, штаб башлыгы Ковригин килеп керде.

— Комачауламыйммы?

— Юк, юк, Михаил Анемподистович, узыгыз.

— Безнең разведчиклар күрше Орловка авылыннан бер полицайны эләктергәннәр. Бәлки сораштырырсыз?

...Урта яшьләрендәге полицай землянка уртасына утырган да, ишек ачылган саен сискәнеп китә. Керосин лампасыннан төшкән яктыда аның шәүләсе кыяфәтсез бер күләгә булып шуыша.

Нурмыев почмактагы түмәргә барып утыруга, өйрәтелгән эт хуҗасына караган кебек, полицейский күзләрен аңа төбәде.

— Полициядә күптән хезмәт итәсеңме? — дип сорады Нурмыев, кесәсеннән куен дәфтәре һәм карандаш чыгарып.

— Мәҗбүр иттеләр, юкса риза була идеммени...

— Төгәлрәк җавап бирергә кирәк. Кайсы айда, кайсы көнне киден бу киемне? Кайсы авылда хезмәт итәсең?

— Дүртенче декабрьдән бирле мәҗбүри хезмәттә, Орловкада.

— Гарнизон зурмы?

— Ике рота, ипт... әфәнде. Барысы 350 кораллы кеше.

— Төннәрен тревогалар булгалыймы?

— Булгалый гына түгел, еш була.

— Соңгы тапкыр кайчан күтәрделәр?

Полицай кипкән иреннәрен ялап алды. Эчкечеләрнеке кебек калтыранган бармаклары белән мундирының керләнгән якасын чишеп җибәрде.

— Шушы көннәрдә, унсигезе иде, ялгышмасам. Дөрес, унсигезенче май көнне.

Орловка гарнизонының кайсы көнне, сәгать ничәләрдә тревога буенча кузгатылганын, кайларда засадалар оештырылуын лейтенант җентекләп сорашты. Полицай сөйләгәннәрне игътибар белән тыңлап, кайберләрен куен дәфтәренә язып барды. Партизан отряды зур көч белән берәр дошман гарнизонын тар-мар итәргә җыенса, шул көнне бөтен җирдә, хәтта ерак гарнизоннарда да тревога күтәрелүгә игътибар итте. Ә заданиегә кечкенә төркемнәр генә киткән көннәрдә, немецларда бернинди борчылу сизелми.

Бер карасаң, немец шымчысын эзләү белән гарнизоннардагы тревогалар арасында бернинди бәйләнеш тә юк кебек. Әмма тикшерүче бәйләнешнең нәкъ менә шунда булуын сизде. Партизаннар һөҗүм итәргә уйламаган гарнизоннарда да тревога булып, сугышка әзерләнәләр икән, димәк, көнен белеп тә, кайда һөҗүм буласын дошман төгәл белми.

Юкса, барлык гарнизоннарда ыгы-зыгы күтәрү кирәк булмас иде. Ә бит нинди һөҗүм әзерләнүен взвод командирлары да, штабка якын башка кешеләр дә белә. Димәк, алардан шикләнмәскә мөмкин булачак, бары тик тагын бер тапкыр бу мәгълүматларның дөреслеген тикшереп чыгарга кирәк. Нурмыев уйлавынча, моның өчен авыл кешеләреннән, мөмкин икән, әсир немецларның үзләреннән сораштырырга кирәк. Әгәр инде тозаклар партизаннар һөҗүм итәргә җыенган урыннарда гына корыла икән, агентны командирлар арасыннан эзләргә туры килер иде.

Полицай сөйләгәннәрне истә тотканда, шымчы бары тик кайбер күзәтүләрдән чыгып кына эш итә, дип уйлады лейтенант.

— Тәҗрибәле, үз эшен яхшы белә, ахрысы. Бәлки профессионал агенттыр. Бу очракта ул хәбәрләрен башка канал буенча да кабатларга тиеш.

Нинди һөҗүмнәр ясалачагын шымчының дөрес чамалавы күзгә ташлана. Әгәр отряд тулысынча яки аның күбрәк өлеше кузгала икән, димәк, ниндидер комендатура яки гарнизон тар-мар ителергә тиеш. Инде автоматчылар белән ун-унбиш кешедән торган шартлатучылар төркеме юлга чыкса, зур күпергә хәвеф яный, дигән сүз. Дүрт-биш кешеле кечкенә төркемнәр исә тимер юл шартлатырга гына йөри. Дошман шымчысы менә шуны белеп алган, ахрысы. Моны тикшереп карарга кирәк булыр. Командир, зур минерлар төркеме оештырып, аларны автоматчылар белән олы юлдагы күпергә җибәрсен әле. Базадан ераклашкач, вак төркемнәргә бүленеп төрле якка таралырлар.

Аның уйларын елый-елый кычкырган хатын-кыз тавышы бүлде:

— Кертегез мине! Ул минем әти-әниемне үтерүче!

Ковригин землянка ишеген ачып:

— Нәрсә булды анда? — дип сорады.

— Иптәш капитан, хуҗалык взводыннан бер хатын сезнең янга кермәкче була,— диде часовой.

Хатын куышка керүгә полицайга ташланды.

— Шул-шул! Бу кабахәт җан минем күз алдымда әти-әниемне атып үтерде! Шул үзе!!

Полицайның бугазына ябышкан хатынны чак-чак аерып алдылар. Полицай: «Иптәшләр, мин гаепле түгел. Мин... миңа... үз теләгем белән түгел... боерык бирделәр...» дип кычкырынса да, аның язмышын бу бәхетсез хатын хәл итүе барысына да аңлашылды. Партизан судының нинди карар чыгарасын ул үзе дә сизә иде инде.

Дошман тылында беренче эш көне менә шулай сораү алу белән тәмамланды.

### 3

Агафон кушаматлы ябык гәүдәле партизан үзе белән сакта торучы иптәшеннән:

— Караңгылык кайда барлыкка килә икән? — дип сорады. — Урманнадыр, ахры. Шуннан сазлыкларга, елгаларга, күлләргә, шәһәрләргә таралады. Синеңчә ничек, Силыч?

Силыч, дин әһелләренеке кебек купшы сакалын сыпыргалап, теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

— Бәлки шулайдыр, ә бәлки түгелдер.

— Монда икеләнергә урын юк инде. Әнә күрәсеңме, кырлар өстендә ничек якты. Ә монда, урман эчендә, җир астындагы кебек караңгы.

Силыч эндәшмәде, бөгәрләнгән фуражкасын басыбрак киде дә, сөйләшергә теләге юклыгын белдереп, арты белән борылды. Дөресен әйткәндә, постта торганда сөйләшергә ярамый да иде.

Тиздән офыкның көнбатыш ягы башта алсуланды, аннары тоныклана барып, күк йөзе куе соры пәрдә белән капланды. Язгы боз кебек күксел

сары болытлар караңгылана барган гөмбәз тышында калып эреде.
Төн уртасында җил кузгалды. Дымлы урман һавасы салкынайды. Вакыт-вакыт җил иркенә бирелгән корыган яфраклар, кипкән үләннәр аяк астында кыштыр-кыштыр килде.
— Яңгыр гына башланмасын инде,— дип пышылдады Агафон.— Болай да рәхәт түгел.
Силыч сакалын сыпырып тын гына ята бирде. Тик Агафон тагын сүз башлады:
— Акыллы кеше бу урыннан үтеп керергә маташмас. Уң якта сазлык, каршыбызда мина кыры. Җитмәсә төнлә. Минага эләгүеңне көт тә тор. Кайсы акыллы башы бу урынны сакларга карар биргәндер инде. Элегрәк...
Силыч коры гына аның сүзен бүлде:
— Җитәкчеләр күбрәк белә.
Сөйләшмә дигән сүзе иде бу аның.
Тиздән тонык кына ай калыкты. Күз күреме аз булса да яхшырды. Хәзер инде түмгәкле сазлык тигезлеген тәбәнәк куаклардан аерырга мөмкин иде. Сугышка кадәр урманчы булып эшләгән Силыч бераздан шомланып:
— Ишетәсеңме, кемдер килә ахры...— диде.
Икесе дә караңгылыкка төбәлделәр.
Агафон автоматын үзенә якынрак тартып куеп:
— Курыкканга куш күренә,— диде.
Куе чикләвек куаклары аларны яхшы каплап тора иде. Шулай да Силыч кымшанмыйча ятарга кушты. Көтеп тагын берничә минут узды. Якында гына ниндидер төн кошы тавышы ишетелде. Шул секундта Силыч иптәшенең иңенә кагылып:
— Теге куаклар юк иде шикелле,— дип пышылдады.
— Ничек инде «юк иде?» Каян килсеннәр ди алар?
Силыч бил каешыннан гранатасын чишеп алды:
— Чынлап та юк иде,— диде.
Болытлар ертыгыннан төшкән ай яктысының да файдасы тимәде, тирә-якны һаман шул шомлы караңгылык каплаган иде.
Силыч Агафонның колагына ук килеп:
— Мин әкрен генә әйләнеп киләм әле,— дип пышылдады.— Карарга кирәк. Син шушында гына тор. Берәр нәрсә-фәлән булса, атарсың. Аңладыңмы?
Силыч тавыш-тынсыз гына караңгылыкка кереп югалды. Шикле куаклар чынлап та күренәләр бит! Дулкынланудан аның сулышы кысылды. Куаклар әкренләп агач араларыннан партизан лагерына таба шуышалар. Икәү генә түгел, дүртәү!
Безнекеләр бу тирәдә йөрми. Йөрсәләр дә качып-посып йөрмәсләр иде. Димәк, немецлар! «Тукта», дип кычкыру файдасыз. Шунда ук атачаклар. Аларга барыбер. Тиз генә гранатаның чекасын тартып чыгарды да аяклы куакларга таба ыргытты. Урман бер мизгелгә яктырып киткәндәй булды.
Шартлау тавышы урманны яңгыратты. Шул ук минутта немец автоматлары да эшкә тотынды. Ату тавышларын ишетүгә, Агафон шулай ук автоматын тырылдатып алды. Якында гына шартлаган граната кыйпылчыгы күкрәгенә эләгүен ул башта сизмәде дә. Башыннан кубанкасы очып төште. Патроннары беткәч кенә, авыртып торган урынын капшап карады: тәнен җылытып нәрсәдер ага! Яраланган икәнлеген ул шунда гына аңлады. Ярдәм килеп җиткәндә ул басып тора алмаслык хәлдә иде инде.
Ә Силыч һәлак булган: пуля нәкъ йөрәгенә тигән иде.
Хәле авыр булса да, Агафон Журкин белән Нурмыевка нәрсәләр, ничек булуын сөйли алды. Аның раславына караганда, мина кыры аша унлап фашист үтеп кергән иде.

Бәрелеш булган урында яшел халатлар кигән өч үле немец солдаты табылды.

Иртәнге якта Нурмыев белән Ковригин дошман үтеп керергә теләгән урынны җентекләп карап чыктылар. Немецлар җидәү булган икән: яфраклары шиңә башлаган җиде куак бәйләме табылды. Димәк, дүртесе качып котылган...

Лейтенантны ике сорау борчыды: беренчедән, немецлар мина кыры серен ничек белә алганнар, икенчедән, нинди максат белән базага үтеп кермәкче булганнар? Дошман караңгы төндә мина кыры аша үтә алган икән, димәк, бу кырның серен ачкан. Минерлар тикшереп чыкканнан соң, бу күңелсез фикер расланды: немецлар миналарны зарарсызландырып та тормаганнар. Шундый куе урнаштырылган коралны!

Бу турыда саперлар кайтып әйткәч, Нурмыевка әллә нәрсә булды. Чигәләре кысылды, тәне чемер-чемер килә башлады, йөзе агарды.

— Әллә хәлегез начарландымы? — дип сорады Ковригин.

— Юк, юк, Михаил Анемподистович,— диде Зәки бераз каушап.— иртәнге салкын тәэсире ахры...

Мина кырының картасы бары тик Ковригинда гына. Миналарның нинди тәртиптә куелганын ул гына белә. Ә аларны урнаштырган тәҗрибәле минер сержант Архипов һәм аның җан дусты минер Галиев ике көн элек тимер юл шартлатканда һәлак булганнар.

Беренче карашка, бүгенге көндә схеманы штаб башлыгы Ковригин гына белә кебек. Ә ул сыналган, ышанычлы кеше. Сугышларда авыр яраланган, орден белән бүләкләнгән. Сүз тарата торган кеше түгел. Димәк, серне тагын кемдер белгән. Архипов миналаган кырны бер агачтан икенчесенә елан кебек туры барсаң гына, исән үтеп була. Башка минерлар үзләренчә миналый. Дөресен әйткәндә, миналар, кирәк вакытта тиз генә алып, башка җирдә кулланырлык итеп куела. Миналар җитми, шунлыктан, алар төгәл исәптә.

Миналарны ничек урнаштыруы турында Архипов башка кешегә сөйләмәде микән? Нурмыев шуны белешергә булды. Ләкин аның белән бергә яшәгән партизаннар бу сорауны ачыкларлык бернәрсә дә әйтә алмады. Бары мыеклары чаларган өлкән яшьтәге сапер Архиповның мина кыры турында Галиевка нидер сөйләвен ишеткән. Ләкин игътибар белән тыңламаган икән.

— Мин йокларга тырышып ята идем,— диде ул.— Хәлдән таеп кайткан чагым, ике төн йокламаган. Ялгышмасам, төшке аштан соң иде. Әйе, исемә төште, чыннан да шулай. Урынга яткан гына идем, алар кайтып керде. Яннарында тагын кемдер бар иде. Бик нык арылган, ике көндә сиксән чакрым юл үткән идек. Алар килеп керүгә, йоклап та киткәнмен.

— Алар кайтканда куышта тагын кем дә булса бар идеме?

Партизан, тәмәке төтененнән саргаеп беткән кытыршы бармаклары белән цигарка төреп кабызгач кына җавап бирде.

— Оныта язганмын. Безнең минерлар короле Порфирий да өйдә иде бит, автоматын чистартып утырды. Менә ул мөгаен барысын да сөйли алыр.

— Ә ул хәзер кайда?

— Бер-ике сәгать чамасы элек «ауга» китте. Иртәгә кайтып житәр. Аның юлы гел уңа. Инде алты эшелонны тәгәрәтте. Уен эш түгел бусиңа. Шулай ич, ә?

Немецлар отряд житәкчеләрен юк итәргә теләде микән? Кемнедер урлап китү өчен килүләре булдымы? Әллә, партизаннарга каршы житди сугыш ачар алдыннан, паника таратырга омтылулары идеме?

Соңгы шөбһә бик төпле түгел. Разведчиклар хәбәр итүенчә, якынтирә авылларда урнашкан гарнизоннарда үткән төнне тыныч уздырганнар. Отрядны житәкчеләрсез калдырырга теләүләре дөресрәк булыр — Нурмыев шундый фикергә килде. Отряд командиры белән штаб башлыгы икесе ике куышта яши. Берьюлы һөҗүм итү өчен, немецлар өч-дүрт кешелек ике төркемгә бүленергә тиеш булгандыр.

Билгеле инде, алар сакта торучыларны тавыш-тынсыз гына юк итеп, штабны гранаталар белән шартлатырга уйлаганнардыр. Ыгы-зыгы купкан арада караңгылыкка кереп сызган булырлар иде. Аларны мина кыры ягында эзләргә беркемнең дә башына килмәс иде, билгеле. Әйе, бу фараз ышанычлырак кебек. Фашистларның партизаннар отряды урнашкан урынны яхшы белүләре дә шуны куәтли. Димәк, шушы көннәрдә һөҗүм итүләрен көт тә тор. Бомбага тотарлармы, берничә гарнизонны бергә туплап ябырылырлармы? Яисә фронттан гаскәр китерерләрме?

Бомбага тотулары да мөмкин, тик очучылар өчен яхшы маяк булмаган таулы-чокырлы зур урманда моның файдасы аз булачак. Өстәвенә, куышлар тирән чокыр ярларына ышанычлы уеп казылган. Шулай да һава һөҗүме куркынычы бар. Немецлар бер тапкыр партизаннар базасын бомбага тотып караганнар иде инде. Тик азрак ялгыш җибәргәннәр: җирдә һөҗүм иртәрәк башлану сәбәпле, партизаннар, разведчиклар хәбәре буенча, урыннарын алмаштырып өлгергәннәр. Бу юлы дошман башта бомбага тотып, шуннан соң гына җирдән һөҗүм башларга мөмкин. Нурмыев уйлавынча, дошман үз ялгышын төзәтергә тиеш.

Разведка мәгълүматларына караганда, отряд урнашкан төбәктә дошманның көче алты йөз кешедән артмый. Бу көч белән генә алар урманга борыннарын тыгарга да куркачаклар. Мөгаен, фронттан ярдәм килүен көтәрләр. Аларга бу ярдәм кайчан киләсен алла белсен. Нурмыев шундый уйлар белән үз куышына ашыкты.

Аны бигрәк тә сапер Архипов белән бер өйдә яшәгән кешеләр кызыксындырды. Һәлак булучылар байтак булганлыктан, бергә торучылар еш алышынгандыр. Сазлыктан текә ярга кадәр араны миналау исә унтугызынчы майда тәгәлләнгән. Димәк, Архипов белән шул көннән алып яшәүчеләрне барларга кирәк. Немец шымчысын да мина кырының сере шушы көннән кызыксындыра башларга тиеш. Архипов белән Галиевнең миналау турында сөйләшүенә бәлки нәкъ менә шул бәндә колак салып торгандыр? Саперлар куышында соңгы вакытта яшәүчеләрне сораштырудан файда чыкмады. Хәлне ачыкларга ярдәм итәрлек бер генә кеше — сапер Порфирий гына калды.

Иртәгесен көн кояшлы, җылы иде. Күктә бер генә болыт та юк. Нарат урманының саф һавасы тән ризыгын искә төшереп ымсындыра.

Нурмыев иртәнге ашка китте. Кечкенә генә бер кисәк дуңгыз мае салынган, суда пешерелгән арпа боткасы аңа ресторан сыеннан да тәмлерәк кебек тоелды. Әле унынчы унбиш минут кына икән. Бая минерлар янына барып килгәндә «аучылар» әле кайтып житмәгән иде. Зәки үзенә-үзе урын табалмый җәфаланды. Зарыктырды Порфирий, зарыктырды.

«Аучылар» төш вакытында кайтты. Тик алар арасында тикшерүче көткән кешенең үле гәүдәсен генә күрергә мөмкин булды. Иптәшләре әйтүенә караганда, аның чигәсенә адашкан бер пуля лагерьдан ерак түгел генә килеп тигән. Бу яңалык Зәкине тәмам аптырашта калдырды. Кояшлы көн аның өчен кинәт караңгыланып, ямьсезләнеп китте. Тирәюньдәгеләр хәрәкәтләнүче шәүләгә әверелде дә күздән төште. Чөнки сер йомгагының бер очы табылган кебек булган иде, хәзер ул тагын югалды.

Тикшерүче Порфирий белән сөйләшүгә шактый өметләр баглаган иде. Архипов белән Галиев сөйләшүен тыңлап торган өченче кешенең шымчы булып чыгуына аның инде иманы нык иде. Һич югында, ул кеше ишеткәннәрен очраклы рәвештәме, белепме агентка сөйләгән булуы ихтимал иде.

Эх, әгәр дә кирәкле кешесен «ауга» киткәнче очратырга өлгергән булса! Бары ике сәгатькә соңарды бит! Ике сәгать — кеше гомеренең бер мизгеле генә бит югыйсә.

Лейтенантның авыр уйларын отряд командиры Журкин бүлде:

— Зәки Шәрипович, минерлар белән сөйләшеп аласызмы? Әллә кайтып ял итсеннәрме?

— Сөйләшәм, әлбәттә, иптәш майор.

Башындагы уйларының рәте-чираты юк, әйтерсең лә аны әле генә йокыдан уятканнар да катлаулы сораулар биреп аптыраталар. Нәрсәне белешәсең инде алардан? Язмыш, күрәсең... Тукта әле, нигә мин Бердәнбер шаһитның үлемен очраклы хәл дип саныйм соң? Кинәт туган бу шик аны айнытып җибәргәндәй булды. Бәлки Порфирийның үлеме чынлап та очраклы хәл түгелдер, дошман шымчысы тикшерүченең Порфирий белән кызыксынуын сизгәндер дә, фаш ителүдән куркып, аны үтергәндер? Ул, күрәсең, төнге «кунакларның» үз бурычларын үтәп, качып котылуына ышангандыр. Бу очракта минерлар белән һичкем дә кызыксынмаган булыр иде. Инде ул эш барып чыкмагач, мәкерле җан бердәнбер шаһиттан котылу юлын тапкан. Архипов мина кыры турында сөйләгәндә куышта тагын кемнәр булуын бары Порфирий гына белгән бит!

Тикшерүче минерлардан иптәшләренең кайсы урында, ничек һәлак булуын сораштыра башлады.

Арон кушаматлы чем-кара чәчле яшь партизан, кипкән иреннәрен ялаштырып, сүзен:

— Мин аның артыннан бара идем,— дип башлады. — Кинәт Порфирий башын, дөресрәге, чигәсен тотып, чайкалып китте. Аннары бер генә адым атлады да җиргә ауды. Мин башта һәлакәтне аңышмый тордым, абынып егылды, дип уйладым. Карасам, чигәсеннән кан ага! Без аптырашып калдык. Тирә-юньдә дошман булырга тиеш түгел иде кебек, якында гына исә безнең үз постларыбыз. Өстәвенә ату тавышы да ишетелмәде.

— Хәтерләмисеңме, ул кайсы чигәсенә ябышты? — дип сорады Зәки.

Бераз гына уйланып торганнан соң, Арон:

— Сул як чигәсенә,— дип җавап бирде. — Мин әле ничек шулай булырга мөмкин дип уйлап та куйдым. База ягыннан дип әйтерлек аттылар бит.

Порфирийның үле гәүдәсен һәм ул һәлак булган урынны карап чыкканнан соң, Арон сөйләгәннәр тулысынча расланды. Тикшерүчене иң гаҗәпләндергәне: партизанга тигән ук нәкъ менә партизаннар посты ягыннан очып килгән иде. Ук кергән һәм чыккан тишекләрне караганнан соң, аның очу юнәлеше дә беленде. Порфирийга пост ягыннан атулары хак. Әлеге посттан сукмакка кадәр бер километр чамасы. Әмма шунысы бар: пост торган урыннан сукмакны күрү мөмкин түгел. Көчәйтелгән постта торучы дүрт партизан да беравыздан, минер һәлак булган сәгать уникедән алып бергә кадәр вакытта гына түгел, иртәнге сигездән бирле бу тирәдә беркемнең дә йөрмәвен, үзләренең беркая да китмәгәнлеген әйттеләр. Ату тавышын да ишетмәгәннәр.

Кайдан атканнар соң Порфирийга? Эзли торгач, ул урынны да таптылар. Яңа сынган ботак, тапталган үлән бу урында кемдер булганлыгын күрсәтте. Арон үлән арасыннан винтовка патроны гильзасын табып бирде. 300—350 метр чамасы ераклыктан атканнар икән. Яфрак та селкенмәслек җилсез тыныч көндә беркем дә ату тавышын ишетмәве гаҗәп иде. Димәк, тавыш йоткыч файдаланылган. Ә отрядта андый әйбер юк бит, зур җирдән җибәрергә әле вәгъдә генә иттеләр. Дымлы йомшак җирдә атучының аяк киеме эзе дә калган иде. Табанында ун тиенлек акча кадәр сырлары булган шомара башлаган солдат итеге. Размерын белеп булмады, үкчә эзе калмаган. Тикшерүче эзнең булган кадәресен үлчәп алды.

Шымчы тавыш йоткыч җайланма куелган винтовка күтәреп йөрмәскә, аны каядыр яшергән булырга тиеш иде. Эзләп-эзләп карадылар, ләкин тапмадылар.

Куышына кайтып житү белән Нурмыев:«Әгәр шымчы ниндидер юл белән минем мина кыры белән кызыксынган кешеләрне эзләвем турында ишеткән булса? — дип уйлады. — Безнең нәрсә турында сөйләшүебезне

беркем дә белергә тиеш түгеллеген кисәткән идем үзе. Бәлки ул яшерен генә тыңлап торгандыр? Яңа кешенең кем икәнен белергә теләүләре бик мөмкин. Ул очракта минем нинди максат белән килүем иртәгә үк отрядтагы бөтен кешегә мәгълүм булачак.

Зәки тиз генә өстенә киенде дә минерлар янына китте. Игътибар белән аяк астына карап, куыш тирәли әйләнеп чыкты. Менә сиңа мә! Янәшәдә үсеп утырган куаклыкта шундый ук түгәрәк сырлы таныш солдат итеге эзе! Үлчәп караган иде — төгәл туры килә. Зәкинең маңгаеннан тир тамчылары бәреп чыкты, йөрәге ярсып тибә башлады. Каушаудан куак төбендә үк җиргә утырды: ул саперлар белән сөйләшкәндә куыш ишеге ачык иде. Димәк, шымчы безнең нәрсә турында сөйләшүебезне рәхәтләнеп тыңлап торган да, тыныч кына китеп барган. Сүз дә юк, миннән житезрәк тә, хәйләкәррәк тә бу мәлгунь.

Аннары Зәки тагын бер тапкыр эзгә күз салды. Уң үкчәсендәге дагасы әллә тузган, әллә сынган. Хәтердә калдырырга кирәк иде моны. Эзне үлчәп тә алды — итек кырык икенче размер булырга тиеш.

Лейтенант бөтен яңалыкларны отряд житәкчеләренә сөйләп бирде. Ул үз куышына кайтып җиткәндә ярты төн узган иде инде. Такта ятакка барып утырды да тагын уйга чумды.

Алга таба нәрсә эшләргә? Бу каһәр суккан бәндәне кайда, ничек эзләргә? Шундый ялгышлардан соң, Зәки үз максатына ирешә — шымчыны тота алырмы?

Яшь вакытта шулайрак була инде ул. Һәр житди уңышсызлык соңгы, хәлиткеч, киләчәккә бөтен өметләрне юкка чыгарырдай ялгыш булып тоела. Бу уңышсызлыклар бик авыр кичерелә, ләкин тиз онытыла торган булалар.

Зәки Нурмыев та бөтен уңышсызлыкларын, язмышның аяк чалуларын бик авыр кичерә иде. Башы сызлый башлый, югалып калган чаклары да булгалый иде. Дөрес, ул үз-үзен тиз кулга ала белә. Әмма күңелдә вакыт-вакыт үзен сиздерә торган яралар кала.

Менә бүген дә шундый хәл булды. Нишләргә белмичә, караңгы куышында ишекле-түрле йөрде. Андый вакытта, авыр кайгы баскан кешедәй, ул бернәрсә күрми, бернәрсә ишетми иде. Эх, Дмитрий Георгиевич Левчук янымда булсын иде дә аның белән киңәшләшсәң иде. Шымчыны кайдан эзләргә икәнен белер иде ул, дип уйлады.

Нурмыев хәлсезләнеп чүгәләде дә салкын җир стенага сөялде. Җир идәнгә шыбырдап вак балчык коелды. Отрядтагы хәл көн кебек ачык — дошман шымчысын тиз арада фаш итәргә кирәк. Ул күңелсез генә елмаеп куйды. Тагын шул ук табышмакка әйләнеп кайтты ләбаса, тик башка яктан гына. Дошман якын гына, тик шулкадәр оста яшеренгән, янынннан узганда да күрмичә үтеп китүең мөмкин.

Нурмыевның беренче остазы, бик яхшы фәлсәфәче һәм юрист Мидхәт Хәбибович Фарукшин исенә төште. Беркем дә белмәгән, беркем дә таба алмаган, беркемгә дә кирәк булмаган хакыйкать — көчсез һәм файдасыз, дия иде ул.

— Хак сүзләр,— дип пышылдады Зәки. — Шул хакыйкатьне таба алганчы миннән бернинди файда юк. Хакыйкать табылгач кына дошманнан үч алырга, аңа тиешле җәза бирергә мөмкин булачак...

Ул урыныннан аяклары ойый башлавын сизгәч кенә торды. Тагын уйга чумып, куыш буйлап йөренә башлады. Кешенең гомере буена сузыла торган бер зур ялгышы була, бу — аның үзе турындагы фикере. Кеше үз мөмкинлекләренә я артыграк бәя бирә, я, киресенчә, тиешле бәя биреп җиткерми. Монда килергә җыенганда Зәки үзе һәр мизгелдә нәрсәне ничек эшләргә икәнен белер кебек иде. Ә менә ничек килеп чыкты. Чынлап та шулай: үз алдыңа нинди дә булса максат куюдан җиңел нәрсә юк, ләкин үз мөмкинлекләреңә туры килердәй төгәл максат куюдан авыррак эш юк.

Әйе... Шушындый кыен минутларда үзеңнең кемлегең бигрәк тә нык

беленә, дип сөйләнде ул үзалдына. Бөек эшләр майтаручы олы шәхесләр белән синең арада, иптәшкәем, тирән упкын ята, ул эшләрне синеке белән чагыштыру да мөмкин түгел.

Үзалдына сөйләнеп, мыгырданып утыру гадәте җиденче класстан бирле килә инде аның. Яраткан укытучысы аңа күбрәк сөйләшергә, үй-фикерләрен телдән кабатларга киңәш бирде. Бу аның сөйләм телен яхшыртты. Ә соңга таба фикерләрен телдән кабатлаганда уйлавы да җиңеләйгәндәй тоелды. Беренче шигырьләре дә кәгазь битендә түгел, телдән язылды.

Тагын Фарукшин әйткән сүзләр исенә төште: кешенең бөеклеген аның бөек эшләре билгели. Әмма бөек эшләр эшләү өчен бөек рух булу мәҗбүри. Теләкләре саф, изге булуы да мөһим.

Әсинең дустым, характер йомшаграк ахры,— диде ул тагын үз-үзенә. Беренче уңышсызлык ук... Бик ансат кына җиңәргә уйлаган идең дә, барып чыкмады, борыныңа кундырдылар.

Аннары Нурмыев, тикшерү эшен, иң яхшы хәрби тикшерүчеләр тәҗрибәсен аз өйрәнгәне өчен, үзен-үзе сүгеп алды. Әйе, үзең эшләгән эш кенә өйрәтә, дип уйлап ялгышкан икән. Мәктәптә укыган вакыттан бирле үз уңышсызлыклары өчен Зәки үзен генә гаепләргә күнеккән иде. Хәзер дә уңышсызлыкның сәбәбен үзендә эзләде. Урынына ятып, күзләрен йомгач та уйлар агышы тукталмады. Нигә кеше башкалар тәҗрибәсенә карата шундый игътибарсыз була икән? Үткән буыннар тәҗрибәсенә таянып яшәгәндә, аяныч хәлләргә илткән күпме зур ялгышлар булмый калыр иде. Тирән акылга ия булганнар гына башкалар тәҗрибәсен файдалана белә.

Зәки шундый уйлар белән йокыга китте.

## 4

Икенче көн бөтенләй файдасызга узган кебек булды. Ары-бире йөреп кич житкәнен сизми дә калды Нурмыев. Хәлдән таеп, үзен-үзе сүгеп, куышына кайтып яткан иде, барыбер йокыга китә алмады.

Менә инде күпме вакыт күзләрен йомып ята. Әллә картая инде. Картлар көндез йокыларын туйдыралар да төн буе боргаланып яталар бит. Әгәр теләгән кадәр йоклап булса, дошман тылында калган халык, бу явызлыкларны күрмәс өчен, тәүлекләр буенча йоклар иде. Юк шул, юк. Йокы алласы кешеләргә бу рәхәтлекне билгеле бер күләмдә генә бирә.

Зәки торып шәм кабызды. Киләсе көнгә план төзеп куярга уйлаган иде, башына бер төпле фикер дә килмәде. Мондый хәл я нык арыган, я ялкау кешеләрдә була. Әлегрәк, башы эшләми торса, моны аз эшләвеннән күрә, ялкаулык баса, дип уйлый, бөтен көчен куеп, ат кебек эшли башлый иде. Бөтен акыллы кешеләр әчкечелеккә сабышудан курыккан кебек, ул ялкаулыктан куркып яшәде. Ялкаулык һәм буар елан үз корбанын тын гына, сиздермичә килеп бер ысул белән үтерә. Аерма тик шунда гына: буар елан кешене шунда ук буа, ә ялкаулык — әкрен-әкрен генә.

Соңрак, ялкаулык һәм эчкечелекне янәшә куеп, ул болай уйлый башлады: кешеләрдә була торган бу кимчелекләр — аларның бигрәк тә үз-үзләренә каршы аңлы рәвештә эшләгән җинаятьләре. Ләкин аның бүгенге сүлпәнлеге ялкаулык аркасында түгел иде. Арыганлык басты ахры.

Утны сүндереп ятуы булды, лагерь өстеннән, колакларны тондырырлык тавыш чыгарып, ике моторлы авыр самолет очып үтте. Тышка йөгереп чыккан иде, бернәрсә дә күрергә өлгермәде. Борынына ылыс, яшел үлән исе генә килеп бәрелде. Җирдән ак төтен кебек күтәрелгән пар, агач ябалдашлары тарафыннан йотылгандай, юкка чыга бара иде. Зәки, берничә минут тирә-якка күз, колак салып басып торды да кереп йоклаpга ятты. Йокыга гына киткән иде, тагын мотор тавышы уятты. Хәшәратләр, әллә белеп очалар иде инде.

Йокы качты. Зәки яктырткыч циферблатлы сәгатенә күз салды. Төнге уникенче ярты. Ә беренче самолет унда очып үткән иде. Төнге сәгать икедә тагын шул хәл кабатланды. Әллә чынлап та база өстеннән махсус очалар инде бу самолетлар? — дип уйлап куйды Зәки. Шулай булуы да бик мөмкин. Соңгы самолет таң алдыннан, урман кошлар җырына күмелгән вакытта, сәгать дүрттә үтеп китте.

Нурмыев йоклар-йокламас ятып торды да, иртәнге җиледә штабка китте. Кичтән яуган яңгырның үлән өстенә төшкән, әле кибәргә өлгермәгән тамчылары кояш нурларында гаҗәеп асылташ бөртекләре кебек җемелди иде. Елганың икенче ягына кояш төшмәгән, анда, мәһабәт чыршылар күләгәсендә, күренер-күренмәс томан йокымсырый. Табигать куркыныч сугыш законнарына буйсынырга теләми, үзенчә яши бирә иде. Шундый уйлар белән Зәки штабка килеп керде.

Командирлар җыелып өлгергәннәр иде инде.

Нурмыев, исәнлек-саулык сорашуга, төнге самолетлар турында кызыксынды.

— Андый очышлар егерме беренче апрельдән башланды,— дип аңлатты майор Журкин. — Ике-өч көнгә генә туктап тордылар.

— Отряд урынын алмаштырган көннәрдә түгелме?

— Нәкъ шулай. — Отряд командиры, кулына папирос алса да, кабызырга ашыкмады. — Май аенда да очтылар. Аннары көннәрдән бер көнне өстебезгә фугас бомбалары яудырдылар.

— Самолетлар белән отрядта эш алып баручы дошман шымчысы арасында бәйләнеш юк микән?

— Кызганычка каршы, бардыр, дип уйлыйм. Көн саен бер үк вакытта юкка гына очмаслар. Отряд башка урынга күчкәч тә озак көттермәделәр... Отряд кушылганчы мондый хәлнең булганы юк иде. Кабат бомбага тотулары да мөмкин. Ә бәлки әле безне куркытырга теләүләре генәдер.

Штабта тынлык урнашты. Ачык ишек аша кошлар җыры гына ишетелә. Ара-тирә сакта торучы партизанның итекләре шыгырдап куя иде.

## 5

Нурмыев берәр дошман гарнизонына һөҗүм оештыруны тәкъдим итте. Эш уңышлы төгәлләнсен өчен, берничә урында тимер юл шартлатып, дошманның игътибарын читкә юнәлтергә киңәш бирде. Полицай сөйләвенчә, партизаннар тимер юлга гына кул сузганда, гарнизоннар әллә ни борчылмаган.

— Ул сөйләгәннәрнең дөреслеген сынап карарга кирәк. Уңсак, гарнизонны тар-мар итәрбез!

Планшетыннан карта чыгарып өстәлгә җәйгән отряд командиры:

— Чыннан да, яхшы фикер бу,— диде.— Юл уңаенда бәлки тагын бер авыр мәсьәләне хәл итеп булыр. Отрядта тоз бетте. Сусыз яшәп булмаган кебек, тозсыз да яшәп булмый икән.

— Димәк, Платон: «аш тозы — аллаларның иң яраткан ризыгы» дип юкка гына әйтмәгән. Ә Гомер тозны «илаһи» дип атаган.

Ковригин өстәлдәге кәгазьләрне җыеп алды да:

— Әйе, кешеләр авырый башлады, хәлсезләнәләр,— диде.— Билгеле булганча, тоз Мовинода, немецларның азык-төлек келәтендә бар. Гарнизон да артык зур түгел — йөз кеше тирәсе. Немецлар һәм бер взвод полицайлар. Ләкин һөҗүм буласын алдан белсәләр, эш барып чыкмас. Эре калибрлы пулеметлардан кырачаклар безне. Уңышка ирешү өчен беренче чиратта дошман шымчыларын алдарга кирәк.

Командир белән штаб башлыгы берьюлы Нурмыевка таба борылып:

— Безне кайчан шундый бәхеткә ирештерерсез икән инде, Зәки Шә-

рипович? — дип сорадылар. — Эшнең гаять катлаулы икәнен дә, монда килүгезгә берничә көн генә үтүен дә аңлыйбыз. Әмма кеше күңеле шундый инде, яхшы эшне озак көтәргә түземлек җитми.

— Әйе, сез хаклы, — диде Зәки. — Мин монда шуның өчен килдем дә инде. Әлегә шымчының кем икәнлеген әйтә алмыйм. Ә менә тоз табуда булыша алырмын, дип уйлыйм. Минем бер планым бар. Тик башта Мовино гарнизонын юк итү өчен күпме көч кирәклеген уйлашыйк әле.

Озак фикер алышканнан соң, план корылып бетте. Сәгать унда отряд сафларга тезелде. Төрле яшьләрдәге чуар киемле партизаннар юлга чыгарга тәмам әзер иде.

Отряд командиры аларга дошман самолетлары активлашуын, яңадан бомбага тотулары мөмкинлеген аңлатты. Берничә көннән отрядка яңа урынга күчәргә туры киләчәген белдерде.

Әүвәле штаб башлыгы балта, пычкы тота белгән иллеләп кешене сайлап алды. Аларны эш кораллары белән тәэмин иттеләр. Тагын иллеләп кеше җир казу өчен билгеләнде. Хуҗалык взводы командиры җитәкчелегендәге бу төркем шунда ук юлга чыкты. Кирәк-яраклар төягән берничә олау да аларга иярде. Шул ук көнне, көндезге сәгать өч белән дүрт арасында лейтенант үзәк белән элемтәгә керде. Нурмыевның чын исемен бары отряд командиры һәм штаб башлыгы гына белә, аны күзгә-күз калганда гына телгә алалар. Башка вакытта, үзәк белән эш иткәндә дә, аның кушаматы Андрей иде.

Шифрорадиограмма
Андрейга

Красов Виктор Петрович турында хәбәр итәм: 1915 елда Пермь шәһәрендә туган. Хөкем ителгәне юк. 1941 елның октябрь аенда хәрби хезмәткә алынган. Җиденче аерым артбригадада хезмәт иткән. 1942 елның февралендә ул хезмәт иткән бригаданың ике дивизионы чолганышта калган. Красов хәбәрсез югалган булып исәпләнә.

Буе 171 см, түгәрәк йөзле, коңгырт чәчле, яшькелт күзле, почык борынлы, аз гына тотлыга, тәне тулы рәсем.

Левчук

Шифрорадиограмма
Левчукка

Ашыгыч

Повзнев Александр Григорьевич турында хәбәр итүегезне үтенәм. 1919 елда Мәскәүдә туган. 1939 елдан тегү фабрикасында мастер булып эшләгән. Хәрби хезмәткә 1941 елның октябрь аенда алынган.

Андрей

Шифрорадиограмма
Михайловка

23 майда азык-төлек төялгән эшелон шартлатылды. Гранаталар һәм пулемет патроннары җитми.

Журкин

Лейтенант кабул ителгән радиограммаларны штабка алып килде. Майор Журкин аларны игътибар белән укыды да уйчан гына:

— Красов шикләләр исәбеннән төшеп кала,— диде.

— Димәк ул, цезарь хатыны кебек пакь,— диде тикшерүче тыныч кына.— Арабызга кереп оялаган бүтән урман иблисен эзләргә туры килер, болай булгач.

Майор тәмәке кабызган иде, ютәлли башлады.

— Шушы чирдән ничек котылырга инде. Никадәр тәтен йотсам, шулкадәр сәламәтлегем какшый кебек. Ютәл дә шуның нәтиҗәсе. Ташламасаң, тагы да көчәюе мөмкин, дип врачлар да кисәтә инде.

Разведчикларга җаваплы бурыч йөкләнде. Алар, әгәр дошман Мовинога ярдәмгә башка гарнизоннардан гаскәр күчерә башласа, сигнал ракеталары белән вакытында хәбәр итәргә тиеш иде.

Немецлар отрядта азык-төлек җитешмәвен беләләрдер. Партизаннарның тоз һәм ашамлык кулга төшерергә теләүләрен көтеп, башка гарнизоннардан да көч туплап, тозак оештырулары мөмкин. Шуның өчен Мовино белән янәшә авылларга күзәтчеләр җибәрелде.

Китәр алдыннан искәртелгән булса да, яңа база төзелешенә җибәрелгән партизаннар иске биләмәгә кичке сәгать унда кайтмаячак иде. Дошман шымчылары хәйләне сизеп, хәбәр итеп өлгермәсен өчен, Мовинога һөҗүм нәкъ кичке унда башланачак. Бу зур авылның тирә-ягында урманнар. Шуңа күрә кичке эңгер-меңгердә авылга сиздерми генә якынаю мөмкин булырга тиеш. Немецлар да партизаннарның төн уртасыннан соң һөҗүм итүенә күнеккән. Моңа кадәр яхшы гына эшләгән шымчылары тегене-моны вакытында хәбәр итәр дип ышанулары да бар ич әле.

Капитан Ковригин җитәкчелегендәге отряд алдан билгеләнгән урынга кичке сәгать унынчыларда килеп җитте. Разведка взводы командиры Назаренко аңа хәлне аңлатты. Әлегә тыныч, дошман бернәрсә дә сизми кебек иде.

Ковригин түземсезлек белән сәгатенә караштыргалады. Унынчы яртыда:

— Барыгыз да үз урыннарыгызга,— дип боерык бирелде.

Аяк астында былтыргы яфраклар кыштырдый иде. Кешеләр берәмберәм караңгылыкка кереп югалдылар. Кайдадыр еракта төн кошы кычкырды. Баш очын караңгы болытлар каплаган иде. Берән-сәрән яңгыр тамчылый. Җил бөтенләй юк дип әйтерлек.

Ун тулырга биш минут калганда телефон чыбыкларын кистеләр — дошман хәзер башка гарнизоннар белән элемтәгә керә алмаячак иде. Шул минутларда старшина Назаренко җитәкчелегендәге разведчиклар тавыш-тынсыз гына сакта торучыларны юк итеп, авылны урап алган дзотлардагы пулемет ояларына ташландылар.

Төнге караңгылыкта әле анда, әле монда чүмәләдәй ут өеме күтәреп гранаталар шартлый башлады. Күп санлы автоматлар, пулеметлар бертуктаусыз үлем чәчәргә кереште. Ату бер тына, бер көчәя. Авыл уртасындагы казармадан үлем сиптерүче эре калибрлы пулемет, түбәсендә ялкын бии башлагач кына тынды.

Уттан качып тәрәзәләрдән сикергән фашистларны партизан уклары каршы алды. Исән калган берничәсе кулларын күтәрделәр.

Ярты сәгатьләр узгач, авылдан көнбатыштарак һавада ракеталар күренде. Димәк, шул яктан дошманга ярдәм ашыга. Инде тиз генә чигенергә кирәк иде. Һавага башта ак, бераздан яшел ракета чөелде. Алдан сөйләшенгәнчә, бу — чигенү сигналы иде.

Лагерьга иртәнге якта гына кайтып җиттеләр. Бер төн эчендә кулга төшерелгән корал, башка кирәк-яраклар күтәргән партизаннар ундүрт чакрым юл үттеләр. Авыр урман сукмаклары күпләрне хәлдән тайдырды.

Соңгы бер ай дәвамында бу уңышлы тәмамланган беренче һөҗүм булды — Мовино гарнизоны тулысынча юк ителде.

## 6

Мовинога һөҗүм вакытында әсир төшкән немецлар һәм полицайлар Орловка полицае сөйләгәннәрне раслады. Дөрестән дә, партизаннар «ауга» чыгып китүгә, бөтен гарнизоннарда да тревога күтәрелә икән. Бу хәбәр Нурмыевка бик мөһим нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирде: шымчы кайсы гарнизонга һөҗүм ителәсен беркайчан да төгәл белмәгән. Димәк, ул штаб тирәсендә йөрүче кеше түгел. Взвод командирларыннан шикләнү дә урынсыз булып чыга.

Тикшерүче өчен тагын бер мәсьәлә ачыкланды: тревога сигналларына караганда, партизаннарның сәфәр чыгулары турында хәбәр немецларга бик тиз арада барып җитә икән. Апрельдә һәм майда булган хәлләрне чагыштырып карагач, сәер бер закончалык күзгә ташланды.

Партизаннар базадан төрле вакытта чыгып киткән. Шуңа да карамастан, немецлар иң күбе ике сәгатьтән тревога күтәргәннәр.

Әсирләр әйтүенчә, гарнизоннарга тревога сигналы ниндидер бер үзәктән рация аша тапшырыла. Мовино гарнизонында да рация булган. Аннан телефон эшләмәгән очракларда да файдаланганнар.

Шымчы бөтен гарнизоннар белән үзе элемтәгә керәме икән? Андый очракта ул рациясез берни эшли алмас иде.

Нурмыев урыныннан сикереп торды. Чынлап та шулаймы икән? Тукта, ашыкма. Орловкада рация булмаган бит, әмма андагылар да партизаннар кузгалуы турында шул ук ике сәгать эчендә хәбәр ала торган булганнар. Димәк, шымчы гарнизоннар белән үзе элемтәгә керми. Алынган мәгълүматларны туплаучы бер үзәк бар, күрәсең. Бу очракта һәр шымчыда рация булу мәҗбүри түгел. Шулай да, хуҗалары белән ул ничек хәбәрләшә икән соң?

Отряд базасыннан иң якын авылга кадәр дә ун чакрым. Төнлә сазлыклар аша, беркемнең дә күзенә күренмичә, Непоновога барып җитеп буламы? Булуын була, тик бик авыр эш бу. Моның өчен якын-тирәне бик яхшы белергә кирәк. Юл буе йөгереп яки атка атланып барырга кирәк. Анда немецлар юк.

Нурмыев Непоновода яшәүчеләрне тикшереп карарга булды. Бәлки элемтәче шундадыр? Тик бу кечкенә авылдан иң якын немец гарнизонына кадәр тагын уналты чакрым кала. Шымчыга отрядтан Непоновога барып җитү өчен дә кимендә сәгать ярым вакыт кирәк. Непоноводан гарнизонга хәбәр итү өчен ярты сәгать кала. Шул вакыт эчендә юлсызнисез җирдән уналты чакрым араны ат белән дә үтеп булмый. Непоновода телефон юк. Димәк, рация бар. Шунсыз ике сәгать эчендә гарнизонга хәбәр итеп булмас иде.

Башкача да булырга мөмкин, дип уйлады лейтенант. Шымчы Непоновога хәбәр итә, ә андагы элемтәче йомышны гарнизонга тапшыра. Мәсәлән, ракеталар белән. Юк. Алай булса, Непоновога барып йөрүнең кирәге юк. Орловка ягына таба бераз барасы да җибәрәсе. Отрядтан Орловкага кадәр унике генә чакрым бит. Чынлап та! Мондый элемтәнең булуы бик мөмкин. Мәсәлән: кызыл ракета — гарнизонга һөҗүм көтелә, яшел ракета — тимер юл шартлатылачак, дигән сүз. Немецлар, ракета күренүгә, тревога күтәрәләр, партизаннарны әзерләнеп каршы алалар. Бу фаразны да тикшереп карарга кирәк. Рацияле элемтәче булу очрагын да онытырга ярамас.

Нурмыев караңгы төшүен дә, яңгыр башлануын да сизми утырды. Биек нарат-чыршыларны чайкалдырырлык көчле җил куыш ишеген шапылдатып япкач кына, уйларыннан арынды, ишекне ачып, һавага чыкты. Яңгыр ешява, икмәк уңар, ахры. Майда яуган җылы яңгырларга авыл картлары да сөенә иде бит. Туган якта ничек икән хәзер? Туган авылы, кадерле әнисе, сеңлесе Сәрвәр исенә төште. Әтисе 1941 елда һәлак булды. Дөньяда әнисе белән сеңлесеннән башка аның туганнары калмады. Сөйгән кызы да көтми. Берәү ошый иде заманында, тик ул Казанга укырга киткәч, кияүгә чыгып өлгергән.

Җил көчәйде. Кичке салкын да җәелә башлаган иде. Сәгатенә карасa, эфирга чыгу вакыты җиткән икән. Зәки ашыгып рациясен көйләргә тотынды.

Шифрорадиограмма

Андрейга

Повзнев Александр Григорьевич турында хәбәр итәм: 1919 елда Мәскәүдә туган. Хулиганлык өчен хөкем ителгән. 1940 елдан тегү фабрикасында слесарь булып эшләгән. 1941 елның октябрь аенда халык ополчениесе составында алгы сызыкка җибәрелгән. Хәбәрсез югалган.

Левчук

Әһә, бик тиз белешкәннәр,— дип уйларга өлгермәде, радиограмманың беренче юллары бөтен нәрсәне оныттырды. Чынлап та, Повзнев-

ның эчеп, тәртип бозып йөрүе башка кабахәт эшләрен яшерү өчен ширма булганмы әллә? Шымчымы ул, түгелме? Намусы саф кешегә элегрәк эшләгән эшләрен яшерү нигә кирәк?

Көтелмәгән хәбәр иде бу. Ә Зәки,юләр, Повзневтан шикләнми башлаган иде инде. Ярый әле башкаларга әйтеп өлгермәде.

Нурмыев штабка ашыкты. Командир сәкедә ютәлләп ята иде. Аның болай да агарынган йөзе лампа яктысында сап-сары булып күренде.

— Сез нәрсә, Илья Иосифович, әллә авырып киттегезме?

— Шулай ахры. Температурам югары, ютәлем дә көчәйде. Мондый һава миңа килешми инде, бигрәк юеш бит. Яңалыклар юктыр?

Журкин торып утырды. Тикшерүче алып килгән радиограмма аны да аптырашта калдырды.

— Менә сиңа мә! Әгәр Повзнев сатлык җан булса?!

— Ул хәзер кайда икән, иптәш майор?

Журкин хәлсезләнеп сәкегә ятты.

— Төшке аштан соң утыз биш кеше тимер юлга китте. Отрядта, таш юлдагы күперне шартлатырга баралар, дип әйттек. Сез өйрәткәнчә. Повзнев та шул төркемдә. Өч көннән генә кайтып җитсәләр инде.

Зәки командир яныннан чыкканда, күзгә төртсәң дә күренмәслек караңгы иде. Йолдызлар гына түгел, болытлар да күренми, җир белән күк тоташ караңгылык.

Ул үз куышына кайтып җиткәндә түбәннән генә самолет очып үтте. Сәгать уникенче ярты иде. Әллә беренче самолет булмадымы бүген? Ишетмәгәнмендер ахры, сәгать унда наушниклар киеп утыра идем шул.

Төнлә тагын аны самолет тавышы уятты.

Куышта бөркү булгангамы, Зәки йокыга китә алмый ятты. Еракта, урман артында, күк күкрәде. Аннары ул якынайганнан-якыная барып гөрелдәде. Яшенле яңгыр башланды.

Күк күкрәвен тыңлап күпме яткандыр, бервакыт ишек артында кыштырдау тавышы ишетелде. Анда кемдер бар кебек тоелды. Тагын тынлык урнашкач, «җәнлек йөридер, ахры дип уйлады лейтенант. Әмма кыштырдау тагын кабатланды.

Ишек бикле, дөресрәге, озын усак колга белән терәтелгән иде. Колганың икенче башы каршы як стенага терәлгән. Ишекне тышкы яктан ачу һич мөмкин түгел, ватарга гына кала.

Кемдер ишекне капшый да капшый.

Лейтенант, тавыш-тынсыз гына урыныннан торып, ишеккә таба атлады. Туктап тыңлап карады. Әйе, кемдер бар иде анда.

Йөрәк менә чыгам, менә чыгам, дип тибә. Чөйдә эленгән пиджак кесәсеннән пистолетын алырга дип үрелгән иде, кулы ялгыш өстәлдәге гильзадан ясалган лампага тиеп китте. Ул шартлап идәнгә төшүгә, ишек артында тынлык урнашты.

Лейтенант, тиз генә пистолетын алып, колганы тибеп төшерде дә, ишекне кинәт ачып, куыштан йөгереп чыкмакчы булды. Тик нindидер түгәрәк әйбер өстенә басты да, аягы таеп, янга ауды. Шул мизгелдә тонык тавыш белән ишеккә нәрсәдер килеп бәрелде. Зәкинең башына кыздырган тимер чыбык тигәндәй булды.

Нурмыев яшен яктысында ишеккә кадалган нечкә йөзле пычакны күреп алды.

Менә нәрсә тиеп киткән икән башыма, дип уйлап алды ул. Ярасыннан ага башлаган канны ул шунда гына сизде. Очраклы рәвештә генә исән калган икән, егылып китмәсә, пычак нәкъ күкрәгенә килеп кадаласы булган.

Зәки пычак очып килгән якка берничә тапкыр пистолеттан атты. Ату тавышын көчле күк күкрәү басып китте.

Лейтенант яр буенда үсеп утырган зирек куакларына таба йөгерде. Ул куаклар арасыннан чыкканда, тау башында бер кеше шәүләсе күренде. Аңа төзәп аткан иде, әмма өлгермәде, теге кеше тагын югалды.

Зәки бөтен көченә тау башына таба йөгерде. Ул менеп җитүгә тагын яшен яшьнәде, Нурмыев шуның яктысында дошманын күреп өлгерде. Шул минутта ату тавышы яңгырады, аның колак төбеннән генә ук сызгырып үтте. Пычакны яхшы ыргытасың, ләкин пистолеттан начаррак атасың, кабахәт! дип уйлап алды Зәки. Дошманы посып торган агачка таба ыргылган иде — беркем юк. Ул алга таба йөгерде, әмма хәзер ату тавышы ишетелде.

Яшен яктысы күзләрне чагылдыра, бернәрсә дә күренми иде. Мондый караңгыда кемнедер эзләү күз бәйләш уены белән бер иде. Табуга караганда качу җиңелрәк. Аяк тавышларын да ишетеп булмый, күк күкрәү озакка сузылган кайтаваз булып яңгырый, бүтән авазларны күмеп китә иде.

Нурмыев куаклар арасыннан да эзләп карады. Әмма дошманны җир йотты диярсең, юк та юк. Ичмасам, Зәкинең кесә фонаре да үзе белән түгел иде.

Штаб ягыннан ут яктылары сирпелде. Әллә күземә күренәләрме, дип башын тотып караган иде, каты авырту Зәкинең бөтен тәненә таралды. Күзләрен бер ачты, бер йомды. Чынлап та аңа таба киләләр. Димәк, базада тревога күтәргәннәр, аңа ярдәмгә ашыгалар.

Лейтенант иптәшләренә каршы атлады.

## 7

Ковригин җитәкчелегендә партизаннар тирә-юньне айкап чыксалар да, беркемне дә таба алмадылар. Төн кошы атышкан агач төбендә генә «Вальтер» системасындагы пистолет гильзалары табылды. Андый пистолетлы партизаннар исемлектә сигезәү теркәлгән иде. Исәпкә алынмаганнары да булырга мөмкин. «Вальтер» ияләре арасында исә Повзнев та бар иде. Тикшерү нәтиҗәсендә: «ауга» киткән җиде кешедән башка берәүнең дә тышка чыгып йөрмәве беленде. Ату тавышын штаб янында сакта торучы партизан ишеткән дә тиз генә отряд җитәкчеләренә хәбәр иткән икән.

Журкин танкка каршы атыла торган гранатаны Зәкигә күрсәтеп:

— Дошман сезнең ишегегез астына менә шуны урнаштырып яткан, тик өлгермәгән генә,— диде. Тәмәке төпчеген ишектән ыргыткач, елмайды:— Пычак үзегездә калсын, истәлеккә.

Нурмыев пычакны кулына алды. Шушы корал аны чак кына үтерми калды бит. Бандитларда, явыз җинаятьчеләрдә генә була торган, кнопкага басуга, йөзе атылып чыга торган пычак.

— Эсэс десантчыларыныкы.

— Әйе, бандитларның кораллары да үзләренә тиң,— диде Зәки утырган урыныннан кузгалып.— Ничек уйлыйсыз, бу һөҗүм радистны юк итү өченме, әллә...

Майор утырган җиреннән генә җавап бирде:

— Радисткадыр кебек. Үзәк белән элемтәне өзәргә телиләрдер. Ә бәлки отрядтагы шымчы берәр нәрсәне сизгәндер. Ни әйтсәң дә, үткән һөҗүмнең уңышлы тәмамлануы алар өчен күңелсез хәл бит. Моны сезнең отрядка килүегез нәтиҗәсе дип уйларга мөмкин.

— Әйе. Минемчә дә радистны һәм рацияне юк итәргә теләгәннәр сыман. Элек килгән радист та шулай һәлак булмадымы икән?

— Бомбага тоту вакытында радист куышын шартлатканнар дип уйлыйсызмы?

— Шундый шик туды. Отряд элек торган урынга барып, карап кайтырга кирәк. Бәлки берәр нәрсә ачыкланыр.

Отряд командиры алюминий кружкадан су эчте.

— Зәки Шәрипович, сезнең аяк киемегез дагалымы?

— Юк.

— Димәк, төнге кунак, үзе дә сизмәстән, «автограф» калдырган. Шымчы граната куяр өчен ишек астына чокыр казыганда, кызыл балчыкка баскан. Үкчә эзе ап-ачык күренә.

— Без аның рәсемен дә ясап алдык,— диде Журкин.— Үкчәсенә сынык дага кагылган.

Рәсемдәге үкчә эзе нәкъ Нурмыев күргән эзгә охшаган иде.

— Шиксез, бер үк аяк киеме эзе,— дип раслады Зәки.

— Сезнең саперлар белән сөйләшүегезне тыңлап торганлыгын да исәпкә алсак, дошман чынлап та сезне ничек булса да үтерергә уйлаган,— дип нәтиҗә ясады Журкин.

Шушы төнге вакыйгадан соң постларга кешеләр ике тапкыр артыграк куелды. Лейтенант исә көне буе төнлә дозорда булган партизаннар белән сөйләшеп йөрде. Тик аларның берсе дә уртача гәүдәле, карасу төстәге пиджак кигән кешене күрмәгән. Алар саклаган яктан элемтәче хатыннан тыш бүтән бер кеше дә узып китмәгән.

Төшке аш алдыннан Нурмыев база тирәсендә йөргән өчен кулга алынган кешеләрдән сорау алды. Аларның күбесе тирә-як авылларда яшәүче хатын-кызлар иде. Отрядта ул авыллардан да кешеләр байтак, шуңа күрә партизаннар үз танышларын кайтарып җибәрәләр, ә инде танымаганнарын кулга алалар иде.

Тикшерүчене бигрәк тә Непоново авылында яшәүчеләр кызыксындырды. Аның фикеренчә, ул авылда немецлар юк, шуңа күрә анда яшәүчеләрдән партизаннар бик шикләнмиләр иде. Гестапочыларның исә шуннан файдаланулары бик мөмкин. Гитлерчылар отрядтагы разведчиклары белән элемтә тоту өчен авылда берәр кеше урнаштырмадылар микән? Непоновода партизаннар да еш була. Авыл кешеләре дә төрле үләннәр җыярга урманга еш йөри, кайберләре базага кадәр барып җитә. Элемтәче шымчыга бик кирәк, шунсыз ул берни дә эшли алмас иде.

Кайдан эзләргә ул элемтәчене? Сукыр тычкан кебек җир астында яткан очракта да, аңа вакыт-вакыт дөнья йөзенә чыгарга туры килә бит. Ниндидер яшерен почта тартмалары булырга тиеш. Тәҗрибәле шымчы башка юл белән дә элемтәгә керә булыр, шунсыз булмас.

Ләкин төп элемтә юлы кайсы? Ул ничек шулай тиз хәбәр биреп өлгерә? Тикшерүче кабат-кабат менә шул сорауларга җавап эзләде.

Үзара сөйләшкәннән соң, штаб башлыгы Ковригин белән барлык постларны әйләнеп чыгарга булдылар. Берничә сәгатькә сузылган бу экскурсия бик ардырды: баш авырту аеруча хәлсезләндерде. Соңгы постларны тикшергәндә кояш инде офыкка житеп килә иде. Корыган куаклар арасындагы постка иңенә винтовка аскан озын буйлы карт белән немец автоматы тоткан бер таза егет баскан иде.

— Кайчаннан бирле торасыз?— дип сорады Ковригин.

Бил каешына лимонкалар таккан егет:

— Ярты сәгать чамасы, иптәш капитан,— дип җавап бирде.

— Бу урында ничәнче тапкыр инде?

Нурмыев соравына тагын егет җавап бирде:

— Санап бармадык. Беренче тапкыр гына түгел инде. Тик күбрәк башка урыннарда торырга туры килә.

— Төнлә йөрүчеләр булгаладымы?

— Булгалый. Тик алар барысы да парольне белә. Үзебезнекеләр, «аудан» кайтучылар.

Базадан сезнең пост аша төнлә берәр кешенең ялгыз гына чыгып киткәне булмадымы?

Партизан, ярдәм көткәндәй бер бабайга, бер штаб башлыгына карап алды да әкрен генә җавап бирде:

— Хәтерләмим. Юк ахры. Без бит андый очракта каравыл башлыгына хәбәр итәргә тиешбез.

Лейтенант Нурмыев кипкән агачларга таба күрсәтеп:

— Болар артында сазлык башланамы?— дип сорады.

— Шул каһәр суккан инде,— диде егет.— Черкиләр шулкадәр күп, берничек тә котылып булмый. Терелэй бөтен каныңны эчеп бетерүләре бар.

— Караштырасызмы соң?

Бераз эндәшми торганнан соң карт җавап бирде:

— Шайтан оясы бит ул. Анда белгән кеше генә йөри ала. Әз генә ялгыш бастыңмы, беттең дигән сүз.

— Сез әллә бу тирә кешесеме? — дип сорады Нурмыев.

— Әйе, Орловкадан.

— Сазлык киңме?

— Биш-алты чакрым бардыр.

— Непоново ягына үтеп буламы?

— Була. Башта турыга, аннары сазлык чиге буйлап олы юлга кадәр сукмак бар. Олы юлдан Непоновога да ерак калмый.

Посттагылар белән саубуллашып кайтырга чыктылар. Нурмыев Ковригиннан сазлык янына өстәмә пост куюын үтенде. Отряд командиры андый күрсәтмә биргән икән инде.

## 8

Штаб яныннан килеп җиткәндә Нурмыев хатын-кыз эндәшүен ишетте.

— Авыру иптәш, мин сезне күптәннән эзлим инде.

Әйләнеп караса, уртача буйлы бер чибәр кыз басып тора икән. Аның зур яшькелт күзләре кызыксыну белән Зәкигә төбәлгән. Башы чалма кебек бинт белән уралган Нурмыев аны күргәч:

— Мин үзем дә сезне күптәннән эзлим,— диде.

— Ничек инде эзлисез? Мин көн буе лазаретта идем, ике тапкыр куышыгызга да кереп чыктым.

Синең кебек бер күрүдә гашыйк булырлык кыз эзли идем, дип әйтергә теләде Зәки. Тик, юк шул, аңлатуы кыенрак икән.

— Без, ни, барып кайттык... соңрак керермен, дип уйлаган идем, онытканмын...

Кыз аңардан күзен алмый карап торды-торды да елмайды.

Зәки дә кыюланып китте. Чибәркәйнең ике битендә нинди матур чокырлар.

— Ярагызны чиста бинт белән бәйләргә кирәк бит,— диде кыз, ярым пышылдап.

Бу таныш булмаган чибәр кызның кем икәнлеген Зәки шул минутта гына аңлады. Төнлә аның ярасын врач бәйләгән иде шул.

Үзенең кем һәм кайда икәнен исенә төшерү дә сүндерә алмады йөрәгендә кабынган ялкынлы хисне. Киресенчә, бу сөйкемле кыз аның күңеленә мәңгегә керде. Азмы-күпме яшәп,бер дә мондый хәл булганы юк иде әле. Көтмәгәндә-уйламаганда шундый очрашу...

Сокланырлык хатын-кызлар очраткалаганы бар иде аның. Бервакыт Зәки хезмәт иткән фронтка концерт бригадасы килде. Артистлар арасында яшь, талантлы җырчы Мөнирә Булатова да бар иде. Аның чибәрлеге, моңлы тавышы Зәкине таң калдырды. Әмма ул — җырчы, сәхнә йолдызы... Ул үзен Мөнирә белән янәшә куеп күз алдына да китерә алмады. Ә бүген...

Ярасын бәйләгәндә авыртуны бөтенләй сизмәде.

— Менә булды да,— диде кыз.— Бәхеткә каршы, ярагыз тирән түгел, тиз төзәлер.

— Мин кемгә рәхмәт әйтергә тиеш соң?

— Врачка, Валентин Владимирович Губинга. Ярагызны кичә ул чистартып бәйләгән бит. Тик сезгә бераз ятып торырга кирәк. Ике көннән яңадан бәйләрбез. Килештекме?

— Гафу итегез, сезнең исемегез ничек?

— Вера. Вера Бунакова. Медфельдшер мин.
— Ә минем исемем — Андрей. Саф һавада ял итеп кайтырга, дип җибәргәннәр иде, менә ничек килеп чыкты иң әле.
— Андрей сезнең үз исемегезме? — Кыз Зәкинең икеләнеп торуын күргәч, дәвам итте.— Димәк, кушамат? Ай, мин нигә әле әлләниләр сорашам. Шулай булырга тиешлеген белә торып.
— Әйе, бу минем кушаматым.
Вера тагын сүз башлап:
— Сезнең профессия кешеләре өчен мондый яра белән генә котылу зур бәхет инде ул,— диде.
— Ничек инде? — диде Зәки. — Радист хезмәте бакчачыныкы кебек тыныч профессия, сәламәтлеккә бернинди зыяны юк.
Вера көлеп куйды.
— Чагыштыруым өчен гафу итегез, ләкин башын комга яшергән тәвә кошын күренми дип әйтү дөрес булмас.
Вераның бу сүзләре Зәкине аптырашта калдырды.
Бер карасаң, гаҗәпләнерлек нәрсә юк та инде. Аның партизаннардан нидер сорашуын, әсирләрдән төпченүен күргәннән соң, Зәкинең кем икәнлегенә төшенү бик авыр түгел иде, билгеле. Хәзер инде яшереп торуның кирәге дә шулкадәр генә. Тик барыбер кызык.
— Нигә, мин радистка охшамаганмыни?
— Кулларыгыз охшамаган. Гадәттә, радистларның куллары пианистларныкы кебек була. Ә сезнекеләр күбрәк боксерларны хәтерләтә. Физик күнегүләр нәтиҗәсе күренеп тора. Өстәвенә, сез артык күп нәрсәләр белән кызыксынасыз, ә бу монда бик тиз күзгә ташлана.
— Менә ичмасам күзәтүчәнлек! Сездән сер яшереп булмый икән,— диде Зәки гаҗәпләнеп. — Китаплардан укып өйрәндегезме?
— Юк,— диде Вера. — Минем әтием — чекист. Игътибарлы булырга да мине ул өйрәтте. Англиядә Честерфилд дигән бер акыл иясе яшәгән. Әтием аның игътибарсыз кеше — төпле кеше түгел, андыйлар еш кына көлкегә кала, ә таркау кеше, гомумән, юләргә охшый, дигән сүзләрен искә төшерергә ярата иде.
Әгәр дә тирә-юньдәгеләргә игътибарымны көчәйтмәсәм, минем дә кеше көлкесенә калуым бар бит, дип уйлады Зәки.
— Вера, өстәвенә сез кызыклы әңгәмәдәш тә икән.
Кыз оялып кына кул селтәде:
— Сез нәрсә, Андрей! Бу... болай гына. Мин бит әле медицина институтын тәмамларга да өлгермәдем. Минскида укый идем...
Шул чак база өстеннән самолет очып үтте. Нурмыев, үзе дә сизмәстән, сәгатенә күз салды: ун тулган икән.
Вера урыныннан торып сумкасын иңенә асты да:
— Ярый, бик соң бит инде, сездә озаграк утырылды, мине лазаретта яралылар һәм авырулар көтә әле,— дип китәргә кузгалды.
— Сезне озатып куярга мөмкинме?
— Кәефегез яхшы булса, әйдәгез.
Зәки, пиджагын киеп, аның артыннан чыкты.
Лазарет базадан бер читтәрәк, зур гына агач йортта урнашкан иде. Баз кебек куышларда яралар озаграк төзәлә. Йорт калкулыкның нәкъ уртасында тора. Тирә-ягында йөзәр яшьлек чыршы, наратлар. «Козгыннар» күзенә бик үк ташланмасын өчен, бөтен яктан түбәсенә кадәр корыган агачлар өелгән, өстенә чыршы ботаклары салынган. Бары тик тимер морҗа башы гына чыгып тора. Йортны урман эченәрәк тә салырга мөмкин булгандыр иң,— дип уйлап алды Зәки.— Сугыш вакыты өчен артык кыюлык бит бу. Игътибар белән карасаң күктән дә күренәдер.
— Менә килеп тә җиттек,— диде Вера.
Алар куе ябалдашлы, кәүсәсе буйлап чәере агып төшкән юан нарат төбендә тукталдылар. Янәшәдә, үлән арасында, чикерткәләр җырлый. Сукмакка терәлеп үк үскән карга миләше, кычыткан, абага исе чәер

исенә кушылып, башларны әйләндерә. Зәкинең хәтеренә мәктәп еллары килеп төште. Класслары белән мәһабәт Алабуга урманнарына беренче көнгә экскурсиягә барганнар иде. Гаҗәеп саф нарат урманы һавасына ул беренче тапкыр шунда рәхәтләнгән иде.

— Ниләр уйлыйсыз? — дип сорады кыз йомшак кына.

— Беренче тапкыр чын урманга баруым исемә төште. Сигезенче класста укыганда килеп эләккән идем наратлыкка.

Ерак түгел генә кәккүк кычкырды.

— Бу кәккүк безгә гомерне бик аз санады,— диде кошка колак салып торган кыз. Икебезгә әллә ике ай, әллә ике ел шунда. Бәлки әле ике көн генәдер.

— Нигә алай дисез, Вера? Без әле ай-һай күп яшәрбез. Безнең эшләрне башка кеше эшләмәс бит.

Зәки, кыңгырау чәчәкләре өзеп алды да, кызга тәкъдим итте.

— Болар сезгә, Вера...

— Ай, рәхмәт сезгә. Минем моңа кадәр аларга игътибар да иткәнем юк иде. Һәрвакыт ашыгам.

— Сез сынамышларга ышанасызмы? — дип сорады Зәки елмаеп.

— Сугышта ышана башлыйсың икән. Иртә белән уянганда сәламәт кешеләр кичен мәңгелек йокыга тала...

Нурмыев, шук малайлар кебек, кул гына селтәде:

— Сугыш турында бераз гына онытып торыйк әле. Теләсәгез, мин сезгә хәзер шигырьләр укыйм.

— Әлбәттә. Шигырьләрдән дә яхшы нәрсә бар бу дөньяда?

Вераның күзләрендәге сагышны елмаю алыштырды.

Әйтүен әйтте, тик куркыбрак калды Зәки үзен мәгънәсез тотмыймы икән? Начар фикер тумасын тагы, нигә дип шигырьләр турында әйтеп ташлады инде, бәлки аңа ошамас та? Ул кызның елмаюлы йөзен күргәч кенә тынычланды.

Беркадәр тынлыктан соң кыюсыз гына башлап җибәрде:

Озын юллар уздым,
Сүзем булыр кыска.
Кояш алып кайттым
Төреп кайнар хискә.

Көчле җилләр исте,
Салкын суда йөздем.

Сагыну сүзен җырга
Җәүһәр итеп тездем.

Җырлыйк әйдә үргә
Илткән юлны зурлап,
Ике йөрәк бергә
Сипкән нурны зурлап.

— Әллә үзегез яздыгызмы?

Зәки «әйе» дигәнне белдереп башын иде.

— Яхшы шигырь, миңа бик ошады. Сез аны берәрсенә багышлап язган идегезме?

Нурмыев баш чайкады. Вера аның тагын нинди дә булса шигырь укуын үтенде.

Нинди шигырь укырга икәнлеген зәңгәр күктә салмак йөзгән болытлардан сорарга теләгәндәй, Зәки, башын югары күтәреп, бераз зәңгәр күккә карап торды.

— Татарстанда бик сәләтле, өметле яшь шагыйрь бар,— диде ул. — Сибгат Хәким. Ул, киләчәктә, һичшиксез, татар әдәбиятында тирән эз калдырыр.

Сызлана кайчакта күңел,
Белмим нәрсә булганын.
Тик син генә юатасың
Иңгә салып кулларын...

Шигырьне уйчан гына тыңлап торган Вера:

— Бик акыллы кешедер ул,— диде. — Хатын-кызның тормышта тоткан урынын ничек күрсәтә, ә?!

Ерактан, урман читеннән, тагын күке тавышы ишетелде. Язмыш хә-

бәрчесен Вера тагын тын калып тыңлады. Йөзендә тагын елмаю сүнде, күзләрен сагыш басты.

Кызны авыр уйларыннан арындырырга теләгәндәй, Зәки ашыгып сүз башлады:

— Вера, беләсезме, мин тагын нәрсә турында уйладым?

— Нәрсә турында?

— Лазарет, минемчә, бик ачык урында тора. Берәр хәл булмасын иде...

— Бу сезнең профессиональ саклык нәтиҗәсе,— диде Вера, көлеп.— Без күнектек инде.

— Кешеләрнең саксызлыкка күнегүе икеләтә куркыныч, хәтта тыныч заманда да.

— Ковригин йортны урман эченә салырга тәкъдим иткән иде, Валентин Владимирович риза булмады. Авыруларга кояш кирәк, юеш урман һавасы зыянлы, диде. Врачларның һәм хәрбиләрнең бурычлары да, фикерләре дә төрлечә бит.

— Сез бүген төнлә дежур торасызмы?

— Гадәттә төннәрен Валентин Владимирович үзе була. Мин зур бәрелешләрдән соң яралылар күп килгәндә генә калам.

Вера саубуллашырга кул биреп:

— Хушыгыз, миңа әле авыруларны карап чыгарга кирәк,— диде.

Зәки кызның кулларын кысып:

— Сезнең белән очрашу мине терелтте дә инде,— диде.— Сез... сез искиткеч, Вера!

Кыз оялып, әкрен генә кулларын ычкындырды. Сез үзегез дә, дип әйтәсе килде аның, тик:

— Чын күңелегездән әйтүегезме? — дип кенә сорады.

— Әйе, чын күңелемнән,— диде Зәки.

Егетнең шатлыгы эченә сыймады бу мизгелдә. Бүгенге көн аңа тормышының иң бәхетле көне булып тоелды. Ярасы да, хәлсезлеге дә онытылды. Ул үзендә чиксез көч тууын сизде. Нурмыев бераз нарат төбендә утырып торды, аннан соң бик озак лагерь буйлап йөрде. Караңгы төшүен дә, штаб янына барып чыгуын да сизмәде Зәки.

## 9

Штаб куышы янында аңа Ковригин очрады.

— Андрей, мин сезне эзлим.

— Тыңлыйм,— диде Зәки.

— Сезнең өчен яңалыклар бар.— Штабка кергәч, Ковригин кесәсеннән химик карандаш белән язылган язу чыгарды.— Сигнал ракеталары турында сорашканыгызны хәтерлисезме?

— Әйе, хәтерлим.

— Дөрестән дә, май аенда моннан ерак түгел ракеталар атылуын күрүчеләр булган. Төрле төстә. Кем атканы билгесез. Ракеталарны кичен дә, төнлә дә күргәннәр. Элекке база янында да күрүчеләр булган. Хәерле хәбәр түгел бу. Гестапо кешеләре эшенә охшаган.

— Бик мөмкин. Алдан килешеп куелган очракта, төсле ракеталар белән күп нәрсәне хәбәр итәргә була...

Ковригин кәгазь кисәген тикшерүчегә сузды:

— Менә бу язуны укып кара әле. Таракан эзе кебек булса да, танырлык.

Зәки язуны бик авырлык белән укыды.

*Отряд командиры майор Журкинга*

Немецлар безнең базаны бомбага тотканнан соң, мин авыр яраланган партизан Ивлиевны лазаретка алып киллем. Юлда Ивлиев берничә тапкыр: «Нигә ракеталар җибә-

рәсен. Нигә...» дип кабатлады. Мин бу сүзләрне яралының саташуы дип аңладым. Шуңа күрә командирга бу турыда әйтмәдем.

*Печков*

— Ивлиев исәнме? — дип сорады Нурмыев.

— Исән, исән. Терелеп килә инде. Мин бүген аның янына кереп чыктым, бераз сөйләшеп утырдык. Аның уң кулына бомба кыйпылчыгы тигән, көчле контузия алган егет.

Бераздан штаб башлыгы:

— Ивлиев бомбалау вакытында бер партизанның төрле төстәге ракеталар чөюен күргән,— диде.— Партизанның исемен белми, күрсәм — танырмын, ди.

Нурмыев урындыгыннан сикереп торды:

— Алай булгач, нигә тик утырабыз соң без?

— Зәки Шәрипович, бу турыда мин үзем кырык минут элек кенә ишеттем. Төн уртасы бит хәзер. Әйдәгез, иртәнгә кадәр көтик инде. Ризамы?

— Чынлап та шулай дөресрәк булыр.

— Төнлә танымавы да бар.

Ковригин үз ординарецын каравыл башлыгы Плавневны чакырырга җибәрде. Плавнев ике атна чамасы элек майның унберенә каршы төндә, базадан өч километр чамасы читтәрәк төрле төстәге ракеталар чөелүен үз күзләре белән күргән икән. Шул яктагы Орловкага таба Повзнев җитәкчелегендә биш кешелек төркем киткән булган икән.

Кем нинди максат белән чөйгән ул ракеталарны — билгесез.

Тагын Повзнев! Эшләр болай барса, аның шымчы икәнлегенә ышана да башларсың. Юк, ашыкмаска кирәк, ялгыш фикерне үзгәртү бик кыен.

Кинәт базадан төньяктарак көчле атыш башланды. Гранаталар шартлаганы ишетелде. Отрядта тревога күтәрелде. Минерларны эзәрлекләп килүче немец жандармнары партизаннар тозагына эләккән икән. Берничәсе генә качып котыла алган. Отрядның төп көчләре килеп җиткәндә бәрелеш беткән иде инде.

Әмма отряд командирының ачуы басылмады.

— Бу хәшәрәтләр бигрәк оятсыз кылана, нәкъ күселәр кебек,— диде ул.— Әз генә ирек бирсәң, күз алдында ачыктан-ачык йөри башлыйлар.

Бераз ютәлләгәннән соң ул Нурмыевка борылып:

— Иптәш лейтенант, эшләр ничек бара, ярдәм кирәк түгелме? — дип эндәште.

Нурмыев бу көннәрдә эшләнгән эш нәтиҗәләре, алдагы көннәргә планнары турында сөйләп бирде.

— Сигнал ракеталары буенча бер җеп очы чыгып тора,— дип өстәде Ковригин.— Зәки Шәрипович әйтми калдырды, тыйнаклык бәласе.

Зәкинең бу турыда әйтмәве аңлашыла. Сигнал ракеталарының шымчыны табарга ярдәм итүенә бик үк ышанып бетми иде әле ул. Инде берничә көн отрядта бөтерелсә дә, әлегә эшенең нәтиҗәсе юк иде. Тозаклар корылган корылуын, тик кайчан эләгер бу куркыныч җанвар — билгесез.

Тирән тылдагы партизан отрядларында дошман шымчыларына каршы көрәш үзенчәлекләрен өйрәнергә туры килмәде аңа. Ә үзенчәлекләр җитәрлек. Тикшерүченең үзен сазлык уртасындагы кечкенә утрауда кебек хис итүе генә дә ни тора!

Тирә-юньдә — дошман. Кемдер партизан кыяфәтенә кергән дә, шыпырт кына синең сугышчан дусларыңны үлем кочагына этәрә. Туганнарың кебек якын кешеләр күз алдында һәлак була, ә син берничек тә аларны коткара алмыйсың. Бу һәлакәтне авыр кичерәсең, ашыга башлыйсың, нәтиҗәдә ялгыш арты ялгыш җибәрүең ихтимал.

Җинаять эшен тикшерү, шикләрне эзләү — иҗади эш. Һәр иҗади

эштәге кебек, монда да билгесезлек күп. Кайчак хәтта үз көчеңә үзең ышанмый башлыйсың: булдыра алырмынмы, хәлемнән килерме, дөрес юл сайладыммы, дигән сораулар калка. Мондый очракта бары ахмак кешедә генә шик тумаска мөмкин. Ахмак эше — иҗади була алмый, ул бернинди ачыш ясамый, билгесезлек шулай кала бирә.

Фронтта, Зур җирдә дошман шымчыларын эзләү, тотуга караганда отрядта күп тапкыр авыррак иде Зәкигә. Ул бу авырлыкның сәбәбен Дмитрий Левчук кебек төп фикерне тиз генә әләктереп ала белмәвендә, тәҗрибәсе азлыкта күрде. Әмма Зәки бу шартларда үз-үзеңне тота белү, бик киеренке, куркыныч хәлләрдә дә алдан төзелгән планнарыңны эзлекле рәвештә тормышка ашыра белү кирәклеген аңлый иде. Халык тулы шау-шулы трамвайда катлаулы мәсьәлә чишәргә мәҗбүр булган галим кебек хис итте ул үзен.

Нурмыев авыр уйларыннан Журкин иңбашына кагылгач кына айныды:

— Әллә хәлегез авырмы, Зәки Шәрипович?

— Юк, юк, борчылмагыз,— диде ул.— Минем сезгә бер үтенечем бар: дошман кулына төшкән Непоново авылында яши башлаган кешеләр исемлеген төзергә иде.

Штаб башлыгы нигә инде андый эш турында командирга мөрәҗәгать итәргә, дигән төсле шелтәле караш ташлады. Аннары:

— Иртәгә кичке якта исемлек әзер булыр,— диде.

Ул төн шундый тыныч, аяз иде. Күктә берсеннән-берсе якты йолдызлар җемелди. Нурмыев бик озак йокыга китә алмый ятты — медфельдшер Вера уеннан чыкмады.Тавышы,әйткән сүзләре искә төште, чәчләре, йөзе күз алдына килде, җылы йомшак куллары, гаҗәеп мөлаем карашы аны һаман иркәли кебек тоелды.

Зәкинең йөрәге шатлыктан бер кысылып туктап калгандай була, бер ашкынып, ярсып тибә башлый иде. Шул минутта ук торып йөгерәсе, Вераны күрәсе,кызыкайга җылы сүзләр әйтәсе килә иде аның. Зәки таң алдыннан гына йоклап китте. Аксыл болытлар артында шәфәкъ кызара башлауга, куыш ишеген шакыдылар. Зәки урыныннан торып пистолетын кулына алды да ишек янына килде.

— Кем бар анда?

Ишек артыннан отряд командиры ординарецы тавышы ишетелде.

— Иптәш лейтенант, сезне майор Журкин штабка чакыра.

Зәки тиз генә киенеп штабка китте. Монда инде отряд җитәкчеләре һәммәсе җыелган иде. Арада таныш түгел бер ир кеше дә бар.

— Повзнев «аудан» кайтты,— дип сүз башлады Журкин.— Без аның берничә сорауга җавап бирүен сорыйбыз.

Штаб башлыгы Ковригин Повзневка соңгы эшнең ничек башкарылуы турында сөйләргә кушты.

Уртача буйлы, каракучкыл йөзен сакал-мыек баскан Повзнев салмак кына сөйләп китте. Тимер юлда дошман патруленә юлыкканнар икән. Немецлар озак эзәрлекләгән. Атышулар барышында дүрт иптәше һәлак булган. Кулы яраланган Повзнев отрядка берүзе исән кайткан. Пиджагын ике җирдән пуля тишеп үткән, сул җиңе канга буялган.

Ул күпсанлы сорауларга җавап бирде. Штабтагыларны әйтелмәгән бер сорау борчый иде: дошманмы Повзнев, юкмы? Повзнев элегрәк хөкемгә тартылганлыгын танырга мәҗбүр булды. Концлагерьдан качканнан соң ышанмаслар дип уйлаган, шуңа яшергән. Немецларга яллanмавын бик катгый икрарь итте.

Повзневның аяк киеменә күз салып, Нурмыев:

— Өченче көн төнлә кайда идегез? — дип сорады.

Сорау алынучы иңнәрен сикертте.

— Яшенле яңгыр яуган төндәме?

— Әйе, нәкъ шул төнне,— диде Зәки.

— Исемә төште. Без Валетов белән Непоново авылына барып чык-

тык. Немецлар безне этләр белән куа киләләр иде, яңгыр башлангач, эзләребезне югалттылар, ахры. Непоновога иртән генә килеп җиттеләр. Бөтен авылның астын-өскә китерә башлагач, без, төн кунган печәнлектән төшеп, урманга таба сыпырттык. Шулвакыт шыксыз гына бер бәндә, бәйгә бәйләнмәгән үгез кебек, үкерергә тотынды: «Каракла-а-ар, каракла-а-ар!» Билгеле инде, немецлар моны ишетеп алдылар да безнең арттан! Тиздән Валерканың башына җиттеләр. Мин ятып ата башладым, өчесен дөмектердем. Калганнары шуннан соң туктап калды. Мин башта караңгылыкка кереп югалдым, аннан сазлыкка. Немецлар сазлыкка керергә курыктылар, пуля яңгыры гына яудырдылар. Шунда эләкте инде кулыма. Озак адашып йөрдем йөрүен, әмма кайтып җиттем...

Тикшерүче Повзневка хәлне ачыклау өчен тагын берничә сорау бирде: кунган печәнлеге кай җирдәрәк, аларны авыл кешеләреннән кем дә булса күргәнме, аваз салган бәндә каян килеп чыккан, аның төс-кыяфәте нинди?

Повзневның коралын да тикшерделәр: «Вальтер» пистолетының көпшәсе чиста, обоймасы да тулы, димәк, ул аңардан соңгы көннәрдә атмаган. Итек табаны эзе дә шымчы калдырган эзгә охшамаган иде.

Повзнев унберенче майга каршы төндә бер төркем партизаннар белән Орловкага разведкага баруын, ракеталар атылуын күрүен дә сөйләде. Тик ул ракеталарны партизаннар чөймәгән, алар бишесе дә һәрвакыт бергә булганнар. Юл уңаенда гранаталар белән бер дзотны юк иткәннәр. Сорау алу иртәнге якта, отрядта «уяну» командасы бирелгәч кенә тәмамланды. Соңрак үткәрелгән тикшерүләр дә Повзневның ракеталар чөймәвен раслады.

Барысы да урыннарыннан кузгалыр алдыннан майор Журкин йомгак ясап:

— Менә нәрсә, Повзнев. Сез сөйләгәннәргә бик ышанасыбыз килә,— диде. — Әмма бер алдаган кешенең икенче тапкыр да алдавы мөмкин. Шуңа күрә без сүзегезнең дөреслеген тикшереп карарга тиешбез. Әлегә сезгә сак астында утырырга туры киләчәк. Үзегезне гауптвахтада дип исәпләгез.

Иртәнге барлаудан соң бөтен отряд аланга тезелде. Отряд командиры Журкин:

— Иптәшләр! Базаны соңгы тапкыр бомбага тотканда кайсыгыз ракеталар атты? Шул кеше ике адым алга чыгарга тиеш,— дип боерды.

Зираттагы кебек авыр тынлык урнашты. Бераздан сафлар корт күчедәй гүли башлады. Алга чыгучы күренмәде.

— Бәлки берәрегез ул ракеталарны күргәндер?

Тагын җавап бирүче булмады.

Ковригин боерыгы буенча носилкада яралы Ивлиевны алып килделәр. Чалкан яткан Ивлиев башын борып сафтагы партизаннарга карап барды. Уртадарак басып торучы тәбәнәк буйлы, аксыл чәчле, гимнастеркасына сержант петлицалары таккан партизанны күргәч, туктарга кушты:

— Менә ул.

— Иптәш сержант, алга чыгыгыз! — дип боерды Ковригин.

Сержант, агарынып, ике адым алга атлады. Ковригин аңа үзе артыннан иярергә кушты.

Сафтагыларның берсе акрын гына:

— Бу эштән кабер исе килә, егетләр,— диде.

Сержанттан сорау алу да штабта барды. Партизан үзе дә моңа әзерләнгәндәй иде — җаваплары көттермәде.

— Иптәш Скишов, сез нигә минем боерыктан соң алга чыкмадыгыз? — дип сорады Ковригин.

— Курыктым, иптәш майор. Җен алмаштыргандай булды,— кулаякларым хәрәкәтләнмәс булды. Юкка гына бөтен отрядны тезеп куймаслар, димәк, ракеталар чөеп дөрес эшләмәгәнмен икән, дип уйладым.

Дошман самолетлары базаны бомбага тота башлагач, ракеталар чөюен Скишов яшермәде.

— Булды андый эш, булды,— дип җавап бирде ул күңелсез генә.

— Кем кушуы буенча эшләдегез бу эшне? — дип сорады штаб башлыгы ачулы тавыш белән.

Куркудан агарынган сержант баш чайкады.

— Мине беркем дә мәҗбүр итмәде, иптәш капитан, мин үзем, үзем.

Майор Журкин тавышы бигрәк тә ачулы иде:

— Ни өчен, Скишов?

— Мин... шулай яхшырак булыр дип уйладым.

Коврвигин сәер генә көлеп куйды:

— Яхшырак булыр, имеш. Бомбалар дөрес ташлана дип хәбәр иткән дә, хәзер безнең башны әйләндермәкче була.

Мөшкел хәлен яхшы аңлый иде Скишов. Калтыранган кулларын угалап, ашыга-ашыга сөйли башлады:

— Мин сугыш башланганнан бирле фронтта. Күп тапкырлар безне бомбага тотканнары булды. Немецлар безнең траншеяларга таба төрле төстәге ракеталар җибәреп, бомбаларны кая ташларга икәнлеген күрсәтә иде. Мин дә шулай эшләргә булдым... Дөресрәге, очучыларны алдарга уйладым.— Сержант командирларның кырыс йөзләренә күз йөртеп чыкты.— Бомбалар нәкъ база өстенә ява башлагач, ракетницам барлыгы исемә төште...

Скишов, кипкән иреннәрен ялап, сөйләвеннән туктады.

— Шуннан? — Журкин инде бераз тынычланган иде. Андый очраклар булгалады бит инде, үзенең дә берничә тапкыр шулай хәйләләгәне бар.

— Ракетницам барлыгы искә төшүгә, база читенә сыздым. Постларга барып житкәч, бер чокырга төштем дә әйдә сазлыкка таба ракеталар чөяргә. Файдасы бик зур булмады булуын. Бары бер звено гына бомбаларын сазлыкка ташлады.

— Ракетницаны кайдан алдыгыз? — дип сорады Нурмыев.

— Бер генә көн элек, кич белән мотоциклда узып баручы ике немецны дөмектергән идек. Мотоцикл бишегендә ракетницалар бар иде, ракеталары да житәрлек. Тапшырырга өлгермәдек. Иртән бомбалаучылар килеп житте...

— Ракеталар чөйгәнегезне кем күрде? — дип сорады тикшерүче.

— Шул инде... теге яралы партизан...

— Аның фамилиясе Ивлиев.

— Димәк, Ивлиев була инде.

— Тагын кем?

— Тагын кемдер бар иде...— Сержант калтыранган куллары белән башын тотып уйга калды.— Әйе, бар иде. Мин сикергән тирән чокырда ул утыра иде инде. Ташла ракетницаңны, хәзер монда бомба ташлыйлар бит! — дип ике тапкыр кычкырды да әле. Аннары куян кебек урманга кереп югалды. Мин аны, башка очратмадым. Мин аны барыбер исемә төшерәм әле. Кайсы якка таба ракеталар чөюмне ул да әйтер.

Ивлиев белән кабат сөйләшергә туры килде. Әйе, кемдер «ракетницаңны ташла», дип кычкырганны ул да ишеткән, тик әмер бирүченең үзен күрмәгән, аңын югалткан. Аңсыз вакытта шуның сүзләрен кабатлаган икән.

Бөтен командирларга әйтеп карасалар да, икенче шаһит ул көнне табылмады.

Нурмыев бер үк сорауга кабат-кабат җавап эзләде: «Нигә икенче шаһит табылмый? Сәбәп нәрсәдә? Бәлки берәр нәрсәдән куркадыр? Кеше язмышы хәл ителә бит, аңларга тиеш. Ракеталарның кая юнәлтелгәнен ул гына әйтә ала. Скишовның дошманмы, түгелме икәнлеген

шунда гына ачыклап булачак. Ә бәлки ул бәндә Скишовның үлүен телидер?

Кичен Нурмыев Үзәк белән элемтәгә керде.

**Шифрорадиограмма** **Бик ашыгыч**
**Левчукка**
**Скишов Михаил Гаврилович турында хәбәр итүегезне сорыйм. 1922 елда Ярославль шәһәрендә туган. 1941 елда 15 номерлы урта мәктәпне тәмамлаган. 1941 елның августында армия сафларына алынган.**
**Андрей**

**Шифрорадиограмма**
**Михайловка**
**Егерме җиденче майда танклар төялгән эшелон юк ителде. Соңгы өч тәүлек эчендә бер дошман гарнизоны тар-мар кылынды. Немецларның барысы 162 солдаты һәм офицеры, кырыкка якын полицай сафтан чыгарылды. 147 данә корал һәм зур күләмдә сугыш кирәк-яраклары кулга төшерелде.**
**Журкин**

**Шифрорадиограмма**
**Журкинга**
**Тимер юлда һөҗүмнәрне көчәйтегез. Төп юнәлешләрдә гаскәрләр күчерелүгә игътибар итегез.**
**Сугыш кирәк-яраклары җибәрәбез. Утыз беренче майга каршы төндә самолет көтегез. Төшү өчен, өчпочмак рәвешендә учаклар ягып, сигнал бирегез.**
**Михайлов**

## 10

Төн уртасында, базаның төньяк читендә көчле атыш башланды. Төнге гранаталар аеруча көчле тавыш белән шартлый, әйтерсең лә кемдер зур чүкеч белән буш тимер мичкәгә суга иде.

Лейтенант Нурмыев бу тавышларны ишетмәде. Үткән төнне йокламагангадыр, ахры, Вера турында уйласа да, бик тиз йоклап китте ул. Ишеген кемдер бик каты кага башлагач та Нурмыев озак кына уяна алмый ятты. Башы чатный, күзләре ачылмый. Торгач та ишек янына исерек кешедәй чайкалгалап барды.

— Кем бар анда?

— Мин, Седов. Дежурный Седов. Иптәш Андрей, отряд командиры сезне үзе янына чакыра. Ул — сазлык янындагы постта.

Тикшерүче шунда гына тәмам уянып җитте.

— Нәрсә булды?

— Сакта торучыларга һөҗүм иткәннәр. Билгесез берәү Охрим бабайны үтереп лагерьдан качкан.

Берничә минуттан лейтенант әлеге постка барып җиткән иде инде.

Сизелер-сизелмәс сузылган сукмак каршыдагы сазлыкка кереп югала. Постларны тикшереп йөргәндә Нурмыев сөйләшеп торган карт партизан әнә шул сукмакта ята. Төнге караңгылыкта ак тап булып аның йөзе генә күренә. Янәшәдә берничә кеше басынкы тавыш белән нәрсә турындадыр үзара сөйләшә иде.

— Кайсы якка качкан? — дип сорады Нурмыев, аларның сүзен бүлеп.

Аягы яраланган партизан кулын сазлыкка таба сузды:

— Әнә шул якка сызды, кабахәт. Әгәр аякка пуля тимәгән булса, мин аны...

Лейтенант отряд командирына таба борылып:

— Эзәрлекләү оештырылдымы? — дип сорады.

— Юк шул. Сазлыкта йөри белүчеләр юк бит, кешеләрне генә харап итәрбез. Охрим бабай үзе генә яхшы белә иде бу сазлык сукмагын.

Нурмыев, үзе дә сизмәстән, кычкырыбрак сөйләшә башлады:

— Әйләнеп булса да артыннан барырга кирәк. Ашыгыйк! — Ул агач ботаклары өстендә яткан яралы партизаннан: — Сукмак сазлык-

ның теге ягында кайсы тирәгәрәк килеп чыга икән? — дип сорады.— Вакыйганы тулырак сөйләп бир әле!

Төн карасында посттагыларга таба атлаучы кеше: «Мин майор Журкин боерыгы буенча», дип сүз куша. Тәмам якынлашкач, кесәсеннән документ алган булып иелә дә, көтмәгәндә партизанның эченә тибә һәм бөтен көченә сазлыктагы сукмакка таба йөгерә. Мәкерле дошман каршына Охрим бабай килеп чыга. Әмма төнге карачкы җитезрәк эш итә, яшен тизлеге белән кесәсеннән пистолет тартып чыгарып, бабайның күкрәгенә төрәп ата. Бабай акрын гына җиргә егылган арада үзе караңгылыкка кереп югала. Авыртуга түзә алмыйча җирдә аунап яткан Иван, автоматын кулына алып, дошман артыннан атып кала. Теге дә бурычлы булып калмый: граната ыргыта. Шуның бер кыйпылчыгы Иванның табанына килеп кергән дә инде. Ничек кенә авыртса да, Иван патроннары беткәнче атудан туктамаган.

Нурмыев дошманның эзләрен карады. Сынык дагалы үкчә эче аңа яхшы таныш инде. Шартлатучылар куышы янында да, үз ишеге төбендә дә шундый ук эзләр калган иде бит.

Майор Журкин да эзләргә игътибар итте:

— Рациягез белән бергә сезне шартлатырга теләгән шымчы инде монда да канлы эшен эшләгән. Качып котылуы бик аяныч...

Командирның бу сүзләре тикшерүчегә үзен гаепләү кебек тоелды.

— Сазлык сукмагы Непоново авылыннан ике чакрым чамасы читтәрәк узган юлга килеп чыгарга тиеш,— диде яралы партизан.— Охрим бабай шулай дигән иде.

Непоново белән Орловка арасындагы бу тар урман юлын Нурмыев картадан күреп белә иде. Ул тезләнгән җиреннән отряд командиры янына килеп басты.

— Иптәш майор, берничә кешене мөмкин кадәр тизрәк атларга атландырып, шул юлга җибәрергә кирәк. Юлны ябарга! Шымчының Орловкага качуы бар. Юлларда сакчылар калдырып, Непоновога таба барсыннар. Авылдан бер кеше дә чыгып китә алмаска тиеш.

Отряд командиры тиз генә тиешле күрсәтмәләр бирде.

Нурмыев элегрәк аның карамагына бирелгән кешеләр белән хәзер үк Непоновога барачагын әйтте. Бу очракта бер нәрсә көн кебек ачык: дошман шымчысы сазлык аша сиздерми генә Непоновога яки урман юлына барып чыгарга теләгәндер. Кем беләндер очрашырга, я булмаса, билгеле бер урында мәгълүматлар калдырырга ашкынадыр, күрәсең. Орловкага барырга теләсә, кире якка китмәс иде, бигрәк тә төн уртасында сазлык аша. Непоновода яшәүче берәр кеше белән бәйләнештә булырга тиеш ул.

Шымчының бу урынга — сазлыктагы сукмакка килеп чыгуы тикшерүченең шикләрен тагын бер кат ныклады: партизан отряды турында хәбәрләрне гестапога тирә-як авылларның берсендә яшәүче кеше тапшыруы хак. Непоновода яшәүчеләр турында белешүнең сәбәбе дә шунда иде.

## 11

Ковригин сүзендә торды — Непоновода яшәүчеләр исемлеге көндез үк әзер иде. Көчеп килгән өч карчыктан һәм мәктәп яшендәге балалардан шикләнмәскә була, аларны Нурмыев шунда ук исемлектән сызып ташлады. Шуннан соң унсигез кешене генә тикшерәсе калды. Үндүрте читтән көчеп килгән, дүртесе шушы авылда туып-үскән халык.

Нурмыев бер төркем партизаннар белән Непоновога таң алдыннан килеп җитте. Таң әтәчләре тагын бер төннең үтүен белдереп хәбәр бирде. Уйсулыкларда, йортлар арасында җәелгән томан тарала башлады. Мүк баса башлаган такта түбәләргә беренче нурлар төште. Йортларның күбесе иске, янтая башлаганнары да бар. Урамда җан иясе күренми. Көн эссе булырга охшый иде.

Әллә каян гына разведка взводы командиры старшина Назаренко килеп чыкты. Шымчыны эзәрлекләүчеләр төркеменә ул җитәкчелек итә иде.

— Иптәш командир, юл тирәләрен айкап чыктык, беркем юк. Сазлыктагы сукмакта тозак корып калдырдык. Авылны чолгап алдык. Тагын нинди күрсәтмәләрегез бар?

— Барысына әйтеп куегыз: авылга килүчеләрне тоткарламасыннар. Үзләре нык яшеренсеннәр. Авылдан беркем дә чыгып китә алмаслык булсын. Немецлар килеп чыга калса, ут ачарга. Әгәр зур көч белән һөҗүм итсәләр, сазлыкка таба чигенергә. Сигнал — кызыл ракета.

Назаренко, честь биреп, йортлар арасына кереп югалды. Партизаннар эшкә керештеләр. Бер төркемгә җитәкче итеп Нурмыевның танышы Арон билгеләнде. Ул элегрәк тә разведка взводына күчерүләрен сорап йөргән икән. Бер сәфәрендә дошманның сугыш кирәк-яраклары төялгән эшелонын шартлаткач та бу уеннан кире кайтмаган. Бу тәвәккәл, житез егет тикшерүчегә беренче очрашуда — минер Порфирийның ничек һәлак булуын тикшергән вакытта үк бик ошаган иде. Соңрак Нурмыевка Аронның авыр кайгысы турында да сөйләделәр: барлык туганнары Киевта яһүдләр геттосында һәлак булган икән. Үзе дә авырлык белән генә кача алган. Шуннан соң ул партизан отрядына килгән. Ефим Абрамович Брагинский (Арон — кушаматы, һәлак булган абыйсының исеме) отрядта бөтен төр коралларны, шартлату эшен, коралсыз сугышу алымнарын аеруча тырышлык белән өйрәнгән. Бик аз йоклау, ябыгу нәтиҗәседерме, аның йөзе каратут төскә кергән иде.

Арон үз төркеме белән авылның икенче башына юнәлде. Йорттан-йортка кереп, фашистлар белән элемтәдә торучылар сизелмиме, төннәрен кемгә дә булса таныш булмаган кешеләр килеп-китеп йөрмиме, кемнәр немецлар турында ялган хәбәрләр тарата, партизаннардан кайсылары бик еш килеп йөри, дип сораштылар. Шик тудырырлык кешеләр торган берничә йортны һәм абзар-кураны җентекләп карап чыктылар. Әмма бернәрсә дә таба алмадылар.

Тикшерүче почмактан өченче йортка үзе керде. Повзнев сөйләве буенча, алар иптәше белән шунда кунганнар. Ишекне талчыккан кыяфәтле бер хатын ачты.

Чыннан да, яшенле яңгыр яуган төнне аның өенә кораллы ике яшь ир-ат килеп кергән. Каратут йөзлесе, сәгать биреп, бер шешә самогон алган. Икесе дә хәйран исергәннәр. Икенчесе, аксыл чәчлесе: «Синең аркада һәлак булды алар, Саша, синең аркада гына, немецлар якынлашуын хәбәр итмичә, син качтың; бер генә тапкыр атсаң да, ишеткән булырлар иде. Хәшәрәт син! Исеңдә тот, мин моны яшереп калдыра алмаячакмын»,— дип еламсырап утырган.

— Озак сыйланып утырганнан соң, печәнлеккә менеп йокларга яттылар,— диде хуҗа хатын.— Иртәнге якта авылга немецлар килеп керде. Тегеләр, немецларны күргәч, качтылар. Шул якта бераз атышу булды. Немецлар арасында яраланганнары да, үлүчеләре дә бар иде, машинага төяп авылга алып кайттылар. Безгә дә керделәр. Тентеп чыктылар. Партизаннар кермәдеме, дип бик озак аптыраттылар. Мин, «юк», дидем.

— Аксыл чәчле партизанның үле гәүдәсен алып кайтмадылармыни?

— Юк-юк. Андый хәл булмады. Мин әле сөенеп тә куйдым: егетләр качып котылганнар икән!

— Берәрсенең кычкырганы ишетелмәдеме?

— Нәрсә дип?

— «Караклар, каракларны тотыгыз!» дип.

Хатын, «юк» дигәнне белдереп, башын чайкады.

— Күршегездә кем тора? — дип сорады лейтенант, тәрәзәгә күз салып.— Каралтыгыз нигә аларныкына терәп үк салынган?

— Минем ике туган абыем шулай итеп эшләде. Ул үзе хәзер сү

гышта. Ә хатыны пеләш башлы үгездәй бер ирне йортка кертте. Исеме Антип. Квартирада торучы булып санала. Чынлыкта исә... Әйтергә дә оят, кешедә намус юк. Абыемның хатыны Анка көлә генә: «Витька кайтса, тыгын да ныграк яратыр. Мин аны яхшы беләм», ди.

— Ул квартирант авылга кайчан килде?

— Ике ай чамасы бардыр, өч ай булмаса. Анка балага үзган инде.

— Анда-монда китеп йөрмиме?

Тикшерүче өстәл янындагы шыгырдавык урындыкка барып утырды.

— Күргәнем юк. Антип өйдә утырырга ярата.

Аннушканың өен дә, сараен да берьюлы тикшерә башладылар. Тенту ике сәгатькә сузылды. Антиптан сорау алуны Нурмыев иң ахырга калдырды. Квартирант үзе болай тыныч кына утыра. Идән астыннан немец маузеры табып алгач кына, боргаланырга кереште.

Лейтенант ваемсыз гына сүз башлады:

— Күптән түгел бу тирәдә караклар йөргән икән. Төнлә шулар яшергәннәрдер инде бу «уенчыкны».

Антипның йөзе агарынды, сулышы ешайды. Бер сүз эндәшмәсә дә, лейтенантның шиге калмады: бу бәндә, фашистларның игътибарын җәлеп итү өчен, чыннан да, «караклар», дип кычкыргандыр.

— Сез нигә яшенле яңгырдан соң, иртәнге якта, «караклар», дип кычкырдыгыз, әллә берәр әйберегезне урладылармы?

Антип бераз вакыт эндәшми торды.

— Кеше печәнлегендә ят бәндәләр йөри иде бит. Бертуктаусыз тәмәке тарталар — янгын чыгарулары мөмкин иде.

— Сез күзәтеп тордыгызмы?

— Юк. Төтен болай да күренә ул.

— Сез немецлар ишетсен өчен кычкыргансыз.

— Нишләп алай дисез? Юкка кара ягасыз. Немецларның авылга килгәнлеген мин белми идем әле.

Лейтенант корал турында юри сораштырмады. Бу адәм актыгын иң борчыганы әлегә шул. Уйласын, бераз зиһене чуалсын. Бәлки ул башка нәрсәдән тагы да күбрәк куркадыр?

Партизаннар аны күзәтә дип уйлаган инде ул. Шуңа күрә немецларга тотып бирергә булган. Аның кем икәнлеген фаш итүләре ихтимал иде бит. Немецлар бу партизаннарны эләктерер дә юк итәр, дип өметләнгән. Әмма ялгышкан. Корал турында сорау файдасыз, алдаячак, минеке түгел, сугыштагы хуҗаныкы, диячәк. Киресен исбатлау мөмкин түгел. Рацияне эзләргә кирәк. Таба алган очракта, эш бетте, дигән сүз. Кайда яшереп тота икән ул аны? Өйдәме? Юктыр. Өйдә Анна, аның ун яшьлек кызы бар. Үзенең кем икәнлеген аларга сиздермәгән булырга тиеш. Ышаныч юк, ычкындырулары да бар. Димәк, рацияне башка җирдән эзләргә кирәк. Ә кайда? Бәлки каршында утыручы кеше әле дошман да, радист та түгелдер. Бәлки ул күршеләр мөлкәтенә күз кыздырган комсыз һәм кабахәт бер җан гынадыр?

Бүлмәгә бер партизан йөгереп керде:

— Таптык! Таптык, иптәш командир,— диде.— Каралты нигезенә күмгән.

Антип урыныннан сикереп торды да янәшәдә басып торган партизанның башына китереп сукты. Тегесе элек стенага килеп бәрелде, аннары идәнгә ауды. Нурмыевның эченә тибәргә теләгән иде, лейтенант өлгеррәк булып чыкты — тегенең аягыннан эләктереп югарыга тартты. Антип гөрселдәп идәнгә барып төште. Селкенергә дә өлгермәде, лейтенант аңа бик каты бер типте дә кулларын артка каерды. Дошман авыртудан аңын югалтты. Шул арада аның кул-аякларын тиз генә бәйләп куйдылар.

Аңына килүгә, тикшерүче берничә сорау биреп караган иде, ра-

дист җавап бирергә теләмәде. Нурмыев боерыгы буенча, аны яшерен генә базага озаттылар.

## 12

Йортта тозак корып калдырылды. Хуҗа хатын сөйләвенә караганда, квартирант янына утыз биш яшьләр тирәсендә уртача гәүдәле бер ир килеп йөргән. Гадәттә, төнгә каршы яки иртән иртүк. Аның кем булуын, хәзер кайда икәнлеген белми икән.

Төш вакытында капка шакыган тавыш ишетелде. Ишек ачарга хуҗа кызы чыкты. Бер генә култык таягына таянган ир уртасы кеше баскычтан бик авырлык белән менде. Өстенә кигән сырманың бер җиңе буш иде. Аягы таплы чүпрәккә уралган, табанына машина көпчәгеннән киселгән калын резина кисәге бәйләнгән. Аркасында буш биштәр.

Йөзе сәер чалшайган, менингит белән авырган, ахры.

Бусаганы атлап керүгә, сорана башлады:

— Кунарга кертмәссезме икән, мәрхәмәтле кешеләр? Хәлем начар, ачтан үләм инде.

Хуҗа хатын өстәлдән икмәк сыныгы алып бирде.

— Башкача ярдәм итә алмыйм. Үзебез дә ачлы-туклы яшибез.

Бераз таптанып торганнан соң, инвалид теләр-теләмәс кенә чыгып китте.

Лейтенант тәрәзә аша күрше ишегалдын күзәтә иде: Тукта, күршеләргә нигә кермәде икән ул? Нурмыев айнып киткәндәй булды: шикле бу кеше. Маңгаена салкын тир бәреп чыккан Зәки кадакка эленгән автоматын алып:

— Медведев, минем арттан! — дип боерды. Партизаннарның калган икесе аптырап командирларына текәлделәр.

— Сез монда калыгыз.

Алар йөгереп чыкканда теге ир кеше авыл башына җиткән иде инде. Нидер сизенеп, артына борылып карады. Үзенә таба йөгерүче кораллы кешеләрне күрүгә, ул барын да аңлады, ахры. Култык таягын читкә ыргытты да кесәсеннән пистолет тартып чыгарды.

Йокыга киткәндәй тыныч авыл урамын ату тавышлары сискәндерде: ишегалларында этләр өрә, тавыклар кыткылдый башлады. Өй кыекларына кунган күгәрченнәр фырылдап һавага күтәрелде.

Медведев сәер генә җиргә ауды. Икенче ук Нурмыевның автоматына тиеп, янга очты. Лейтенант:

— Авыл чолгап алынган! Бирелегез! — дип кычкырды.

Җавап бирмичә генә, агент тагын берничә тапкыр атты, әмма тидерә алмады.

Нурмыев ут ачарга ашыкмады. Дошманны ничек тә терелэй кулга төшерергә кирәк. Серле йомгакның җеп очы аның кулында бит.

«Аксак» алын-артны карамый, яхшы ау эте кебек йөгерә. Нурмыев, автоматын кулына алып, аның аякларына атарга теләде. Әмма ук автоматның затворына тигән икән, янчелгән затвор урыныннан кузгалмады.

Лейтенант, автоматын ташлап, тагын алга омтылды. Көтмәгәндә автомат тавышы ишетелде. Агент берничә адым атлады да, карт чыршы төбендә җиргә ауды. Лейтенант килеп җиткәндә, аның сулышы тынган иде инде.

Нурмыев аптырап як-ягына каранды. Куаклар арасыннан автомат иясе — яшь кенә егет күренде.

— «Тукта!» — дип кычкырган идем, һаман йөгерә. Сезне күргәч үк, мин аның шпион икәнлеген аңладым. Күрә торып качырып булмый ич инде.

Лейтенант мәетнең сырмасын салдырып алды. Бил каешында гранаталар, пиджагының эчке кесәсендә тагын бер «Вальтер» системасындагы пистолет. Сул кулы күлмәктән ертып алынган чүпрәк белән бәйләнгән. Антип өенә көндез килүенең сәбәбе менә нәрсәдә икән. Юлда аны яралаганнар. Бәлки сазлыктадыр? Зәки бераз читкәрәк барып басты. Тукта, бу нәрсә? Дошман аягындагы ботинкада — сынык дага! Якынрак килеп, ботинка табанын игътибар белән карап чыкты. Шунда ук яңгырлы төн, яшен яктысында тонык ялтыраган эсэс пычагы, Порфирийның һәм Охрим бабайның сазлыкта һәлак булуы исенә төште. Әйе, күп бәла-каза китердең син, козгын,— дип уйлады Зәки.— Җитмәсә, сереңне дә үзең белән теге дөньяга алып киттең. Ул сер миңа ничек кенә кирәк иде!

Отрядта ул үзе генә булдымы икән? Әллә тагын кемдер бармы? Яшерен урынга һәм радистка хәбәрләрне еш ташыганмы? Бу бәндәнең үлеме бөтен мәшәкатьләргә нокта куярга мөмкинлек бирерме? Үзем ахмак, вакытында башыма килмәде. Әшне ничек тиз тәмамларга була иде бит!

Лейтенант шулай аптырап, ачынып торганда авылның икенче башында ату тавышлары ишетелде, шунда ук берничә граната шартлады. Немецлар дисәң, кай арада килеп җиткәндер? Нурмыев постка таба йөгерде.

— Егетләр, тиз генә старшина Назаренконы табыгыз,— диде ул.— Чигенергә сигнал бирсен.

Үзе баягы йортка юнәлде. Хәзер тозак коруның кирәге юк иде инде. Партизаннарны чакырып чыгаруга, урам башында дошман мотоцикллары күренде. Алдагы машинадагы пулемет котырынып ут ачты, уклары янәшәдән генә сызгырып үтте. Берничәсе юл тузанын туздырды. Янәшәдә генә йөгерүче Арон автоматтан озын чират биргән иде, беренче мотоцикл үкереп бер йорт стенасына килеп бәрелде. Аңарда утыручылар, капчыклар кебек җиргә коелып, хәрәкәтсез ятып калдылар. Партизаннар кайсы кая яшеренеп ут ачты. Гитлерчылар да автоматлардан, пулеметлардан бертуктаусыз ук яңгыры яудырырга тотындылар. Борылыштан килеп чыккан бронетранспортер үзенең автомат пушкасы белән аларга аеруча зур ярдәм итте. Партизаннарның хәле сизелерлек авырайды.

Һавада кызыл ракета күренде.

— Сазлыкка таба чигенергә,— дип боерды Нурмыев, якынлашып килүче дошманга атуын дәвам итеп. Янында яткан Арон сирәк кенә, әмма бит оста ата. Аткан саен берничә «соры мундирлы» җиргә ава иде.

Шулай ата-ата бакчалар аша куаклыкка җыелдылар да лагерьга таба атладылар. Тозактан курыктылар ахры, немецлар урманга якын килмәде. Базага кайтканда партизан Валетовның үле гәүдәсе табылды. Ике аягы гына яраланган үзенең, күп кан югалтудан үлгән, ахры.

— Нәрсә, ул үзе генә чыгып киткән идеме? — дип сорады старшина Назаренко.

— Үзе генә түгел. Повзнев белән.

— Яраланган гына булган ул, иптәш командир. Аны ташлап киткәннәр!

— Ташламаган булсалар, үлмәгән булыр иде!

Баһадир гәүдәле, һәрвакыт тыныч, киң күңелле Назаренко ярсып кычкырды да, күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, читкә борылды. Аларның нинди дуслар икәнлеген, Валетовның бервакыт аны үлемнән коткаруын отрядта берничә кеше генә белә иде.

Зәки сак кына Назаренконың иңбашына кагылды.

— Без моны әле ачыкларбыз.

Отрядка кичке якта гына кайтып җиттеләр.

*Ахыры киләсе санда.*

## Госман Садә

### Кура ярында

Яңгырдан соң сөттәй аксыл төскә кереп,
Күбекләнеп, ярсый-ярсый бөтерелеп,
Нәкъ Тбилиси уртасыннан ага Кура...
Ни могҗиза!— оча ярда төклетура.

Адашканмы, нигә монда килеп чыккан,
Бал җыймыйча чәчәкләрдән, көмеш чыктан?
Кая очу юлын һәркем үзе сайлый!—
Әйтер шулай корыч җайдак Горгасали.[1]

Ул да шулай илләр гизгән, җир сайлаган,
Монда килеп Тбилисига нигез салган.
Якын иткән Кура ярын, аны — Кура...
Нәрсә эзләп оча монда төклетура?

Горгасали атына ул килеп куна...
Аның җанын ничек аңлыйм? Гаҗәп миңа.
Туган җире шушы булгач, кая барсын?!
Күбекләнеп ага Кура яңгырдан соң...

❁

Мтацминда тавы күкрәгендә
Сандугачлар моңы, чәчәк назы.
Йоклый монда ике тугры йөрәк —
Грибоедов, Нина Чавчавадзе.

Ышанмасаң әгәр мәхәббәткә,
Мтацминда җилен тыңла килеп,
Яуган чакта кичен яңгыр коеп,
Яшьнәгәндә яшен күкне телеп.

Мтацминда җиле иңрәп-үксеп,
Агачларның йолкып чәч толымын,
Сөйләр сиңа гүзәл мәхәббәтен
Грузин кызы белән рус улының.

Пар чәчәкләр ничек бергә үсеп,
Бүлеп эчкән кебек чык тамчысын,
Алар эчкән сөю касәсеннән
Уртак кояш нурын, көн яктысын.

Ул кояшны Тифлис бүләк итсә,
Алыштырган аны Тәһран төнгә.
Елагандыр Нина чәчен йолкып
Мтацминда тавы күкрәгендә.

Ышанмасаң әгәр мәхәббәткә,
Мтацминда җилен тыңла килеп:
Сөйләр сиңа шагыйрь мәхәббәтен
Яшен булып яшьнәп, күкне телеп.

...Мтацминда тавы күкрәгендә
Язның үзе кебек сөю назы.
Йоклый монда ике тугры йөрәк —
Грибоедов, Нина Чавчавадзе.

---

[1] Горгасали Вахтанг — Тбилисига нигез салучы. Кура ярында аңа һәйкәл куелган.

## 1979 ел кышыннан соң

Иманлеккә килгәч исем китте —
Исем өчен исән имән юк.
Имәннәрне кышкы салкын кырган,
Салкын кышта шәфкать, иман юк.

Нигә мондый явыз, кырыс җәза?
Ходайгамы каршы барганнар?
Шул имәннәр, шулар күпме безне
Давыллардан саклап калганнар...

Кем алдында алар гөнаһлылар?—
(Әйтегезче, моны белгәннәр.)
Яңа елга каршы салкын төндә
Аягүрә туңып үлгәннәр.

Тәннәреннән купкан кабыклары,
Тере килеш гүя суйганнар.
(Освенцимда шулай үлгәннәр бит
Илне сөйгән безнең туганнар!)

Шүрәледәй нинди шыксыз алар —
Корычтан нык мәгърур имәннәр
Шыр сөяктән торган бармак кебек
Ботакларын җиргә игәннәр.

Табигатьнең усал шаяруы,
Кайгы булып, төшкән кыйммәткә.
(Бу тормышны янып сөйгәннәргә
Һәрбер үлән, имән исәптә!)

...Тамырлардан яңа шытым калкыр
Иманлектә, җансыз җирләрдә.
Асылда бит — көрәшләрдә түгел,
Салкын җаннан сына ирләр дә.

## Иске йортта

Ул искергән инде. Ул картайган,
Хуҗасыдай, җитеп сиксәнгә...
Ачуланмас, рәхмәт кенә әйтер
Бүген килеп аны сүтсәң дә.

Бер нигезе череп җиргә сеңгән,
Авышкан ул бер як кырыйга.
Юлдан арып кайткан карт дөядәй,
Тели булыр ятып торырга.

Теләмичә генә тәтен чыга
Морҗасыннан аның кич белән.
Шул төтендәй әкрен генә эреп
Гомер үткән. Гомер кичелгән.

Ишек алдын куе үлән баскан,
Сукмак эзе чак-чак беленә...
Өйдән шулчак ялгыз карчык чыга,
Шәлен бәйләп бөкре биленә.

Каш өстенә какча кулын куеп,
Карый кичке шәфәкъ иңгәнен,
Мүк каплаган йорты кыегында
Көннең соңгы нуры сүнгәнен...

Йөткерә дә әби хәлсез генә
Кереп китә тагын йортына.
Өй алдында күксел эңгер ята
Үз мәчесе кебек тын гына.

Чишелмәгән кара йомгак төсле
Үрмәли төн өйнең эченә.
Өйдә тынлык... Әби йоклый анда...
Нәрсә керер аның төшенә?

## Тай

Кешни-кешни җилләрдә
Болыннан бер тай чаба...
Чаба бер тай болыннан
Нинди язмышка таба?

Җилләр дә бик телиләр
Җитәргә аны куып.
Аны куып җитәр җил
Җитмәгән әле туып.

Тай чаба койрык чәнчеп,
Яллары янып тора.
Нинди дәрт, кодрәт аны
Кайларга ашыктыра?

Булырмы гел алдында
Ямь-яшел сусыл үлән?
Көтәме аны чишмә
Көмештәй суы белән?

Җилләр белән узышып,
Кешни-кешни тай чаба...
Чаба ярсып, ашкынып
Нинди язмышка таба?

Бәйгеләрдә чабышы
Булырмы гел җиңүдән?
Зур сорау билгеседәй
Калка күктә Җидегән.

Язмышны кем юраган?
Кем аны алдан белгән?
Тай бары кешни генә,
Кимәгән әле йөгән.

Иһаһайлап кешнәве
Таңнарны ярып үтә.
...Ялкын яллы ул тайны
Сарайдаияр көтә.

---

Аңлашулар күчсә әгәр
Бары тик хатка,
Һәрбер сүзнең икеләтә
Кадере арта.

Килсен хатлар таулар кичеп
Ерак тарафтан.
Тау кадәрле кадерле сүз:
«Мәңге яратам!»

Сөю тулы хатлар йөрсә
Таулы бу якта,
Мәхәббәткә йөз мәртәбә
Ышаныч арта!



*Мәгъсум Насыйбуллин — җитмешенче һәм сиксәненче елларда татар совет әдәбиятында детектив жанрын үстерүгә зур өлеш керткән язучы. Укучы аның «Без капчыкта ятмый» (1972 ел), «Төнге ату» (1975 ел), «Йөрәк таш түгел» (1981 ел) һ. б. китапларын яратып кабул итте. Үзе дә зур тормыш юлы үткән, Бөек Ватан сугышында катнашкан, утыз елдан артык прокуратурада эшләгән автор сурәтләргә алынган өлкәсен нык белеп яза. Аның әсәрләрендәге күренешләр ышандыра, геройлар истә кала.*

*Бүгенге көндә язучының төрле характердагы әсәрләре тупланган 14 китабы бар. М. Насыйбуллинның повесть һәм хикәяләре башка телләргә дә тәрҗемә ителә, алар рус, башкорт, казах, үзбәк, каракалпак, якут укучыларына да барып ирешә.*

*СССР Язучылар союзы члены, Татарстан Язучылар союзының иҗтимагый-хокук комиссиясе председателе каләмдәшебез Мәгъсум Насыйбуллинга шушы елның октябрь аенда алтмыш яшь тула. Редакция юбилярны кайнар котлый, ныклы сәламәтлек, иҗат уңышлары тели һәм укучыларга аның яңа әсәрен тәкъдим итә.*

## Мәгъсум Насыйбуллин

# ШӨБҺӘ

**хикәя**




ашлык Гайнанны каршысына утыртты да туп-туры сүзгә күчте.

— Минем янда әле генә Аланлыкның халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты директоры булып китте. Шәрәпов Марат Мансурович. Өлкән яшьтә, алтынчы дистәне сүтә. Коммунист. Бөек Ватан сугышында катнашкан. Район прокуратурасыннан зарлана. «Дәүләт акчасын үзләштерүдә гаепләделәр»,— ди. Соңыннан, тикшерү тәмамлангач, аны эзәрлекләүдән туктаганнар, әмма өстендә хөкемгә тартырлык дәлил житенкерәми дигән шик калдырганнар. Төшенәсезме?

— Борынгы Рим юристларыча әйтсәк, абсолютио аб инстанция [1],— диде Гайнан.

— Эзенә бастың! Җинаять кылуда гаепле дип исәпләнгән кешене

[1] Хөкемнән азат итү (латинчадан).

судсыз гына шикле килеш калдырганнар. Сәбәбе — дәлил җитмәү. Шәрәпов моңа каршы: «Нишләп мин шикле исемен күтәреп йөрергә тиеш? — ди.— Гаебем булса, хөкемгә тартыгыз, соңгы сүзне суд әйтер. Юк икән, эзәрлекләүне туктатыгыз». Ул район тикшерүчесе кулланган вариантны кире кага. Бу аңлашыла да. Мә, гаризасын ал, таныш. Аланлыкка барып кайт. Иртәгә үк! Район прокурорына әйтелгән. Эшне җентекләп өйрән. Кирәк тапсаң, үзең тотын, яңадан тикшереп чык.

Икенче көнне Гайнан район үзәге Аланлыкта иде инде. Ул барлык вакытын тикшерү эшен өйрәнүгә багышлады. Һәм дүрт көннән ике томлы тегелмәнең соңгы битен япты. Кылынган җинаять һәм Аланлык район прокуратурасы оештырган тикшерү эше үзенең бөтен нечкәлекләре белән аның күз алдыннан үтте.

Комбинат бухгалтеры Вера Воронина чибәрлек өләшкәндә йоклап калган затлардан түгел. Ул чиядәй кывыл ирен, ул энҗе кебек тешләр, ул зәңгәр күзләр дисеңме — барысы да сокланып туймаслык. Елмайса, тулы бит алмаларында уймак-уймак мәхәббәт чокыры хасил була, күзләреннән нур бөркелә. Андый чакта тавышы да күгәрченнекедәй гөлдерәп кенә чыга.

— Сара Әбраровна, ике йөз сум акча биреп тор әле әҗәткә,— дип килә ул кассир янына.— Кибеткә затлы пальто кайткан, алып каласы иде, дим.

Сара Әбраровна Башкировага кырык биш яшьләр чамасы. Хезмәте буенча ул Ворониnaның кул астында эшләүче. Бердәнбер уллары читтә яши, ире белән икесе әйбәт кенә тормыш кичерәләр. Баш бухгалтер шулай көлемсерәп акча сораган чакларда Башкированың чырае сытыла, төсе китә. Ник дисәң, кассир мондый елмаюларны күп күргән, аларның нәрсә икәнен яхшы белә. Воронинаның һәр көлемсерәве җилкәнә авыр йөк булып ята башласа, сытарсың чыраеңны!

Башкирова үзенчә уйлый: «Яшь чак — кесә тулы борчак» дигәндәй, купшырак киенәсе килә торгандыр, күрәсең. Егерме сигез белән генә бара бит әле Вера. Ә үзе — баш бухгалтер, югары белемле экономист. Хәер, казна акчасы белән гаилә бюджетын аера белергә тиеш ләбаса! Тормышы да түм-түгәрәк бит югыйсә. Ире Виктор да төшеп калганнардан түгел. Институттан ук культура сарае директоры итеп җибәрделәр үзен. Эш хаклары да тормыш алып барырга җитәрлек. Юк бит, бер дә белми бу Воронина акча аермасын. Килә дә: «Сара Әбраровна!..» Әйтерсең кассирның башы ике дә, аның кулындагы касса — «төпсез кое». Шуңа күрә ул касса сейфын ачарга бер дә атлыгып тормый.

— Вера, матурым, ревизия килеп төшсә, нишләрбез, ә?

Баш бухгалтерның моңа бер дә исе китми. Ул, әүвәлгечә мөлаем елмаеп, кассирны бүлдерә:

— Килмәс, Сара Әбраровна, бер дә борчылма.

— Аңлыйм, аңлыйм.— Воронина өстәлдән бер бит кәгазь ала да, тиз-тиз генә нидер язып, бүлмәдәшенә суза.— Курыксаң, мә сиңа расписка, рәсми кәгазь.

Башкирова расписканы алып укый. «Мин, В. З. Воронина, кайтару шарты белән, кассадан ике йөз сум акча алып тордым». Инде кассир сейфны ачарга мәҗбүр. Расписканы сейф шүрлегенә куя да, ике кат санап, баш бухгалтерга акча суза. Әмма чырае барыбер язылмый, сытык килеш кала. Вера исә елмая да елмая, акчаны да санап-нитеп тормый гына сумкасына сала. Мондый хәлләр өч ел элек башланды. Бер күнегеп киткәч, Воронина кәгазь-мазар язып та азапланмый. Көн аралаш диярлек елмая да:

— Сара Әбраровна, егерме биш сум гына биреп торчы...

Яисә:

— Илле тәңкә кирәк иде, Сара Әбраровна...

Тавышы гөлдерәп кенә чыга баш бухгалтерның. Кассир хатынның

йөзе дә ул кадәр борчулы түгел инде хәзер. Ул да көнегеп килә. Шулай да баш бухгалтерның исенә төшерүне урынлы саный.

— Вера, кадерлем, бирәсе бурычың җиде йөзгә җитте бит. Кайчан гына түләп бетерерсең икән?

— Кызыл кар яугач,— дип шаярта Вера. Шаяртып кына калмый, үзенең өстәл тартмасыннан чек ала да яза — «тугыз йөз унсигез сум сиксән тугыз тиен»: — Мә, Сара Әбраровна, тот, банкка барып акча алып кайт, аннары сөйләшербез.

Сумкасына иллелекләр тутырып кайткан кассирны баш бухгалтер бусага төбендә үк каршылый.

— Я, Сара Әбраровна, булдымы?

— Әйе, алып кайттым.

— Алайса, бир әле минем распискаларны.

Башкирова аны-моны абайларга өлгергәнче, баш бухгалтер үзенең элекке распискаларын кассирдан тартып ала да, вак-вак кисәкләргә ерткалап, чүп савытына ыргыта.

— Нишләвегез бу, Вера Зотеевна?

— Хәзер күрерсең нишләвемне,— Воронина әлеге чекның кырыена «218 сум 89 тиен» дип яза, комбинат директоры Шәрәпов имзасы белән рәттән үзенекен дә сырлый.

— Мә, Сара Әбраровна,— дип, күзе шардай булган кассирга кöрешок тоттыра.— Исәп-хисабыңа банктан алган акчаның шушы күләмен генә күрсәт.

— Ә җиде йөзен? — дип сорый Башкирова, зиһене таркалган хәлдә.

— Җиде йөзе белән теге әҗәтне капла.

— Белсәләр? — Кассир куркуыннан калтырана башлый.

— Кем белсен ди аны?

— Азмыни хәзер контролер дигәннәре? Директор белсә?

— Директор?!.— Баш бухгалтер шаркылдап көлә.— Директор дисең, ә? Алтын бит ул безнең Марат Мансурович. Каян килсен ди аның башына тикшерү-фәлән?!. Андый беркатлы кеше нишләп казынсын ди.

— И-и Вера, шулай да, кем белгән...— Башкирова һаман икеләнә.

— Ташла әле, Сара Әбраровна,— дип, Воронина өстәл тартмасыннан чек кенәгәсе тартып чыгара.— Мә кара, чекмы бу? Чек! Акча суммасы язылганмы? Язылмаган! Кем имзасы бу? Марат Мансуровичныкымы? Монысы — Вера сеңелеңнеке. Дәүләт банкындагы акчаны алырга хакыбыз бармы? Бар. Тотарга кем хаклы?

— Билгеле, сез икегез,— ди Башкирова килешеп. Ләкин аның башына директорлары Шәрәпов турында төрле фикер килә: «Бергәләшеп туздыра микәнни соң болар казна акчасын? Ышанырга мы моңа, юкмы? Булуы да ихтимал. Бик кыю сөйләшә бит Вера...»

— Курыкма, Сара Әбраровна,— баш бухгалтер тагын да мөлаемрак елмая. Кассирга яңа чек тоттыра.— Монысы синең өлеш. Төптөгәл ике йөз. Аңлашыламы?

Тәки кызыга бит кассир хатын: байтак икеләнеп йөргәннән соң барыбер баш бухгалтер ягына авыша. Комбинатның банктагы счетын хәзер алар бергәләп кимерә башлыйлар. Яңадан алынган тугыз йөз илле тугыз сумның өч йөзе генә күрсәтелә, калганы Воронина белән Башкирова кесәсенә күчә.

Көннәрнең берендә баш бухгалтерның йөзеннән елмаю кача, кассирның да чырае караңгылана. Комбинатка кинәт ревизия килеп төшә. Тикшерү дә андый-мондый гына түгел — Казаннан! Комбинат конторында яшенле яңгыр алдыннан була торган бөркү, сулышны кыса торган тынлык урнаша.

Иртән эшкә килүче Воронинаны туктатып, директор Шәрәпов аны бер ир-ат белән таныштыра:

— Вера Зотеевна, бу иптәш Казаннан. Министрлык вәкиле, бездә ревизия үткәрәчәк. Николай Сидорович Копейкин.

Вәкилнең югары белемле, тәҗрибәле экономист икәнен, министрлыкның бер идарәсендә баш бухгалтер булып эшләвен Воронина үзе дә белә иде.

«Бетте баш!» — дип, караклар котылу юлын эзләп, кайгы-хәсрәт бөҗрасында талпынганда, «ярдәм кулын» Копейкин үзе суза. Эшне тизләтү нияте белән, ревизия актының караламасын язу Воронинага йөкләтелә. Үзенең балыкка йөрергә яратуын да яшерми ревизор. Вера җиң сызганып акт язарга керешкәндә, аның ире Виктор, культура сараендагы кабинетына йозак элеп, Николай Сидоровичны моторлы көймәдә Иделнең аръягына алып чыгып бара иде инде. Санаулы көн тиз уза, диләр. Хак икән. Ревизия көннәре дә үтеп китә. Ярый әле Вера Зотеевна бар. Ул, тынгысыз җан, Копейкин балыктан кайтуга ревизия актын язу белән генә чикләнми, машинкада да бастырып куя. Кайда ул Копейкинга олы башын кече итеп банкка бару да, чек белән корешокны чагыштырып утыру! Вакыты тар аның! Чагыштырдың ни, чагыштырмадың ни, барыбер ләбаса! Әнә, бухгалтердан чек корешокларын ал да чут төймәсен тарт! Сумма әзер, җәмгысы әзер. Нинди ышанычлы, нинди игътибарлы аларның Ворониналары! Җитмәсә нинди сөйкемле! Бер елмаюы ни тора! Яшерен-батырын түгел: министрлыклары үнды Копейкиннарның. Воронина аларның ышанычын тулысынча аклый. Теләсә нинди премиягә лаек кадр! Озак та үтмәс, идарәгә тартып китерерләр үзен, кирәксә, Мәскәүгә дә җитәр! Әйе, шәп кадр үсә Аланлыкта. Копейкин үз фикерен утырышта да әйтәчәк, характеристикасын да язачак.

Аланлык комбинатында яшен дә яшьнәми, күк тә күкрәми. Баш өстендә куерган болыт үзеннән-үзе таралып бетә.

— Я, Сара Әбраровна күрдеңме?! — Воронина ревизорны озаткан соң атылып кассир янына керә.— Йөгер банкка! Мәҗлес бүген, шатлык мәҗлесе!

Уйный-җырлый, идән сындырырлык итеп бии-типтерә болар. Мәҗлес таңгача гөрли. Ә иртәгесен кассир яңадан банкка китә. Хәзер кассага алып кайтылган дәүләт акчасының бер өлеше генә тәти, калган өч өлеше үзе кесәләрендә кала. Шулай итеп, дәүләт малын туздыра сердәшләр.

Үзе урлый, үзе шүрли кассир Башкирова. Кереп батканчы китеп котылыйм дип, берзаман үзе теләге белән эштән чыга. Кассир вазифаларын Сәвия Мотыйгуллина үти башлый. Баш бухгалтер аның кылларын да чиртеп карый. Хәлбуки, Сәвия дәүләт акчасына кызыкмый.

Воронина, чек тотып, банкка үзе йөри башлый. Барган саен дүртәрбишәр йөз аның кесәсенә күчә, аннары әйбер булып Ворониналар өенә кайта. Идел суында бу гаиләнең биш йөз сумлык зәңгәр көймәсе чайкала. Дүртәр йөзгә ике мотор алына. Сарайларында күрше-күләндә булмаган «Электрон» мотороллеры. Дүрт яшьлек кызлары да пианинолы була. Кием-салым да артканнан-арта. Воронинаның аппетиты ачылганнан-ачыла бара.

Сәвиянең күңеле нидер сизә, борчыла. Тирә-ягындагы пычракка, урлашуга чыдый алмыйча, гариза яза да китеп бара.

Яңа кассир итеп Валентина Смирнованы алалар. Ул да финанс эшендә яңа кеше түгел. Заманында сәүдә училищесын тәмамлаган, эш тәҗрибәсе дә бар. Кияүгә дә чыгып караган, әйтүенчә, уңмаган. Хәзер баласын ялгыз тәрбияли икән. Билгеле, Воронина аңа башта шикләнеп карый. Әмма комсызлык шиктән көчлерәк булып чыга. Яңа кассирны кулга төшерү, тозакка каптыру шул ук ысул белән эшләнә.

Воронина кассирны үзенә кунакка чакыра. Килүенә табында иң яхшы сый-хөрмәт тора. Нигъмәтләрдән өстәл сыгыла! Смирнованың исе китә. Менә дәстәрхан ичмаса! Табын янында сүзе дә табыла, берсе икенчесенә ялганып кына тора. Вераның ире Виктор пианинода уйный икән. Җитмәсә, баянчы егетне дә чакырганнар. Ямь өстенә ямь! Барысы

да бик ошый яңа кассирга. Ирләр тәмәке көйрәтергә чыккан арада, ике хезмәттәш уртак телне тиз табалар. Кассир булып килүенә ун көн дигәндә, Смирнова беренче имтихан уза: кассадагы биш йөз сум дәүләт акчасын Воронина белән бүлешә. Ярты ел эчендә биш мең дүрт йөз сум акча «чумыралар». Күз алларына челтәрле тәрәзә килеп баса башлагач, Смирнова да гариза биреп үкчәсен ялтырата.

Дәүләт банкына Воронина тагын үзе йөри башлый. Казнаны талау дәвам итә.

Җәйнең матур көннәрендә Аланлыкка кабат ревизия килеп төшә. Бу илле яшьләр тирәсендәге тәҗрибәле ревизор Мукасова Аза Васильевна була.

Воронинаның коты оча. Монысы эшләпәле ир-ат түгел, хәмер белән дә, балык тоту белән дә алдап булмас, безнең эшне ачмаса ярар иде, дип шүрли кала баш бухгалтер.

Тик юкка гына хафаланган икән. Ревизия дигәннәре бу юлы да шома гына узып китә: урлашу ачылмыйча кала. Воронина шатлыгыннан тәмам шашына. Мәҗлес арты мәҗлес җыя. Әүвәлгечә дәүләт кассасын талый бирә. Җепшек кар әүмәкләнеп зурайган төсле, яман шеш тә үскәннән-үсә.

Комбинат директоры Шәрәпов бухгалтериянең исәп-хисап кәгазьләрен раслап утырганда, кинәт кечкенә генә бер ялгышка тап була. Бер чек буенча җиде йөз кырык сум акча кергән, банк кәгазендә исә җиде йөз сиксән сум акча бирелде, диелгән. «Нәрсә бу?» — Директор пошаманга төшә. Расланган кәгазьләрне дә кире актарып, дикъкать белән чагыштыра башлый. Тагы бер ялгыш таба: банктан башка бер вакытта алынган зур сумма касса кәгазендә йөз сум унбиш тиенгә киметелеп язылган. Бер генә булса, очраклы хәл дияр идең. Ике тапкыр... Ялгышу гынамы бу, әллә?.. Җавап табу өчен баш бухгалтерны чакыра.

— Вера Зотеевна, бу нәрсә? — Шәрәпов Воронина алдына очыочка ялганмаган кәгазьләрне китереп куя.

— Нәрсә дип, ни...— Воронина тотлыга башлый.

— Я, ник эндәшмисез? Әйдәгез, хәзер үк банкка барабыз, корешокларны андагы чеклар белән чагыштырабыз!

— Кирәкми, Марат Мансурович! Зинһар, кирәкми! — Баш бухгалтер еларга тотына.— Хода хакына дип үтенәм, тавыш күтәрмәгез. Мин сезне бервакытта да онытмам.

— Нәрсә сөйләгәнегезне беләсезме сез?! Ревизия килеп төшсә?!.

— Беләм, Марат Мансурович, бик беләм. Ревизиянең яхшы үтәчәгенә ышанам мин, башымны кисәргә бирәм.

— Эш ревизиядә генәмени? Сүз намус хакында, җинаять турында бара бит.

— Аңлыйм, Марат Мансурович,— Воронина директорның күзенә керердәй булып очына.— Гариза биреп, эштән үзем китәм.

— Юк, Вера Зотеевна, мин йомып калдыра алмыйм. Дәүләт акчасы белән шаярырга ярамый,— ди Шәрәпов, тирән көрсенеп...

Без капчыкны тишеп чыккач, район тикшерүчесе Башкированы да чакыртты. Коелып төште Сара Әбраровна, әмма кырын эш турында ләм-мим.

— Әйе, мин эшләгән чорда Вера кассадан акча алып торгалады. Мин аңа: «Вера, бурычың арта, кайтарырга кирәк»,— дидем. Аның үз исәбе генә исәп иде. «Курыкма, счетыңны үзем төзермен»,— дип юатып торды. Башта бернәрсә дә аңламадым. Соңыннан борчыла башладым. Кассир хезмәтен ташлап киттем.

— Тагы ниләр беләсез?

— Башка берни дә белмим.

— Беләсез, Сара Әбраровна. Я, хәтерләгез әле, Воронина белән биш ай бергә эшләү дәверендә кесәгә күпме акча салдыгыз?
— Мин салмадым.
— Алай булгач, якынрак килеп утырыгыз әле,— диде аңа тикшерүче, берәм-берәм чеклар күрсәтеп,— Бу чекта акча алучының имзасы сезнекеме? Тугыз йөз сум сиксән тугыз тиен акча алдыгызмы?
— Әйе, минем имза. Акча да алдым шикелле.
— Нишләп касса «керем»ендә ике йөз унсигез сум сиксән тугыз тиенен генә күрсәттегез?
— Вера кушкач, ни...
— Җиде йөзе кайда?
— Вера әҗәтен каплады,— элекке кассир Башкирова телен ачканнан ача барды. Күзенә терәп күрсәткәч, дәлилләрне берәм-берәм раслый башлады. Бигүк тәгаенлисе килмәсә дә, сер йомгагын сүтәргә тотынды.— Әйе, миндә дә гаеп бар. Мин дә алгаладым. Тик аерма шунда, мин күпләп алмадым, егермешәр-утызар сумлап кына.
— Җәмгысы?
— Барлыгымы? Минеке мең тугыз йөз сумнан артмас.
— Ул акчаны нишләттегез? Кая куйдыгыз?
— Кем белә инде аның кая киткәнен. Тормыш бит...
— Шулай да?
— Хәтерләмим, ике ел ярым вакыт узды бит.
— Алайса, хәтерегезгә төшерәм. Тыңлагыз.— Ул Сара Әбраровна сатып алган әйберләрне саный башлый.
— Кайдан белдегез сез боларны? — дип сорады, ниһаять, Башкирова аптыравыннан.
— Кирәксә, тиененә хәтле саныйсың аны, Сара Әбраровна. Ә сез «белмим» дисез. Авызың чалыш булса да, сүзең туры булсын, ди халык.
— Ярар, белгәнемне яшермәм.
— Сез ревизиядә катнаштыгызмы?
— Әйе, сез таләп иткәч, ни...
— Алай булгач, нишләп «1900 сум гына алдым», дип барасыз? Ревизия ачыклаганча, сез эшләгән биш ай эчендә кассадан өч мең дүрт йөз егерме тугыз сум акча урланган. Бу сумма дөресме?
— Дөрес булмыйча, күбесен Вера алды бит аның.
— Кассадагы акча өчен иң башта сез җаваплы. Ул кадәр сумманы кайчан түлисез?
— Вера урлады, Вера түләсен.
— Капма-каршы очраштырам, Воронинаның үзенә әйтерсезме?
— Әйтмичә ни! Әйтәм! Әйтү генә түгел, күзен чукып алам әле мин ул тотнаксыз җилкуарның. Аның өчен түлә имеш. Тот капчыгыңны!
— Аңлашылды, Сара Әбраровна! Хәзер магнитофонга һәм беркетмәгә язылганнарның дөреслеген раслап имзагызны куегыз.
— Дөреслекне раслыйм мин. Бирегез беркетмәгезне.
— Рәхмәт. Күзгә-күз очраштыру иртәгә була.
Валентина Смирнова да дулап кына киртә җимерә алмаячагын аңлады, күрәсең. Тикшерүче каршына килеп басу белән, икеләнмитартынмый кылган эшләрен раслый башлады. Фаш ителәсе көнен зарыгып көтеп алган диярсең.
— Эшли башлавымның икенче көнендә үк Воронина илле сум акча сорады. Бирдем. Язып куярга кушты. Баш бухгалтер бит, ничек итеп үтенечен аяк астына салмак кирәк. Аның сүзе — кассир өчен закон, дип уйладым. Бер башлангач, бу хәл дәвам итте. Вера көн саен диярлек кассадан акча ала иде. Мин үзем дә алгаладым. Баулыдагы туганыма җибәреп тордым. Бөгелмәдә яшәүче әниемнең шифоньерында хәзер дә урланган акчаның җиде йөз сумы саклана. Үземә джинсы чалбар, кыйммәтле туфлиләр, костюм алдым.

— Ревизиядә катнаштыгыз бит?

— Әйе, катнаштым.

— Ревизия сез эшләгән ярты елда кассагыздан биш мең дүрт йөз сум урланган дип тапты. Шундый нәтиҗә белән килешәсезме?

— Килешүен килешәм, әмма аның күбесе Верада.

— Өлешен тәгаенли аласызмы?

— Кызганычка каршы, хәзер әйтә алмыйм.

— Түләргә ризамы?

— Риза булмыйча, үзем мәми авыз ич.

— Кайчан түлисез?

— Бер атна вакыт бирсәгез, бөтен чүпрәк-чапракны акчага әйләндерәм. Воронина да үз өлешен бирер. Алганда алды ич! Тиенена хәтле китерермен.

— Яхшы,— диде район тикшерүчесе, тәвәккәлләп.— Мин сезне иректә калдырам. Үз гаебегезне тулысынча икърар итүегез, акчаны түләвегез судта, һичшиксез, искә алыныр. Шулай да хөкем эше нечкә нәрсә, барысында алдан күреп бетереп булмый. Кызыгызны урнаштыруны да кайгыртыгыз. Япа-ялгыз калмасын, дим.

— Рәхмәт, акча табу белән килермен,— Смирнова кыңгыр эше белән бәйләнешне шулай берьюлы, кырт кисәргә булды.

Воронина исә кырт кисүчеләрдән түгел икән.

— Шулай итеп, сезнең өскә җәмгысы 15377 сум чыга,— диде аңа район тикшерүчесе, исәпләү нәтиҗәсен аңлатканда.

— Минем өскә? — Вера утырган урындыгыннан ук калыкты.

— Әйе, комбинатның элеккеге баш бухгалтеры Воронина өстенә. Килешәсезме?

— Килешергә, минем башыма ат типкән мәллә! Ревизия алай булмый ул, актларына да имза куймыйм.

— Әйдәгез, бергә саныйк, алайса. Башкирова эшләгән чорда кассадан өч мең дүрт йөз егерме тугыз сум урланганмы?

— Башкирова кассасы белән башымны катырмагыз. Мин бернәрсә дә белмим. Башкированың үзеннән сорагыз. Касса өчен ул җаваплы.

— Аңлашыла. Смирнова эшләгән чактагы биш мең дүрт йөз сумны кая куйдыгыз?

— Смирновадан сорагыз! Кассадагы дәүләт акчасының һәр тиенена хәтле белергә тиеш ул.

— Ә сез нәрсә карадыгыз?

— Баш бухгалтерның вазифалары бетмәс-төкәнмәс аның. Адым саен җитәкләп йөртергә ясле баласы түгел алар.

— Ярый, бу да мәгълүм булсын,— диде тикшерүче түземле генә.— Сез үзегез банкка йөреп алган акчаның алты мең биш йөз кырык сигез сумы кайда?

— Анысын, гражданин следователь, Шәрәповтан сорагыз!

— Имза куеп, чек белән акчаны сез алгансыз.

— Беркатлы булмагыз, гражданин следователь, мин үзем дә юрист кеше. Законга сыймый бу!

— Бик сыя! Сез үзегез дә бит банктан акчаны имза куеп алган кешедән, Башкирова белән Смирновадан, таптырасыз бит. Үзегез алган акчага килеп терәлгәч, әйткәнегезне онытасыз. Закон һәр кеше өчен дә тигез ул. Ә сез, «юрист» имеш. Логика юк бит, Вера Зотеевна. Финанс белгеченә дә зарури ул логика. Я, ул алты мең биш йөз кырык сигез сумны кайчан түлисез?

— Распискасы кайда? Дәлилегез?

— Кызык! Шаһит әйтеп тора, сез дәлилләр таләп итәсез. Шаһит сүзен хокук гыйлеме дәлилнең иң яхшысы дип саный түгелмени?

— Дөрес, хокук буенча шаһит сүзе «дәлил». Әмма монда җитди аерма бар: сез шаһит түгел, гаепләнүче.

— Алайса, ник статьясын әйтмисез?

— Әйтәм, Вера Зотеевна. 93 нче статья, беренчесе. Дәүләт яки җәмгать мөлкәтен аеруча зур күләмдә урлау.

— Артык тырышасыз... Сигез елдан унбишкәчә иректән мәхрүм итү яисә үлем җәзасы диган сүз бит бу.

— Минем вазифам шундый, Вера Зотеевна.

— Заяга тир түгәсез, теләгәнегез барыбер барып чыкмаячак.

— Әйдәгез, сезнең күзлектән карап карыйк, нәрсә күренер икән? Нишләп чыкмасын ди?

— Башкирова, Смирнова, Шәрәпов урлаган акчаны минем җилкәгә өймәкче буласыз. Бернинди нигезсез бит бу, следователь.

— Сез фәрештә икәнсез, алайса?

— Фәрештә, димим. Миңа үз ялгышым да бик җиткән.

— Мәсәлән?

— Минем гаеп беркатлылыкта, игътибарсызлыкта. Тирәмдәге ерткычларга азык булганмын. Булырсың да! Вакытында әйтү-нитү юк. Өйрәтәсе кеше я эчкече булып чыга, я алтын-бәллүр артыннан куучы чүпрәкбаш.

— Кемгә ишарә бу?

— Копейкинны әйтәм, йөгәнсез зат. Бар белгәне аракы белән юбка. Министрлыкта ничек түзәләрдер үзенә. Мукасовасы да шул чыбыктан сөрелгән: «Тегене тап, моны тап!» Казаннан йөзләгән йомыш төяп килгән. Франциядә эшләнгән бюстгалтерга кадәр таптырды бит! Аның йомышын йомышлап, Казан белән Аланлык арасында җилдертә-җилдертә комбинатның «Жигули»е сафтан чыкты, инде тугыз ай буе тик ята. Шәрәпов та алардан калышмый. Ә сез бар гаепне минем өскә өясез.— Воронинаның күзләрендә яшь күренде.— Үзем батып, аларны коткарыр хәлем юк. Берсен дә калдырмыйм! Директорын да, ревизорларын да!

Воронина дулкынланып сөйли, бер үк сүзне кабатлый.

Директор Шәрәпов өстенә дә шик төшә, ул да прокуратураның игътибарын җәлеп итә.

Дистәләгән сорауга җавап эзли район тикшерүчесе.

— Ышанмагыз бу җир биткә,— ди Башкирова да, капма-каршы утыртып сорау алганда Воронинага күрсәтеп.— Нахакка бимазаламагыз Шәрәповны. Безнең упкынга тәгәрәүдә менә шушы елан гаепле. Һәр елмаюы, һәр сүзе агу аның.

— Следователь, нәрсә карыйсыз! — дип, нишләргә белмичә талпынып ала Воронина.— Баш бухгалтерны мәсхәрәләү бит бу! Җавапка тартыгыз үзен!

— Чәпчемәгез, Вера Зотеевна, сез икегез дә бер хәлдә хәзер икегез дә гаепләнүче.— Тикшерүче аларны тынычландырмакчы була.— Я, Сара Әбраровна, өч мең дүрт йөз егерме тугыз сумны кайсыгыз түли?

— Әнә, үзе түләсен,— Башкирова Воронинага төртеп күрсәтә.— Ул йотты акчаны. Кайтарып бирсен!

— Үзең кайтар! — ди Воронина, кулларын йодрыклап.— Кассага ул җаваплы, ул түләсен. Тиенен дә түләмим мин.

Смирнованы чакырткач та шундый ук хәл кабатланды.

— Йә, биш мең дүрт йөз сумны ничек бүлдегез?

— Дүрт меңгә якыны Верада аның,— ди Смирнова кыяр-кыймас кына.

— Ялган! — Воронина урыныннан ук сикереп тора.— Үзеннән таптырыгыз азгынның. Урлаган икән — түләсен, тиененә хәтле таптырыгыз. Директор белән бүлеште ул, үз күзем белән күрдем.

— И-и, Вера, Вера, нигә юкны сөйлисең! Яла ягу бит бу! — Смирнова хәйран кала.— Директорның бер тиен алганы булмады.

Тикшерүче бертуктаусыз җавап эзли.

— Шәрәпов намуслы... Гадел кеше...— Шаһитлар Марат Мансуровичны яклап, яхшы яктан гына телгә алалар.

Хәлбуки, район тикшерүчесенә болар гына аз була. Шуңа күрә Шәрәповка каршы тикшерү эшен туктатса да, «җинаятькә катнашмаган, гаепсез» дип карар чыгарырга кулы күтәрелми. Шәрәпов шөбһә астында калдырыла.

Дөресме бу, юкмы? Тикшерү закон таләпләренә туры киләме? Шәрәповның республика прокуратурасына юлланган шикаяте урынлымы?

Хәзер җавапны Гайнан Ибраһимов әйтергә тиеш. Тик ул моны эшләргә ашыкмады. Кисканче җиде кат үлчисе бар иде әле. Моның өчен алар район прокуроры бүлмәсенә җыелдылар...

Аланлыкта: «Воронина, Башкирова, Смирноваларның дәүләт акчасын үзләштерүендә Шәрәповның да катнашы бар икән»,— дигән шөбһәле сүз чыккан... Шәрәпов үзе бер хәл. Моңа гаиләсе ничек түзәр? Хәләл җефете ни уйлар? Гаризасында Шәрәпов үзенең сигез бала атасы икәнен дә язган бит! Җинаятьчеләр белән элемтәгә кергән өчен Шәрәповка балалары, оныклары нәрсә әйтер? Туган-тумачасы, дус-ише ни уйлар? Райкомда нинди нәтиҗә ясарлар, министрлыкта?..

— Райком хәлне даими белешеп торды,— диде район прокуроры.— Министрлыктан да шалтыраттылар.

— Күрдегезме! Димәк, шөбһә — еландай шуыша, үз эшен эшли. Аны директорлыктан азат итү өчен шундый имеш-мимешләр җитәме?

— Җитүе дә бик ихтимал,— дип прокурор баш какты.

— Калганнарын санап тору артык. Воронина миңа, «Угрыны тот!» дип, икенче берәүгә күрсәтеп йөгергән каракны хәтерләтә. Максаты апачык. Беренчедән, фаш итүчедән үч алу, икенчедән, үзенең шайкада токан атаман ролен кечерәйтү һәм булачак хөкем җәзасын җиңеләйтү. Шул юл белән барсак, без, һичшиксез, җинаятьчел максат белән астыртын яла ягучының тегерменөнә су коячакбыз. Чын угры моңа сөенәчәк кенә. Шәрәпов исә, «җинаятьне үз башыма ачканмын», дип көенәчәк. Явызлык, гаделлекне аяк астына салып таптый-таптый, тантана итәчәк. Кечкенә генә бер гариза эзеннән килеп, мин нинди хәлләргә тап булдым. Һәммәбез өчен дә сабак булырлык.

— Рәхмәт, Гайнан абый,— дип, дикъкать белән тыңлап утырган яшь тикшерүче дә сүзгә кушылды.— Миңа хәзер нишләргә кушасыз?

— Гомумән әйткәндә, җинаятьне сез үзегез дә уңышлы ачыклагансыз, әмма нәтиҗәләре белән генә килешеп булмый. Тикшерүне кичектерми тәмамлап, җинаять эшен судка җибәрәсе калган. Аңарчы тасвирлап дүрт карар язасы бар. Беренче карар яшь хезмәттәшемнең Шәрәповка тамга суккан карарын гамәлдән чыгаруы турында булыр.

— Аңлашылды,— дип сүзне район прокуроры күтәреп алды.— Бүген үк язам мин ул карарны.

— Бер нөсхәсен миңа бирергә онытмагыз.

— Ярар, Гайнан Ибраһимович. Икенчесе?

— Сөйләшкәнчә, Шәрәпов фәрештә түгел. Комбинат директоры буларак, игътибарсызлыгы аркасында үз бурычларын тиешенчә үтәмәгән, шуның нәтиҗәсендә караклар, өч ел эчендә зур сумма үзләштереп, дәүләткә аеруча зур зыян китергәннәр. Бу җинаять. Икенче карар, димәк, Шәрәповны гаепләү, хөкем җавабына тарту турында. Дөресме?

— Әлбәттә,— диде яшь тикшерүче.— Карарның бусын язу минем эш.

— Карарның өченчесе хакында да тыңлап карыйк,— диде прокурор.

— Аңарчы сезнең фикерне ишетәсем килә. Копейкин ревизия үткәргәндә кассадан күпме акча урланган була?

— Дүрт меңгә якын.

— Мукасова үткәргәндә?

— Сигез меңнән артык.

— Боларны фаш итү кемгә йөкләтелгән?

— Беренче нәүбәттә, ревизиягә, әлбәттә.

— Ревизорлар үз вазифаларын үтәгәннәрме? Урлашуны ачканнармы?

— Юк, ачмаганнар.

— Урлашу үз вакытында ачылган булса, зыян шулкадәр зур суммага җитәр идеме?

— Икеләнмичә әйтәм, яман шеш вакытында тишелер иде,— прокурорның фикере катгый яңгырады.

— Шулай булгач, нишләп аларны күләгәдә калдырдыгыз!

— Министр аларның икесенә дә каты шелтә белдергән. Боерыгының бер нөсхәсен күрсәтә алабыз.

— Кирәкми,— диде Ибраһимов кырысланып,— укыдым мин ул нөсхәгезне. Ширма бу, күз буяу.

Район прокуроры мәсьәләгә аңлатма кертүне кирәк тапты:

— Гайнан Ибраһимович, ришвәт алмаганнар, акчаны кесәләренә салучы да юк. Каты шелтә, минемчә, аз түгел.

— Хөрмәтле прокурор, начарлык кешеләрнең әшәкелегеннән генә килеп чыкмый, бәлки мәкер алдында артка чигенүләр, йомшаклык күрсәтүләрдән килеп чыга. Ришвәт алса, урлашса, кесәсенә салса, айһай, алар белән кем исәпләшеп торыр иде икән? Сүз «ревизор» исемен йөртүче ваемсыз, гамьсез затлар турында бара. Дөньяда күпме җинаять шул Копейкин, Мукасова кебекләрнең сүзсез генә тамаша кылып торуы аркасында эшләнә бит. Копейкин, Мукасова кебек күзле сукырларга закон таләбе нинди булырга тиеш?

— Хөкем җавабына тарту, билгеле,— яшь тикшерүче, ниһаять, үз ялгышын чамалады.— 172 нче статья.

— Менә бусы дөрес,— диде Гайнан көлемсерәп.— Эш бетте, көлтә җыясы гына калды.

— Воронина чыгымчы аттай тәртәдән сикерә. Соңгы вакытта безнең сүзне колагына да элми! Сөйләшүе дә латинча гына. Кәгазьләргә дә кул куймый. Тикшерүнең тоткарлануы бар. Сезнең килгәнне ишеткәч, очрашырга рөхсәт сорады. Вакыт тапсагыз, кабул итегез, зинһар. Безгә зур ярдәм булыр иде,— диде прокурор.

— Алай икән...— Гайнан беравык уйланып утырды.— Яхшы, милиция начальнигына әйтеп куегыз. Воронинага да әйтсеннәр.

Милициягә килеп керү белән Гайнан Ибраһимовны начальник бүлмәсенә озатып куйдылар. Утыз яшьләрдәге чандыр гәүдәле милиция майоры аны аягүрә басып сәламләде. Өстәл аша аның каршысында утырган яшь чырайлы чибәр хатын да, урындыктан күтәрелеп, баш какты.

— Гайнан Ибраһимович, бу сезнең белән очрашырга теләгән Воронина,— дип, начальник сүзне рәсми башлады.— Минем урынга утырып сөйләшегез, үземнең йомышлар бар.— Ул бүлмәсеннән чыгып китте.

Ибраһимов начальник тәкъдименнән баш тартты, Воронина янындагы буш урындыкка урнашты, әмма сүз башларга ашыкмады. Воронина моны үзенчә аңлады.

— Гайнан Ибраһимович, хезмәтегездән аердым, гафу итегез инде,— диде ул ягымлы гына.

— Борчылмагыз, Вера Зотеевна, үземнең дә күреп сөйләшәсем килгән иде.

— Рәхмәт инде, минем эше тоткын сүзенә дә колак салгач,— шундый сүзләр белән тикшерүче һәм тоткын арасында бер-берсен өйрәнү башланып китте.— Гражданин следователь, безнең эш кая таба тәгәри соң?

— Сезнең эш, латинча әйтсәк, актум ист[1]. Судка тәгәри ул, Вера Зотеевна, судка.

— Актум ист? — дип эләктереп алды Воронина.— Ничек инде «эш тәмам?» Мине дело белән таныштырмадылар бит.

[1] Эш тәмам, мәсьәлә хәл ителде.

— Күрәм, Вера Зотеевна, сез латинча аңлыйсыз икән. Хокук тәртипләрен дә яхшы беләсезме?

— Әйе, беләм, Гайнан Ибраһимович. Мин дә, сезнең шикелле, юрист кеше.

— Юрист? Вера Зотеевна, мин бернәрсә дә аңламыйм. Сезне министрлыкта «Воронина финанс-экономика институтын гел «биш»ләгә генә тәмамлады»,— дип мактадылар. Белмичә шапырынганнар, дисәң, дәрәҗәле кешеләр әйтте.

Мактаулы сүз ишеткәч, Воронина иректәгечә иркенәеп, сихерле генә елмаеп алды.

— Мине беләләр анда, бергә укыган ахирәтләр эшли. Финанс белгече дипломын соңыннан алдым. Мәктәптән соң туп-туры университетка кердем, юридик факультетны өченче курстан соң гына ташладым.

— Нәрсә булды соң, Вера Зотеевна? Күз тидеме әллә?

— Күз тимәде, күз ачылды. Әйе, әйе, күз ачылды, кешегә карата да, тормышка карата да.

— Ягъни мәсәлән?

— Юристлыкның исеме җисеменә туры килми аның.— Воронина яшьлек хатирәләренә чумды.— Эше токы, ашы такы. Юристлык белән мәңгегә саубуллаштым, ягъни актум ни агас. Хыялым чәлпәрәмә килде.

— Шулай да латинны белү калган.

— Латин теле миңа ана сөте белән керде, бишектә тирбәлгәндә үк. Ул минем бәхетле балачагым. Әле хәзер дә мине яшәртеп, дөньямны киңәйтеп, тормышымны нурландырып җибәрә. Мисал өчен «аскум мементо ребус ин ардуис серваре» [1] дигән әйтемне генә алыйк. Еш кына кабатлыйм мин моны. Әти-әниемә рәхмәтләр укый-укый кабатлыйм. Икесе дә врач, алар өйрәтте мине ул гаҗәеп, борынгы телгә. Ана сөте белән кергән гомерлеккә сеңеп кала икән.

— Гыйбрәтле сүз! Әти-әниегез хәлегезне беләме соң?

— И-и, Гайнан Ибраһимович, кайда ул белү! — Воронина кулъяулыгы белән яшьле күзен сөртте.— Мин күптән ятим инде. Әтием галим иде, соңгы елларда Медицина институтында укытты. Бөтен фәнни хезмәтләрен эчүчелеккә, алкоголизмга каршы көрәшүгә багышлады. Гомер буе кешеләрне алкоголь агуыннан коткармакчы булып чаң сукты. Хезмәтләренең дүртесен шул юнәлештә эшләүче атаклы юрист, Мәскәү профессоры Герцензон белән бергә язып бастырдылар. Мин юрфакның өченче курсында укыганда әти фаҗигале рәвештә үлде. Урам чатында автобус көтеп торганда, йөк машинасы таптатып китте үзен. Шоферы исерек булган. Кайгы-хәсрәттән әнием дә сыгылып төште. Ике елдан соң ул да китеп барды. Юрфакны ташлауга болар сәбәп булды.

— Аяныч та, гыйбрәтле дә бу! Тик шулай да, ярты юлны үткәч, өч ел укыганны ташлап калдыру, ай-һай... Финансчы һөнәренә этәргән башка сәбәп булмыйча калмагандыр бит?

— Гайнан Ибраһимович, хәзер моңа мин үзем дә хәйран калам. Нишләптер миңа, финансчы булгач, акча эчендә йөзәрмен кебек тоела иде, чөнки әти-әни канаты астында үстем, гаиләдә бердәнбер бала, яшьтән үк акчага аптырамадым. Аның кайдан, ничек кергәнен белми дә идем. Билләһи, дим.

— Ышанам, Вера Зотеевна,— тикшерүче Воронинаның хәленә керде.— Бердәнбер баланың иркә булуы аңлашыла.

— Яхшымы бу, начармы, бүгенге көнгә хәтле төшенә алганым юк әле. Күпме өйрәтәләр, күпме шелтәлиләр, ана сөте белән кермәгәнне, тана сөте белән кермәс инде. Менә бүгенге хәлемне генә алыйк! Ичмасам сез дә куандырмыйсыз, эшебезне «судка тәгәри», дисез.

---

[1] Кыен шартларда да күңелеңне төшермә.

— Вера Зотеевна, сез сорагач кына әйттем. Тикшерү эше белән үзегез дә танышырсыз. Беренче битеннән соңгысына хәтле укырга, язып алырга, өстәмә үтенечләр белән мөрәҗәгать итәргә хакыгыз бар. Белеп торыгыз, дим.

— Рәхмәт! Шәрәповка каршы тикшерү туктатылган икән. Димәк, прокуратурада да кул кулны юа!

— Киресенчә. Шәрәпов хокук җавабына тартылды. Ул судта сезнең кебек үк гаепләнүчеләр эскәмиясендә утырачак.

— Сөенечле хәбәр өчен мең рәхмәт сезгә, Гайнан Ибраһимович, гаделлек бар икән әле.

— Исегездә тотыгыз, гаделлек аерым кеше теләгәнчә булмый янсә аның теләгеннән генә тормый.

— Әлбәттә, Гайнан Ибраһимович! — Воронина шатлыгыннан очына ук башлады.— Ә Копейкин? Мукасова?

— Алар да сезнең белән янәшә утырачак. Гаепләнүче сыйфатында.

— Рәхмәтләр генә яусын! Күпме әйттем, тыңламадылар бит башта ук. Бик әйбәт булган, Гайнан Ибраһимович, коньяк чөмереп йөрмәсеннәр иkенче.

— Ник эчерттегез?

— Эчертмичә кара! Бөтен дөньяның астын өскә әйләндерерләр.

— Ярамаганын белгәнсез, үзегез узындыргансыз.

— Үзләре бит, Гайнан Ибраһимович. Берсенә дә авызына салмадык. Тотнаксыз бәндә упкынга үзеннән-үзе тәгәри. Рим хокукында язылган кагыйдә. Сезнең дә ярты гомерегез командировкада уза. Сез эчәсезме соң?

— Юк, Вера Зотеевна, эчмим.

— Заманчамы соң бу?

— Әүвәлгечә дә, заманча да бу, Вера Зотеевна. Халык: «Аек башта аек акыл»,— ди. Хәзерге кискен көрәш заманында, башны җүләрлеккә салып, аракы чөмереп, фани дөньяны онытып йөрү — түбәнлек кенә түгел, зур җинаять тә! Ә сез ревизорларны алкоголь белән агулагансыз.

— Дөрес, Гайнан Ибраһимович, гаеп атта да, тәртәдә дә бардыр инде.

— Сез алай гаебегезне кеше өстенә аударырга тырышмагыз. Барыбер җавап бирергә туры киләчәк. Барыгызга да.

— Хөкем шулай ук каты булыр микәнни?

— Анысын инде, Вера Зотеевна, суд хәл итәр, соңгы сүзне ул әйтер.

Сүзне беткәнгә санап, Гайнан урыныннан торып басты. Ә башы иелгән Воронина, иңнәренә ниндидер авырлык китереп баскандай, күзләрен билгесез бер ноктага төбәгән килеш һаман утыра бирде.

................

# Сергей Есенин

⁂

Шундый ишекләр бар бу Һарсанда,
Кызыл гөлгә чумган юллары.
Уйчан әкият кызы яши анда.
Шундый ишекләр бар бу Һарсанда,
Аларны тик ачып булмады...

Шөкер генә көче кулларымның,
Чәчләремдә бакыр һәм алтын,
Ә ул кызның өне назлы, моңлы...
Шөкер генә көче кулларымның,
Ишекне тик ача алмадым.

Батырлыкка сөюдән ни бәһа,
Жырым белән назлыйм кемнәрне?
Һич көнләшми хәзер миннән Шаһә,
Ишекне шул ача белмәдем.
Батырлыкка сөюдән ни бәһа?

Житте Россияма кайтыр көнем,
Фарсы иле, сине калдырам.
Артык сагындырды туган илем,
Мәңгегәме синнән аерылам?
Житте Россияма кайтыр көнем.

Сау бул инде, хуш, әкият кызы,
Ишекләрең ябык бүген дә,
Ләкин нинди кичерешләр узды!—
Мин жырлармын сине илемдә,
Сау бул инде, хуш, әкият кызы!

⁂

Зәгъфран төсе сеңгән кичке нурга,
Гөл йөгерә кырларда тагын.
Шундый бер жыр миңа, бәгърем, жырла,
Хәтта Хәйям жырламаганын.
Гөл йөгерә кырларда тагын.

Күбәләкләр күче күк йолдызлар,
Ай яктысы Шираз өстендә.
Пәрәнжәле, никтер, хатын-кызлар,
Бу ошамый миңа һич кенә.
Күбәләкләр күче күк йолдызлар.

Бөтенләйгә әллә сүнгәннәрме
Каплап тәннең бакырдай төсен,
Саклыйлармы әллә ак тәннәрен
Ныграк гашыйк булсыннар өчен,
Каплап тәннең бакырдай төсен.

Пәрәнҗәгә дус булма син артык,
Киңәшемне сеңдер күңелгә,
Бәхет өчен җитми бит ул вакыт,
Кеше гомре мәңге түгел лә.
Киңәшемне сеңдер күңелгә.

Хәтта язмыш биргән ямьсезлек тә
Балкый үзгә матурлык белән,
Шуңа күрә, шундый сылу биткә
Шәүлә нигә пәрәнҗәләрдән?—
Матурлыкны табигать биргән.

Гөл йөгерә кырларда тагын.
Ерак илне йөрәк төштә күрә,
Үзем сиңа бер җыр җырлап бирәм,
Һич тә Хәйям җырламаганын...
Гөл йөгерә кырларда тагын.

**ЗӨЛФӘТ** тәрҗемәләре

*Күренекле шагыйрь, прозаик һәм драматург, 1934 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы, Бөек Ватан сугышы ветераны Салих ага Батталга 80 яшь тулды.*

*Салих Вазыйх улы Батталов 1905 елның 8 августында Татарстанның Алексеевский (элекке Биләр районы) Олы Тигәнәле авылында туган. Хезмәт юлын бик иртә башлап, уналты яшендә Мәскәү өлкәсендә төрле җирләрдә, аннары «Лукино» совхозында эшли. 1924 елда, В. И. Ленин үлгәннән соң, комсомолга керә, шул ук елда, Щелково туку фабрикасында эшләгәндә, аның стена газетасы өчен язган беренче шигыре Мәскәүдә, татар телендә чыга торган «Эшче» газетасында басылып чыга. Әдипнең иҗат юлы әнә шулай башлана. Аннары ул фабрика, завод эшчеләре өчен пьесалар («Организатор» һ. б.) яза, ике еллык белем күтәрү курсларын тәмамлый. 1927 елда исә үз теләге белән РККАның Хәрби-һава көчләре сафына килә, очучылар әзерли торган курслар тәмамлап, озак еллар очучы булып хезмәт итә. Иҗатын да инде төрле жанрларда дәвам иттерә: «Язулы яулык», «Сынау» кебек пьесалары Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелса, утызынчы елларда ул «Очучылар» романын, повестьлар, хикәя һәм очеркларын яза, шигырь, поэмалар бастыра.*

*Бөек Ватан сугышы елларында Тын океан Хәрби-һава көчләре частьларында хезмәт итә, совет сугышчыларының батырлыгын данлаган күп санлы шигырьләрен, «Капитан Гастелло» кебек мәгълүм поэмасын яза.*

*Сугыштан соң әдипнең иҗаты киң полотнолы әсәрләрдә яңа колач һәм көч белән ачылып китте: аның «Олы юл буйлап» исемле шигъри повесте «Новый мир» журналы аша бөтенсоюз укучысына ирешә, шулай ук «Сигезенчесе кем?» исемле повесте да русча басылып, киң яңгыраш алды. Әдипнең «Чирмешән якларында» исемле шигъри романы һәм «Баштан үткәннәр» дип аталган автобиографик әсәре дә тәнкыйть һәм укучылар тарафыннан бик җылы каршыланды.*

*Саналганнардан тыш, 60 еллык иҗат гомерендә С. Баттал барлык жанрларда да күп, үзенчәлекле әсәрләр язды дип әйтә алабыз: аның сатира-юмор һәм балалар әдәбияты өлкәсендә дә зур хезмәте бар.*

*Әдәбият өлкәсендәге уңышлары өчен 1957 елда ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.*

*Әдип бүген дә юбилеен яңа әсәрләр язып, чын иҗат дәрте белән янып каршылый. Журнал редакциясе, редколлегия һәм күп санлы укучыларыбыз исеменнән аны зур юбилее белән котлап, бу санда шагыйрьнең яңа әсәреннән — автобиографик язмалардан өзек тәкъдим итәбез.*

## Салих Баттал

# ЯКТЫРТУ

Миң дә тугыз йөз дә егерме өч.
Хезмәт биржасында — чиратым.
Очраклы эшләрдә тирләп, туңып,
Мәскәү тирәләрен урадым.

Карыйм — тагын кайсы завод тирелә;
төтен болгап чакыра морҗасы? —
Чабам: килә эш бәхетен татып,
кочагына арып егыласым!

Китерәләр анда вагон-вагон
утын, торф, күмер... Бушатам.
Акча алам. Ашыйм. Заводны да
табынымда бергә ашатам.
Пар казаны әй ярата сине,
ашарына күмер китерсәң,
аның дәрте чиктән ашып китеп,
манометр кашын сикертә!
Утның теле аңлаешлы — нигә
ул чаткылар чыртлап очалар,—
кәрәк «речь!» сөйли, ә ялкыннар
аягүрә балкып кул чаба...

***

Эзли торгач, әнә, шундый бәхет,—
үз урнымны таба алдым мин,—
Щелковоның туку фабрикасы
кочегаркасында калдым мин.
Ышанычлы урным. Һәркөн саен
барып тотынам дустым кәрәккә;
ә мич, кызулыкта калышмаска
ярыш ача минем йөрәккә.
Утым аша күреп эшлим,— бөтен
фабрикага электр нур бирәм;
клубта Назыйм Хикмәт рәсемнәре
яктырсыннар минем нур белән!
Андагы стена гәзитенең
художнигы әле юклыктан,
рәсемнәрен ясап китә иде
Назыйм Хикмәт килеп КУТВтан [1]
Шундый чакларында аның белән
очрашырга туры килгәндә
җансыз, хәрәкәтсез нәрсәләрне
ясаттыра иде миннән дә.
Әйтик, өстәл, ящиклардан өйгән
баррикада рәсмем артына
Назыйм коралланып баш күтәргән
эшчеләрне китереп бастыра.
Ә гәзитнең исме — «Яшьләр таңы».
Яшь гомерем шунда яктырды.
Һәр клубта, һәр тел ярдәмендә
Ленин шулай таңнар аттырды.
Минем кебек татар эшчеләре
фабрикада күпме,— биш дистә,
плюс бала-чагалары белән
гөрләп торган клуб бик истә.
Сәхнәсендә бүреләрне хурлап,
җанландырып Тукай мәзәген,
нәни Фәхри [2] нәкъ тормыштагыча
дүрт аяклап уйный Кәҗәне.

Кем уйлаган, ул чак шушы бала,—
уйнап, җырлап, күнегеп һәр кичне,
торып басар, диеп,— Насретдинов —
РСФСРның халык артисты!

[1] КУТВ — Коммунистический университет трудящихся Востока. Ул елларны шунда — Мәскәүдә укыган Назыйм Хикмәт Щелково фабрикасына килгәләп, культура эшләрендә ярдәм күрсәтеп китә иде.

[2] Артист Фәхри Насретдинов турында сүз бара. (Автор).


Эх, исәпкә аласылар бар бит
нурлы клубларның бу санын,—
Мәскәү татар эшчеләре клубын,—
чыгышларын анда Мусаның...
Мавыктыргыч яктыртучы эше,
Әйтерсең лә, минем мич аша
тәүлек, атна, айлар... хәтта еллар
өзлексез көн булып тоташа!
...Көтелмәгән хәлләр булып алды...
Эштән алмашынган чагымда
күмерле кул белән язган шигырем
балкып чыкты «Яшьләр таңында»...

Минем иҗатымның башы — Ленин.
Аның язмышына кушылган
иң беренче шигырем китте кабынып,
дөрләп, аның соңгы сулышыннан.
Тетрәндерде үлеме, зур көрәшкә
рухландырып минем күңелне;
антым булып, минем шигырем дә
клуб диварына эленде:
«...Безнең өстә кайгы хөкем сөрсә,
без беләбез дошман көләсен,
онытмабыз, ләкин, юлбашчыны
агулаган дошман пулясын!
Эшчән халык күген каплап алган
кара болыт кебек кайгылар
корал булып каты көрәш өчен
күңелләрдә берегеп калдылар».

Айлар үтте шулай, язлар җитте.
Клубка бер кергән чагымда
күзләремә ышанасы килми,—
Туфан шигыре «Яшьләр таңында»!
Укыйм:
«Кояш күзле майга әзерлекне —
плакатлар - ниләр какканны,
ә мин әзлим комач фабригының
батыр эшче Салих Батталны...
Зур истәлек булып калыр, дуслар,
сезнең биргән төпле киңәшләр,
бәлки алар минем җырларымда
яңгырарлар әле, иптәшләр...»
Әле кайчан гына мич алдында
көрәк тулы күмер күтәргән
«батыр эшче», ике смена эшләп,
тәүлек буе йоклап үткәргән!
Эзләгәннәр аны, тапмаганнар
торагыннан барып карап та:
«батыр эшче» кайтып җитә алмый,
ауган арып күрше баракта...
Назыйм Хикмәтләрне, Туфаннарны
хәзер искә алу кызык ул,—
ничек якынайткан, «көрештергән»,
берләштергән безне бер үк нур!

Тукайның 100 еллыгына

# УРАЛЬСКИДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ



Шагыйрь эшләгән типография станогы. Ул Г. Тукай исемен йөрткән типографиядә — Семаков йортында торган (якын арада типография яңа бинага күчәчәк).

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

**Яхъя Абдуллин,**
философия фәннәре докторы, профессор.
**Рашат Әмирханов,**
философия фәннәре кандидаты.

# РЕВОЛЮЦИОН-ДЕМОКРАТИК ИДЕОЛОГИЯ ҺӘМ XX ЙӨЗ БАШЫНДА ӘДӘБИ ХӘРӘКӘТ

Беренче рус революциясе барышында Идел буе һәм Урал татарлары арасында революцион-демократик идеологиянең барлыкка килү һәм үсүе яңа татар әдәбиятының формалашуы белән тыгыз рәвештә бәйләнгән иде. Әгәр революцион-демократик лагерьның иң күренекле вәкилләре Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Ибраһимов, М. Гафури һәм башкаларның, милли әдәбиятны яңа баскычка күтәрешкән атаклы язучылар, шагыйрьләр, публицистлар булуын да искә алсак, XX йөз башындагы алдынгы иҗтимагый фикер үсешендә матур әдәбиятның нинди роль уйнавы тагын да ныграк аңлашыла төшәр.

Революцион демократларның әдәби иҗаты алдынгы иҗтимагый идеяләрне чагылдырып кына калмый, ә бәлки ул идеяләрне халыкка җиткерүче трибуна, бер чара төсен дә ала.

Классик рус әдәбиятының иҗтимагый тормышны үзгәртеп корудагы роленә басым ясап, А. М. Горький: «Әдәбиятыбыз — безнең горурлыгыбыз, милләт буларак без тудырган иң яхшы нәрсә. Шунда безнең бөтен фәлсәфәбез, шунда безнең рухның бөек омтылышлары гәүдәләнгән»,[1] — дип язган иде. Идея байлыгының зурлыгын, өлгергән иҗтимагый мәсьәләләрне чишү юлларын эзләвен, халык мәнфәгатьләрен кайнар рәвештә яклый баруын, шулай ук халыкның рухи тормышындагы ролен истә тотып фикер йөрткәндә, XX йөз башындагы алдынгы татар әдәбияты да шундый ук бәягә лаек. Г. Тукайның:

> Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт бәндә бар,—
> Бәнчә, бунда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар![2]

дигән юлларында чагылган караш XX йөз башындагы алдынгы татар әдәбиятының төп девизына әйләнә. Матур әдәбият әсәрләренә халыкның идея җитәкчесе булу вазифасын йөкләп, Ф. Әмирхан әдәбиятны алдынгы идеяләрне таратучы иң көчле бер чара дип саный, шуңа күрә дә: «бер кавемнең яшьләренең бер фикер иҗтимагыйгә вә милли мәсьәләләрендә бер нәзарга килүе фәкать бер әдәбият тәэсире белән вөҗүткә килә аладыр»,[3] — дип өсти. Матур әдәбиятны милләтнең рухи яңарышка бару юлында хәлиткеч бер чара дип санау фактларын Г. Тукайда, Г. Ибраһимовта, М. Гафурида һәм татарның башка демократик фикер ияләрендә очратырга мөмкин. XX йөз башында критик реализм юлына аяк баскан һәм киң катлау укучы массалары арасында тирән мәхәббәт яулап өлгергән матур әдәбиятның идея-тәрбияви йогынтысы бик нык көчәеп китә, һәм прогрессив культура әһелләре аның иҗтимагый тормышта тоткан ролен тагын да тирән-

---

[1] Горький М. Собрание сочинений в 30-ти томах. т. 24, М., 1953, 64 б.
[2] Тукай Г. Әсәрләр 4 томда, 1 т., Казан, 1975, 90 б.
[3] Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр 2 томда. 2 т., Казан, 1958, 337 б.

рәк аңлый башлыйлар. Шуңа күрә дә XX йөз башындагы демократик татар әдәбиятының идея-концептуаль эчтәлеген шул чордагы алдынгы иҗтимагый фикернең үсеш закончалыклары һәм милли яңарыш үзенчәлекләре белән бәйләнештә караганда гына дөрес фикергә килергә мөмкин. Әдәби юнәлешләр һәм сәнгатьчә индивидуальлекләр ни хәтле генә төрле-төрле булмасын, бу чордагы әдәби хәрәкәтнең төп тенденцияләре киң катлау хезмәт иясе массаларының идеологлары — революцион демократлар иҗатында аеруча ачык чагыла.

Татар халкының иҗтимагый фикере үсешендә 1905-1907 еллардагы революция чорында туган революцион-демократик агым Россиядәге азатлык көрәшенең пролетар этабында формалаша. Бу вакытта Россиядә крепостнойлык калдыкларын, аның төп терәге булган самодержавиене һәм алпавыт җир биләүчелеген бетерү бурычы әле көн тәртибеннән төшмәгән була. Шуңа күрә боларга каршы көрәш революцион демократлар иҗатында төп мотивларның берсенә әйләнә.

Шуның белән бергә, XX йөз башындагы Россия шартларында революцион демократик идеология урта гасырчылык калдыкларына каршы гына түгел, ә бәлки капиталистик мөнәсәбәтләргә каршы да юнәлтелгән иде. Г. Ибраһимов шул чордагы җәмгыятьнең төп җитешсезлеге итеп халыкны хәерчелеккә һәм газапка дучар иткән, кешедәге кешелек сыйфатларын гариплиндергән буржуаз мөнәсәбәтләрне, һәр нәрсәгә хуҗа булып алган капиталны һәм хосусый милекчелекне саный[1]. Г. Тукай фикеренчә дә гади кеше өстенә төшкән бәла-казалар хосусый милекчелектән һәм капитал изүеннән килеп чыга, әгәр кеше шулар властена буйсынмаса, аңа яшәве бик тә кыенга туры килә .

Билгеле ки, татар революцион демократларының төп өлеше баштан ук социал-демократларның идея йогынтысында формалаша, татар укучылары арасында марксистик характердагы әдәбиятны пропагандалау эшендә актив катнаша. Революцион татар демократиясенең күп вәкилләре социал-демократлар — большевиклар белән тыгыз бәйләнештә була. Әйтик, Г. Тукай әле Уральскида яшәгән заманнарда ук «Уралец» газетасы редакциясендә эшләгән большевиклар белән элемтәдә тора, аларның эшләрен үти. «Марксизм идеяләре белән танышлык Тукайны большевикларга якын торган ныклы революцион-демократ ясый. «Инде соңрак» Х. Ямашев белән аралашып яшәү аның ышанычын ныгыта, аны тагын да чыныктыра төшә»[2].

Татар иҗтимагый фикеренең Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Камал, М. Гафури кебек күренекле вәкилләренең революцион-демократик карашлары шулай ук революционер-ленинчыларның турыдан-туры тәэсире йогынтысында формалаша.

Марксистик социологиянең революцион-демократик фикер ияләренә йогынтысы аларның кешелек тарихының революцион сәхифәләрен, сыйныфларның барлыкка килү һәм аларның көрәшен ачып биргән материалларга турыдан-туры мөрәҗәгать итүләрендә дә ачык чагыла. Г. Тукайның «Ачлык-падишаһ», «Мөхарәбә вә Государственная дума», Ф. Әмирханның «71 нче ел Коммуна»сы, Р. Рәкыйбинең «Француз революциясе» кебек тәрҗемә әсәрләрендә тарихи прогресс гаделле җәмгыять өчен сыйныфлар көрәше тарихы буларак ачыла.

Дөрес, алдынгы татар революцион-демократик фикере марксизмны әле эшчә сыйныфларның мәнфәгатьләрен һәм бурычларын һәрьяклап нигезләп биргән бөтен бер карашлар системасы итеп карамый. Марксизм бөтен кешелек җәмгыятенең үсеш перспективаларын фәнни яктан аңлатып биргән тәгълимат буларак кабул ителми. Әмма шул кадәресе бәхәссез, марксизмның аерым идеяләрен үзләштерү татарның алдынгы карашлы фикер ияләренә экономика, хокук һәм сәясәт арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыкларга, сыйнфый көрәшнең җәмгыять тарихында һәм шул чактагы реаль чынбарлыкта тоткан әһәмиятен дөрес аңларга булыша. Иң мөһиме шунда, революцион татар демократлары илебез тарихындагы хәлиткеч борылыш моментында Октябрь идеяләрен кабул итәргә һәм аның казанышларын якларга әзер булып чыгалар.

Татар халкы арасында революцион-демократик идеологиянең формалашуына гомум Россия күләмендәге закончалыкларның хәлиткеч йогынтысына басым ясап, бу идеология үсешенең кайбер үзенчәлекләренә конкретрак рәвештә тукталып узасы килә. Ул үзенчәлекләр милли яшәешнең спецификасы, бездәге идея традицияләре белән бәйләнгән булып, социалистик җәмгыятьне дөньяга караш ноктасыннан чыгып ничек нигезләүдә ачык чагыла.

Революцион демократларның социологик карашларындагы мөһим сыйфат — ул татар иҗтимагый фикер үсешенең бу яңа этабында, бигрәк тә аның башлангыч чорларында, социалистик идеяләрнең мәгърифәтчелек идеаллары белән тыгыз үрелгән булуы.

Мәгърифәтчелек идеяләрендә тәрбияләнгән революцион-демократлар баштарак

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр 8 томда. 5 т.

[2] Наф

Казань, 1964, 313 бб.

чорларда социалистик идеологияне мәгърифәтчеләрнең гуманистик принципларының алга таба үсеше тәсендә күзалладылар. Әмма мәгърифәтчеләрдән үзгә буларак, алар бу принципларны бөтенхалык революциясе нәтиҗәсендә тормышка ашачак дип уйладылар. Социал-демократларның политик көрәше һәм максатлары белән килешсәләр дә, максатның асылын — социалистик җәмгыять төзүне алар идеалистик тестә аңлыйлар. Әйтик, Г. Тукай: «Минем чын мәсләгем — юлым бөтенләй социаллардай» ,— дип язганда, социалистик тәгълимат тарафдары буларак эш итә. Әмма бу тәгълиматны тормышта хөкем сөргән гаделсезлектән котылуның «чын юлы» дип кабул итүендә Тукайның социализмны кешенең табигате, аның тигезлек һәм гаделлек принципларын тормышка ашыруга табигый омтылышы, шулай ук кеше акылының үсеш логикасы үзе таләп итә торган социаль идеал тәсендәрәк күз алдына китерүе сизелә. Башкача әйткәндә, Г. Тукайның социалистик идеалны күзаллавы, башка фикердәшләренеке кебек үк, рационалистик характерда булып, социаль-экономик үсешнең объектив зарурияте тәсендә чагылмый иде.

Алдынгы карашлы фикер ияләре иҗатында патриархаль мөнәсәбәтләрне тәнкыйть итү, иске дөньяга яңа җәмгыятьне, шулай ук мәгърифәтле, дини хорафатлардан азат булган, гаделлек һәм ирек өчен көрәшүче яңа кешене каршы кую яңа иҗтимагый строй өчен көрәшнең төп процессы тәсендә чагыла. Ф. Әмирхан әсәрләре — шуның ачык мисалы. «Яшьләр» драмасында, мәсәләң, аталар һәм балалар проблемасын автор иске тәртипләрне яклаучыларның яңа җәмгыять төзергә тиешле яшь көчләр белән көрәше рәвешендә сурәтли. Пьесаның төп геройларыннан Газиз: «Бу тавышлар — иске тормыш белән яңа тормыш арасында»,— ди.

Яңа җәмгыять хакындагы карашларын язучы тагын бер әсәрендә — «Фәтхулла хәзрәт» исемле фантастик повестенда гәүдәләндерә. Биредә Ф. Әмирханның социалистик иҗтимагый идеалы фән, техника, сәнгать чәчәк аткан, кешеләр үзара һәм тирә-юньдәге табигать белән килешеп яшәгән җәмгыятьне сурәтләп бирүендә чагыла.

Беренче рус революциясе һәм аның идеяләре революцион демократларны мәгърифәтчеләр калдырган мираска социалистик һәм революцион позицияләрдән чыгып якын килергә, аңа революцион күтәрелеш елларында көн тәртибенә менгән лозунг — самодержавиене бәреп төшерү бурычы яктылыгында карарга мәҗбүр итте. Шул бурычлар ноктасыннан карап, революцион демократлар мәгърифәтчелекне экономик артталыктан, социаль һәм милли изүдән котылырга булыша торган бер чара тәсендә аңлаталар. Мәгърифәтчелек яңа эчтәлек белән баый — кешенең мәгърифәтле булу-булмавын ул үзләштергән белем запасы гына түгел, ә бәлки бу белемнең изелгән халык мәнфәгатьләре өчен көрәштә корал булырга яраклымы-түгелме икәнлеген билгели башлый. Уку, дип саный Г. Тукай, «...безнең һәртөрле чалмалы бурлаклар тырнагыннан азат булуыбызга вә бюрократия золымыннан, башка милләтләр илә берлектә, безнең дә котылуыбызга иң беренче вә иң тугры юлдыр. Укымак — дөрестнең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр»[1]. Биредә Г. Тукай асылда шул чордагы чынбарлыкның һәм социаль, һәм мораль терәкләрен җимерүгә юнәлтелгән революцион мәгърифәтчелек программасын яклап чыга. «Әльислах» газетасында басылган мәкаләдә татар тормышында тамырдан үзгәреш кирәклеген яклап, Ф. Әмирхан да халыкны агарту эшен аның социаль-экономик хәлен үзгәртү белән бәйләп карый[2]. Шуның белән бергә, Г. Тукай да, Ф. Әмирхан да, Г. Ибраһимов та, милләтнең тормыштагы һәртөрле яңалыкка аеруча сизгер булган катлавы һәм аның үзен үткәннән авыр йөгеннән азат итәргә тиешле иҗтимагый көч буларак, яшьләргә аеруча зур өмет баглыйлар. «Безнең милләт тә,— дип яза Г. Тукай,— башка милләтләрдәге кеби, хамисез, мәлҗәсез, фәкыйрь вә эшче халыкның файдаларына тырышучы, биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алмаштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егетләргә мохтаҗ»[3].

Татар халкы арасында революцион-демократик идеологиянең формалашу үзенчәлекләрен тикшергәндә исәпкә алынырга тиешле тагын бер момент — бу халыкның тормышында ислам диненең тоткан роле. Мәгърифәтчелек идеологиясенең таралу һәм 1905-1907 еллардагы революция нәтиҗәсендә ислам диненең позицияләре беркадәр какшаса да, XX йөз башында аның хәле әле һаман да шактый нык була. Бу, берьяктан, исламның мөселман дөньясында дини генә түгел, ә бәлки экономика, хокук һәм көнкүреш кодексы буларак та мөһим роль уйнавы белән аңлатыла, шул нәрсә аңа иҗтимагый һәм шәхси тормышның бөтен тармакларына үтеп керергә юл ача. Икенчедән, самодержавиенең кырыс милли политикасы да исламга үз позицияләрен саклап килергә ярдәм итә.

---

[1] Тукай Г. Әсәрләр. 3 т., 156 б.
[2] Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр. 2 т., 156 б.
[3] Тукай Г. Әсәрләр 3 т., 155—156 бб.

Милли дәүләтчелек булмаган, мәдәни тормышның теләсә нинди заманча формалары тыелган, көчләп чукындыру һәм руслаштыру яшәп килгән шартларда XX йөз башында да мөселман дине татар халкы өчен милли үзенчәлекне саклауга булышучы мөһим идеологик терәк һәм изүгә, кыерсытылуга каршы протестның бер формасы буларак көчен саклап килә. Ислам диненең шул функцияләре халыкның рухи тормышында тоткан урынын билгели.

Икенче яктан, исламның тарихи рәвештә формалашкан роле котылгысыз төстә патриархаль мөнәсәбәтләрне, дини ортодоксияне саклауга китерә, җәмгыятьнең социаль һәм мәдәни яңарышын тоткарлый иде. Дини фанатизмны алга сөреп һәм үз мәнфәгатьләрендә тормышның консерватив формаларын яклап чыгып, диннең халык тормышындагы роленнән динчеләрнең реакцион өлеше сорыкортларча файдалана иде. Алар тормыштагы һәртөрле яңалыкка каршы чыгалар, шул җәһәттән караганда, татар иҗтимагый тормышын секулярлаштыруга каршы чыккан самодержавие белән бер политиканы уздыралар иде.

Татар халкының рухи тормышында гасырлар буе хакимлек иткән ислам дине революцион-демократик фикер ияләренең дөньяга карашына да йогынты ясамыйкалмый, билгеле. Тукай, Әмирхан, Гафури һәм башка алдынгы культура әһелләре, берьяктан, халыкның прогресска баруы, алдынгы Европа һәм рус культурасы белән якынаю юлында киртә булып торган, татар тормышындагы һәртөрле артталыкны, торгынлыкны яклап килгән клерикализмны, консерватив динчеләрне фаш итеп чыгалар. Шул ук вакытта иҗтимагый үсеш законнарын аңлауда идеалистлар булып калганлыктан, үткән чорларның бөек утопистлары кебек үк, алар диндә социаль һәм милли тигезлек принципларына нигезләнгән иҗтимагый стройга мораль санкция бирерлек көч күрәләр, чөнки хәзергә әле тарихи материализм позицияләреннән чыгып андый җәмгыятьнең объектив зарурият булуын дәлилләп күрсәтә алмыйлар. Практик планда алганда, алар төрле хорафатлардан арындырылган диннең уңай ролен аның этик һәм тәрбияви функцияләрендә күрәләр. Диннең әлеге функцияләрен Ф. Әмирханның киләчәк җәмгыятьне сурәтләвендә («Фәтхулла хәзрәт»), Г. Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән китапка язган кереш сүзендә һәм кайбер шигырьләрендә очратабыз. Бу яктан Г. Тукайның «Шартлар» исемле мәкаләсендәге: «Капиталистический строй бетеп, дөньяга социалистический тормыш чыкмыйча, капиталның һәр хакыйкатькә пәрдә булып торуы бетмичә, мин үземезне мөселман дип йөрүдә бер мәгънә дә тапмыйм.

Бу тормышка кальбән разый булган кеше мөселман да түгел, мөэмин дә түгел, инсан да түгел диясем килә»[1],— дигән юллар бик тә характерлы.

Г. Тукай иҗатын өйрәнүче галим И. Нуруллин бик хаклы язганча, бу өзектә дингә байлар хезмәтчесе булудан азат итәчәк социалистик җәмгыять җиңгәч кенә, дин, социаль гаделсезлекне каплап торган пәрдә булудан котылып, кешеләргә чын-чынлап хезмәт итә башлаячак, дигән фикер ачык яңгырый.

Билгеле булганча, бездә революцион иҗтимагый фикер ике катлы изү — социаль һәм милли изү хөкем сөргән шартларда формалаша, бу да татар чынбарлыгына хас бер үзенчәлек булып тора. Шул нәрсә алдынгы фикер ияләренең Россиядәге милли мөнәсәбәтләр мәсьәләсенә аеруча сизгер булуларын китереп чыгара. Алар карашынча, социаль тигезлек кебек үк, милли тигезлек тә яңа җәмгыятьнең политик системасында принципиаль мәсьәлә булып торырга, күпмилләтле дәүләттә бер милләтнең икенчесе өстеннән хакимлек итүенә юл куелмаска тиеш.

Милли аңның үсүенә, Россиядәге төрле милләт хезмәт ияләренең сәяси активлыгы көчәюгә бәйле рәвештә милли хәрәкәтнең җанлана төшүе милли мәсьәлә тирәсендә барган идея көрәшенең үткен төс алуын, патша самодержавиесенең бу өлкәдәге тирән кризисы шартларында милләт һәм халыкларның киләчәге һәм үсеш юллары хакында төрле дискуссияләрне китереп чыгара. Революцион демократлар үз эшчәнлекләренең беренче адымнарыннан ук социал-демократларның: самодержавиене себереп ташлау өчен, Россиядәге барлык халыкларның изелгән сыйныфлары берләшергә тиеш, дигән лозунгысын яклап һәм хуплап чыгалар.

Бу уңайдан аларның «Мөселман иттифакы» дигән буржуаз милләтчелек партиясенә, аның дини һәм милли урталыкны сыйнфый аерымлыклардан өстен куярга азапланган идеологларына мөнәсәбәтләре игътибарга лаек. Г. Тукай «Мөселман иттифакы»ның дин һәм милләт пәрдәсенә төренгән сыйнфый асылыннан усал төстә көлә, аны үз идолына — капиталга табынучы байлар партиясе, дип атый[2]. Хезмәт ияләренең сыйнфый мәнфәгатьләре позициясеннән торып, «Иттифак»ның программасын һәм максатларын революцион-демократик рухтагы күп кенә матбугат органнары фаш итеп чыга[3]. Сыйнфый

---

[1] Тукай Г. Әсәрләр, 3 т., 197 б.

[2] Тукай Г. Әсәрләр, 2 т., 37 б.

[3] «Азат халык», 1906, 4 һәм 10 саннар; «Таң йолдызы», 1906, 3 һәм 44 саннар; «Туп», 1907, 1 сан һ. б.

каршылыкларны йомшартырга тырышучыларга каршы чыгып, Г. Ибраһимов, башка барлык халыкларга хас булган кебек үк, сыйнфый көрәш татар милләтенең формалашуына да хас күренеш, дип басым ясап әйтә. Ул җәмгыять үсә бару белән бергә милләтләрнең аерымлана баруын һәм социаль-экономик билгеләр буенча милләтнең үз эчендә дифференциация процессы баруны закончалыклы күренеш, дип саный[1].

Сыйнфый җәмгыятьтә милли бердәмлекнең иллюзия генә икәнлеге, милләтнең үз эчендәге байлык белән хәерчелекнең капма-каршылыгыннан килеп чыга торган социаль антагонизмнарның котылгысыз булуы хакында Ф. Әмирхан да яза[2]. Татар халкы узган тарихи юлны өйрәнеп һәм аның киләчәген бәяләп, Г. Ибраһимов буржуаз концепцияләр белән бәхәстә безнең халыкның, аның тарихының, теле, мәдәниятенең үзенчәлекле һәм мөстәкыйль булуын яклап чыга[3].

Татар культурасының прогрессив вәкилләренең иҗаты халыклар дуслыгы идеясе белән сугарылган иде. Бу мәсьәләдә алар мәгърифәтчеләр мирасындагы гуманистик традицияләрне дәвам иттерүчеләр булып торалар. Пролетариат идеологиясе тәэсирендә интернационализмның гомум гуманистик нигезе сыйнфый төс ала, халыкларның сыйнфый бердәмлеген пропагандалауга әйләнә. XX йөз башындагы татар иҗтимагый фикере һәм мәдәнияте өчен әлеге традицияләрдәге төп яңалык әнә шунда. Бу эштә, ягъни халыкларның сыйнфый бердәмлеген пропагандалауда демократик татар матбугаты, Г. Коләхметов, Г. Тукай, Г. Ибраһимовларның әсәрләре, революцион публицистика зур роль уйный, В. И. Ленинча итеп әйтсәк, «самодержавиенең каһәр төшкән тарихы»н[4] юкка чыгару эшенә лаеклы өлеш кертә.

Татар халкының прогрессив фикер ияләренең интернационалистик карашлары ныгуда XIX йөздәге алдынгы рус иҗтимагый фикеренең, аның әдәбияты һәм мәдәниятенең тәэсире бик зур. Г. Коләхметов, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һәм башка татар язучылары Белинский, Чернышевскийлар калдырган идея мирасына тирән хөрмәт белән карыйлар. Пушкин белән Гогольдән алып Толстой белән Горькийга кадәрге демократик рус язучыларының гражданлык һәм иҗат позицияләренә югары бәя бирәләр. Прогрессив рус әдәбиятында алар художниклык таланты белән халык алдындагы гражданлык бурычын аңлауның органик төстә бергә кушылуының менә дигән үрнәген күрәләр. Г. Ибраһимов тәнкыйтьче буларак Белинскийның тарихи ролен язучыдан тормышка халыкчанлык позицияләреннән чыгып, күпьяклы, дөрес, тәнкыйтьчел мөнәсәбәт таләп итүдә, халыкның кайгы һәм шатлыкларын үзенеке итүдә күрә. Рус әдәбияты, дип басым ясый татар тәнкыйтьчесе, «халыкка якынлыгы, тик халык өчен яшәве, халык йөрәгеннән туып, аның авыр хәятенә бер нур, бер җиңеллек бирүне үзенә вазифа итеп алган булучылыгы белән... аерылып тора... Рус әдәбияттан үз кайгысына бер җиңеллек котә»[5]. Н. В. Гоголь иҗатын критик реализмның байрагы итеп карап, Ф. Әмирхан татар укучысының игътибарын Гоголь «Рус тормышындагы бик күп гаепләрдән үзенең шәфкатьсез көлүе, рус мәгыйшәте бәдәнендәге яраларны оста җәррах шикелле тәшрих итеп галәмгә күрсәтүе белән рус әдәбиятына бик зур хезмәт иткән шагыйрь»...[6] дигән фикергә юнәлтә.

Иҗатлары һәм тормышлары белән Россиядәге изелгән халыкларның хәлен яклап чыккан мәдәният әһелләре татар демократларының аеруча зур мәхәббәтен казана, яңа Россиянең киләчәген алар аның территориясендә яшәгән барлык халыкларның иркле, тигез хокуклы үсешендә күрәләр. Л. Н. Толстойның самодержавие һәм акча власте тудырган бозыклыкларны рәхимсез төстә фаш итеп чыгуы Г. Тукай каршында аны рус зыялыларының рухи җитәкчесе, намусы дәрәҗәсенә күтәрә. Толстойның үлемен ул берни белән алыштырып булмастай рухи югалту дип кабул итә. Украин халкының бөек шагыйре Т. Шевченконы Г. Ибраһимов тормышы һәм иҗаты халыкка ихлас күңелдән хезмәт итүнең үрнәге булган шагыйрь-гражданин итеп сурәтли. Короленконың тууына 60 ел тулу уңае белән язылган мәкаләсендә аның иҗатына һәм гомумән алдынгы рус әдәбиятына тулаем хас булган характерлы сыйфатларга тукталгач, Ф. Әмирхан: «Бу зат рус милләтенә генә түгел, башкаларга да бертигез хөррият вә гадәләт булуын тели вә шул эшкә хезмәт итә торган хөрриятпәрвәр вә гадәләтпәрвәр мөхәррирләрдәндер»,[7]—дип яза.

Демократик татар язучыларының иҗатына һәм дөньяга карашына бөек замандашлары М. Горькийның уңай йогынтысын басым ясап билгеләп үтәргә кирәк. «Әгәр алдынгы татар әдәбияты турында тулаем сүз алып барсак,— дип яза Г. Халит,— пролетар

---

[1] Хасанов М. Х. Галимджан Ибрагимов. Казань, 1977, 40 б.
[2] Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр, 2 т., 308—309 бб.
[3] «Шура», 1911, 8 сан; 1912, 9 сан.
[4] Ленин В. И. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә, 6 т., 465 б.
[5] «Йолдыз», 1913, 17 март.
[6] Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр. 2 т., 367—368 бб.
[7] Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр. 2 т., 421 б.

язучысының татар әдәбиятындагы критик һәм демократик тенденцияләргә генә түгел, ә бәлки социалистик тенденцияләрнең көчәеп китүенә уңай йогынтысы әйтеп бетергесез зур булды»[1]. Пролетариат әдәбиятына нигез салучының йогынтысы татар әдәбиятында беренче тапкыр булarак үзенең драма әсәрләрендә революция темасын, ул революциядә эшчеләрнең һәм интеллигенциянең ролен «революция хәбәрчесе»нең идея-эстетик позицияләреннән торып сәнгатьчә яктыртырга омтылып караган Г. Коләхметов иҗатында аеруча нык сизелә.

Мондый мисалларны күпләп китерергә булыр иде, әмма китерелгән кадәресе дә үзенең идея-эстетик үсешендә демократик татар әдәбиятының нинди критерийларга һәм ориентирларга таянганын бик ачык күрсәтеп тора. Бу җәһәттән караганда, Җ. Вәлиди сүзләре белән әйтсәк: «халык илә бергә, халык өчен, халык йөрәгендән» сөйләгән[2] Г. Тукай иҗаты бигрәк тә характерлы. Үз халкын ирекле, тигез хокуклы, мәгърифәтле итеп күрергә хыялланып, интернационалист шагыйрь аның киләчәген рус һәм Россиядәге башка халыкларның язмышы, шул киләчәк өчен аларның туганнарча дуслыгы һәм уртак көрәше белән бәйләп карый.

***

Революцион-демократик идеология формалашуның алда телгә алган үзенчәлекләре уңае белән аның конкрет формаларының прогрессив әдәбиятның идея эчтәлегендә ничек чагылуына бәйле кайбер характерлы моментларга тукталып узыйк.

1905 елгы революция, шул революция нәтиҗәсендә яулап алынган кайбер сәяси ирекләр прогрессив даирәләрдә баштарак мәгърифәтчелеккә хас иҗтимагый идеалларның тормышка ашуы рәвешендәрәк кабул ителә. Әле революциягә хәтле үк халыкны мәгърифәтле булырга, әхлакый камиллеккә өндәгән, техник прогрессны яклап чыккан («Себер тимер юлы», «Яшь гомерем» —1903) М. Гафури 1905 елда язган «Шатлык шигыре», «Алмашыну» кебек шигырендә милли үсешкә киң юл ачкан революция нәтиҗәсендә яулап алынган ирекләргә тирән соклануын белдерә. Бөтен кеше прогресс чарасы буларак белемгә омтылган бер чорда Ф. Әмирхан балалар өчен чыга торган «Тәрбиятел-әтфаль» журналында табигый-фәнни темаларга багышланган мәкаләләр бастыра. Шул юл белән табигатьтә барган процесслар, Җир, Кояш һәм күк җисемнәренең төзелеше хакында фәнни белем тарату эшенә үз өлешен кертә. Шул ук вакытта Г. Камал «Беренче театр» пьесасында яшь буынның тыелгысыз төстә яңага омтылуының бүтән аспектын бу очракта сәнгатькә якынаю аша тартылуын сурәтли.

Г. Тукай 1905 ел революциясен хуплап каршылый. «Хөррият хакында» дигән шигырендә ул «китте хәсрәт, әләмнәр», «коллык, тарлык, ким-хурлык» дип өметләнә, барлык кешеләр «том (тулы) азатлык алдыя», ди. Бирегә әле шагыйрь яңарышка бару юлын дөньяви белемнәргә ия булуда, мәгърифәттә, алдынгы Европа һәм рус мәдәниятен үзләштерүдә күрә һәм аларны шул чор җәмгыятенә хас барлык золымнардан котылу чарасы дип саный («Гыйлем бакчасында» шигыре). Бу чордагы публицистикасында да ул шундый ук карашлар уздыра. Әйтик, «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дигән мәкаләсендә шагыйрь җәмгыятьнең һәм аның гражданнарының үсешен күрсәткән төп берәмлек итеп әдәбият, сәнгать һәм матбугатның таралу дәрәҗәсен ала[3].

Әмма шушы мәкаләдә үк инде без революцион-демократик идеологиянең туып килүен раслаган моментларны да очратабыз. Г. Тукай монда прогрессның чын дошманнарына карата халыкның күзен ачкан мәгърифәтнең социаль бурычларына басым ясый: «Тагы да ул кортлар вә ул козгыннарның милләтне ни рәвештә ашаганнарын рәссамнар хезмәте илә милләтнең үзенә күрсәтик, милләтне аларга каршы ачуландырыйк... милләт аларны аяк астына салып изсен, һич дөньяга килмәгән кеби итсен...»[4] Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камаллар иҗатының башлангыч чорында ук мәгърифәтчелекнең революцион бурычларына акцент ясалу җәмгыять һәм шәхес турындагы мәгърифәтчел концепцияләргә яңа идеяләр үтеп керүе хакында сөйли иде. Революцион демократлар иҗатында ул яңа эчтәлек белән байый — идеаль шәхесне билгеләүче өлге булып белем һәм кылган яхшылыкларның коры суммасы гына түгел, шуларны җәмгыятьне яңарту өчен барган көрәштә кулланырга әзер булу да санала башлый.

Революция үсә, сыйнфый көрәш кискенләшә барган саен, патша манифесты игълан иткән ирекләр хакындагы иллюзияләр дә тарала башлый. Алдынгы фикер ияләре полициячел-бюрократик режим, сыйнфый тигезсезлек һәм эксплуатация хөкем сөргәндә шәхес һәм җәмгыятьнең алга таба үсеше өчен мәгърифәт һәм фән генә җитмәвен торган саен ныграк аңлый башлыйлар. Кешене изә һәм кыса торган сәяси атмосфераны Г. Тукай бик ачык тоя. Шуңа күрә дә ул:

«Зобанилар, кылыч, туп, казак, мылтык, палачлар белән һәрьяктан: уң, сул, аст, өстән чолгап алынганбыз»[5] —дип яза.

---

[1] Халит Г. Тукай и его современники. Казань. 1966, 83 б.
[2] «Вакыт», 1913, 26 июль.
[3] Тукай Г. Әсәрләр. 3 т., 11—13 бб.
[4] Тукай Г. Әсәрләр. 1 т. 335 б.
[5] Тукай Г. Әсәрләр. 1 т. 335 б.

Җәмгыятьнең төзелеше социаль-экономик мөнәсәбәтләргә бәйле булуы Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камалларның революция дулкыннары чигенә һәм татар тормышының эчке анохронизмын гына түгел, ә бәлки самодержавие Россиясенең социаль-политик тәрәкләре дә черек булуын күрсәткән кара реакция чоры башлангач язган публицистикасында торган саен эзлеклерәк төстә чагыла башлый. Ф. Әмирханның «Авырулар галәмендә» исемле публицистик мәкаләсе шул хакта сөйләүче бер мисал була ала.

«Нинди контраст! — дип яза әдип.— Бу йортта үлеп яталар, аның күршесендә бик ләззәт белән гомер сөрәләр. Үйлап-үйлап гаҗәпләнә башлыйм: бәгъзе кешеләр шуның икесен бер диләр бит... әгәр сез монда без гомер сөрсен өчен үлеп ятсагыз, җәннәттә сез дә безнең шикелле булырсыз дип юатырга тырышалар бит!»[1]

Социаль идеалның матур әдәбиятта яңа сыйфат алуы татар халкының алдынгы фикер ияләренең критик реализм позицияләренә күчүләрендә һәм буржуаз җәмгыятьнең социаль каршылыкларын тәнкыйть итүләрендә ачык күренә. Татар әдәбиятының ничек итеп мәгърифәтчелек эстетикасының тар кысаларын ватып чыгуы Г. Тукай иҗатында бик ачык күренә. Әгәр 1906 ел башында:

«Бу дөнья, бел, ярлылык дөньясыдыр,»
Вакытлы бер хурлык дөньясыдыр»,[2] —

дип язган шагыйрь җәмгыятьтәге бозыклыкларны төзәтүнең юлын күп төрле белемнәр белән коралланган шәхеснең халыкка хезмәт итүендә күрсә («Шәкерт, яки бер очрашу»), бер елдан соң язган «Тавыш хакында» исемле шигырендә инде җәмгыятьне үзгәртеп коруның революцион программасын күтәрә һәм эшчеләргә:

Эшче туган! тартыш кирәк, кирәк тартыш;
Тартышмасаң, эшчеләргә бик батар теш;
Изге эштер тартышмаклык хокук өчен,
Тартыш, эшче! Тартыш, зинһар, тартыш, тартыш![3] —

дигән чакыру белән мөраҗәгать итә.

Ф. Әмирхан «Татар кызы» хикәясендә бөтен киләчәген һәм мөмкинлекләрен катып калган тирәлек харап иткән шәхеснең гомумиләштерелгән образын бирә. Художник-гуманист анда җан ачысы белән кешене хокуксыз, ирексез итә, «җанлы курчакка әйләндерә торган иҗтимагый шартлар белән бүтәнчә килешү мөмкин түгел, дип яза,— хикәянең социаль пафосы әнә шунда. Шул теманы дәвам итеп, «Яшьләр» пьесасында Ф. Әмирхан Фәхерниса образында «Татар кызы» хикәясендәге героеның реаль прототибын бирә. Ун ел элек шат күңелле тере, кызыксынучан табигатьле булган кызның характерында тирән үзгәрешләр барлыкка килүнең сәбәпләренә тукталып, Газиз болай ди: «Нинди каһәр суккан шомлык аның кешелек сыйфатларын бетергән? Ул шомлык безнең күз алдыбызда, ул — иске татар тормышы»[4].

«Яшьләр»дә Ф. Әмирхан татар әдәбиятында беренче тапкыр барлык демократларны борчыган тема — шәхес иреге, хөр фикерле, иҗади шәхес тәрбияләү кебек мәсьәләләр хакында бөтен тавышка сөйли. Газизне гамәлдәге шартлар яшәп килгәндә иҗади шәхеснең үсүенә мөмкинлек булмау борчый, чөнки чорнап алган тирәлек кешене кысуын һәм изүен, рухи һәм интеллектуаль яктан ярлы, төссез кешеләр тәрбияләвен ул бик яхшы аңлый. «Хөррият шәхсиям миңа бар нәрсәдән дә кадерле,— ди ул.— Мине татар тормышыннан туйдырган нәрсә дә именно шул хөррияте шәхсиянең юклыгы»[5]. Язучы үз геройлары авызыннан «иске татар тормышын» әнә шулай тәнкыйтьли. Әмма язучының гомумән җәмгыятьнең алга барышына комачаулый торган барлык кара көчләрне яклап килгән самодержавие строен да күздә тотканлыгы шул чор укучыларына ачык була. Пьесаның икенче пәрдәсендә автор иске белән яңаның бәрелешен сурәтләүдән конкрет төстә «нәрсә эшләргә?» дигән мәсьәләгә күчкәч, бу — бик ачык чагыла. Ф. Әмирхан әлеге сорауга Базаровларча — «искене вату» дип җавап бирә. Ә искелек дигәндә феодаль-патриархальлек калдыклары гына түгел, ә бәлки гомумән эксплуататорлык җәмгыятенең социаль-экономик нигезләре дә күздә тотылганлыгы икенче пәрдәнең соңгы күренешеннән бик ачык күренә. Шулай бервакыт бәхәс чыккач, пьеса геройларыннан Әхмәт полемик рәвештә 25 ел буе яшәү дәверләрендә җәдит мәдрәсәләре милләтне алга җибәрү эшенә бернинди өлеш кертмәделәр, ди. Моның белән ул иҗтимагый үсешнең

---

[1] Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр. 2 т. 307—308 бб.
[2] Тукай Г. Әсәрләр, 1 т., 267 б.
[3] Шунда ук, 86 б.
[4] Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр, 2 т., 20 б.
[5] Шунда ук, 34 б.

буржуаз мәгърифәтчелек программасын шик астына ала. Ул үзе нәрсә тәкъдим итә соң? «Юк, брат,— ди Әхмәт,— әгәр сез, татарны чынлап алга җибәрәсегез килсә, фәкыйрь халыкка: крестьян, рабочийга сознание кертергә тырышыгыз. Фәлән байның һиммәте, фәлән байчураның шәфкате дип кәгазь буяганчы, шул фәләннәрнең ничек итеп кеше эшләгәнне ашаганлыкларын, шулар эше аркасында баеганлыкларын языгыз».[1] Бирегә яшәп килгән җәмгыятьнең эксплуататорлык асылына кагылмаганга күрә буржуаз иҗтимагый идеалның чикләнгән булуы турыдан-туры тәнкыйть ителә.

Гомумән, «Фәтхулла хәзрәт» повесте кебек үк, «Яшьләр» драмасы да — революцион-демократлар иҗатында феодаль-буржуаз җәмгыятьне социаль, этик һәм эстетик нокталардан карап һәр яктан тәнкыйть итүдән ничек итеп, томанлырак төстә булса да, шәхеснең һәм җәмгыятьнең социалистик принципларга йөз тоткан сыйфат ягыннан өр-яңа идеалга үсеп җитүе хакында сөйли торган бер мисал була ала. Бу революцион-демократларның җәмгыять һәм шәхес турындагы карашлар эволюциясендә иҗтимагый даирәне һәм шул даирә формалаштырган шәхесне системалы һәм эзлекле төстә тәнкыйть итүдән килеп чыга торган мөһим этап булып тора.

Үзләре яшәгән тормышны һәрьяклап тәнкыйть итү процессында демократик фикер ияләренең җәмгыять һәм шәхес турындагы эстетик идеаллары да формалаша. Ф. Әмирхан иҗатыннан ачык күренгәнчә, буржуаз җәмгыятьне тәнкыйтьләү процессында әлеге идеалның үсентеләре үзләренә юлны торган саен ныграк сала баралар. Гомерен халыкны социаль һәм милли изелүдән азат итү өчен көрәшкә багышлаган шәхес идеалын Г. Тукайның гражданлык лирикасында ачык төсмерләргә мөмкин («Татар яшьләре», «Хөрмәтле Хөсәен ядкәре», «Аң» һ. б.) Үзенең «Акчарлаклар» повестенда Ш. Камал буржуаз җәмгыятьнең рәхимсезлегенә һәм кырыслыгына хезмәт кешеләренең әхлакый сафлыгын, рухи көрлеген һәм оптимизмын каршы куя. Әсәрнең Шәрәфи, Гариф, Газизә кебек геройларындагы әлеге сыйфатларны даими мохтаҗлык, авыр хезмәт тә бетерә алмый: киресенчә, алардагы иптәшлек, ярдәмчеллек, коллективизм кебек хисләрне тагын да көчәйтә төшә. Үзенең повесте белән Ш. Камал гүя ки бәхетле һәм гадел тормышка нәкъ менә шушы кешеләр лаеклы, киләчәк тә алар кулында булырга тиеш, дип әйтергә тели.

Буржуаз чынбарлыкны тәнкыйтьләү һәм аңа үз эстетик идеалыңны каршы кую татар әдәбиятының романтик агымында да дәвам иттерелә. Бу яктан Г. Ибраһимов иҗаты бай материал бирә. Художник Г. Ибраһимов өчен шәхес белән, аның рухи азатлыгына бәйле мәсьәләләр белән тирәнтен кызыксыну, кешедәге потенциаль иҗат көчләрен барлау бик тә характерлы. Иҗатының башлангыч чорында ул тирә-юньдәге социаль чынбарлыкта үзенең эстетик идеалына җирлек күрми, шуңа күрә аны мәхәббәт, сәнгать, табигать дөньясыннан эзли. Геройны «гөнаһлы чынбарлыктан» аерып алып, язучы тирә-юньнең күңел кайтаргыч социаль һәм рухи шартлары тарафыннан җәберләнмәгән шәхеснең матурлыгын күрсәтә («Сөю-сәгадәт», «Табигать балалары», «Яз башы» хикәяләре, «Яшь йөрәкләр» романы). Әдипнең кеше хисләре, сәнгать һәм табигать даирәсендәге гүзәллекнең асылы белән аеруча нык кызыксынуы аның дөньяны аңлавындагы үзенчәлек белән генә аңлатып булмый. Монда объектив сәбәпләр: татар җәмгыятенең культура ягыннан артталыгы, бу җәмгыятьнең алдынгы катлауларында кешелек җәмгыяте ирешкән рухи-эстетик казанышлардан, җир тормышының рәхәтлекләреннән баш тартырга өндәгән ортодоксаль дини моральгә каршы реакциянең үсә-көчәя төшүе үзен нык сиздерә. Мондый шартларда Г. Ибраһимовка шәхеснең нинди булырга тиешлеген, аңарда нинди зур рухи көчләр яшеренгәнен күрсәтү мөһим була. Хыялны чынбарлыкка, шәхеснең эстетик идеалын тирәлеккә каршы куюның романтик характеры ахыр чиктә хакимлек иткән социаль һәм идеологик мөнәсәбәтләрне, әйтик, Г. Тукай яки Ш. Камал әсәрләрендәге кырыс реализмга караганда һич тә көчсезрәк яки сүлпәнрәк кире какмый иде. Хәер, хыял белән чынбарлыкның туры килмәве революцион лагерьдагы башка художниклар иҗатында да лирик геройны романтик төстә даирәгә каршы куюны китереп чыгарды. Моның ачык мисалы — С. Рәмиев поэзиясе. Беренче рус революциясе җиңелеп, реакция чоры башлангач, шагыйрь романтик идеалларының тормышка ашачагына өмет өзә, нәтиҗәдә ул бөтен дөньяга каршы куелган бунтарь шәхеснең образын тудыра:

Мин! дидем мин, «мин» дидисәм,
Миңа бер зур көч кирә,
Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә[2].

М. Гафури иҗатында социаль чынбарлыкны инкарь итү, Г. Ибраһимов әсәрләрендәге кебек үк, кешенең эчке хисләре һәм табигать күренешләре белән мавыгуда чынбар-

---

[1] Шунда ук, 51 б.

[2] Рәмиев С. Таң вакыты. Казан, 1980, 28 б.

лыктагы чын гүзәллек һәм байлыкның төп чыганагы һәм өлгесе булып саналган кешене табигатьнең бер өлеше дип карауда чагыла. Бу — «Хәмитнең хәяте» повестенда һәм «Мәхәббәт хатлары» хикәясендә, әдипнең лирик шигырьләрендә бик тә ачык күренә. Социаль дисгармониягә табигатьтәге гармонияне, шулай ук кешенең табигый, реаль хисләрен каршы куеп, язучы аларны яшәешнең хәлиткеч принциплары, кешенең яшәеше өчен өлге дәрәҗәсенә күтәрә. «Саф калеб, гыйффәт вә тугърылык сыйфатлары юлбашчысы булган мөддәтә,— ди «Мәхәббәт хатлары» хикәясенең герое Нәҗи,— инсаннарның рәхәт вә сәгадәткә ирешүләрендә шөбһә юк икәненә ышандым. Фәкать шул сыйфатларны сәгадәткә ирешү юлында иң зур корал итеп истигъмаль кыйлырга гына кирәк»[1].

Кеше гомеренең мәгънәсе һәм гүзәллеге хакында фәлсәфи эзләнүләрендә революцион-демократларның күбесе теге яки бу дәрәҗәдә антропологизм принципларына таянып эш итәләр. Дөньяга караш ноктасыннан карaганда, мондый эзләнүләрне алдынгы иҗтимагый фикернең идеализмнан материализмга күчә баруы, аның алдынгы вәкилләренең тормыш процессларын билгеләүче законнарның җирдәге нигезләренә ориентация тота башлаулары, дип карарга мөмкин.

Гамәлдәге чынбарлыкка каршы «шигъри бунт»ны алдынгы фикер ияләре үзләренең идеалларын иске җәмгыятькә каршы куйган, әмма иҗатларында әле аны чынбарлык, яңа җәмгыять төзү өчен көрәшүчеләр — революционерлар белән ныклап бәйләргә өлгермәгән бер чорда шәхес мәсьәләсен фәлсәфи-эстетик аңлауда күчеш этабы дип карарга туры килә. Эстетик идеалның чынбарлык белән, революционерларның социалистик җәмгыять төзү өчен көрәше белән кушылуы Г. Ибраһимов иҗаты мисалында бик ачык күренә.

Илдә революцион күтәрелеш, социалистик идеяләрнең татар халкының революцион фикер ияләренә тәэсире көчәя барган саен, Г. Ибраһимовның идея-эстетик позицияләре дә ныгый бара. Эстетик идеал эзләү буларак, тормышны образлы чагылдыруның сәнгатьчә принципларына турылыклы калган хәлдә, идеаль шәхес төшенчәсен яңа эчтәлек белән баетып, Г. Ибраһимов гүзәллек төшенчәсенең даирәсен киңәйтә төшә. «Мәрхүмнең дәфтәреннән» исемле хикәядә герой үз исеменнән күпме явызлык эшләнгән һәм кан коелган диннән дә, халыкларны бер-берләреннән аера һәм дошманлаштыра торган милләтчелектән дә, тук мещаннар һәм эшлексез аристократлар зәвыгын канәгатьләндерүче буржуаз культурадан да өмет өзә. Шәхеснең эстетик идеалының иң камиль үрнәген без Г. Ибраһимовның революциягә кадәрге әсәрләреннән «Безнең көннәр» романында очратабыз. Халыкка хезмәт итү идеалы биредә үзенең иң югары формасында — революционерларның самодержавиегә һәм изүгә каршы көрәшен поэзияләштерүдә гәүдәләнә. Халык бәхете өчен көрәшү, хәтта үлү — тормышның иң зур мәгънәсе һәм аның матурлыгының иң бөек чагылышы шунда, ди автор бу романы белән. Шулай итеп, әгәр беренче чор әсәрләрендә Г. Ибраһимов үзенең геройларын томанга күмелгән романтик биеклеккә алып китсә, хәзер инде ул геройларын реаль социаль җирлеккә төшерә, чынбарлыктан читләшкән геройны түгел, ә җирдә үз урынын тапкан көрәшче геройны поэзияләштерә.

Шул рәвешчә, XX йөз башында алдынгы татар әдәбияты үзенең идея-эстетик яктан үсешендә төп закончалыклары һәм милли гәүдәләнеш үзенчәлекләре белән, мәсьәләләр даирәсе, аларны чишү юллары белән бергә, революцион-демократик идеология формалашуның төп мөһим этапларын чагылдыра. Үз чорының революцион-азатлык идеяләрен сәнгатьчә сурәтләп, ул шактый зур дәрәҗәдә халыкның милли һәм сыйнфый аңы үсүгә булышты. Бу яктан караганда, татар әдәбияты, көндәлек матбугат кебек үк, Россиядәге башка төрки халыкларның демократик культурасын формалаштыруда мөһим роль уйнады. Казахстан, Кыргызстан, Урта Азия, Кавказ һәм Башкортстанның күп язучылары, галимнәре, җәмәгать эшлеклеләре бу хакта бик теләп сөйли һәм язалар. Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәттә, татар әдәбиятының әлеге интернационалистик миссиясен Ленин премиясе лауреаты Ч. Айтматов бик матур итеп әйтеп бирде. «Төрки телле барлык халыклар,— диде ул,— әлеге көнгә хәтле Г. Тукай иҗатына изге бер хис, тирән хөрмәт белән карыйлар... Чөнки безнең халыклар рус культурасын һәм рус халкының тәҗрибәсен тиешле дәрәҗәдә үзләштереп өлгермәгән бер чорда Тукай Европа һәм русның революцион сәнгатьчә фикерен безгә җиткерүче булды»[2]. Эпоханың революцион идеяләренә һәм алга киткән әдәбиятларның сәнгатьчә-эстетик казанышларына таянып үскән демократик татар әдәбияты кыска гына бер тарихи чорда халыкның рухи тормышының мөһим факторына, аның милли азатлыкка һәм социаль прогресска омтылышында ышанычлы таянычына әйләнә.

---

[1] Гафури М. Әсәрләр 4 томда. II т. Казан, 1983, 244 б.

[2] Габдулла Тукай. Сборник статей. Казань, 1979, 220 б.

# ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕАТР

Алма-Ата татар яшьләре Октябрь революциясенә кадәр үк, һәвәскәрләр труппасы төзеп, спектакль куялар. Бу турыда матбугатта азмы-күпме язылды да инде[1]. Бу мәкаләләрдә Кустанай, Казалы һәвәскәрләр труппалары турында да әйтелә. Без исә бөек шагыйребез Габдулла Тукай исемендәге труппа турында әйтеп китмәкче булабыз. Билгеле булганча, әлеге коллективлар репертуарында зур полотнолы пьесалар да урын ала. Труппаларның составы шактый зур булу моңа мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Алма-Ата труппасы 1914 елда Г. Камалның «Банкрот»ын сәхнәләштерә. Афишада спектакльдән килгән саф файда Верный шәһәрендә мөселман китапханәсе һәм уку залы файдасына бирелә, диелә.

Һәвәскәрләр труппасының 1918 ел, 16 сентябрьдә чыккан афишасында: «Тукай музыка вә драм җәмгыяте тарафыннан татарча театр бирелә»,— дип языла. Ягъни Алма-Атада бу вакытта Тукай исемендәге җәмгыять оешкан була.

Биредә, Г. Камал әсәрләреннән тыш, Г. Гумирскийның «Сугышта», М. Фәйзинең «Яшьләр алдатмыйлар» исемле әсәрләре куела. Бу җәмгыять, даими рәвештә әдәби кичәләр оештырып, татар, казах яшьләре арасында аң-белем тарата. «Тукай музыка вә драм җәмгыяте» гражданнар сугышы елларында да эшен дәвам иттерә. Егерменче еллар башында ул «Алма-Ата музыка вә драм труппасы» исемен йөртә башлый, ягъни Тукай исемендә профессиональ труппага әверелә. Труппа татар әдәбияты классигы Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасын 1924 елның 12 июлендә кабатлап куя. Шул ук коллектив СТС клубында[2] (афишада елы күрсәтелмәгән) М. Фәйзинең «Асыльяр» драмасын күрсәтә.

1924 елны Тукай театры артист һәм режиссер Хан Исмәгыйлевнең сәхнә эшчәнлегенә ун ел тулуны билгеләп үтә. «Кабил-Һабил» трагедиясе куелып, анда Кабил ролен остаз үзе башкара. Афишага мондый сүзләр языла: «Төркстанның караңгы почмагы булган җиде суда 10 елдан бирле сәхнәне дәвам иттереп килгән Хан иптәшнең ун еллык хезмәтен Алма-Ата халкы тәкъдир итәр дип труппа ышана». Һәм чыннан да, татар һәм казах яшьләре аны тәкъдир итәләр. Юбилей тантаналы үтә, зур бәйрәм төсен ала. Шуны әйтеп үтик, бездә «Кабил-Һабил» исемле пьеса юк. Бәлки Һади Такташның «Җир уллары» трагедиясе куелгандыр?

Билгеле булганча, 1926 елны татар театрының тууына егерме ел тулу уңае белән Казан, Уфа, Оренбург, Мәскәү, Ленинград, Әстерхан, Троицк һ. б. шәһәрләрдә тантаналы кичәләр уздырыла. Шулай ук Алма-Ата труппасы да әлеге бәйрәмне билгеләп үтә. Хан Исмәгыйлев Г. Камалның «Беренче театр»ы белән М. Фәйзинең «Авыл бәйрәме»н куя. Афишада: «Россиядә татар сәхнәсенең башланып дәвам итүенә 20 ел тулу мөнәсәбәте белән Алма-Атадагы карт һәм яшь театр һәвәскәрләре иштираке белән тантаналы бәйрәм кичәсе ясала»,— диелә. Шулай итеп Алма-Ата татар театры эшен дәвам иттерә.[3] Труппаның составы да зурая. Коллектив классик әсәрләргә киңрәк мөрәҗәгать итә башлый. Ә 1927 елның 26 маенда Фәтхи Бурнашның «Камали карт»ы куела. Камали карт ролен бу вакытта биредә эшләгән Хәсәен Уразиков башкара. Һәм ул режиссерлык та итә. Труппаның репертуары аның заман сулышы белән яшәвен күрсәтә. Моңа мисал итеп 1932 елның 13 мартында Мәмләкәт театры бинасында татар труппасы тарафыннан, Алма-Ата сәхнәсендә беренче мәртәбә, Ш. Камалның «Ут» драмасы куелуын күрсәтергә була.

---

[1] Гобәйдуллин Х. Провинциаль труппалар. — «Совет әдәбияты», 1964, 8 сан; «Татар театрлары Казахстанда», — «Җолдыз», 1964, 12 сан.
[2] СТС — сәүдә хезмәткәрләре клубы.
[3] Мартынов Г. Первая театральная труппа в Верном. — «Алма-Атинская правда», 1961, 26 июнь.




Тукай исемендәге театр афишаларыннан фотокүчермә.

Театрның баш режиссеры Хан Исмәгыйлев, 1931-1932 еллар сезонын үткәргәч, Казанга чакырыла. Ул 1933 елдан 1956 елга кадәр Татар дәүләт күчмә театрында эшли. Төрле пландагы сәхнә образлары иҗат итә.

Без Алма-Ата татар театрының барлык репертуарына тукталуны максат итеп куймадык. Тик татар һәм казах яшьләренең бөек Тукайга булган тирән мәхәббәтләрен әйтеп китәргә булдык.

Эльмира ГОБӘЙДУЛЛИНА.



**Х. К. Хәйретдинов,**
КПССның Зеленодольск шәһәр комитеты беренче секретаре

# ГӨЛБАКЧАДА ЯШИБЕЗ

Безнең Зеленодольск районы өч орденлы Совет Татарстанында үзенең лаеклы урынын алып тора. Аның географиясе, табигать шартлары, тарихы һәм бүгенгесе башкалардан шактый аермалы. Шулай да без, үзгә сыйфатларга тукталганчы, районнарыбызны гына түгел, ә барлык совет кешеләрен берләштергән уртак якларны барлап чыгыйк.

Зеленодольскилылар, Совет Татарстанының барлык хезмәт ияләре кебек үк, үзләренең бөтен осталыкларын КПССның XXVI съезды һәм аннан соңгы Пленумнары карарларын тормышка ашыруга юнәлтәләр. Безнең район кешеләренә партия чакыруларын, Ленин идеяләрен, коммунизм идеалларын олылау, шулар хакына фидакарьләрчә тырышып хезмәт итү хас. Бу сыйфатлар хуҗалыкның төрле тармакларындагы эштә дә, культура төзелешендә дә ачык чагыла.

Инде әлеге сүзләрне раслардай кайбер мисалларга да тукталыйк. Шәһәребездәге һәм районлардагы завод-фабрикалар ике йөз илле төрле әйбер ясый: өй җиһазлары, савыт-саба, балалар киеме, тире әйберләр, шпаллар, фанер, тимер-бетон һәм пычкы чүбеннән коелган плитәләр... Промышленностебез эшләп чыгара торган продукциянең сыйфаты елдан-ел яхшыра бара, төрләре дә ишәя. Аларны илнең төрле якларында, кайбер чит илләрдә дә көтеп алалар.

Татарстан күләмендә җәелдерелгән социалистик ярышның 1984 елгы нәтиҗәләре өчен безгә КПСС өлкә комитетының, Татарстан Министрлар Советының, Профсоюзлар өлкә Советының һәм ВЛКСМ өлкә комитетының Күчмә Кызыл Байрагы тапшырылды. Районны җиңүчеләр сафында алып баруда мебель фабрикасы, 33-мостопоезд, ипи салу комбинаты, пассажир автотранспорт оешмасы уңганнарының роле зур. Партия тарафыннан һәр коллектив алдына куелган, хезмәт җитештерүчәнлеген бер процентка күтәрү, ясала торган әйберләрнең үзкыйммәтен ярты процентка киметү турындагы мәгълүм бурычны тормышка ашыруда «Хезмәтнең җиңүе» заводы, азык-төлек комбинаты, 5 тимер-бетон әйберләре ясау заводы, урман хуҗалыгы алда бара. Бу максатка ирешүдә Бөек Җиңүнең 40 еллыгына, стахановчылык хәрәкәтенең 50 еллыгына багышлап оештырылган социалистик ярышлар нык ярдәм иттеләр. Ярышның алгы сафында баручылардан коммунист, СССР Дәүләт премиясе лауреаты, җайланмалар төзәтүче Е. В. Железняков белән коммунистик хезмәт ударнигы коллективы бригадиры Р. Х. Гыйрфановны, иң югары сыйфат күрсәткеченә ия булган токарь И. В. Скворцов һәм А. Е. Кашин җитәкчелегендәге 20 нче төзү-монтаж идарәсенең балта осталары бригадасын санарга мөмкин.

Хезмәт фронтында җиңеп килүче биш мең эшче, төзүче һәм юлчылар үзләренә алмашка шундый ук уңган дүрт мең яшүсмерне дә тәрбияли. Шәһәребезнең комсомоллары Бөтендөнья яшьләренең һәм студентларының XII фестивале алдыннан аеруча тырышып эшләделәр. Өмәләрдә тупланган хезмәт хакларыннан 15 мең сумны фестиваль фондына күчердек. Бөек Ватан сугышы елларында безнең яшьләр «Зеленодольск комсомолы» исемле самолет ясар өчен акча биргән. Бу экипаж фронтта зур батырлыклар күрсәткән. Быел яшьләребез шул самолет экипажы исемен алу өчен социалистик ярыш оештырды һәм хезмәттә моңарчы күренмәгән нәтиҗәләр бирде.

Казан шәһәре янындагы зонага кергәнлектән безнең районга авыл хуҗалыгын аеруча нык камилләштерү, үстерү бурычы да төшә. Сиксән меңләп гектар җиргә ия булган унбер колхозыбыз, ун совхозыбыз, ит, сөт, яшелчә һәм бәрәңге җитештерү буенча специальләшә. «Май», «Мичурин», «Уразлы», «Яшелчәче» кебек совхозларыбыз Татарстанда өлгертелә торган барлык яшелчәләрнең егерме биш процентын бирә. Тоташтан промышленность ысулларына нигезләнгән бройлер фабрикабыз бар. Кырчылыкта аеруча зур уңышларга ирешкән хуҗалыклардан Ленин исемендәге һәм Ильич исемендәге колхозларны күрсәтәсе килә. Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре илнең Азык-төлек программасын уңышлы үтәүдә көчләрен кызганмыйлар. Районда гына түгел, республика күләмендә үрнәк итеп күрсәтерлек Н. К. Романов, И. Б. Рәхмәтуллин, Р. А. Мингалиев кебек механизаторларыбыз; И. Г. Зәбихуллин, Н. Г. Тимершин, А. Н. Смирнов кебек кукурузчыларыбыз; И. Г. Чупакова, Н. И. Клопов, И. И. Тимершин кебек чөгендер үстерү осталарыбыз; сыерлардан мөмкин кадәр күбрәк сөт алырга тырышучы З. И. Заһриева, В. П. Егорова, К. А. Савина, Ф. И. Михайлова, К. И. Маскалина, В. П. Филиппова, А. М. Емельянова кебек савымчыларыбыз бар.

Авыл хуҗалыгының алга таба үсеше шәһәр белән авыл арасындагы дуслык мөнәсәбәтләренә дә бик нык бәйләнгән. Соңгы елларда Осиново, Бишнә, Айшә авылларында; «Искра», Горький исемендәге колхозларда, Ключинский совхозында киң колач алган төзелешләрне шәһәрдәге оешмалардан башка күз алдына китерүе дә авыр булыр иде. Терлек азыгы әзерләгәндә дә, урак өстендә дә, көзен бәрәңге-чөгендер җыйганда да колхоз-совхозларга шәһәр эшчеләре ярдәм кулы суза. Алар белә: авылларның киң басуларында күп көч түгеп өлгертелгән ашлыкны югалтусыз җыеп алу яки терлек-туарны мул азык белән асрау илнең һәр кешесенә тәмле ризык булып кайтачак.

Шәһәр белән ике арадагы дуслык элемтәләренең ныгуы авыллардагы культура үсешенә дә уңай йогынты ясый. Партиянең Зеленодольск шәһәр комитеты район хезмәт ияләрен яңадан-яңа уңышларга әйдәп тора. Райондагы тугыз меңгә якын коммунист аның ышанычлы таянычыннан санала. Партия членнарының 78 проценты материаль байлык җитештерү тармагында эшли. Башлангыч оешмалар хезмәткә иҗади караш булдыруны,яшь буынны коммунизм идеяләре рухында тәрбияләүне алга сөрә. Мондый чараларда районның данлы үткәненнән, аның тарихы битләреннән файдаланырга бик зур мөмкинлекләр бар. Революция давыллары, гражданнар сугышының шаулы еллары, данлы бишьеллыклар, стахановчылык хәрәкәтенең күңелләрне җилкендергеч нәтиҗәләре, Бөек Ватан сугышында райондашлар күрсәткән каһарманлыклар, сугыштан соңгы чорда хезмәттәге җиңүләр — болар һәммәсе тәрбия эшендә алыштыргысыз үрнәкләр.

Безнең кешеләр район тарихында бөек В. И. Ленинның да турыдан-туры катнашкан булуы белән аеруча горурланалар. 1918 елның 15 августында Халык Комиссарлары Советының В. И. Ленин председательлек иткән утырышында Парат затоны янында бараклар салырга һәм яңа шәһәр кору буенча тикшеренүләр башлап җибәрү өчен 2 миллион 30 мең сум акча бүләргә махсус карар кабул ителә. Бераздан яңа шәһәрдә промышленность предприятиеләре торгызу өчен да акча җибәрелә. В. И. Ленин шуңа охшаш чаралар турындагы тагын берничә карарга кул куйган.

Башта Яшел Алан (Зеленый Дол) дип аталган бу яңа поселок 1932 елның 10 мартында Зеленодольск шәһәре итеп үзгәртелә.

Партиянең шәһәр комитеты, Халык депутатларының шәһәр һәм район Советлары Зеленодольск кешеләренә яшәү рәхәт, кызыклы, уңайлы булсын өчен барлык мөмкинлекләрне эшкә җигәләр. Хезмәттән тәм табып яшәүче халкыбызның хезмәтенә күрә хөрмәтен дә татытабыз. Өй туйларын ел саен ешрак үткәрәләр бездә. Үткән ел, мәсәлән, 70 мең квадрат метр торак салынды. Моңарчы бу кадәр үк тизе алмый идек.

Күпләргә мәгълүм: Зеленодольск турында сүз чыкса, иң элек аның яшеллеген, гөлбакча эчендә утыруын телгә алалар. Бу бер дә юкка гына түгел. Безнең шәһәр гаҗәеп матур урынга салынган. Аны өч яклап урманнар уратып алган. Анда гасырлар буе үскән имәннәр дә, төз наратлар да, нәфис каусәле ак каеннар да, бөдрә юкәләр дә бар. Шәһәр дүртенче яктан Иделгә барып чыга. Районда Идел-Кама дәүләт заповеднигы булуы үзе үк табигый шартларыбызның бик үзенчәлекле, кадерле икәнлегенә ишарәлидер. Безнең заповедник бердәнбер. Аның Раиф урман киңлеге искиткеч бай һәм фәнни тикшеренү-

лэр өчен гаҗәп кыйммәтле. Дендрология бакчасында агач һәм куакларның биш йөздән артык төре үсә.

Районыбызның тагын бер хикмәте бар. Ул автономияле өч милли республика чигендә утыра: Татарстан, Чувашия һәм Мари АССР. Идел буендагы бу дус республикаларны бер-берсе белән бик күп төрле элемтәләр бәйли. Аерым предприятиеләрнең үзара эшлекле мөнәсәбәтләре дисеңме, хуҗалыкларның тәҗрибә уртаклашуларымы, культура тормышындагы аралашуларны аласыңмы — барысы да туганнарча дус, тату яшәүнең матур үрнәгеннән раслаучы дәлилләр. Районның үзендә дә төрле милләт халкының вәкилләре яши. Максатлары, омтылышлары, кылган гамәлләре уртак булгач, аларның милли төрлелеге, бал өстенә май килешә дигәндәй, чынбарлыкка бер күркәмлек өсти.

Шуны да әйтергә кирәк: районыбыз халкы бүгенгедәй рәхәт тормыш өчен көрәшкән батырлары турындагы истәлекләрне кадерләп саклый белә. Шәһәрдә 1905 елдан КПСС члены А. Семенов, 1903 елдан КПСС члены И. И. Гаврилов, 1916 елдан КПСС члены И. Я. Гладилов кебек революционерларның яшәгән булуы безне чиксез горурландыра. Революция дошманнары кулыннан һәлак булган кыю чекистларга Раифта һәйкәл бар. Аңа безнең район кешеләре генә түгел, республиканың күп якларыннан килеп йөриләр.

Бездә сәяхәтчеләр игътибарын җәлеп итәрлек урыннар шактый күп. Борынгы Зөя шәһәре дә истәлекләргә бай. Аның читтә калган утравындагы Успенский монастыре матур һәм катлаулы архитектурасы белән күпләрне сокландыра. Бу монастырьны салучылар арасында Мәскәүдәге Василий Блаженный храмын төзегән осталарның берсе Постник Яковлев та булган.

Безнең якларда Татарстанның күренекле галимнәре, язучылар, сәнгатебезнең талантлы осталары да үсеп чыккан. Кече Ширдан авылы халкыбызның күпкырлы әдибе, мәгърифәтче һәм галим Каюм Насыйриның туган җире буларак билгеле. Хезерге чор галимнәреннән — М. Т. Нужин, Г. Ф. Саттаров, Җ. И. Гыйлманов, Г. М. Дюрягин, Н. Г. Ханзафаровны; язучылардан — Идрис Туктар, Афзал Шамов, Мәхмүт Хәсәновны; сәнгать әһелләреннән рәссамнар Ф. Әминов, К. Васильев, артистлар У. Әлмиев, И. Гыйззәтуллин, В. Бортяков, режиссер Г. Хөсәеновны күрсәтергә мөмкин. Талантлы яшьләр тагын да күбрәк. Алар хәзергә колхозларда, завод-фабрикаларда эшлиләр, ял вакытларында, һәвәскәрләрнең төрле түгәрәкләренә йөреп, җырга, биюгә, уен коралларында уйнарга, нәфис сүзгә өйрәнәләр. Араларыннан профессиональ сәнгать эшлеклеләре чыгуына без нык ышанабыз, чөнки югарыда саналган артистларның да күбесе сәхнә юлын үзешчәннәр коллективыннан башлап җибәргән. Бүгенге яшьләргә бик матур үрнәк бу.

Өлкәннәрдән кабул итеп алырлык күркәм сыйфатлар шактый күп. Якташларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән тиңсез батырлыгы үзе генә дә гасырдан-гасырга моңлы җыр итеп көйләрлек. Зеленодольскиның мемориаль паркында мәһабәт һәйкәл бар. Ул яу кырында ятып калган унтугыз меңнән артык каһарман якташларыбызга багышлап куелган. Советлар Союзы Геройлары Х. Х. Хәсәнов, Н. А. Катин, В. А. Петров, Н. Д. Волостнов, В. Х. Хаҗиев, Г. Г. Морзаханов, И. М. Засорин, И. А. Норкин, Х. З. Хәйруллин — районыбызның ил алдындагы йөз аклыгы.

Үткәндә ирешелгәннәр безгә алда торган зур-зур бурычларны үтәп чыгарга бер этәргеч булып та санала. Артка чигергә, өлкәннәрдән мирас итеп алынган матур гадәтләргә хилафлык китерергә хакыбыз юк безнең. Тагын да тырыша төшәргә, уңышларның тагын да зуррагын яуларга кирәк. Иң олы максат — хезмәт җитештерүчәнлеген күтәреп, экономиканы ныгыту. Хезмәт коллективлары үз эшләрен, нигездә, шул юнәлештән алып баралар. Соңгы вакытта һәр кешенең җаваплылык тоеп, иҗади эшләвенә ирешү өчен, нык-лы тәртип өчен көрәш бара. КПССның XXVII съездын лаеклы каршылау өчен хуҗалыкның һәр тармагында социалистик ярыш башланды. Без, алар гөлбакчада яшиләр, дигән сүзләрнең бервакытта да чынбарлыктан аерылмавын телибез.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

Барлас Камалов

# ТӨП ҺӨНӘРЛӘРЕ — ӨЙРӘНҮ

ОЧЕРК

Китәләр. Китәләр. Китәләр... Хәмитнең чигә тамырлары шулай дип тибә идеме икән, һәрхәлдә, шушы сүзләр кабатлануын тойган хәлдә уянып китте. Бүлмәдәше тәмләп йоклый иде әле. Вакыт бик иртә, апрель таңы атып кына килә... Күпләп булмаса да, ник китәләр? Ни батса да, суда дулкын калка, агач ауса, шавы чыга дигәндәй, берәүнең генә китүе дә бүтәннәргә тискәре йогынты ясый.

Татарстан атом электр станциясен коруда республика удар комсомол төзелешенең штаб начальнигы Хәмит Мөстәкыймов үз алдына куйган сорауга җавап эзләде.

Ник дип, күңелләре утырмаганга күрә китәләр. Күңелләре ник утырмыймы? Шартлар җитми. Торакның рәте-чираты юк. Кемнәрдер көн саен Түбән Камага (илле километр!), Брежнев каласына (йөз!), Зәйгә (җитмеш чамасы!) кайтып йөрергә мәҗбүр, кемнәрдер — әле яңа урынга күченә генә башлаган Кама Аланындагы йортларда өйдәшлектә.

Туклану да кирәгенчә җайга салынмаган. Мае бетсә, машина да йөрми, төзүченең табыны аерата мул булырга тиеш. Акча төшүе дә чөеп мактарлык та, салып таптарлык та түгел. Ялның оештырылуы да ташка үлчимрәк. Кама Аланы авылындагы борынгыдан калган чиркәүдәге клубта ни генә майтарасың?! «Авыл клубы» дигән язуны «Татарстан атом электр станциясен төзүчеләрнең Культура сарае» дип алыштырудан нәрсә генә үзгәрде соң әле?

Ху-у-уш! Һәммәсе дөрес, һәммәсе шулай да булсын, ди. Ә соң ил яшьлеге монда, Кама Аланына, шыңшырга, сыкрап-сыктарга җыелдымыни? «Килдем. Күрдем. Җиңә алмадым» дип табан ялтыратыр өченме? Юк бит, алай түгел! Төзергә дип килдек без бирегә. Авырлыкларны җиңәргә дип! Безгә кадәр буыннар күрмәгәнме зәһәр җилләрдә каклануны, тау-тау актарып ыргытылган балчыкка бата-чума йөрүләрне?! Яктылык эзле-эзле күзләренә ак төшсә дә, максатка омтылуларыннан бизмәгән ич алар. Ерак барасы да түгел, КамАЗны һәм Яңа шәһәрне салучылар үрнәгенең кайнар сулышы бәреп тора лабаса!

Тормыш итү сабакларын алырга килдек бит без бу төзелешкә. Бәлки күп һөнәребез алышыныр, шәхси дөньяларыбыз бозылыр да көйләнер, ә төп һөнәребез булып ө й р ә н ү калырга тиеш. Яшәргә өйрәнү, эшләргә өйрәнү, укырга, ял итәргә өйрәнү, сөяргә өйрәнү, иң мөһиме — Кеше булырга өйрәнү. Шул юлда каршылыкларны җиңәргә тау-таш күкрәген ярып чыккан чишмәләрдән өйрәнергә кирәк безгә.

Хәмит Салихович (төзелешнең иң яшь комсомоллары кайчак аңа шулай да эндәшәләр) кичә генә яшь бер инженер белән гәпләшүен искә төшерде. Табигатьнең дә чырай сыткан чагы, тегенең дә. Аяк асты лычкылдап тора, тегенең кәефе дә лычкылдык. «Китәм!» — ди. Әйтте Мөстәкыймов: «Инде дә үҗәтләнәсең икән, дүрт ягың кыйбла. Тик «китәм» чирен башкаларга гына йоктырып йөрмә!» — диде. Гел акланып, гел сакланып вәгазь укырга калсаң, вакланып китүең дә бар бит. Комсомол вожагына килешми бу тиклесе. Ярамый!

Бер үк телдә сөйләшкәндә дә, хыялыннан, вөҗданыннан качып китүче телен аңлап булмый. Дипломлы белгеч, белеме югары, ләкин тормыш сабагыннан дипломы юк икән әле егетнең.

Шул кадәресе дә мәгълүм: төзелештә тормыш имтиханын шпаргалка белән тапшырып булмый! Эшлим дисәң, чын төзүче булыйм дисәң, үзеңнең кире гадәтеңне җиңәрлек көчне үзеңдә таба белергә кирәк. Җир шарының үзенә охшарга! Җир гайрәтен җиңәрлек көч җирнең үзендә табылды ич: Җир тарту көчен җиңеп, ракеталар Галәмгә күтәрелде!

Эш сәгате башлануга, Хәмит Мөстәкыймов Татарстан АЭСен төзү идарәсенең партком секретаре Рифкать Кәшипович Кәтиев янына килде. Секретарь һәрчак сабыр, игътибарлы була белә, зарыңны тыңлый, киңәшләрен бирә. Үзенә гозер белән килгән, эше төшеп мөрәҗәгать иткән кешеләрне дә бервакытта да конкрет җавапсыз борып чыгармый, читкә тибәрми. Шуңа күрә дә Хәмит Мөстәкыймов Рифкать абыйсы янына булышлык күрми калмасын белеп килә.

Бу юлы да партком секретаре комсомол төзелеше штабы начальнигын ачык чырай белән каршылады. Күзлек пыяласы аша да аның күзләрендәге ихтирам галәмәте ачык сизелә иде.

— Уһу, комсомолия! — диде ул, гадәтенчә кинәнеп елмайды.— Әйдүк, түрдән уз, Хәмит! Күрәм, нигәдер сөмсерең коелган. Нәрсә бар?

Хәмит аңа өченче көн килеп төшкән дүрт егетнең тәртәләрен кире борырга ниятләүләрен әйтте, ничек кенә булмасын, аларны тулай торакны итәргә кирәген исбатларга ашкынды. Аларның китеп барулары күңелләре төзелешкә утырып җитмәгәннәрне иләс-миләс итәргә җитә калачагына басым ясап сөйләде.

— Аңлашылды.— Партком секретаре уң кулы белән өстәлгә кагылып куйды.— Мине уртак эш файдасына кирәкле гамәл кылырга агитацияләү кирәкми.— Ул төзелеш комсомол җитәкчесенә сынаулы караш ташлады да чыдамады, киң итеп елмайды.— Хәзер, Хәмит Салихович...

Рифкать Кәтиев телефон трубкасын алды, саннар җыйды.

— Миңнехан Галимуллович! Хәерле иртә! Вакыт табып, парткомга керсәгез икән. Әйе, җитди сүз бар...

Төзелеш идарәсе начальнигының көнкүреш һәм кадрлар буенча урынбасары Миңнехан Галимуллович Шәрифуллин озак көттермәде.

Ул — гаять оператив һәм булдыклы кеше. Андыйлар турында, кулында ут уйната, диләр. Эшнең төбенә тоз коярга ярата. Бәйнә-бәйнә сорашыр, азаккача аңлашыр. Аннары ашыкмый-кабаланмый гына уйлар. Шуннан соң гына сүзен әйтер. Коры вәгъдәләр бирмәс. Кырысрак, мәгәр эшлекле кырыс.

Төзелешкә бик тансык әлеге егетләрнең торак мәсьәләсен дә шул сәгатьтә хәл кылдылар.

Уңай нәтиҗәне ирештерергә дип, егетләр янына штаб начальнигы үзе китте. Иренеп торалармыни мондый чакта?! Һәркем үзенә бер дөнья бит, һәр кеше өчен көрәшә белергә кирәк. Мондый төзелешләрдә шуңа да өйрәнәләр. Шатлыгына ялгызы гына күмелеп көн итмәскә, кайгысы белән дуслар күңелен каралтмаска, коллектив янганда янарга, бүтәннәр өшегәндә өшергә дә өйрәнү бик мөһим.

Хәмит Мөстәкыймов аңлый инде хәзер: кеше кайгысының яшенен сүндерә алсаң гына, рухи биеклек яулап була. Күпме сыналса да сынмаган, тормышның олы имтихан икәненә азаккача инанган, иманы хаклык, көрәш булган кеше биеклектә чутлана ала.

Тулай торакка урнаштырасы егетләр янына барганда, Хәмит Мөстәкыймов бу төбәктәге беренче адымнарын хәтерләде.

...1983 елның ноябре иде. Казан төзелеш инженерлары институтын промышленность-гражданлык төзелеше белгечлеге буенча тәмамлаган, аннан соң ике ел Совет Армиясендә хезмәт иткән запастагы өлкән лейтенант атом электр станциясе төзелешенә комсомол путевкасы белән килеп төште. Шыр далага түгел, әмма шартлар бүгенгегә караганда күпкә кайтышрак иде. Ләкин егете дә — чакматаш. Тумышы белән Азнакайдан Иген игүчеләрне дә, нефтьчеләрне дә күргән, читенлекләрнең дә ни икәнен төшендереп торасы юк.

Килде дә мастер булып эшли дә башлады. Шыңшымады, зар түкмәде, эшләп күрсәтте. Күрделәр, бәяләделәр, ышандылар. Төп эшендә генә димик, җәмәгать эшләрен дә җиренә җиткерүен бик ошаттылар. Республика комсомол удар төзелешенең штаб начальнигы кандидатурасы турында сүз чыккач, фикерләр икегә бүленмәде: яшь коммунист Хәмит Салих улы Мөстәкыймовны тәкъдим итәргә! — диделәр.

Шуннан бирле ул — төзелештә комсомол башлыкларының берсе. Төзелеш идарәсенең ВЛКСМ комитеты секретаре Исмәгыйль Хафизов белән бергә җигелеп эшлиләр, тик бер-берсен кабатламыйлар.

Хәмит Мөстәкыймов, штаб начальнигы буларак, корылышка үзеннән керткән өлеш хакында гомумән сөйләми, гүя төзелеш хәлләрен хикәяче буларак кына бәян итә. Чынлыкта исә, төзелешкә килгән яшьләрнең фидакарь хезмәтен оештыруда күп көч куйган җитәкче ул. Бүгенгәчә ирешелгәннәргә аның көче дә байтак кергән. Хәмит Мөстәкыймов үз эшчәнлегендә, аныңча әйткәндә, «өч кит»ка таяна. Ул «китлар»: Инициатива, Җаваплылык, Контроль. Шуларны оста үреп бара алган җитәкче ялгышмый.

— Хәрбиләрдә зур һөҗүмгә хәзерлек дигән төшенчә бар,— ди Хәмит. Аның фикер сөреше дә, сөйләве дә дәрт-дәрманлы, чын мәгънәсендә комсомолларча. Төз буй-сыны да сокланырлык. Тәвәккәллек сөйләп торган ачык йөзе, яшәү очкыннары уйнаткан үткер күзләре дә сөйләгәннәрен раслый кебек.— Безнең идарәнең бүгенге көнгә кадәр булган эшен дә зур һөҗүм алдыннан башкарыла торган хәстәрлеккә тиңләп була.

Төзелештән хәбәрдар түгел кешеләр кайчак болай уйлыйлар: төзүчеләр җыелып, коралланып киләләр дә шундук атом электр станциясе реакторының нигезен салырга керешәләр. Юк шул, алай була алмый.

Иң әүвәл торак мәсьәләсен хәл итәргә алынабыз. Атомчы энергетиклар шәһәрчеге корыла (бу эшне, башлыча, «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе Йортлар төзү комбинатының 12-нче төзү-монтаж идарәсе башкара).

Шәһәрчектә хәзер торак йортлар, тулай тораклар, кибетләр, аптека, амбулатория, почта, саклык кассасы, тегү ательесы, көнкүреш хезмәте күрсәтү оешмасы, мунча, «Союзпечать» бүлекчәсе һәм, әлбәттә инде, мәктәп бар.

— Безнең идарә дә,— дип дәвам итә штаб начальнигы,— йортлар да сала, мәктәпләр һәм балалар бакчалары да, культура объектлары да кора, әмма аның иң мөһим, иң төп эше алда әле. Алда — Тат. АЭС мәйданында. Шуның өчен дә яшь энтузиастлар хәлиткеч һөҗүмгә күчәр алдыннан позицияләрне ныгыталар. Иөз җитмештән артык коммунистны берләштергән партия оешмасы җитәкчелегендә дүрт йөздән артык комсомолы булган безнең оешма — төзелештә төп көч дияр идем.

Төзелештә хәзерлек чоры тәмамланып, быел төп эшләр башланды. Беренче энергоблок 1989 елда сафка басачак. Салып бетергәннән соң Татарстан атом электр станциясенең тулаем куәте 6 миллион киловатт булачак.

Сусаклагыч-суыткычка су Кама елгасыннан алыначак.

— Бүгенгә байтакны башкардык,— ди Хәмит һәм, күңеленнән счет төймәсе тарткандай, аз гына тынып тора.— Пионер базасында, Югары һәм Түбән базаларда... Пар һәм кайнар су бирәчәк резерв-котельный, бетон заводы, су чистарту корылмалары (су шуның аша котельныйга һәм бетон заводына бирелә), металл монтажы складлары. Май аенда 320 балага исәпләнгән комбинат өлгерде, икенче комбинатны ел азагында тапшырачакбыз. Яңа уку елына йөзү бассейны, ике спорт залы булган 1500 урынлы урта мәктәп бинасын файдалануга тапшырачакбыз. Ярекгә тагын бер мәктәп төзибез. Күптән түгел ике кибет һәм ашханә төзеп тапшырдык. Март аенда Минэнергоның эшчеләрне тәэмин итү бүлеге — ОРС оештырылды...

Аннары штаб начальнигы Азык-төлек программасын үтәүгә үзләре кертә торган өлеш турында сөйләде.

«Прикамский» совхозында ашлык комплексы (ике ындыр табагы, дүрт склад, үлчәү җайланмасы), яшелчә саклау урыны, мөгезле эре терлекләр комплексы төзеп бирәчәкләр икән.

Яшьләрнең ялына игътибар арта. Яңа Культура сарае коруга керешәчәкләр. Ул чагында Кама Аланындагы элекке клуб дискотека урыны булып калачак. Кама Аланы шәһәрчеген ике заллы кинотеатр бизәп торыр көннәр дә ерак түгел.

Тат. АЭС төзелеше идарәсе яшьләре үзләренең гаилә корыр, балалар үстерер төбәкләрен яшелләндерүгә дә һич тә битараф түгелләр. Табигать биргән гүзәллеккә янә ямь өстәргә телиләр алар. Шуның күркәм бер дәлиле — бөек Җиңүнең 40 еллыгын билгеләп утыртылачак аллея. Җиңү аллеясенең түренә мәһабәт монумент куелачак...

Атом электр станциясен төзү идарәсенең ВЛКСМ комитеты 22 башлангыч оешманы берләштерә. Болар — төзелеш-монтаж идарәләренең оешмаларыннан тыш, баш механик бүлеге, баш электрик бүлеге, эремә - бетон заводы,

торак-коммуналь бүлек, амбулатория, ашханә, Тат. АЭС идарәсе оешмалары. Берләшкән комитет 420 ВЛКСМ членын үз эченә ала. Әйтүле көч бу!

Әлеге оешманың йөз аклыгы булырдай фидакарьләре күп. Хәмит Мөстәкыймов аларның һәркайсын йөрәк җылысы белән телгә ала.

Әйтик, 2-нче төзелеш идарәсе монтажчысы, комсомол оешмасы секретаре Геннадий Жарков, 3-нче төзелеш идарәсенең балта остасы, оператив комсомол дружинасы штабы начальнигы Харис Сәләхетдинов, 7-нче төзелеш идарәсенең буяучы-сылаучысы комсомол оешмасы секретаре, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты члены Светлана Настина, шул ук идарәнең икенче буяучы-сылаучысы группкомсорг Зоя Даниловaны кемнәр генә белми! Апалы-сеңелле буяучы-сылаучылар Резеда белән Зөбәйдә Әгъләмҗановалар да — күз өстендә каш диярлек эшчеләр. Поселок Советы депутаты, баш электрик бүлегенең комсомол оешмасы секретаре Илшат Зарипов — корылышта мактаулыларның берсе. Ул һәрчак башлап йөрүчеләрдән. Техник комплектация идарәсенең комсомол оешмасы секретаре Азат Заһидуллин да бик күп алдынгыларга охшаган булдыклы егет. Комсомол вожакларының берсе, берләштерелгән ВЛКСМ комитеты члены, өлкән механик Павел Усачев хакында да мактау сүзләре генә әйтергә мөмкин. ВЛКСМ комитеты члены, бүлек инженеры Галина Роготневаның да уңганлыгына, иптәшләре белән мөгамәләсенә, комсомол эшен нечкәләп белүенә сокланалар монда. 12-нче котельныйда машинист, комсомол оешмасы секретаре ярдәмчесе Резеда Массарова да — ышанычлы таяныч булырдай уңган кыз.

Шофер кешенең күп вакыты юлда уза. Җәмәгать эшләренә җай да калмыйдыр төсле. Юк, алай түгел икән! Теләк кенә булсын. 3-нче автохуҗалык шоферы, оператив комсомол дружинасы штабы члены Наил Сибгатуллин үрнәге, теләк булганда, бик күпкә ирешеп булуны раслый. Йортлар төзү комбинатының 12-нче төзелеш-монтаж идарәсеннән группкомсорг Гөлсинә Сәләхова эшчәнлеге дә шуның дәлиле. Төзелә торган атом электр станциясе дирекциясендә бухгалтер, комсомол оешмасы секретаре һәм берләштерелгән ВЛКСМ комитеты члены Надежда Смышляева да зур корылышның беренче көннәреннән үк бик күпләр өчен өлге булып яши һәм эшли...

Саный китсәң, байтак монда чын мәгънәсендә алдынгылар. Хезмәттә дә, җәмәгать эшләрендә дә, яшьләрнең ялын оештыруда да, укуларында да сынатмый баручылар. Аларга заман яшьләренең, сиксәненче еллар яшь гвардиясенең иң калку сыйфатлары тупланган. Шул сыйфатларның берсе, иң кыйммәтлесе — өйрәнү. Совет кешесе дигән горур исемне тулысынча аклап яшәргә өйрәнү.

— Шундый комсомоллар төзелешебезнең паспортын тәшкил итәләр,— ди Хәмит Мөстәкыймов, хаклы мактануын яшерергә дә теләмичә.— Ә өйрәнер кешеләр бар, өлге булырдай өлкәннәребез аз түгел...

Аннары республика удар комсомол төзелеше штабы начальнигы буяучы-сылаучылар бригадиры, КПССның XXV съезды делегаты Ольга Андреевна Макарова, скреперчылар бригадиры Камбулат Наурбиев, балта осталары-бетончылар бригадиры Камил Әхмәдиев, монтажчылар бригадиры Василий Аксаков кебек ветераннарның исемнәрен хөрмәтләп телгә ала,аларның яшьләр алдында чыгыш ясап, тәҗрибә уртаклашулары турында сөйли. Буыннар эстафетасына җитди дикъкать итү — комсомол комитетының да, штабның да хезмәтне оештыруда, социалистик ярышны җәелдерүдә бик дөрес сайлаган ысулы.

Ә коллективларның ярышы чын мәгънәсендә эшлекле оештырылган. Ярышучылар алда торган максатларын яхшы беләләр, аңа ирешү юллары һәр төзүчегә мәгълүм. Нәтиҗәләр даими яктыртылып килә, һәр декада саен һәм һәр ай азагында ясалган йомгаклар бөтен коллективларда тикшерелә.

— Көзен, яфрак коеп, урман ачыкланып калгач, кәкре-бөкре күбрәк күренүчән була бит,— ди Хәмит Мөстәкыймов.— Әмма моңа карап шомга төшәргә ярамый, чын урманда бар агач та шәмдәй булмый. Бездәге ярыш йомгаклары күп нәрсәне ачыкларга мөмкинлек бирә. Игътибарны планны үти алмаучыларга күбрәк юнәлтәбез. Тәҗрибәләре аз яшьләрне үз эшләренең осталары булып җитешкән иптәшләр шефлыгына тапшырабыз. Өйрәнү дәвам итә.

Комсомол-яшьләр бригадалары ярышы бөтен төзелешнең игътибарын җәлеп итте дигәндә дә, хата булмас. Җиңү көне хөрмәтенә барган хезмәт бәйгесенә йомгак ясаганда, бетончылар бригадасының авангардта баруы ачык-

ланды. Бригадир Рәшит Кәлимуллин белән группа комсоргы Иван Филиппов аик күпләрнең тәбриген кабул иттеләр. Алар хөрмәтенә Хезмәт даны флагы җилфердәде. Бригадага Мактау грамотасы һәм күчмә вымпел тапшырылды. Егетләр:

— Күчмә вымпелны күчермәс өчен тырышабыз,— диделәр.

Апрель үтте, май узды. Кояшы-яңгыры, җылысы-суыгы белән июнь керде. Татарстан атом электр станциясе төзелешенә Совет Армиясе сафларыннан демобилизацияләнгән егетләр килә башлады. Мондый чакта комсомол башлыкларының телендә инде сөенечле сүзләр кабатлана: «Киләләр. Киләләр. Киләләр!..»

Хәмит Мөстәкыймовның да кәефе аяз көн шикелле. Ят күзләр алдында артистланмаса да, торакта үзе генә калгач, үзалдына гына шигырь укып җибәрсә, гаҗәпмени?! Шагыйрь ничек дигән?

...Тау җимерелә,
Урман артка чигә.
Безгә монда нигез саласы.
Һәйкәл булып безнең ярсуларга
Яшәр әле яшьлек каласы.

---

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

СОРАУ:

— Яшь иҗат көчләренә Сезнең нинди теләкләрегез бар?

ГОМӘР БӘШИРОВ, СССР Дәүләт премиясе лауреаты:

— Күптән түгел без — өлкән буын әдипләр һәм шагыйрьләр бөтен республикадан җыелган яшь иҗат көчләре белән очраштык. Аларның күбесе, бик яшь булуларына карамастан, игътибарга лаеклы берничә әсәр язарга да өлгергән инде... Мин шунда үземнең 13 яшьтә язган беренче хикәямне кызганып утырдым. Аны мин әти белән әнигә генә укыдым шул. Аларга бик тәэсир итте ул... Әгәр хәзерге шартлар булса, [illegible] хикәя басылмыйча калып, эзсез югалмас иде. Мин дә бәлки әдәбиятка [illegible] ел алданрак килгән булыр идем.

[illegible]ртләре ташып торган шушы алсу битле яшьләргә мин чынчыннан кызыгып, хәтта алардан бераз көнләшеп тә куйдым. Алар бит XXI гасырның ишеген ачып керәчәк кешеләр! Алар безнең бөтен халык иҗаты байлыгына, Кол Галидән башлап хәзерге көннәргәчә җыелган әдәби мирасыбызга, безнең буын канлы көрәшләрдә яулап алган хөррияткә, яңа тормышка — һәммәсенә хуҗа булып калачаклар!

Шул вакыт күңелгә шик тә төшеп куйды — алар бу тиңдәшсез байлыкның кадерен белерләрме? Үзләренә ерак-ерак бабаларыннан калдырылган бик зур рухи көчне яшәтеп, дәвам итеп, тере хәлендә үз оныкларына тапшыра алырлармы алар? Балалары яки оныклары иң җитди сорауларны биргәндә, алар дөрес җавап бирә алырлармы?

Әлбәттә, мин яшьләргә ышанам. Алар безнең эшне лаеклы дәвам итәрләр. Ләкин әле генә куелган сораулар турында җитди уйлансыннар иде алар. Халкыбызның олы тормыш тәҗрибәсен, аның үлемсез рухи байлыгын үзләренә күбрәк сеңдерү хакында күбрәк уйлансыннар иде бүгенге яшь иҗат көчләре!

**Флүн Мусин**

# ДЕТЕКТИВ ТУРЫНДА

Матбугатны күзәтеп баручылар моңа кадәр ничектер күләгәдәрәк калып килгән бер жанрга соңгы вакытта игътибарның шактый көчәюен күрәләр. Ул — детектив. Әледән-әле бу жанрның совет әдәбиятында тоткан урыны, үсеш тенденцияләре турында сүз алып барыла, полемик мәкаләләр басыла, «түгәрәк өстәлләр», «диалоглар» үткәрелә, күзәтүләр, интервьюлар, укучы хатларына җаваплар бирелә.

Эш нәрсәдә соң? Нигә әле күптән түгел трамвайда яки пляжда гына укырга яраклы, ягъни түбән сортлы әдәбият дип каралган детектив белән хәзер язучылар, тәнкыйтьчеләр, гомумән, киң әдәби җәмәгатьчелек шулай якыннан кызыксына башлады?

Сорауга бер төрле генә җавап биреп булмый, әлбәттә. Бу хәлнең төрле-төрле сәбәпләре булырга тиеш. Шулай да, аларның иң әһәмиятлеләреннән берсе, һичшиксез, детективның укучылар арасында гаять зур популярлык казануы. «Литературная газета» битендә булып узган бер дискуссиядә, мәсәлән, мондый статистик мәгълүмат китерелгән иде: детектив белән фәнни хезмәткәрләрнең 75 проценттан артыграгы, ә югары белемле белгечләрнең 65 проценты мавыга икән. Биредә күренекле әдәбият-сәнгать һәм фән эшлеклеләренең фикерләре дә кызыклы. Мәсәлән, танылган совет академигы И. И. Артоболевский үзенең бер интервьюсында болай диган: «Мин детективны яратам. Детектив — минем ярдәмчем. Мондый китаплар миңа көчле эмоциональ һәм нәтиҗәле заряд бирәләр». СССРның халык артисты Михаил Жаров та детектив әсәрнең аңа «сюжетлы фикерләүне үстерергә... персонажның эш-хәрәкәт пружинасын эзләп табарга ярдәм итүе» турында әйтә.

Бездә хәзер детективны яше дә, карты да ратып укый. Бу жанрга караган китаплар басылып чыгу белән, күз ачып йомганчы таралып бетәләр, ә әдәби журналларның тиражы кайчак аларда детектив булу-булмауга бәйле. Тагын шунысы да бар: безнең нәшриятлар китап сату оешмаларының детектив әсәрләргә булган заказларын бары 10-15 процентка гына үти алалар.

Бу төр әдәбиятның төрле буын һәм категория укучылары арасындагы гаять зур популярлыгы детективны кешеләргә идея, әхлакый һәм эстетик йогынты ясауның бик үтемле чарасына, алай гына түгел, хәзерге киеренке идеологик көрәштә көчле коралга әверелдерә. Бу жанрның шундый зур мөмкинлекләреннән соңгы вакытларга кадәр тулысынча диярлек безнең идея дошманыбыз — буржуаз пропаганда файдаланып килде. Әйе, буржуаз идеологлар безгә караганда күп мәртәбә элгәрәк детективны үз максатларына хезмәт иттерә алдылар. Бу хәл билгеле бер дәрәҗәдә детективның жанр буларак Көнбатышта формалашуы һәм анда шактый зур үсеш алуы белән бәйләнгән. Шуңа күрәдер, бездә ул байтак вакытлар буена совет әдәбиятына ят булган «буржуаз» жанр дип кире кагып киленде. Мәсәлән, 1935 елда күренекле совет тәнкыйтьчесе С. Динамов болай язган иде: «Детектив жанр — әдәби жанрлар арасында бөтенләе белән буржуаз җәмгыять казанында формалашканы һәм аның тарафыннан әдәбиятка китереп кертелгәне». Жанрны шушы рәвешле бәяләү әле Зур Совет Энциклопедиясенең сугыштан соңгы басмасында да (1952 ел) нигездә саклана. Бары тик Кече Әдәби Энциклопедиядә генә мәсьәләгә караш үзгәрә. Анда инде: «Бу жанрның иң яхшы әсәрләре серле һәм хәйләле итеп үрелгән сюжетка, җанлы һәм күпьяклы, әмма вакыйгаларның үз агышы белән ачыла торган характерларга ия; алар эзләү һәм каһарманлык романтикасы белән сугарылган, аларда социаль мотивлар тарафыннан тудырылган серле һәм гадәти булмаган җинаять белән акыл һәм кыюлык үзара бәрелешә»,— диелә.

Җәмәгатьчелек һәм тәнкыйть фикеренең детективка карашы болай үзгәрүгә байтак дәрәҗәдә әдәби практика үзе булышты. Чөнки сугыштан соңгы чорда, бигрәк тә 60 ел-

лардан соң, бездә бу жанрга караган күп кенә әсәрләр дөнья күрә. Рус әдәбиятында детектив өлкәсендә профессиональләшкән бер төркем язучылар пәйда була. А. Адамов, агалы-энеле Вайнерлар, Ю. Семенов, Ольга һәм Александр Лавровлар, П. Шестаков, Н. Томан кебек авторларның әсәрләре, укучылар арасында популярлык казану белән бергә, кинематографта да детектив жанрның нык үсеп китүенә булыштылар. Шул ук вакытта әлеге авторларның әсәрләре «совет детективы» дигән жанрны прогрессив характердагысыннан да шактый аерылуын, үз традицияләрен тудыруын күрсәттеләр.

Безнең тәнкыйтьчеләр һәм әдәбиятчылар моңа кадәр кызыксынмасалар да, детектив жанрга татар язучылары да байтактан игътибар биреп киләләр. Хәтта безнең бу өлкәдә билгеле бер тарихыбыз һәм традицияләребез дә бар дияргә мөмкин.

Татар әдәбиятында детектив сюжет алымнарына һәм чараларына беренчеләрдән булып Заһир Бигиев мөрәҗәгать итә. Монда иң әүвәл бер сорау туа: ни өчен яшь автор үзенең беренче әсәрендә үк аңа кадәр татар әдәбиятында очрамаган уголовный детектив алымнарыннан файдалана? Бирелә, әлбәттә, З. Бигиевның бик яшьли рус һәм француз романнары, бигрәк тә аларның мажаралылары белән мавыгуы билгеле бер роль уйнагандыр. Шул ук вакытта мондый омтылышның җитдирәк сәбәпләре дә булырга тиеш. Шуларның берсе, минемчә, мәгърифәтче әдипнең киң катлау укучыларга исәпләнгән, алар яратып укырлык массовый әдәбият тудыру теләге. Әсәр укучыга кызыклы да, аңлаешлы да булырга тиеш. Мәгърифәтчеләрнең әдәбият алдына куйган мөһим таләпләреннән берсе шул иде. Рус һәм француз прогрессив язучыларын укып тәрбияләнгән З. Бигиев, табигый, туган әдәбиятын да демократлаштырырга, халыкка якынайтырга тырыша. Ул заманда Европа әдәбиятларында популярлашкан детективның бу эштә бик кулай булачагын З. Бигиев яхшы аңлаган, күрәсең.

Инде З. Бигиевның «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә» исемле мәгълүм романына килик. Анда детективлык нәрсәдә чагыла соң? Барыннан да элек, әсәр серле җинаятьне ачуга багышланган. Автор үзе сурәтләгән үтерешне тормышта чыннан да булган итеп күрсәтә. Моның өчен ул сүзне «иң элек вакыйганың кай җирдә һәм ни вакытта булганлыгы»н белдерүдән башлый. һәм укучыга романда «аңлашылачак эш моннан берничә еллар элек Казан шәһәрендә» булды дип хәбәр итеп. Шуннан соң әлеге эшнең кайда булуы турында газета хроникасындагыдай конкрет һәм төгәл хикәя кылына: «Иртән сәгать унда Казан гостиницаларыннан иң яхшысы булып саналган бер гостиница янына күп кенә кешеләр җыелганнар иде. Җыелган халыклардан шундый сүзләр ишетелә иде:

— Нәрсә бар, нәрсә карыйсыз, нәрсә булган?

— Нәрсә булсын, бүген бу гостиницада мөсафирә бер хатынны үтергәннәр.

— Гаҗәп! Кем үтергән? Үтерүче тотылганмы?

— Ул кадәресе билгеле түгел, хәзер полиция һәм судебный следователь киләләр, тикшерү булачак, бәлкем, үтерүче дә табылыр».

Күренә ки, З. Бигиев романында хикәяләү нәкъ менә классик детективтагыча башлана. Алга табан бу җинаятьне ачуга «ул вакыттагы иң атаклы Шубин исемле сыщик-шымчы» алынуы белдерелә һәм аның үз эшен башкаруы әлеге жанр таләпләреннән чыгып сурәтләнә. Дөрес, яшь кыз Зөләйханы үтерүче кешене табу процессы автор тарафыннан шактый катлауландырыла. Шубин, гәрчә язучы аны бик сәләтле һәм тәҗрибәле шымчы дип тәкъдим итсә дә, җинаятьнең серен ачканда байтак вакыт ялгыш юлдан бара. Башта ул Зөләйханы үтерүдә Мусаны гаепли, аны төрмәгә дә яптыра, ә бу геройның гаепсез булуы ачыклангач, Габденнасыйрны шик астына ала һәм соңыннан гына героиняның үзен-үзе үтергәнлеге мәгълүм була.

Хикәяләүне болай зигзаг рәвешендә алып бару, бәлки, аның киеренке агышын озаграк саклау нияте белән эшләнгәндер. Аннан соң бу хәл чит әдәби йогынты белән дә бәйләнгән булырга мөмкин. Дөресрәге, андый йогынты романда шактый сизелә. Заманында Ф. Әмирханның З. Бигиев әсәрләре хакында «рус типларын татар ясап чыгардылар. Бу романнарда камилән татар тормышыннан алынган типлар... юк дияргә мөмкиндер»,— дип язуы нигезсез түгел, әлбәттә.

Нәтиҗәдә әсәрләренең тормыш җирлеге буенча да һәм стиле белән дә З. Бигиев үзенең мәгърифәтче замандашларыннан шактый аерыла. Шуңа да карамастан, З. Бигиев мәгърифәтчелек реализмы тарафдары булып тора. Романда бу методның төп таләпләреннән һәм сыйфатларыннан берсе ачык чагыла. Ул — көндәлек тормыш-көнкүрешкә игътибар арту, геройны аның гадәти тирәлегендә һәм үз иркенә куеп сурәтләү. Бирелә автор беркадәр объективистлык позициясенә дә баса кебек. һәрхәлдә ул сурәтләгәннәргә үз бәясен белдерергә ашыкмый. Үзәк геройлар — яшь сәүдәгәрләр Муса һәм Габденнасыйр үз стихияләрендә күрсәтеләләр. Аларның һәр икесе дә Әхмәди бай кызы Хәдичәне «йөз мең сум илә кәләшлеккә» алырга тырышалар. Кәләшнең үзеннән бигрәк аның шушы бай бирнәсе кызыксындыра бу ике сәүдәгәрне. Автор да аларның һәр икесе Хәдичәне кәләшлеккә алырга лаек дип карый, һәрхәлдә аларның берсен икенчесеннән өстен куймый. Язучының шушындый карашын чагылдыргандай, Зөләйханы үтерүдә гаепләнеп төрмәгә

ябылган Мусаның «каторжный хезмәткә китәчәген» ишеткән Әхмәди бай, «Габденнасыйр әфәндедән башка күңелгә ошарлык кеше булмаганлыктан», озак уйлап тормыйча үз планнарыннан баш тарта һәм кызын йөз мең сум акчасы белән шушы егеткә бирергә була. Шулай да автор Муса яклырак. Бу хәлнең сәбәбе шунда: Әхмәди бай кызын Мусага Габденнасыйрдан алдарак вәгъдә иткән. Шуңа күрә әдип Хәдичә тугашның бирнәсе белән Мусага насыйп булуын телирәк төшә кебек. Ә кыз атасының баштагы ниятен үз файдасына үзгәртергә теләүче Габденнасыйр белән мәгърифәтче автор инде һич тә килешергә теләми. Габденнасыйрның бу адымы соңыннан аның әхлакый җинаяте дип бәяләнә һәм моның өчен ул каты җәза ала. Кыскасы, әсәрдә әдипнең үз геройларына шактый абстракт төстә гәүдәләнгән әхлакый хөкеме тантана итә. Шушы хөкем нигезендә Муса акланып төрмәдән чыгарыла һәм Хәдичәне йөз мең белән хатынлыкка ала, ә Габденнасыйр үз-үзен үтерә.

Романда бер кызыклы момент бар. Эш шунда, геройларга автор карашы белән укучы карашы тәңгәл килеп бетми. Әсәрдә сурәтләнгәннәр объектив рәвештә безгә, укучыларга, персонажларга киңрәк планда карау һәм бәяләү мөмкинлеге бирәләр. Һәм без Муса белән Габденнасыйрның социаль яктан бер үк типтагы шәхесләр булуын күрәбез. Алар икесе дә байлык артыннан куучы, моның өчен барысын да — мәхәббәтне дә, дуслыкны да корбан итәргә әзер торучы затлар булып гәүдәләнәләр. Детектив линия — Зөләйханың үлүе серен ачыклау — шушы объектив хакыйкатьне тагын да ассызыклап күрсәтергә булыша кебек.

Детектив сюжет, икенче яктан, татар хатын-кызының үткәндәге аянычлы хәлен ачыграк күзалларга ярдәм итә. Әйтергә кирәк, бу хакыйкать монда да хикәяләүнең үзеннән килеп чыга. Ягъни детективлык ярдәмендә чагылдырылган объектив фикер авторның мәгърифәтчелек карашларыннан өстенрәк булып чыга. Героиняларны сурәтләгәндә мәгърифәтчеләрнең мәгълүм бер карашы алга сөрелә. Алар шәхеснең тормыштагы юлын һәм язмышын билгеләүдә гаилә тәрбиясен хәлиткеч фактор итеп карадылар. Шуңлыктан алар яхшы гаиләдә дөрес тәрбия алган бала киләчәктә инсафлы һәм инсаниятле, ата-анасы күрсәткән юлдан барырга тиеш дигән караштa тордылар. Мондый ата-ана сүзеннән чыккан балалар исә мәгърифәтчеләр тарафыннан каты хөкемгә тартылалар. «Мәңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә»дә ата-анасы рөхсәтеннән башка кияүгә чыгарга теләгән Зөләйха үз максатына ирешә алмый: башта кызга өйләнергә вәгъдә биргән Муса хәзер аңардан баш тарта. Бу бәхетсезлегендә кыз бары үзен генә гаепли. Үз гаебен исә ата-анасы сүзеннән чыгуда күрә. Үләр алдыннан әнисенә язган хатында ул: «Сезнең рөхсәтегездән башка качып китүем сәбәпле, сәфәрем хәерле булмады»,— ди.

Ә менә Хәдичә беркайчан да әтисе сүзеннән чыкмый. Әтисе аны сөйгән егете Мусадан аерып бөтенләй чит кешегә хатынлыкка бирергә карар иткәч, Хәдичәнең кичерешләрен автор болай тасвирлый: «Ни эшләсен! Ата-анага буйсынмый булмый». Хәдичәнең мондый күндәмлеге мәгърифәтче әдип тарафыннан хуплана һәм югары бәяләнә. Ул үз теләгенә ирешә — Мусага кияүгә бирелә. Автор үз әсәрен бәхетле финал белән — Муса һәм Хәдичәнең «шатлыклы туен» сурәтләп тәмамлый. Бездә, укучыларда исә әлеге финал шатлык хисе уятмый. Чөнки без Муса белән Хәдичәнең «бәхете» Зөләйха бәхетсезлеге һәм фаҗигасе исәбенә ирешелгәнен беләбез. Романның детектив линиясе бу хакыйкатькә тагын да ныграк инандыра.

Революциядән соңгы әдәбиятыбызда детектив сюжет алымнарына беренчеләрдән булып Г. Ибраһимов үзенең «Тирән тамырлар» романында мөрәҗәгать итә. Бу әсәр барыннан да элек яңа тип әдәбият — социалистик реализм әдәбияты вәкиленең детективлыкны нинди максатларда файдалануын ачыклау ягыннан кызыклы. Революциягә кадәрге классик детектив аңарда сурәтләнгән җинаятьнең хосусый характерда булуын яклады. Әйтик, җинаять нинди дер байлыкны яки мирасны кулга төшерү өчен, я булмаса көнләшү аркасында һәм шөһрәт казану нияте белән эшләнергә мөмкин. Әмма ул һич тә социаль яңгыраш алмаска, иҗтимагый системага, аның социаль һәм экономик нигезләренә кизәнмәскә, аларны тәнкыйтьләмәскә тиеш. Икенче төрле әйткәндә, классик детектив үзенең төп максатын хосусый характердагы җинаятьнең серен вакыйгаларны мөмкин кадәр катлауландырып һәм мавыктыргыч сюжет ярдәмендә ачуда, бу эшкә алынган кешенең криминалистик талантын калку итеп гәүдәләндерүдә күрде. З. Бигиев романыннан күренгәнчә, мәгърифәтчеләр шушындый эшне башкару дәвамында үзләренең кайбер мәгърифәтчелек идеяләрен чагылдыру турында кайгырттылар.

Ә менә Г. Ибраһимовка килсәк, ул детектив алымнар ярдәмендә шул чор совет әдәбияты каршында торган мөһим мәсьәләләрне яктыртырга алына. Әлеге алымнарны формаль яктан куллануда ул беркадәр З. Бигиев тәҗрибәсеннән дә файдалана кебек. Мәсәлән, З. Бигиев шикелле үк, ул да романын җинаять ясалу фактыннан («Фәхрине үтереп ташладылар») башлый. Үтерүчене эзләү дә ялгыш юлдан китә: Фәхрине үтерүдә аның көрәштәш дусты Садыйк гаепләнә һәм кулга алына. Ә чын җинаятьче бары әсәр ахырында гына ачыклана.

Бу ике әсәр арасындагы охшашлык шушында бетә. Чынлыкта үзләренең идея-эстетик юнәлешләре буенча алар бер-берсеннән нык аерылалар. «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә»дә Зөләйха шәхси сәбәпләр аркасында, мәхәббәте барып чыкмаудан һәм ата-ана каргышыннан куркып үз-үзен үтерә. Г. Ибраһимов романындагы җинаятьне исә һич тә хосусый планда гына карап булмый. Гәрчә Вәли бай шулай итеп күрсәтергә бик тырышса да. Чөнки Фәхри барыннан да элек иҗтимагый шәхес, гомум мәнфәгатьләр белән рухланып, шулар өчен көрәшеп яшәгән кеше. Ул — авылда яңа тормыш төзү өчен көрәшне әйдәп баручы. Ул — бик күпләр өчен кирәк һәм алар тарафыннан ихтирам ителгән кеше. Автор да: «Фәхрине яраталар иде. Үз итеп, туган итеп, авыр йөккә төптән җигелеп өстерәүче итеп яраталар иде. Аның үлеме, аның үз араларыннан, тормыштан китүе — күңелләрдә ятимлек тойгысы уятты»,— ди. Фәхринең үлеменә авыл халкының мөнәсәбәте тагын түбәндәге детальдә ачык чагыла: «Ир, хатын, бала-чага, яшь-карт — һәммәсе, эшләрен, сүзләрен, уеннарын онытып, Ямankул чокырына агылдылар».

Геройның шундый олы иҗтимагый шәхес булуы аның үлемен тикшерүне дә катлауландыра. Әгәр З. Бигиев романында шымчы Шубин Зөләйханың үлемендә бары ике генә кешене гаепләсә, «Тирән тамырлар»да тикшерүче Паларусов Фәхрине үтерүчене табар өчен бик күп нәрсәне өйрәнергә, белергә кирәк икәнен аңлый. Нәтиҗәдә әлеге җинаятьнең серен ачу әсәрдә катлаулы һәм көрәшле чорны киң колачлап, төрле яклап күзаллауны сорый. Шул сәбәпле, детектив моменттан башланган роман тора-бара бөтен заманны, аның төп үсеш тенденцияләрен гәүдәләндергән киң полотнога әверелә. Фәхринең үтерелү сәбәпләрен тулырак күз алдына китерү өчен авторга үткәнгә — империалистик сугыш, февраль һәм Октябрь революциясе, гражданнар сугышы елларына да мөрәҗәгать итәргә туры килә. Болар барысы ахыр чиктә Фәхри биографиясенең турыдан-туры халык тарихы белән бәйләнгән булуын ачуга, ә аның үлемен яңа тормыш төзү өчен көрәштә зур югалтуларның берсе итеп күрсәтүгә китерә.

Фәхри үлеменең шундый зур социаль-фәлсәфи яңгырашка ия булуы фаҗигане ачуга багышланган хикәяләүгә дә тирән эз сала. Әйтик, шул ук З. Бигиев романыннан аермалы буларак, биредә ул полифоник яңгыраш ала һәм эпопеяны хәтерләтә башлый.

Бер нәрсә ачык: «Тирән тамырлар»дагы детективлык «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә»дәге кебек шәхси характердагы җинаятьне ачуга гына хезмәт итми. Биредә ул зур социаль-сыйнфый эчтәлекле җинаятьне тикшерү булып тора, билгеле бер тарихи этаптагы иҗтимагый-рухи үсешне аның иң кискен моментларында һәм калку итеп чагылдыру чарасына әверелә. Нәтиҗәдә, детектив хикәяләү алымнары социалистик реализмның иҗат палитрасына органик рәвештә килеп керәләр һәм аны баеталар.

Детективның татар әдәбиятында мөстәкыйль жанр буларак чыгыш ясый башлавы исә 60 елларга туры килә. Соңгы унъеллыкларда бу жанрга А. Расих, Р. Ишморатова, М. Маликова, Т. Әйди һәм, ниһаять, М. Насыйбуллин һәм З. Фәтхетдинов мөрәҗәгать итәләр. «Ниһаять» дип әйтүемнең бер сәбәбе шунда: әгәр башта телгә алынган авторлар детективка караган әсәрләрен бу жанрда бер каләм сынап карау яки эзләнү нияте белән язсалар, соңгыларының иҗатында исә ул төп урынны ала.

А. Расихның «Урланган хәзинә» повесте музей баскан каракларны эзләүгә багышлана. Бу эшне тикшерү капитан Ризван Рахмановка тапшырыла. Жанр таләпләрен күздә тотып, автор музейдан Болгар һәм Алтын Урда чорларына караган алтын-көмеш тәңкәләрне урлаучыларны эзләү һәм тотуга корылган сюжетны эзлекле һәм динамик төстә үстерә.

Әмма җинаятьне ачу әсәрдә никадәр мавыктыргыч итеп сурәтләнмәсен, моны сурәтләү автор өчен бердәнбер максат түгел. Әлеге процессны яктырту дәвамында ул кайбер иҗтимагый-әхлакый яңгырашлы мәсьәләләргә дә туктала. Аерым алганда, ул яшьләр арасындагы негатив күренешләргә, аларның туу сәбәпләренә дикъкать итә. Хәмит һәм Клара кебек җиңел тормыш эзләүчеләр борчый аны. Чөнки аларның язмышы еш кына драматик һәм хәтта фаҗигале төс ала. Тормышка җиңел карау, җаваплылык хисе булмау сәбәпле, алар үзләре дә аңламастан, җинаять юлына басалар.

А. Расих повестенда әле беркадәр эпизодик рәвештә күтәрелгән бу мәсьәләгә (яшьләр арасындагы җинаятьчелек күренешләрен ачыклауга) Р. Ишморатованың «Милиция лейтенанты» повестенда игътибар тагын да көчәя, ул хәтта әсәр үзәгенә куела дияргә мөмкин. Повестьның үзәк герое — участок инспекторы Зөлфәт Мәрданов һәм аның иптәшләре нәкъ менә яшүсмерләр арасындагы җинаятьчелек белән көрәштә күрсәтеләләр. Әмма алар инде Галим һәм Коля кебек җинаять юлына баса башлаган яшүсмерләрне тотып җәзага тарту турында гына уйламыйлар. Автор да аларны чын мәгънәсендәге җинаятьчеләрдән бигрәк тормышларында вакытлыча буталып калучылар һәм ялгыш юлга кереп китүчеләр дип карый. Әсәрдә совет милициясенең һәм суд органнарының мөһим функциясе — җинаятьчелекне алдан, яралгы хәлендә үк күреп алу һәм үз вакытында зарарсызландыру өчен көрәшү ачык чагыла. Моның өчен, әлбәттә, иң әүвәл җинаятьнең туу җирлеген һәм сәбәпләрен белергә кирәк. Бу мәсьәлә белән Р. Ишморатова да якыннан кызыксына. Яшь геройларының тормышта ялгыш юлга басуларының төп сәбәпләреннән

берсен ул семьяда күрә. Повестьта бигрәк тә Галим белән Коляның бик яшьли ата-ана мәхәббәтеннән мәхрүм булулары шактый тәфсилләп сурәтләнә. Моның белән язучы тагын бер мәртәбә баланы тәрбияләүдә семьяның зур роль уйнарга тиешлеген искәртә.

Әйтергә кирәк, А. Расих, һәм Р. Ишморатова повестьларында яшьләр арасындагы җинаятьчелек мәсьәләсе күтәрелүгә безнең болай игътибар итүебез һич тә очраклы түгел. Бу мәсьәлә хәзер гомумән совет детектив әдәбиятының мөһим максатларыннан һәм бурычларыннан берсенә әверелеп килә. Ни өчен дисәң, яшьләр мавыгып укый торган бу төр әдәбият әлеге мәсьәләне үз укучыларына башка жанрларга караганда да үтемлерәк һәм тәэсирлерәк итеп яктырта. Моның белән детектив жанр бик кирәкле һәм әһәмиятле эш башкара. Чөнки ул яшь буынның социаль һәм әхлакый яктан сәламәт булып үсүе, аның тормышындагы бозык күренешләрне үз вакытында күреп алып, юкка чыгару өчен көрәшә. Хәлбуки, яшь буынны тәрбияләү — бөтен җәмгыять эше һәм ул буыннан-буынга системалы рәвештә алып барылырга тиешле эш. Борынгы Көнчыгышта болай дигәннәр: «Әгәр синең планнарың бер елга исәпләнсә — тары чәч, әгәр алар унар елга исәпләнсә — агачлар утырт, әгәр инде синең планнарың гасырларга исәпләнә икән ул вакытта кешеләрне тәрбия кыл». Борынгыларның бу әйтеме белән күренекле совет криминологы профессор М. Н. Гернетның: баланы тәрбияләүгә ул туганчы йөз ел элек тотынырга кирәк, дигән фикере бик аваздаш яңгырый.

Шундый зур әһәмиятле мәсьәләләрне яктыртырга алынуы детективның идея-эстетик кыйммәтен дә күтәрә. Аннан соң, безнең профессиональ язучылар, гомумән, бу жанрның максатын һич тә теге-бу җинаятьне ачуга гына кайтарып калмыйлар. Алар үз алларына социаль-әхлакый яңгырашлы бурычлар да куялар. Ә кайчак хәтта детектив форма авторларның шушындый омтылышларын тормышка ашыру чарасына әверелә. Мәсәлән, М. Маликованың «Хөкем» һәм «Адашканга юл кайда?» повестьларында җинаятьне ачу автор өчен бердәнбер максат түгел.

«Хөкем» беренче карашка гадәти детективны хәтерләтә. Анда сүз судья Вәлидә исеменнән алып барыла. Ул үзенең иптәшләренә моннан унҗиде ел элек авылда эшләнгән бер җинаятьне ничек ачулары турында сөйли. Таштимер авылында булган җинаятьне — авыл советында каравылчы булып эшләгән Алия исемле хатынның кем тарафыннан үтерелүен ачыклау процессын автор детективка хас формада яктырта. Һәм бу хакта хикәяләү шактый мавыктыргыч булып чыккан. Әмма Вәлидәнең бу хакта байтак еллардан соң искә төшерүенең үзгәрәк сәбәпләре дә бар икән. Повестьның исеме дә күбрәк героиняның үзенә карый. Вәлидә үткәндәге бер хатасы өчен әсәрдә үз-үзен хөкем итә. Әле яңа институт дипломы алып, тикшерүче булып эшли башлаган Вәлидә ул вакытта тәҗрибәсезлеге аркасында Таштимердәге кеше үтерүне тикшергәндә ялгыш юлдан китә: шул авыл советы председателе Мөгыйн Саттаровны гаепли. Тәҗрибәле тикшерүче Җәүдәт Харисович исә үтерүченең бөтенләй икенче кеше булуын ачыклый. Шушы хатасы өчен Вәлидә инде менә ничә ел үз-үзен газаплый. Вөҗданы тынгылык бирми аның. Моның белән М. Маликова тикшерүче эшенең бик тә җаваплы булуын, биредә җибәрелгән хатаның гаепләнүче өчен генә түгел, гаепләүче өчен дә зур рухи-әхлакый җәзага әверелү мөмкинлеген күрсәтә.

Т. Әйдинең «Бөҗра» повесте исә «саф» детективка якынрак тора. Ул «Тасманур» заводыннан бер тонна көмеш урлаучыларны эзләп тотуны тасвирлый. Игътибарын тулысынча диярлек шушы җинаятьне тикшерүгә юнәлтеп, автор бу эшнең шактый катлаулы төс алуын, аңа тотынган геройлардан бик күп эзләнү, уйлану, криминалистик осталык соравын күрсәтә. Әйтергә кирәк, әсәрдә җинаятьләрне ачу эшенә романтик караш белән полемикага керү сизелә. «Кайберәүләр уйлаганча, җинаятьчене тотар өчен ах-ух килеп, машинадан машинага утырып куа бару, җәрәхәтләнгәнче көрәшү генә җитми. Андый мачаралар бөтенләй булмаска да мөмкин»,— диелә анда. Шушындый фикердән чыгып, автор ялтыравык маҗаралылыктан качарга тырыша, җинаятьне ачуның прозаик ягына күбрәк игътибар итә кебек.

Бер сүз белән әйткәндә, Т. Әйди повесте үзенең хикәяләү рәвеше буенча А. Расих, Р. Ишморатова һәм М. Маликова әсәрләреннән беркадәр аерыла. Соңгылары күбрәк фантазиягә таянсалар һәм хикәяләүнең әдәби сыйфаты турында кайгыртсалар, «Бөҗра»да җинаятьне ачу процессын криминалогик яктан төгәлрәк һәм тулырак яктыртуга басым ясала. Бу нәрсәгә З. Фәтхетдинов һәм М. Насыйбуллин иҗатында игътибар тагын да арта төшә. Һәм ул аңлашыла да. Чөнки бу авторлар профессияләре буенча тәҗрибәле юристлар. Биредә профессиональ компетентлык барыннан да элек әлеге эшне бөтен кыенлыклары һәм хәтта каршылыклары белән чагылдырырга омтылуда күренә. «Ачылган серләр» повестенда З. Фәтхетдинов тикшерү өчен аеруча катлаулы җинаятьләргә туктала. Әсәрдәге вакыйга сугыш алды елларында бара. Шәһәр Советы башкарма комитеты хезмәткәре Древцовның үтерелүе һәм квартиры талануы кебек уголовный практика өчен гадәти җинаятьтән башлап, автор ахырда немец разведкасының тәҗрибәле резидентын тоту шикелле зур һәм кыен операцияне яктыртуга барып чыга. Нәтиҗәдә аның әсәре бездә

киң таралган уголовный детектив рәвешендә башланып китсә дә, соңга таба аның идея-иҗтимагый колачы киңәя, ул политик детектив төсмерләрен дә ала. Республика эчке эшләр халык комиссариатының тикшерү бүлеге начальнигы подполковник Чурбанов җитәкчелегендәге тикшерүчеләргә дошманның бик нык яшеренгән шпионлык оешмасы белән очрашырга туры килә. Бу оешма члены узләренең җинаятьчел эшләрен зур профессиональ осталык белән һәм эз калдырмыйча, чиста итеп эшләргә өйрәнгәннәр. Чекистларның шушы яшерен оешманы ачу өчен алып барган, мажаралы хәлләргә бай булган, шул ук вакытта зур гына корбаннар да сораган көрәше әсәрдә сыйнфый янгыраш та ала. Чөнки немец разведкасы резиденты Волковская йөзендә без совет властеның килешмәс һәм мәкерле дошманы белән очрашабыз. Соңыннан, шпионлык эшчәнлеге тулысынча фаш ителгәч, революциягә кадәр Россиядәге иң бай кешеләрдән берсенең кызы булган бу хатын үзенең чын йөзен ачып сала:

— Күрә алмыйм мин сез кабахәтләрне! Изәргә, таптарга кирәк сезне! Ишетәсезме, таптарга! Шунысы кызганыч — бик аз үтердем мин сезнең кебекләрне!

Әле генә каралган әсәрләр, инде әйтелгәнчә, детективның туган әдәбиятыбызда мөстәкыйль жанр булып яши башлавында зур гына роль уйнадылар. Ә инде бу жанрның бездәге гомум торышы, төп сыйфатлары, минемчә, М. Насыйбуллин иҗатында тулырак чагыла. Ул — соңгы ун-унбиш ел эчендә детектив өлкәсендә иң актив эшли торган, дөресрәге, үз иҗатын тулысынча шушы жанрга багышлаган бердәнбер авторыбыз. М. Насыйбуллинның детектив өлкәсендә эшләве һич тә очраклы хәл түгел, бәлки бик табигый һәм законлы күренеш. Чөнки аның күп еллар юрист булып эшләү дәвамында туплаган тәҗрибәсе нәкъ менә детектив өчен аеруча бай материал бирә. Табигый, ул үз әсәрләрендә башлыча милиция һәм прокуратура органнарының җинаятьчелеккә каршы көрәше турында сөйли. Моңардан аның иҗатының мөһим сыйфаты — тормыш җирлеге нык булу килеп чыга.

М. Насыйбуллин әсәрләренә хас тагын бер әһәмиятле момент авторның жанр үзенчәлекләрен һәм таләпләрен яхшы белеп эш итүе белән бәйле. Ул сюжетның мавыктыргыч булуына дикъкать бирә. Кайбер детективлардан аермалы буларак, М. Насыйбуллин повестьларында мавыктыргыч сюжет һич тә ниндидер шаккатыризмга, баш әйләндергеч трюкларга яки гадәттән тыш вакыйгаларга корылмый. Хикәяләүнең тормышчанлыгына омтылып, ул башта бик катлаулы һәм серле булып күренгән җинаятьләрне ачканда да тормышта булырдай гадәти юлларны таба. Мисалга «Телсез шаһитлар» повестен алыйк. Бер авыл янында кар астыннан хатын-кыз мәете табыла. Мәетнең аяклары кисеп алынып, гәүдәсе капчыкка салынган булуы әлеге хатын-кызның кем тарафыннандыр үтерелүе турында сөйли. Шуннан башка бу үтерешкә кагылышлы бернинди дәлил дә табылмый. Мәет салынган капчыкны һәм кар астыннан килеп чыккан кечкенә бау кисәген исәпкә алмаганда, әлбәттә. Тәҗрибәле тикшерүче Гайнан Ибраһимов өчен исә алар әлеге җинаятьне ачуга нык булышкан «телсез шаһитлар»га әвереләләр. Беренче карашка бернинди әһәмияте булмаган кебек күренгән мондый детальләрне шулай уңышлы файдалануда тикшерүченең криминалистлык осталыгы, логик фикер йөртү сәләте мөһим роль уйный. Гомумән, М. Насыйбуллин тикшерүче геройларының профессиональ осталыгын ачуга зур игътибар бирә. Укучыны ул әледән-әле җинаять тикшерүнең эчке «лабораториясенә» алып керә, аның серләре белән таныштыра. «Алтын алка» повестенда автор болай яза: «Җинаятьчелек белән көрәшкәндә бер-берсенә охшамаган төрле-төрле чаралар күрергә, яңадан-яңа, моңарчы билгеле булмаган ысуллар, юллар эзләргә туры килә. Бу хезмәтнең бердәнбер максаты — җинаять кылырлык ышанычсыз затларга яисә җинаять эшләгән кешеләргә йогынты ясау, дөрес юлга бастыру. Йогынты ясау кешегә һичшиксез рухи тәэсир итүне дә күздә тота».

Язучы җинаятьне ачуда хәзерге фән-техника казанышларыннан файдалануга зур игътибар бирә. Моннан тыш җинаять урынында калган аяк эзләре буенча җинаятьченең буй-сынын чамалау яки чукраклар белән эш итүче тел белгече — логопед ярдәмендә яшерен камера белән төшерелгән кешеләрнең ирен хәрәкәтләренә карап, аларның нәрсә турында сөйләшкәннәрен ачыклау кебек алымнар тикшерүче эшенең профессиональлыгын конкрет күзалларга булышалар. Автор үз әсәрләрендә юридик белем пропагандалау белән дә шөгыльләнә. Кыскасы, М. Насыйбуллин җинаятьне тикшерүче геройларын — милиция һәм суд-прокуратура органнары хезмәткәрләрен — үз эшләренең осталары итеп күрсәтүгә нык игътибар бирә. Хәтта аның повестьларында җинаятьне ачу процессы катлаулы производство төсен дә ала дияргә мөмкин. Гомумән, геройларын хезмәттә күрсәткәндә М. Насыйбуллин беркадәр «производство» романнарындагыча эш итә кебек. Ягъни ул герой хезмәтен мөмкин кадәр конкрет һәм эзлекле күрсәтергә тырыша. Шул ук вакытта, боларны сурәтләү автор өчен бердәнбер максат булмавын да әйтергә кирәк. Ул бу хезмәтнең аналитик акыл белән эш итүне соравын күрсәтүгә, аның эчке җегәрен, поэзиясен ачуга басым ясый. Югарыда искә алынган Гайнан Ибраһимов үз эше турында болай ди: «Профессияләрнең берсе дә бу кадәр күпкырлы, бу кадәр мавыктыргыч

түгелдер. Тикшерүче кеше табигатенең бөтен якларын күзәтә, социаль тормышның кискен күренешләре белән очраша. Тикшерү эшенең күңелне тартып торган якларын санап бетерерлек түгел: кискен, мавыктыргыч көрәш, даими эзләнү, иҗат итү һәм, ниһаять, хакыйкатьнең җиңеп чыгуы». М. Насыйбуллин геройларының үз хезмәтенә мондый карашы аларның профессиясе белән генә түгел, бәлки тормыш позицияләре белән дә билгеләнә.

Менә шушы сыйфатлар М. Насыйбуллин повестьларын коры детективлыктан азат итә, аларның идея-эстетик яңгырашын көчәйтә. Әйе, теге-бу җинаять ачуны сурәтләү, укыр өчен никадәр генә кызыклы булса да, автор өчен үзмаксат түгел. Боларны тасвирлаганда ул үз алдына зуррак идея-эстетик бурычлар да куя. Аны якыннан һәм даими рәвештә кызыксындырган төп мәсьәләләрнең берсе — ул безнең тормышта ике төрле яшәү рәвешенең бәрелешен күрсәтү. Әсәрләрдә сурәтләнгән җинаятьләр дә нигездә бары үз мәнфәгатьләре турында кайгыртып, җиңел кәсеп белән һәм сорыкортларча яшәргә омтылуның котылгысыз нәтиҗәсе булып торалар. Мондый фәлсәфәгә бирелгән персонажлар үзеннән-үзе җинаять юлына баса. Шунлыктан М. Насыйбуллин повестьларында җинаятьчелеккә каршы көрәш безгә чит булган яшәү рәвеше белән көрәш төсен ала. Намуслы хезмәттән баш тартып, башкалар исәбенә, дәүләт исәбенә яшәргә омтылучылар «Яшерен касса» һәм «Алтын алка» повестьларында тулырак сурәтләнәләр. Дөрес, бу төр персонажларның яшәү фәлсәфәсе ничектер фараз кылып һәм декларатив рәвештәрәк күз алдына бастырыла. Икенче төрле әйткәндә, бирелә авторга еш кына персонажның эчке дөньясына үтеп керү җитенкерәми. Моңа кадәр үзенең дөрес яшәмәгәнен аңлый башлаган кешенә (мәсәлән, «Алтын алка»дагы Чекушкинны) тасвирлаганда бу эшнең кирәклеге бик тә сизелә. Персонажның эчке дөньясына ныграк игътибар иткәндә, психологик анализны көчәйткәндә образның идея-эстетик яңгырашы тагын да артыр иде.

Үз әсәрләрендә үзәк урын алган тикшерүче образын бирүдә М. Насыйбуллин уңышлырак эш итә. Автор алар хезмәтенең иҗтимагый-әхлакый мәгънәсен ачуга зур игътибар бирә. Алар җинаятьне тикшерү белән генә канәгатьләнмиләр, аның ничек хасил булуы турында да тирәнтен уйланалар. Бу уңайдан Гайнан Ибраһимовның түбәндәге уйлары кызыклы: «Кеше тумыштан чәчәк таҗына таңда төшкән чык тамчысыдай пакь була. Бернинди бозыклык та, начарлык та үз-үзеннән килеп чыкмый. Аларны кешеләр булдыра. Ләкин бер явызлык та, бер җинаять тә кешенең шәхси сыйфатлары белән генә билгеләнә алмый. Монда тормыш шартларының да йогынтысы юк түгел, әлбәттә». Дөрес, кеше тумыштан чәчәк таҗына таңда төшкән чык тамчысыдай пакь була, ягъни үткәндәге педагогика раслаганча, бала туганда ак кәгазь битен хәтерләтә һәм аңа ни теләсәң, шуны язарга мөмкин, дигән фикер хәзер фән тарафыннан бәхәскә алына. Генетика галимнәре кешене био-социаль зат дип бәяләүне яклап чыгалар. Кайбер тикшеренүләргә караганда, теге яки бу яшь кешенең җинаять юлына басуында нәселдән килә торган факторлар да билгеле бер роль уйныйлар. Аннан соң көндәлек тормышта да баланың теге яки бу сыйфаты белән ата-анасына һәм хәтта әби-бабасына охшавы еш очрый.

Әлбәттә, җинаятьчелек сәбәпләрен тикшергәндә биологик, ягъни нәселдән килә торган моментларны да искә алырга чакыру һич тә Ч. Ломброзо теориясен яклау дигән сүз түгел. Мәгълүм ки, бу буржуаз теория җинаятьчелекнең сәбәпләрен бары биологик факторларга гына кайтарып калдыра. Без исә җинаятьчелекнең социаль сәбәпләр белән дә бәйләнгәнлеген һәм аны булдырмау өчен киң җәмәгатьчелек, бөтен җәмгыять көрәшергә тиешлеген яхшы беләбез. Инде әйтелгәнчә, бу мәсьәләне хәл итүдә әдәбият өстенә дә зур эш төшә. Күргәнебезчә, аның белән безнең детектив жанрда эшләүче авторларыбыз да актив кызыксыналар. Дөрес, яшүсмерләрнең җинаять юлына басу сәбәпләрен алар хәзергә башлыча бер өлкәдә — семьяда эзлиләр. Әлбәттә, аларның яшь буынны тәрбияләүдә семьяның ролен күтәрергә чакырулары кирәкле һәм урынлы. Чөнки күп кенә семьяларда татулык булмау яки аларның еш кына таркалуы баланы үстерүгә кире йогынты ясый. Шуның белән бергә, яшь буынны тәрбияләү, анда җинаятьчелек күренешләрен булдырмау мәсьәләсе бер семьяга гына кайтып калмаганын, аның башка, бәлки әле тагын да җитдирәк факторлар белән дә бәйләнгәнлеген онытырга ярамый.

Безнең хәзерге тормыштагы җинаятьчелек күренешләрен киңрәк планда һәм тирәнрәк, психологик анализ ярдәмендә дә чагылдыруларын теләү белән бергә, детектив өлкәсендә эшләүче авторларыбыздан бу жанрны тематик яктан төрләндерүләрен дә көтәсе килә. Әйтик, тарихи, хәрби һәм политик темаларга багышланган әсәрләр язылсын иде. Мондый темаларга алыну жанрның яңарак формаларына мөрәҗәгать итүне, сәнгатьчә эзләнүләрне активлаштыруны сорый, әлбәттә.

Гомумән алганда, бер нәрсә ачык: детектив өлкәсендә эшләнгән эшләребезне искә алу һәм нигездә уңай бәяләү белән беррәттән, безгә бу жанрга игътибарны тагын да арттырырга, язучыларыбызның гомумсовет детектив әдәбиятына зуррак өлеш кертүләренә ирешергә кирәк.

# УЙЛАНДЫРА, ТӘЭСИР ИТӘ

Кайберәүләр укыган китапларының кыскача эчтәлеген, төп геройларның сыйфатларын, аларга карата үз фикерләрен аерым дәфтәргә язып баралар. Моның файдасын белсәк тә шуңа ирешеп булмый. «Вакыт юк»,— дип акланырга күнеккәнбез.

Шулай да Газиз Кашаповның «Язмышыңа ышан» дигән романын укыгач («Казан утлары», 1985, 3—4 саннар) кайбер нәтиҗәләремне, уй-фикерләремне язып куярга булдым әле. Ул гына җитмәде, язганнарымны «Казан утлары» журналына да җибәрергә кыюлык итәм.

Газиз Кашапов романы бүгенге көн вакыйгаларының кайнар эзеннән язылуы белән үзенә тарта. Автор башта «Татарстан АЭСын төзүчеләргә багышлыйм» дип үз иңенә гаять зур вазифа алуын игълан итә. Төзелеш барышына күз салу, әлбәттә, үзе дә бик кызыклы. Әмма әсәрне укыганда син анда эшләүче күп санлы кешеләр арасыннан сайлап алынган дистәләп геройның язмышы, алар башыннан кичкән вакыйгалар, шатлыклар, кайгылар, хәтта фаҗигаләр тәэсирендә каласың. Шул ук вакытта аларга карата үз фикерләрең дә туа бара.

Төзелеш берләшмәсе җитәкчесе Вергилий Никифорович Дикопольцев минем күңелдә соклангыч образ булып урнашып калды. Ул, автор әйтмешли, зур төзелешләрдә эшләп һәм яшәп, энә күзеннән кереп, җепнең очыннан чыккан кеше. Аны инде берниндиг кыенлык, төзелешләрдәге ыгы-зыгы, иң югарыдагы җитәкчеләрнең килүе белән дә каушата алмыйсың. Каты куллы, принципиаль, таләпчән, үзенең һәр сүзенә хуҗа булып әверелгән җитәкче. Вакыт-вакыт үтә кырыс та кебек. Алай ук ярыймы икән, дип тә уйлап куясың. Шул ук вакытта ул бик гади тоелган нәрсәләргә дә игътибарлы. Мәсәлән, аерым кешеләрне туган көннәре белән котларга да онытмый. Әмма «кайчагында безнең Атакай кебек (Дикопольцевны шулай дип йөртәләр) акыл иясе, тәҗрибәле җитәкче дә ялгыша». Тик искиткеч рухи көчкә ия булган бу кеше ялгышын таныргa да, аны төзәтергә дә көч таба.

Вергилий Никифорович образы никадәр сокландырса да, миңа бигрәк тә йортлар төзү комбинаты начальнигы Фазыл Артышевич Айбулатов образы күбрәк ошады. Яңа шәһәрнең урыны турында аның үз фикере бар. Ул табигать матурлыкларын саклап калу ягында. Берләшмә җитәкчесенең бу идеягә каршы булуына карамастан, ул үз планын кискен яклый, югарыдагы коллегиядә үз фикерен үткәрүгә ирешә.

Фазыл Айбулатов яшь шәһәрләрнең һәркайсы матур, киләчәк буын кешеләренең зәвыкларына туры килә торган булырга тиеш дип саный. Һәм ул юк проектны бар итеп, Чаллыярда йорт төзегәндә спорт сарае, су бассейны, яшь гаиләләр өчен махсус йортлар коруны да киләчәк интересларыннан чыгып эшли.

Чынлап та, яши торган төбәгеңнең, тора торган йортыңның матурлыгы рухыңа тәэсир итмичә калмый бит. Матур урында үзеңне дә матур тотасы килә.

Төзелешне нәрсәдән башларга? Монда да Айбулатовның үз принцибы. Беренче зур бина мәктәп бинасы булырга, беренче сентябрьгә кадәр һичшиксез тәмамланырга тиеш. Һәм ул шулай була да. Монда без җитәкченең сүзе белән эше арасында ныклы бердәмлекне күрәбез. Әле бит аңа аяк чалып торучылар, кирәкле материаллар белән тәэмин итүдә тоткарлык ясаучылар да бар.

Партиянең шәһәр комитеты секретаре Мирас Гайнанович Борнашев образы да биләп ала. Төзелештәге эшләргә ул һәрвакыт игътибарлы, кыен хәлләр туганда ярдәм дә оештыра. Берәүгә дә каты орынмый, әмма һәрвакыт таләпчән.

Менә шушы җитәкчеләрнең эшләрен күз алдыннан үткәрәсең дә, үз хезмәтеңне ничек оештыруың турында уйланасың. Бүгенге көн белән генә яшәмибезме? Киләчәк буыннар безгә рәхмәт әйтерлек итеп эшли беләбезме? Бу барыннан да элек җиргә, табигатькә мөнәсәбәтебезгә кагыла. Һәркем күңеленә яраулы ачкыч таба алабызмы? Арада әле эчкечеләр, дисциплина бозучылар да очрап куя. Аларга карата битарафлар, йомшак

күңелләләр бар. Житәкче исә андыйларга катгый булырга тиеш.

Гаяр Сәфәров та төзүчеләр арасында зур дәрәҗә казанган кеше. Ләкин егет масая башлый, үзен коллективтан өстен тота. Ул коллективның мактаулы төзүчесен буләкләнүчеләр исемлегеннән хатыны сүзе белән төшереп калдырырга барып житә. Соңыннан ул, әлбәттә, үзенә нәтиҗә ясый. Бай тәҗрибә туплаган төзүче буларак зур бер коллективның житәкчесе итеп билгеләнә. Миңа Гаярның көндәлек дәфтәр алып баруы бик ошады. Шуны эшли алсак, кечкенә генә булса да бер коллективның күпме тарихын теркәп барыр идек.

Дикопольцев романда корыч ихтыярлы житәкче итеп гәүдәләндерелә. Югыйсә ул инде күптән лаеклы ялда булырга тиеш, җиденче дистәне тутырган ветеран. Сугыш елларын ул фашистларның үлем лагеренда үткәрә, биш тапкыр качып та, кабат эләгә. Какшамас рухы, физик ныклыгы белән мең әҗәлне кире бора, каршылык группасы житәкчесе буларак, фашистларга каршы яшерен көрәш оештыра. Әсирлектән котылгач та язмыш аңа каты сынаулары белән кизәнә... Ләкин ул үзен башкача күз алдына китерә дә алмый. Инде картаюны, үзенә алмаш кирәклеге турында уйланса да, бу хәл белән килешәсе килми. Әсирлектә үзен үлемнән коткарышкан Санук апа белән очрашканнан соң аның йөрәге бу хәлдән туган көчле дулкынлануны күтәрә алмый. Терелгәч инде ул үз урынына Фазыл Айбулатовны тәкъдим итә. Ләкин бөтенләй отставкага китү шарты белән түгел. Биредә трактор заводы төзелү хәбәре аны кабат яшәрткәндәй була. Ул әле төзелештә консультант булып та үзенең өлешен кертә алачак. Партия органнары аның бу теләген хуплыйлар гына.

Шулай ук гыйбрәт алырлык вакыйга бу! Без кайбер талантлы житәкчеләрне лаеклы ялга иртәрәк озатмыйбызмы? Озатсак та, соңыннан аларны онытып җибәрмибезме? Бәлки безгә теге яки бу мәсьәләне хәл иткән чагында, аптырап калганда, ветеран агайның бер киңәше житә торгандыр!

Романда алардан башка да гыйбрәтле язмышлар шактый. Гөлфирә белән Нурлыбикә — бер-беренең капма-каршысы. Гөлфирә яшь кенә булса да көчле ихтыярлы, саф күңелле хатын буларак күз алдында үсә барса, җиңел тормыш яратучы Нурлыбикә исә һаман түбәнгә таба тәгәри. Ахырдан иренә хыянәт итеп, үтә хәйләкәр бер мошенник кармагына эләгә, тәмам хурлыкка кала.

Олы бер төзелеш, төрле-төрле язмышлар. «Язмышыңа ышан» — ди автор романына исем кушканда. Язмышка ышанып тору житмидер, мөгаен. Чөнки, көрәшсез генә язмыш дулкынында чайкалып бара алмыйсың.

Мин романның азагына житкәнче анда төзелеш партия комитетының роле күренер дип уйлаган идем. Бу булмады. Аннан соң, ни өчендер, авыл вәкилләре белән дә очрашмадык. Исемнәре саналып кына үткән образлар да бар. Роман Айбулатовның җәмәгате Йолдызбану белән башланып китсә дә, соңыннан ул пәрдә артында калды.

Роман ил күләмендә билгеле олы төзелешне колачлаучы, андагы эшне яктыртучы әсәр буларак күңелдә кала. Андагы образлар практик тормышта үз «киңәшләрен» биреп торалар төсле.

**Равил СӨНГАТУЛЛИН,**
Саба районы «Беренче Май» колхозы председателе.

* * *

Г. Кашаповның «Язмышыңа ышан» дип исемләнгән романын зур кызыксыну белән укып чыктык.

Үзебез турында берничә сүз язып китми булмас. Без Башкортстанда туып үстек. Милләтебез — татар. Соңгы елларда Татарстанның Зәй каласында тордык. Хәзерге вакытта Төмән өлкәсенең Ноябрьск шәһәрендә яшибез.

Башкортстаннан күчеп, Зәйдә тора башлагач, «Казан утлары»н даими рәвештә укып барабыз. Ноябрьск шәһәрендәге китап кибетендә үзебезнең журналны сатып алу — үзе бер зур бәйрәм булды.

Күңелгә ятышлы тел белән язылган «Язмышыңа ышан» романын без тиз генә укып чыкмадык. Һәр кичне бер бүлекне укыйбыз, аның турында фикерләшәбез, бәхәсләшәбез.

Бу әсәр күп меңләгән кешеләр катнашында барган төзелешләр турында һәм алай гына да түгел.

Бигрәк тә безнең туган-үскән җирләребездә башланган бу төзелешкә халкыбызның мөнәсәбәте, аның күкрәк киереп, иркен сулап, эшләрнең үз эчендә кайнавы, һәм шул ук вакытта киләчәк тормыш турында матур итеп уйлый

белүе, киң характерлы геройлар аша бирелгән булганлыгы әсәрнең зур отышыдыр.

Мондый әсәрне без күптән көткән идек. Уйлавыбызча, аның бик күп отышлы яклары бар.

Әсәрдә күтәрелгән төзү-төзелеш мәсьәләләре, табигатьне саклау турындагы бәхәсләр, гаилә, ир-хатын, балалар хакында уйланулар, әхлакый бурыч турында каты итеп язулар — болар барысы да безне тыныч кына калдыра алмады.

Айбулатовның без халкыбызның иң матур, иң акыллы, батыр егетләре арасыннан үсеп чыккан кеше икәнен аңладык. Аның төзелештә алып барган уңышлары, кешеләргә булган гаять тә зур таләпчәнлеге, шул ук вакытта кешелекле булып калуы, алар белән, гади эшчеләр белән аралашып яшәве ышандырырлык язылган.

КамАЗ, АЭС төзелеше башлану бик зур төбәк — Кама буе халкының яшәвен үзгәртте. Андагы яшь шәһәрләрдә яшәгән халыкның күбесе кичәге авыл кешесе. Алай гына да түгел, күбесе татар милләте кешеләре. Ә менә шул халыкның барлык булган иң уңай сыйфатларын җыйган һәм ил күләмендәге югарылыкка күтәргән Айбулатов үзенең «ролен» бик ачыклап җиткерми кебек. Без аның авызыннан үзебез көткән кайбер сүзләрне ишетмибез. Ачыклабрак әйтсәк, сүз йортлар төзегәндә татар милли бизәкләрен куллану, урамнарны бизәү, туган телебезнең чисталыгы өчен көрәш һ. б. турында бара.

Шулай ук Айбулатовның, чыгышы буенча авыл егете булып та, һәм башка эшчеләрнең күбесе җирдән яңа гына аерылган булсалар да — зур шәһәрләр, заводлар төзү бу төбәкне искитмәле нык үзгәртсә дә — аның, Айбулатовның, бу мәсьәләләргә, шәһәр-авыл мөнәсәбәтләренә карашын без аңламадык. Чөнки алар әсәрдә юк дәрәҗәсендә. Ә бит, шәһәр-авыл мөнәсәбәтләре Чаллы, Түбән Кама якларында гаять тә олы эш диеп исәпләнде һәм исәпләнә дә.

**МӘҖИТОВЛАР** гаиләсе.

# КЫЗЫКСЫНЫП УКЫДЫМ...

Барлас Камаловның «Өметең өзелмәсен» романы герое Илфат Маннуровка әсәр башында ук Алтын Йолдыз тапшырылды. Бу укучыны сагайта да, шул ук вакытта кызыксыну да уята. Һәм менә көтелмәгән авыру геройга безне үткән тормышы белән таныштырырга, узган гомеренең иң истәлекле вакыйгаларын яңабаштан хәтереннән кичерергә мөмкинлек бирә.

Илфат Маннуровның бу зур финишка ничек әзерләнүен, аның шәхес буларак формалашуын автор укучыга ача алган. Бөек Ватан сугышы авырлыклары ул чор буынын чыннан да зур сынауларга дучар итте һәм аны уңышлы үтүчеләр бүген дә хезмәт фронтының алгы сызыгында.

Төп геройның тормыш юлын кат-кат уемнан кичерәм һәм аны зур финалга алып килгән сукмакларны күз алдына бастырырга тырышам. Роман герое Илфат яшьлек елларының һәр вакыйгасын җентекләп хәтерләсә дә, бүгенге көн проблемаларын аз исенә төшерә. Ә бит Алтын Йолдыз гади бүләк түгел. Һәм ул бүгенге уңышларны күздә тотып тапшырылган да. Мондый дәрәҗәгә бары тик алдынгы алым белән эшләүче, алдагы көнне күрә белеп яшәүче хезмәт кешесе генә ирешә ала. Бүгенге хезмәт коллективында игътибар сораучы проблемалар күп һәм алар, әлбәттә, конфликтларсыз, җиңел генә хәл ителә торган мәсьәләләр түгел. Аларны тормышка ашыруда һәр коллектив членының актив эшләве кирәк. Илфат Маннуровны әнә шул рольдә дә күрәсем килгән иде минем.

Миңа калса, автор романда үзенең күңелендә сакланган балачак, үсмер еллар вакыйгаларын сөйли һәм Илфат Маннуров әнә шуларны укучыга җиткерүдә бәйләнеш чылбыры вазифасын үти төсле.

**Х. ШӘРИПОВ,**
Пермь өлкәсе, Барда районы.

библиография

# АЗАТЛЫК ҖЫРЧЫСЫ

Күренекле тарихчы һәм узган гасырның 60 нчы елларындагы иҗтимагый хәрәкәтнең актив эшлеклесе Афанасий Прокофьевич Щапов (1831 — 1876) турында соңгы елларда Казанда бер-бер артлы ике китап дөнья күрде[1]. Бу очраклы күренеш түгел, әлбәттә. Чөнки фаҗигале язмышка дучар булган А. П. Щапов нәкъ менә Казанда алдынгы карашлы, хөр фикерле галим булып формалаша. Казан студентларының революцион түгәрәге эшчәнлеге дә А. П. Щапов исеме белән тыгыз бәйләнгән. Галимнең бу өлкәдәге эшчәнлеге үзенең иң биек ноктасына Россиядә беренче революцион ситуация (1859—1861) елларына туры килә. һәм ул чор Щаповның Казанда яшәгән елларын эченә ала.

А. П. Щаповның иҗат мирасын өйрәнү эше узган гасырның 70 нче еллары азагында башланган. Бу эштә башлап юл яручылар галимнең шәкертләре һәм якташлары була. Аларның тырышлыгы нәтиҗәсендә А. П. Щаповның биографиясен һәм фәнни мирасын өйрәнү өчен мөһим булган күп кенә чыганаклар Октябрь революциясенә кадәр үк дөнья күрәләр.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң Щаповның тормыш юлын һәм эшчәнлеген өйрәнүгә Казан тарихчысы Е. И. Чернышев күп көч куя. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә бу темага караган бик күп кыйммәтле тарихи чыганаклар тикшеренүчеләргә билгеле булды, басылып чыкты. Щаповның тормышын һәм иҗат мирасын өйрәнүчеләр арасында оригиналь фикерләре һәм полемик рухта язылган хезмәтләре белән аерылып торган күренекле совет тарихчысы, академик М. В. Нечкина исемен дә атарга кирәк.

Ләкин галимнең тормыш юлын, фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлеген өйрәнүнең йөз елдан артык тарихы булуга карамастан, әлегә кадәр бу өлкәдәге казанышларны гомумиләштергән фундаменталь монография язылганы юк әле. Шундый хезмәтне барлыкка китерү юлында тикшерелә торган ике китап яңа зур адым булып тора.

В. Ф. Семеновның «Үлемсез исемнәр» сериясендә чыккан китабында, А. П. Щаповның тормыш юлы, иҗтимагый-политик, тарихи һәм экономик фикерләре эволюциясе эзлекле рәвештә тасвирлана. Щаповның катлаулы, каршылыклы фикри үсеш кичерүе соңгы елларга кадәр аның идея позицияләренә бәяләмә бирүдә буталчыклыклар китереп чыгарды. В. Ф. Семенов бу уңайдан әйтелгән фикерләргә кыскача анализ ясый, һәм академик М. В. Нечкинага кушылып А. П. Щаповның революцион-демократик позицияләрдә торганлыгын ышандырырлык дәлилләр белән исбат итә.

Галимнең фикри үсеш тарихын автор дүрт этапка бүлә һәм һәркайсына кыскача характеристика бирә. Россиянең экономик үсеше һәм политик экономия тарихы проблемалары буенча А. П. Щапов фикерләре анализланган бүлекләр аеруча кызыксыну уята. Узган гасырның 60—70 елларында алдынгы иҗтимагый фикер тарихында тирән эз калдырган А. П. Щапов турында укучыларга кыскача мәгълүматлар бирү максатыннан язылган бу хезмәте белән В. Ф. Семенов үз максатына тулысынча ирешкән дип әйтәсе килә.

Икенче китапның авторы профессор Г. Н. Вульфсон А. П. Щаповның тормыш юлын һәм эшчәнлеген өйрәнү, тикшерү белән озак еллардан бирле шөгыльләнә. 1940 елның көзендә ул А. П. Щаповның Куртинск панихидасында, ягъни тантаналы җеназада катнашуы турында студентларның фәнни түгәрәкләрендә чыгыш ясый. Шул вакыттан бирле аның революционер-галим тормышы һәм эшчәнлеге белән кызыксынуы дәвам итә. һәм, ниһаять, безнең алдыбызда күптөрле тарихи чыганакларга таянып язылган хезмәт ята. Бу китап үзенең күләме һәм эченә алган материаллары белән дә элекке хезмәтләрдән күп яклары белән аерылып тора. Тарихи биографик жанрда язылган хезмәтнең һәр сәхифәсеннән зур эрудициягә, тарихи чыганаклар белән эшләүнең югары осталыгына ия булган тикшеренүче кулы сизелеп тора.

Г. Н. Вульфсон Щаповның тормыш юлын дүрт чорга бүлә: 1) тууыннан алып Иркутск академиясен тәмамлаганга кадәрге чор (1831—1852 еллар); 2) Казан чоры (1852—1861 елның апрель азагы); 3) Петербург чоры (1861 маеннан 1869 елның язына кадәр); 4) полиция күзәтүе астында Себердә яшәү чоры (1869 елның җәеннән 1876 елның февраленә кадәр). Шунысын әйтеп үтү зарури: автор А. П. Ща-

[1] Семенов В. Ф. А. П. Щапов. Казань, 1983; Вульфсон Г. Н. Глашатай свободы. Страницы из жизни Афанасия Прокофьевича Щапова. Казань, 1984.

повның тормыш юлын һәм эшчәнлеген тулысынча яктыртуны максат итеп куймаган. Монографиядә сүз асылда галимнең Казандагы эшчәнлеген тасвирлауга багышланган. Тагын да төгәлрәк әйткәндә, төп игътибар А. П. Щапов биографиясендә зур урын алып торган җиде ай вакытны яктыртуга юнәлдерелгән.

Монографиядә А. П. Щаповның Россия тарихына карашлары формалашу, разночинец интеллигенциясенең революцион көрәшендә катнашуын күрсәтү төп урынны алып тора.

Әйе, ерак Иркутск губернасының караңгы бер авылында, ярлы дьячок һәм бурят хатыны гаиләсендә дөньяга килгән А. П. Щаповка авыр һәм гыйбрәтле тормыш юлы үтәргә туры килә. Иркутскидагы дини мәктәп — бурсаны бетергәч язмыш аны Казандагы дини академиягә китерә. Дини уку йортларында уку Щаповның беренчел карашларына йогынты ясамый калмаган, әлбәттә. Ләкин дини академиядә укыганда ук аңарда алдынгы иҗтимагый-политик, тарихи һәм экономик карашларның элементлары формалаша башлый. Илдәге социаль һәм экономик каршылыкларны ачып салган Кырым сугышыннан (1853—1856) соң туган хәл иҗтимагый фикергә дә йогынты ясамыйча калмады. Дини академиядә дә яшерен әдәбият тарала башлый. Шуларның тәэсирендә А. П. Щаповта да заман проблемалары белән кызыксыну көчәйгәннән-көчәя бара. Узган гасырның илленче елларында академия студентларына, шул исәптән Щаповка да, Г. З. Елисеев, А. Ф. Гусев, А. А. Бобровников кебек укытучыларның йогынтысы зур була. Әйтик А. Ф. Гусев таныштыра; соңыннан «Современник» журналы редакторларыннан берсе булган Г. З. Елисеевның рус тарихы буенча укыган лекцияләре тыңлаучыларда демократик карашлар туугa җирлек әзерли. Шул чорның прогрессив галиме профессор Т. Н. Грановскийның шәкерте, тарихчы С. В. Ешевский, Россиядә славян филологиясенә нигез салган галим В. И. Григорович белән танышлык та Щаповка уңай йогынты ясый. Дини академиядә уку һәм укыту чорында язылган хезмәтләрендәге фикер каршылыкларына, дини карашлар белән өртелгән фикерләренә карамастан, хәтта рәсми газета — «Казанские губернские ведомости» газетасы да, аларда социаль изүгә каршы кыю протест булганлыгын танырга мәҗбүр була.

А. П. Щаповның карашлары формалашуда Чернышевский, Добролюбов, Герцен, Огарев кебек революцион-демократларның роле аеруча зур булган.

1860 елның көзендә А. П. Щапов Казан университетында рус тарихын укыта башлый. Беренче лекциясеннән үк ул демократик студентларның яраткан укытучысына әверелә. «Великорус халкы тарихына гомуми караш» дип аталган беренче лекциясе үк Щаповны заманының алдынгы карашлы вәкилләре сафына бастыра. Университет кафедрасыннан яшь галимнең «тарихта төп фактор — халык, тарихның төп эчтәлеге — халык тормышы» дигән сүзләре яңгырый.

Рус халкы тарихи мәсьәләләрен лектор турыдан-туры ул заманның иң мөһим социаль-экономик проблемалары белән бәйләп аңлата. Ә андый мәсьәләләрнең иң зурысы һәм иң катлаулысы Россиядә крепостнойлык тәртипләрен бетерү мәсьәләсе иде. Крестьяннарны крепостнойлык тәртипләреннән азат итү тарихы турында сөйләгәндә ул моны исемнәре үк властьларда курку һәм нәфрәт тудырган Радищев, Рылеев, Герцен исемнәре белән бәйли. Бу — ул чордагы рәсми тарих фәнендә күрелмәгән хәл була. Яшь галимнең икенче бер лекциясендә сүз декабристлар хәрәкәте һәм аның идеяләре турында бара. Щаповның бу лекциясе турында Г. В. Плеханов: «Безнең университетлар тарихында бердәнбер дип әйтерлек һәм гаҗәеп дәрәҗәдәге кызыклы факт»,— дип яза.

Университетта укыту белән бергә А. П. Щапов Казан разночинец интеллигенциясенең революцион-демократик хәрәкәтендә дә актив катнаша. Казан студентлар түгәрәгенең идея җитәкчесе була.

1861 елда Казан губернасы Спас өязенең Бездна авылында зур крестьяннар восстаниесе була. Бу — крепостнойлык тәртипләрен бетерүнең крепостниклар мәнфәгатьләреннән чыгып үткәрелүенә каршы иң зур протест иде. Восстание властьлар тарафыннан канга батырыла. Вәхшиләрчә үч алуга җавап итеп студентлар 16 апрельдә Казан зиратындагы (Куртин чиркәве дип аталган) чиркәүдә «Ирек өчен чуалышларда үтерелгән» крестьяннарга багышлап тантаналы җеназа үткәрәләр. Анда Щапов дулкынландыргыч речь белән чыга һәм чыгышын демократик конституция таләп итү белән тәмамлый. Щаповның бу чыгышы 60 нчы еллар башындагы Россиядә булган революцион ситуацияне чагылдыручы мөһим программ документлардан санала.

Александр II Щаповны кулга алырга, ә Синод монастырьга ябарга хөкем итә. Ләкин Н. Г. Чернышевский тарафыннан оештырылган протест һәм киң җәмәгатьчелек фикере басымы астында патша бу карарны юкка чыгарырга мәҗбүр була. Щаповның Казан чоры тормышы әнә шундый давыллы вакыйгаларга бик бай.

А. П. Щаповның тормышын, фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлеген өйрәнүне тарихчылар киләчәктә дә дәвам итәрләр, әлбәттә. Шуңа күрә, бу өлкәдә тәфсилле анализ таләп итүче кайбер мәсьәләләргә тукталасы килә.

В. Ф. Семенов брошюрасының 59 битендә күренекле татар галиме һәм мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның дөньяга карашлары формалашуы А. П. Щаповның политик һәм социаль-экономик идеяләре тәэсирендә бар-

ды дип раслана. Бу — кызыклы, ләкин яңа фикер түгел. Моңа кадәр дә кайбер тарихчылар (мәсәлән, С. М. Михайлова) бу фикерне әйткәннәр иде инде. Ләкин ул декларатив, конкрет тарихи чыганакларга нигезләнмәгән фикер булып кала бирә. Тарихчыларыбыз алдында бу фикерне бер хезмәттән икенчесенә күчереп йөртү урынына, конкрет тарихи фактлар, чыганаклар белән дәлилләү вакыты җитте, мөгаен. Һәрьяклап тикшеренүне таләп итүче тагын бер проблема: ул А. П. Щаповның рус булмаган халыкларның язмышына, тарихына карашы мәсьәләсе. Анализлана торган хезмәтләрнең берсендә дә бу проблема махсус тикшеренү объекты итеп алынмаган. Ләкин ике автор да бу мәсьәләне читләтеп үтмиләр. Узып барышлый булса да Щаповның рус булмаган халыклар турындагы фикерләренә игътибар иткәннәр. Рус революцион-демократларының алдынгы вәкилләре кебек үк интернационализм позицияләрендә торган А. П. Щапов бөтен рус халкын «рус булмаган көнчыгыш халыклары — безнең туганнар» икәнен аңларга өнди. «Татарларны гына түгел, ә бәлки бурятларны, кыргызларны һәм камчадалларны да уку-укыту тәҗрибәсе, безнең рус булмаган көнчыгыш халыкларының фәнни үсешкә сәләтлелеген күрсәтә»,— дип яза галим. Киләчәктә тарихчыларыбыз бу мәсьәләгә дә игътибар итәрләр дип ышанабыз.

Кыскасы, авторлар укучыны Ватаныбызның А. П. Щапов кебек күренекле галиме һәм гражданины белән таныштыруда зур эш башкарганнар.

**Җәүдәт МИҢНУЛЛИН.**

# *Хатлардан юллар*

Безнең халык матур уйлый, матур эшли һәм матур сөйли дә. Әнә авыл агайлары, эшләрен бетереп, бераз тын алырга, дөнья хәлләрен сөйләшергә утырганнар да гәп саталар. Тема киң: янки-чәнкиләрнең җиде бабасын барлап чыгу дисеңме, төрле тарафлардан килеп ишетелгән гыйбрәтле хәлләрме, авылда элек һәм хәзер булган һәм киләчәктә булачак вакыйгалар, фәлән язучының яңа гына чыккан әсәренә иң беренче тәнкыйть сүзе... Аларның сүзен соклану һәм гаҗәпләнү катыш мөкиббән китеп тыңлап торыйк та, алар теленә эләккән бер язучының китабын ачып карыйк. Менә бер өзек: «Ашханәдә өстәл янына утырган гына идек, ишектән ашыгып парторг Рунт килеп керде. Кулында кәгазь, күзләренә мөлдерәп яшь тулган.

— Иптәшләр! Кадерле сугышчан дусларым! Бүген 6 ноябрьдә иртәнге сәгать дүрттә Беренче Украина фронты гаскәрләре Советлар Украинасының башкаласы, Россия калаларының әнкәсе булган Киевны фашист илбасарлардан тулысынча азат иткәннәр!»

Нәрсә җитешми? Җөмлә төзек, озын, информациягә бай, җөмлә кисәкләре барысы да үз урынында. Мондый халәттәге кеше алай сөйләми, хисләр дулкыны кешегә җөмләне төзекләп торырга ирек бирми, иясе-хәбәре булса — бик шөкер, ә бу өзектәгечә тарихи экскурслар ясап тору мөмкинме соң. Язучы ситуацияне дөрес тасвирламый. Музыка теле белән әйтсәк, әсәрнең бу урынында тавышны яртымы, бер тонгамы бозып ала. Ә бу укучыларның сизгер колагын авырттыра. Ш. Рәкыйповның «Кипарислар җыры»нда очучы батыр кызларыбызның сөйләве һәм фикер йөртү рәвеше әнә шулай еш кына авторныкыча. Шул ук авторның «Кайдан син, Жан?» әсәреннән бер өзек: «Ә «җанвар» алдавычка капты, егетләр дә аптырап калмадылар. Әллә шулай киенеп йөргән үзебезнең кешене кәкрәйттеләрме?»

Ә укучы бу юлларны укыгач, аптырап кала тек кала инде. Беренче җөмләдә «егетләр аптырап калмасалар да», ә икенчесендә аларның аптырап калуларын күрсәткән сорау туа. Рәттән торган ике җөмләдәге капма-каршылыкны автор күрмиме?..

Дөрес, кешенең үлүе турында «үлде, вафат булды, һәлак булды, кәкрәйде, дөмекте» дигән сүзләр белән сөйлиләр. Ләкин бу сүзләрнең һәркайсының үз урыны, үз мәгънәсе, төсмере, нагрузкасы бар. Әгәр сугыш операциясе вакытында кеше үлсә (сүз безнең кеше турында бара!), бу үлемне без авыр кичереп, баш иеп, «һәлак булды» дибез. Ә «кәкрәйде, дөмекте» дию бу очракта ямьсез сүз әйтү булып яңгырый.

Әсәрнең нигезен тәшкил иткән материал никадәр әһәмиятле булмасын, аның сюжеты никадәр мавыктыргыч булмасын, әгәр «сүзләр-солдатлар» үз урыннарын алмаса, әсәрнең сәнгать югарылыгына күтәрелә алмаячагын көт тә тор. Сүзләрне үз урынына куймыйча, аларның бизәкләрен, көч-куәтен, җегәрен чамаламыйча әсәр тудырырга тырышу — әйбәт төзү материалын бозу, кибәнне кыек итеп өю белән бердер.

**М. ТАЙМАСОВ.**
Минзәлә шәһәре.

# ЗАҺИДӘ БУРНАШЕВА

ТУУЫНА 90 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Яңа революцион күтәрелеш елларында матбугатка килеп, лирик шигырьләр язуы белән танылган, бөтен гомерен социализм казанышларын саклау һәм үстерүгә биргән карт большевик Заһидә Бурнашеваның тормыш юлы бик гыйбрәтле.

Ул 1895 елның 19 октябрендә хәзерге Рязань өлкәсенә кергән Әҗе авылында сәүдәгәр-маклер гаиләсендә туа. Башлангыч белемне үз авылында ала, соңрак күрше авыл мәктәбендә укый. Үз авылларында яшәүче рус кызлары белән аралашу аңа яшьтән үк рус телен үзләштерергә ярдәм итә. Ул Пушкин, Лермонтов, Кольцов, Тукай, Ф. Әмирхан һәм Дәрдмәнд кебек классикларның әсәрләрен яратып укый.

Заһидәнең укуга бирелүен, яңалыкка омтылуын патриархаль тәртипләргә ябышып яткан ата белән ана гаилә башына төшкән бәхетсезлек дип карыйлар. Ничек кенә булмасын, аны бу юллыннан туктатып калырга тырышалар, рәнҗү-каргау белән куркыталар. Кызының шигырь язуын һәм рус мәктәбенә укырга китәргә җыенганын белгәч, анасы бөтенләй ярсый, аның барлык китапларын, язган нәрсәләрен яндыра. Кием-салымын бикләп куя, хәтта иптәшләре белән аралашудан да тыя. Ул гына да түгел, үз кызына үзе яла ягуга кадәр барып җитә. Старшинадан кызына паспорт бирмәвен үтенә.

1914-1915 елларда Заһидә чын фамилиясен яшереп, «Гыйффәт туташ» псевдонимы белән шигырьләр бастыра башлый.

З. Бурнашева 1915 елның 6 сентябрендә «Вакыт» газетасында басылган ачык хаты белән татар халкының прогрессив көчләренә мөрәҗәгать итә.

Заманның прогрессив кешеләре яшь кызның мөрәҗәгатен игътибарсыз калдырмыйлар. Беренче чиратта аны алдынгы татар матбугаты яклап чыга. Петербургта укучы татар студентлары «Вакыт» газетасында: «...Бертуктаусыз яхшылыкка вә югарылыкка омтылган шагыйрәнә күңелнең кара көчкә бирелеп, аның тырнагында кала алмаганын аңлыйбыз. Шагыйрәбезнең бу көчтән котылу юлындагы батырлыгы алдында тез чүгәбез вә бөтен күңелебез белән алкышлыйбыз»,— дип язалар.

Сокландыргыч батырлыкка ия булган Заһидә Бурнашева, ниһаять, Мәскәүгә килеп чыга. Аңа авылдашлары Ибраһим Бурнашев (соңыннан танылган партия эшлеклесе), Габдулла Бурнашев эшкә урнашырга ярдәм итәләр. Аның шигырьләре газета-журналларда бер-бер артлы басыла башлый. Нәтиҗәдә, 1915-1916 елларда аның «Гыйффәт туташ шигырьләре» исемле җыентыгы дөнья күрә. Өч кисәктән торган бу җыентыкның бер өлеше, табигый, аһ-зар лирикасыннан гыйбарәт.

Шул ук вакытта Заһидә Бурнашева көрәштә нык характерлы булуны, түземле булырга кирәклекне расларга омтыла («Сәбат»,[1] «Өмиткә», «Әзлим»). Киләчәккә ышанып яшәү, якты тормышка омтылу аңарга илһам бирә, ул башкаларны да көрәшү, җиңү дәрте белән яшәргә чакыра. Аның поэзиясендә гаделсез тормыш изүенә протест мотивлары төп урынны алып тора.

З. Бурнашева бер үк вакытта матбугатта үткен фикерле публицистик мәкаләләр дә яза. «10 еллык матбугатыбызда хатын-кыз» дигән тәнкыйть мәкаләсендә ул (1916) татар матбугатының 10 еллык тарихында хатын-кызларның сизелерлек эз калдыруын әйтеп уза да, «Сөембикә» журналының кеткәнне бирә алмавын тәнкыйть итә.

Барлык демократик язучылар шикелле үк З. Бурнашева да, кайда гына булмасын, хезмәт халкының авыр тормышта яшәвенә борчыла, империалистик сугыш тудырган кыенлыкларны һәм караңгылыкны күреп әрни. 1916 елның гыйнварында басылган «Караңгыда» дигән шигырендә ачынып болай ди:

Ниндидер көрләр вә золмәтларга ил чумган хәзер,
Ныклыгын һәм пакьлеген, йолдызларын җуйган хәзер.

З. Бурнашева — революция елларында чын мәгънәсендә азатлык өчен ялкынлы көрәшчеләр сафына баса. Сыйнфый көрәшнең иң кызган чорында —1917 елның июнендә Урта Азиягә килеп, Сәмәрканд, Ташкент һәм Кәттә Курган шәһәрләрендә Совет властен урнаштыру һәм ныгытуда актив катнаша. Ул башта Сәмәркандта партия өлкә комитеты органы булган «Михнәткәшләр» газетасында эшли, соңрак аның редакторы

[1] Сәбат — нык тору, чигенмәү.

була. 1918 елның августында Коммунистлар партиясе сафына алына һәм озакламый яшь коммунистны Кәттә Курганга өяз мәгариф халык комиссары урынбасары итеп җибәрәләр. Ул анда 1918 елның көзеннән 1919 елның маена кадәр эшли.

З. Бурнашеваның Урта Азия хатын-кызларыннан мәгариф һәм җәмәгать эшлеклеләре хәзерләүгә куйган хезмәтенә Марксизм-ленинизм институтының Ташкент филиалы чыгарган бер китапта гаять югары бәя бирелә[1].

Партия З. Бурнашевага берсеннән-берсе җаваплырак эшләр тапшыра. 1920 елның маенда аңа Төркстан Компартиясе Үзәк Комитеты каршындагы мөселман хатын-кызлары арасында эшләү секциясе белән җитәкчелек итү йөкләнә, соңрак ул Төркстан Компартиясе Үзәк Комитетында хатын-кызлар бүлеге мөдире булып эшли. Бер үк вакытта укыту-педагогик эшчәнлеген дә ташламый.

Нәкъ менә шул елларда З. Бурнашева тарихи әһәмиятләре зур булган съезд һәм конгрессларда катнашу бәхетенә ирешә. 1920 елның 15 маенда Ташкентта уздырылган Төркстан хатын-кызларының беренче корылтаенда делегат булып катнаша, җыелышның президиумына сайлана. Шул корылтайда Михаил Фрунзеның речен үзбәкчәгә тәрҗемә итә[2].

1920 елның җәе З. Бурнашева өчен аеруча истәлекле була: ул беренче мәртәбә Ленин белән очраша, аның ялкынлы речен тыңлый. «Онытылмас көн» дигән мәкаләсендә ул бу хакта бик [illegible] язып та чыкты.

1920 елның 30 июленнә[illegible] августына кадәр Мәскәүдә бөтендөнья коммунист хатын-кызларының беренче конференц[illegible]ла. Шул конференциядә З. Бурнашева Көнчыгыш хатын-кызларының бердәнбер вәкиле [illegible]тында катнаша. Аны Инесса Арманд, Роза Вольштейн (Германия), Ньюбальд (Англия), Ката Далостова (Швеция), Николаева (Петроград), Смидовичлар (Мәскәү) белән бергә конференциянең президиумына сайлыйлар[3].

1921 елның гыйнварында З. Бурнашеваны Мәскәүгә — партиянең Үзәк Комитеты аппаратына эшкә чакырып алалар. Ул анда РКП(б) Үзәк Комитетының хатын-кызлар бүлегендә инструктор булып эшли. 1921 елның апрелендә Мәскәүдә булган Көнчыгыш хатын-кызлары арасында эшләүче-оештыручыларның беренче киңәшмәсендә «Хатын-кыз кустарьлар арасында эшләү» һәм шул елның җәендә уздырылган Шәрык коммунистлары киңәшмәсендә «Көнчыгыш халыклары хатын-кызлары арасында эшләү бурычлары» дигән темаларга докладлар ясый[4].

Тарихи вакыйгаларның эчендә кайнаган З. Бурнашева партия тапшырган эшләрне һәрвакыт һәм һәр җирдә намус белән үти, көрәш һәм эш фронтының беренче сафында атлый.

Менә ул яңадан Урта Азиядә культура революциясе фронтында. Бер үк вакытта берничә эш алып бара: Урта Азия коммунистик университеты лекторы, Ташкент шәһәрендә политмәгариф работнигы, хатын-кызлар институтында укыту эшләре мөдире була.

1924 елда Төркстан берничә мөстәкыйль республикага бүленгәч, З. Бурнашева Төркмәнстанга җибәрелә. Ул анда 1924 елның октябреннән 1927 елның июненә кадәр республика Совет-партия мәктәбендә укыту эшләре мөдире вазифасын үти. 1927 елның июненнән 1928 елның февраленә кадәр ВКП(б) Үзәк Комитеты хатын-кызлар бүлегенең Көнчыгыш группасында методист-пропагандист булып эшли. 1929 — 1933 елларда Урта Азия ефәк промышленносте техникумы директоры була, бер үк вакытта Үзбәкстан дәүләт нәшриятының политредакторы вазифасын үти.

1933 — 1951 еллар арасында З. Бурнашева Кыргызстанда төрле җаваплы эшләр башкара, колхозларны ныгыту чорында МТС политбүлегендә эшли, Ватан сугышы елларында аңа Кыргызстанның Главлит начальнигы хезмәтен үтәү бурычы йөкләнә. Шушы чорда Мәскәүдәге Бөтенсоюз юридик институтын читтән торып тәмамлый.

1943 елда З. Бурнашева Кыргызстанның Фрунзе шәһәренең юридик мәктәбендә марксизм-ленинизм фәнен укыта.

Заһидә ханым 1952 елда, ялга чыгып, Буа шәһәренә кайта. Аннары ул Казанга күчеп килә.

Соңгы елларда З. Бурнашева хатын-кызлар азатлыгы мәсьәләләренә караган материаллар җыю һәм өйрәнү өстендә эшләде, һәм шулар нигезендә азатлык көрәшенә караган китап язды. Ул «Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан» дигән исем белән 1971 елда басылып та чыкты.

Бездә, гадәттә, революциягә кадәрге татар хатын-кызларының хәле турында язганда, мәсьәләнең бары тик бер ягына — колларча изелеп яшәүләрен күрсәтүгә генә басым ясала иде. Шул традициядән аермалы буларак, Заһидә ханым Бурнашева татар хатын-кызларының патша Россиясе шартларында ук җәмәгать байлыгын тудыру өлкәсендә дә катнашучылар булуларына игътибар итә. Чынлап та, алар капиталистик предприятиеләрдә, крестьян һәм алпавыт хуҗалыкларында иң авыр эшләрне эшлиләр һәм ирләргә караганда ныграк эксплуатацияләнәләр. Китапта бу мәсьәләләр безнең әдәбиятта беренче буларак киң яктыртыла.

---

1. Пробуждение Великим Октябрем. Ташкент, 1961, 70, 84 66
2. «Совет Татарстаны», 1959, 10 март.
3. Отчет I Международной конференции коммунисток, 1921.
4. «Коммунистка», 1921, № 12, 13.

1905 ел революциясе чорында ук иҗтимагый-азатлык көрәшендә актив катнаша башлаган алдынгы татар хатын-кызлары арасыннан мөгаллимәләр, язучылар, матбугат хәбәрчеләре, җәмәгать эшлеклеләре үсеп чыктылар. Октябрь революциясенең җиңүе өчен барган көрәш көннәрендә татар эшче хатын-кызлары ирләр белән бер сафта торып хәрәкәт иттеләр. Гражданнар сугышының авыр елларында, яшь Совет дәүләтен дошманнан саклап калу, ныгыту өчен барган көрәшләрдә, мәгариф һәм культура, халык сәламәтлеген саклау өлкәсендә алдынгы татар хатын-кызлары зур фидакарьлекләр күрсәттеләр. Китапта шул авыр һәм җаваплы елларда хатын-кызлар күрсәткән батырлыклар да җылы һәм ышандырырлык итеп язылган.

Заһидә Бурнашева — демократик әдәбиятыбыз тарихында якты эз калдырган язучы. Дөрес, аңа, революция солдаты буларак, шигырь язуын сирәкләтеп, бөтен тормышын партия эшенә багышларга туры килә. З. Бурнашеваның бу адымын Г. Ибраһимов дөрес бәяләп чыкты. Ул 1922 елда язган мәкаләсендә: «Гыйффәт туташ, Габдрахман Сәгъди кебек әүвәлге матбугатта әдәбият мәйданында исемнәре булган шагыйрьләр, мөхәррирләр революциянең шигарьләрен[1] аңладылар гына түгел, болар инде рәсми рәвештә коммунистлар сафына — партиягә кереп, язмышларын партиягә багышладылар, рәсми рәвештә эшче-крестьян диктатурасының көчәюе юлында көрәшкә үзләрен бирделәр»,— диде.

Әнә шундый гаҗәеп язмышлы партия солдаты, көрәшче, язучы — халкыбызның горурлыгы иде ул Гыйффәт туташ!

З. Бурнашева 1977 елның 5 ноябрендә вафат булды.

Мөхәммәт ГАЙНУЛЛИН,
филология фәннәре докторы, профессор.
Җамал ВӘҖИЕВА,
филология фәннәре кандидаты

[1] Шигарь — лозунг.

# ҮЗ АҺӘҢЕ БАР

### ИЛДУС ЯКУБОВКА 50 ЯШЬ

Беренче музыкаль тәэсирләр... Булачак композитор күңелендә алар кайчан уяна башлый? Иксез-чиксез музыка дәрьясына талантны нинди дулкын алып кереп китә? Гомерлек «моң әсирлеге»нә Илдус Якубов, мөгаен, скрипкада уйнарга өйрәнгәндә үк бирелгәндер. Теоретик әзерлек остазы һәм хормейстер А. Бормусов аны зур сәнгать юлына җитәкләп чыгара. Аннары Казан музыка училищесында ул профессор А. Леман классында композиторлык серләрен өйрәнә башлый. Укуын консерваториядә дәвам иттерә. Инструментовка буенча аңа профессор Н. Җиһанов үз осталыгын өйрәтә, ә композиция буенча ул шул ук Альберт Семенович кул астына эләгә.

Югары уку йортын тәмамлаганда (1964 ел) яшь композитор беренче симфониясе белән имтихан тота. Шушы уңайдан әйтеп үтик, И. Якубов үзенең иҗат эшчәнлеге дәвамында барлыгы җиде симфония язды. Композиторның бер өлештән торган икенче симфониясе — В. И. Ленинга багышланган зур әсәре һ. Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы нигезендә иҗат ителә. «Героик төзелеш», «Мәһабәт Кама», «Сабан туе»... Авторның алтынчы программ симфониясе әнә шундый бүлекләрдән тора, һәм ул, бүлек исемнәреннән үк күренгәнчә, КамАЗ төзелешенә багышланган.

Композитор И. Якубов төрле жанрлар буенча эшли: симфония, кантата-оратория, камера музыкасы, балалар өчен әсәрләр... Опера һәм балетларының тематикасы аеруча күп кырлы. Әйтик, 1965 елда ул М. Горькийның «Италия турында әкиятләр»енә нигезләнгән балет яза. Шулай ук аның аерым әсәрләр буенча иҗат ителгән «Хуҗа Насретдин» (1966), «Вий» (1972) исемле балетлары да бар, һәм без авторның «Акыллылык бәласе» дип исемләнгән өч актлы опера клавирын да (1977) беләбез. Итальян язучысы Дж. Родариның «Джелсамино алдакчылар илендә», татар шагыйре Х. Халиковның «Эшләпәле дуслар» кебек әсәрләре буенча язылган операларда балалар тормышы чагылдырыла. Бүгенге замандашыбызның хезмәт батырлыгы композиторның игътибарын һәрвакыт тартып тора, һәм әлеге теманы ул төрле жанрларда гәүдәләндерергә омтыла. Кама автомобиль гигантына багышланган алты өлешле ораториядә (Р. Харис либреттосы) авторлар фән-техника революциясенең кешеләр рухындагы чагылышын, шушы өлкәдәге чалым-үзгәрешләрне күрсәтүгә ирешәләр.

Үзенең камера әсәрләрендә композитор милли җирлеккә күбрәк таяна шикелле. Мәсәлән, икенче квартетында ул «Башмагым», «Ай, былбылым», «Тәфтиләү», «Баламишкин» кебек татар халык көйләреннән файдалана, әсәрнең финалында әлеге темаларны органик рәвештә үзара берләштерә. Халык җырлары интонацияләре авторның прелюдияләрендә дә, фортепиано белән оркестр өчен язылган концертында да ишетелгәли.

Композитор вокаль музыка өлкәсендә дә актив эшли. Текст авторлары даирәсе киң: А. Пушкин, Я. Райнис, М. Җәлил, Ә. Ерикәй, Ш. Галиев, Р. Харис... И. Шакиров башкаруында композиторның «Яшьлегемә кайтыр идем» дигән җыры киң популярлык казанды. Вокаль цикллары (барысы өчәү) темалары буенча гына түгел, ә башкарылыш формалары ягыннан да бер-берсеннән аерылып торалар. Аларның беренчесе (А. Пушкин сүзләре), мәсәлән, баритон һәм фортепиано өчен, икенчесе (Я. Райнис) җырчы тавышы, скрипка һәм фортепиано өчен язылган. Мәскәү шагыйрәсе И. Токмакова сүзләренә язылган циклны автор үзенең нәни тыңлаучыларына юллаган. Вокаль әсәрләрнең дә тематикасы төрле. Аларда — туган як гүзәллеге дә («Язгы таң»), якты мәхәббәт хисе дә («Раушан йолдыз»), моң-сагыш та («Кыз җыры»), шаянлык та («Күршеләр»)... Балалар җырлары композиторның иң яраткан жанрларыннан санала. Аның «Бишек җыры» (1966), «Балалар өчен ун җыр» (1968), «Батыр куян» (1977) кебек җыентыклар чыгаруы да әнә шул хакта сөйли.

Гомумән, композитор милли җирлектәге катлаулы нәфис гармониялелеккә омтыла. Интонацион стиле күпкырлы. Сүзләрнең характерына карап, әсәр татар яки рус интонацияләренә корыла. Балалар җырларында кечкенәләрнең санамышлары, бию такмаклары лирик әсәрләр һәм бишек җырлары интонацияләре белән аралаша. Иҗатчының якты колоритлы стиленә хыялыйлык хас, ә бүгенге музыкага характерлы «хәрәкәтчәнлек» алай ук сизелми. И. Якубов — лирик башлангычка күбрәк таяна торган композитор. Нечкә һәм шул ук вакытта катлаулы гармоник стиле аны кайчак импрессионистик сурәтләүгә дә китереп чыгара. Композитор мелодик яктан сәләтле. Әлеге сыйфат вокаль әсәрләрдә аеруча ачык чагыла. Кыскасы, Илдус Якубов композиторлар «хоры»нда үзгә аһәңе белән аерылып тора, һәм татар музыка сәнгатендә аның үзенчәлекле үз урыны бар.

Роза ИСХАКОВА-ВАМБА.

Фирдәвес Әһлиуллина

# ЧЫНЛЫККА ОМТЫЛУ

Тышта буран себерә. 1984 елның февраль бураны. Горький урамы буйлап Татар дәүләт академия театры бинасына якынлашам. Ниятем — СССРның халык артисты, РСФСР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты Шәукәт Хәсәнович Биктимеров белән очрашу.

Театрда гадәти эш көне. Кайдандыр эчтән төрле авазлар ишетелә, мастерскойларда, костюмнар һәм яктырту цехларында эш кайный. Сары витраж тәрәзәләр аркылы йомшак яктылык сирпелә. Киң мәрмәр баскыч култыксасына ике яклап кәрзинле чәчәкләр куелган. Алар язны хәтерләтә.

Икенче каттагы музей ишеге ябылып бетми калган. Анда КПСС Үзәк Комитетының февраль Пленумы карарларына багышланган партия җыелышы бара. Эчкә карыйм. Һәм яны белән утырган Шәукәт Хәсәновичны күреп алам. Йөзендә дулкынлану, ораторлан күзен алмыйча, гәүдәсе белән алга омтылган. Менә торып басар да сүзгә кушылып китәр кебек.

Җыелыш байтак дәвам итте. Менә актерлар шаулашып ишектән килеп чыктылар. Алар үз театрларының бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшәләр иде. Шәукәт Хәсәновичның да кәефе күтәренке. Аны яшьләр чолгап алган. Бергәләп баскычтан төшәләр. Актерга мөрәҗәгать итәм, театрны яратуымны, аның иҗаты белән кызыксынуымны, әгәр мөмкин булса, репетицияне күрәсем килүен әйтәм. Минем дулкынлануымны күреп, ул елмая, мин дә бераз тынычлангандай булам, әйбәт, ярдәмчел кеше дип сөйлиләр иде, дөрес икән, дип уйлап алам.

Юлым уңды. М. Горькийның башлангыч чор иҗаты буенча эшләнгән «Һаваларда йолдыз» спектакленең репетициясе башланырга тора икән. Бөек язучының Казанга беренче тапкыр килүенә 100 ел тулу уңаеннан театр бу спектакльне Горький шәһәрендә үткәреләчәк декадага әзерли. Шушыларны сөйләгәч, Шәукәт Хәсәнович гафу үтенде, үзенең репетиция өчен костюмнар сайларга тиешлеген әйтте. Моңа мин куандым гына, үзе белән алуын үтендем: театрның эченә үк кереп карыйсым килә иде.

Без ишегалды аркылы театрның «эш» бүлегенә кердек. Монда актерларның грим ягу бүлмәләре, мастерскойлар һ. б. лар урнашкан. Костюмерныйда безне озын буйлы, ак халатлы җитди ханым — Рәхилә апа Солтанова каршылады. Шәукәт Хәсәнович аның белән бик үз итеп исәнләште.

— Миңа озын итәкле, киң җиңле мул бер күлмәк кирәк иде.

— Бездә андый күлмәкләр бар барын да, әмма алар җиңсез, хитоннар, үзең беләсең,— дип җавап бирде Рәхилә апа.

— Юк, миңа җиңсез булмасын. Мин уйнаган булочный хуҗасы гел шушындый күлмәктән йөри: ишегалдында да, урамда да... Күлмәген беркайчан да салмый, ул аның тәненә ябышып каткан кебек. Күлмәк аның өчен бик уңай, иркен дә...— дип сөйләнде Шәукәт Хәсәнович. Мин аның күзләрендә нидер кабынуын күреп алдым.— Менә хуҗа алпан-тилпән атлап ишегалдына чыга, йөзе караңгы-горур, йөнтәс куллары белән корсагын тоткан.— Шәукәт Хәсәнович рольгә керә дә башлады, ахрысы. Репетиция костюмерныйдан ук башлана икән ләбаса. Менә ул кулын кушырды, аякларын аерыбрак басты һәм кинәт үзгәреп китте — карашы усалланды, күзләре хәтта төсен үзгәртте.— Ул үзен пекарня хуҗасы итеп кенә түгел, кешеләр язмышын хәл итүче итеп тә саный. Мәсәлән, Алексей Пешков кебекләрнекен,— дип сүзен дәвам итте актер.

Без Рәхилә апа белән гаҗәпләнеп актерга карап тордык. Күз алдында ул икенче кешегә әверелде. Безне «җиргә» кайтару нияте белән булса, кирәк, Шәукәт Хәсәнович:

— Күлмәк әллә ни ак булмаса да ярый, соргылт та батар иде,— диде.

— Алайса бу күлмәк үзе бер образ инде,— Рәхилә апа үз вазифаларына

кайтты.— Яңаны тегәргә туры киләчәк. Ә репетиция өчен ирләр күлмәге алыгыз, өстән хитон киярсез.

— Юк,— диде Шәүкәт Хәсәнович, репетиция өчен генә дип ташлама ясарга теләмичә.— Юк, Рәхилә апа, алайса миңа «Зәңгәр шәл» абыстайларының берәр күлмәген китерегез, мулрак булсын.

— Көләчәкләр бит сездән,— Рәхилә апа актерларны күздә тота иде.

— Әй, көлә бирсеннәр...

Аның шулай таләпчән булуы, һәр детальгә игътибар итүе мине гаҗәпкә калдырды. Зур оста өчен вак нәрсә юк, күрәсең.

***

Рәпетиция башланды. Празат Исәнбәт, инсценировка авторы һәм режиссеры буларак, иң элек массовый күренешләрдә катнашучы яшьләргә кайбер киңәшләр бирде. Аннан соң алар читкәрәк китеп бастылар.

Менә сәхнә уртасында Хуҗа-Шәүкәт Биктимеров чыгып басты. Ул әле бер сүз әйтергә өлгермәде, ә мин инде театр каршындагы йортны күз алдыма китердем. Бер гасыр чамасы элек аның подвалында бөек рус язучысы М. Горький пекарь ярдәмчесе булып эшләгән. (Бу йортта хәзер язучының музее урнашкан.) Менә Хуҗа кулларын олы корсагына кушырып баскан да, баш бармакларын әйләндергәләп, эш сорап килгән үсмергә тупас итеп кычкыра:

— Бар, бар, торма монда! Эш юк! Нинди эш ди ул кышын!

М. Горькийның «Хозяин» хикәясендәге бик күп детальләрне актер үз арсеналына алган: шешенгән сакалсыз йөз, зур маңгайлы баш, сизерәгән чәчләр, ике шешәдәй күренгән юантык аяклар...

Әлбәттә, бу чалымнар аңа бөек язучы әсәрен кулга карандаш тотып өйрәнү нәтиҗәсендә табылган. Димәк, репетициягә хәтле дә күпме эш эшләнгән, күпме уй уйланган... Актер тышкы яктан гына түгел, эчтән дә ямьсез булган әлеге адәм образын «бөртекләп җыйган», җиңел генә тудырмаган. Бу кыяфәтсез кеше үзенең наданлыгы һәм тупаслыгы белән үсмер малайның йолдызларга ашып хыялланган җанын таптый... Әмма бай рухи тормыш белән яшәүче малайда бу кеше нәфрәт түгел, ә кызгану хисе уята. Чөнки мыскыллаучының хәле бит тагын да аянычрак: ул әле кеше рәтенә кермәгән дә, күңелендә изгелек дигән нәрсә бөтенләй юк, ул үлгән, күмелеп калган.

Соңрак, Шәүкәт Хәсәнович белән якыннанрак танышкач һәм аның иҗат лабораториясенә тирәнрәк үтеп кергәч, бу образның нәкъ шундый булуы Горький әсәреннән генә килмәвен аңладым. Эш шунда ки, Горькийга хас гуманизм актерның үз иҗат принцибына, аның кредосына әверелгән, ул уй-фикерләренә, хисләренә туры килә.

***

Шәүкәт Хәсәновичка төрле характердагы рольләр өстендә бер үк вакытта эшләргә туры килгәли. Әйтик, театрда Горький әсәре буенча репетиция барса, телевидение һәм радиода Шәриф Камал пьесасы әзерләнә.

Миңа Шәүкәт Хәсәновичның радиога язылуын күзәтергә туры килде.

...Актер калын портфелен ачты да, аннан машинкада басылган «бер кочак рольләр» тартып чыгарды һәм арадан берсен сайлап алды. Бу «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясеннән Хаҗи әфәнде роле иде.

— Һич ятлап бетереп булмый, алар шулкадәр күп,— дип зарланып алды ул.

Менә спектакльдән бер күренешне язарга керештеләр. Язып бетереп, җиңел сулыш алырга да өлгермәделәр, аппаратныйдан яңадан язарга туры киләчәген әйттеләр. Магнитофоннары бигүк төзек булмаган. Мәчегә көлке, тычканга үлем, дигәндәйрәк килеп чыкты. Артистларның кәефе кырылды, әмма берни эшләр хәл юк, кабат язарга кала. Тагын эш башланды. Тирләп-пешеп эшләделәр. Шәүкәт Хәсәнович бу очракта да үзен тыныч тотты, яшьләрне тынычландырды, кайвакыт шаяртып та алгалады. Аның тынычлыгы башкаларга да тәэсир итте...

Үзен изге кеше дип йөргән Хаҗи әфәндене чын йөзен актер костюмсыз һәм гримсыз минем күз алдында, аз гына да көчәнмичә, ачты да салды.

— Мондый җиңеллеккә сез ничек ирешәсез? — дип сорыйм Шәүкәт Хәсәновичтан тәнәфескә чыккач.

— Бу рольгә юллар шактый озын булды,— дип уйга калды ул.— Беренче

тапкыр «Хаҗи әфәнде» белән мин 1946 елда таныштым. Казан театр училищесының беренче курсында укый идем. Ширияздан ага Сарымсаков куйган спектакльгә эләктем. Ул вакытта Хаҗи әфәндене РСФСРның атказанган һәм ТАССРның халык артисты Зәйни ага Солтанов уйнады. Спектакльдә театрның йөзен билгеләүче сәхнә осталары — РСФСРның халык артисткасы Фатыйма Ильская, РСФСРның атказанган һәм ТАССРның халык артисткасы Гөлсем Болгарскаялар катнашты... Минем өчен бу зур мәктәп булды. Ул чакта бәлки моны аңлап та бетермәгәнмендер, ләкин спектакль бик нык тәэсир итте. Театр мине торган саен ныграк тартты. Зәйни агадан күземне ала алмый карап утырдым. Аның сәхнәдә табигый яшәвеннән зур ләззәт алдым. Ул образның системасын бик төгәл төзи иде. Ә бу бит актерлык эшендә иң кыены. Мин моны хәзер генә, байтак еллар үтеп, күпмедер тәҗрибә туплагач кына аңлый башладым...

Шәүкәт Хәсәнович уйга чумды. Күзләрендә якты очкыннар уйнап алды. Ул татар театрының корифейлары, аларның ярдәме, калдырган мирасы турында уйлый иде, күрәсең.

— Соңрак Хаҗи әфәнде ролен ТАССРның халык артисты Хөсәен Уразиков уйный башлады. Ул Зәйни ага Солтановның укучысы, аның эшен дәвам итүче иде,— диде Шәүкәт Хәсәнович кечкенә генә паузадан соң.— Ул рус театрыннан килгән реалистик мәктәп традицияләрен үстерде. Аның уйнавын мин күп мәртәбәләр күрдем, күзәтеп, өйрәнеп утыра идем. Актерның табышлары каныма сеңә барды. Күземне йомсам, зур мастерлар тудырган шушы спектакльләр хәзер дә күз алдыма килеп баса... Хаҗи әфәнде образы өстендә мин бик сөенеп эшләдем. Нинди материал, нинди бай образ бит ул! Аның белән үзеңне тагын бер кат сынап карыйсың...

Тәнәфес бетте. Актерларны кабат студиягә чакырдылар. Шәүкәт Хәсәнович белән саубуллашып, мин дә урамга чыктым.

***

4 нче март ял көненә туры килде. Театр өчен бу гадәти эш көне иде. Р. Батулланың «Кичер мине, әнкәй!» пьесасын уйныйлар. Шәүкәт Хәсәнович спектакльдә тимерче Әбүбәкер ролен башкара.

Актерның беренче чыгышы ук алкышлар белән каршыланды. Менә ул сәхнә түреннән, зәңгәрсу эңгер-меңгердән килеп чыга, бер мизгелгә генә тукталып кала. Карашы өзелеп яраткан Миңзифасына төбәлгән. Миңзифа да аның шикелле гади, эчкерсез, башыннан бик күпне кичергән (бу рольдә ТАССРның халык артисткасы Нәҗибә Ихсанова уйный). Әбүбәкер, Миңзифасының уйларын бүлдерүдән курыккандай, сак кына аның янына килеп утыра. Һәм шул вакыт, күңелләрне нечкәртеп, нәфис моң сузыла башлый. Әбүбәкер — виолончель, Миңзифа — скрипка. Моң сине үзенең бишегендә тирбәтә, үзгә дөньяга алып китә. Күпме гүзәллек, нечкәлек, хис бу моңда! Ике йөрәк, ике күңел сөйләшә, серләрен уртаклаша!.. Бу күренеш тамашачыны әсир итә. Залда гаҗәеп тынлык, актерларның сулыш алуына хәтле ишетелеп тора...

Әбүбәкер үзе төп роль булмаса да, Шәүкәт Хәсәнович уйнавында ул аерылып тора, хәтергә, күңелгә уелып кала. Шулай бер сөйләшү вакытында актер ничектер әйткән иде: рольләрнең зурысы-кечесе юк, барысы да актердан тора. Әйтер сүзең булса, һәрбер роль зур була, моның өчен актер үзе шәхес булырга тиеш... Шулай булганда ул кечкенә рольдә дә үзен күрсәтә алачак.

Әбүбәкер үзенең Миңзифага булган чын мәхәббәте аркылы ачыла. Күңеленең һәр кылы сөйгәненең кагылуын көтә. Шушы мәхәббәт аның олы йөрәкле чын кеше икәнен раслый. Бу образ аркылы актер да: «Кешеләр, бер-берегезнең кадерен белегез, хөрмәт итеп, яратып, бер-берегезне саклап яшәгез, дөньяда мәхәббәттән дә зур бәхет юк»,— дип әйтергә тели.

Ул көнне Шәүкәт Хәсәновичның сәхнәдән изгелек, мәхәббәт, кешелеклелеккә дан җырлавы очраклы хәл булмагандыр, күрәсең. 4 нче март көнне халык аны СССР Верховный Советына депутат итеп сайлады, шулай итеп аңа үзенең ышанычын һәм хөрмәтен белдерде, өметләрен баглады.

Кич саен Шәүкәт Хәсәнович тамашачыларга хисләрен, күңел җылысын өләшә. Ә театрдагы яшьләр өчен ул өлкән иптәш тә, дус та, киңәшче дә. Шуңа күрә яшь артистлар аңа тартыла, борчыган мәсьәләләрен килеп сөйлиләр.

Көннәрдән бер көнне репетиция алдыннан актриса Алсу Гайнуллина Шәүкәт Хәсәновичның ярдәме хакында сөйләп торды. Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» пьесасын куйганда була бу хәл. Алсуга Гөлчирә ролен бирәләр. Әмма роль «ки-

релэнэ», актриса борчыла, эчтэн күп йөри. Спектакль азагындагы: «Онытма, Мирзахан, кайчан да булса бер моның өчен алырмын!» дигән сүзләрне актриса бөтен көчен, пафосын биреп әйтсә дә, тамашачы битараф кала. Гөлчирәнең этисе Биктимер карт ролен уйнаган Шәүкәт Хәсәнович, барысын да күреп, мыекка чорнап торса да, актрисаның кәефен төшерүдән куркып, берни дә әйтми. Күп тә үтми, Алсу үзе аңа мөрәҗәгать итеп киңәш сорый. Актер аны читкәрәк алып китә дә тыныч кына аңлата башлый: «Алсу, син Гөлчирәнең хәлен аңларга тырыш. Ул бит этисен алдады, алар кунакка киткәч, аулак өйгә егетләрне кертте. Аннан соң бай малае Мирзаханнан йөкле булды. Менә ул соңгы өмет белән үзен алдаган кеше каршысына килә, бала хакына гына булса да өйләнүен, гаебен юуын үтенә. Ә егет ярдәм итү урынына акча тәкъдим итә, көлә, мыскыл итә. Күз алдыңа китер — кызның соңгы өмете өзелде. Ул хәзер нишләргә дә белми. Аңа үз-үзенә кул салырга гына кала. Аның хәтта утырган урындыгыннан күтәрелергә дә хәле юк. Шулай да кыз, стенага тотынып, акрын гына күтәрелә, аякларын өстерәп ишеккә таба китә. Бетте, сынды, дип уйлыйсың. Әмма юк! Кыз, соңгы көчен җыеп, алдаучысына борыла, айлар буе күкрәгендә йөргән авырту, әрнү пышылдау булып ишетелә: «Онытма, Мирзахан, моның үчен алырмын!..»

Шушы киңәшне истә тотып, Алсу икенче спектакльдә бөтенләй башкача уйный. Тамашачылар Гөлчирәнең (шул ук вакытта актриса Алсу Гайнуллинаның да) үз-үзендә көч табуын хуплап кул чабалар.

***

Өйгә кайтышлый тагын Әбүбәкер язмышы турында уйлыйм. Үзенең актерлык гомерендә Шәүкәт Хәсәнович кешеләргә күпме күңел җылысы биргән, ул уйнаган образларның күпмесе кеше йөрәгенә кереп калган! Алар авыр минутта кешегә ярдәм иткәннәрдер, дөрес юл сайларга, ялгышмаска өйрәткәннәрдер. Шәүкәт Хәсәнович уйнаган образларны — Ч. Айтматовның Байтимерен, Т. Миңнуллинның Бәхтияр Канкаевын, Т. Гыйззәтнең Биктимерен бер нәрсә — кеше бәхете өчен үз-үзеңне аямыйча көрәшү берләштерә. Әмма бу көрәшне дә бер планда гына карарга ярамый. Актер тискәре типларны күрсәтү белән дә кеше бәхете өчен көрәшә.

Бер көнне спектакль башланыр алдыннан Шәүкәт Хәсәнович белән шул хакта сөйләшеп алдык. Ул Т. Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» драмасындагы Җәллад ролен әзерли иде. Мин аннан бу рольгә мөнәсәбәтегез ничек, Җәлладны уйнау авыр түгелме, дип сорадым.

— Әйе, бу Муса Җәлилне һәм аның иптәшләрен җәзалаган җәллад. Кеше гомере аның өчен 300 марка гына тора. Хөкем карарын үтәү, кешеләрне җәзалау — аның төп эше. Әлеге бәндәнең җанын цинизм һәм тупаслык басып киткән. Шул ук вакытта бу җәллад безнең коммунистик идеяләрнең үлемсезлеген дә аңлый, алар каршында үзен көчсез сизә, чөнки бу идеалларны гильотина астына салып кына юк итеп булмаячак!

Уйлана-эзләнә торгач, мин бөтен дөнья җәлладларының гәүдәләнеше булган бу җәлладның «философиясен» аңладым кебек. Тарих һәм Муса истәлеге алдында үземне бурычлы санап, мин аның асылын ачып салырга, хөкем чыгарырга тырыштым. Чөнки без кешелек дөньясы җәлладларына нәфрәт белән карап кына калмыйча, аларга каршы көрәшергә дә тиешбез. Ә моның өчен аларны яхшылап өйрәнергә кирәк. Бу хәзер бигрәк тә актуаль яңгырый, чөнки океан арты җәлладлары дөньяга сугыш белән яныйлар. Элекке сугыш та кешеләргә күпме бәла-каза китерде, ә яңасы... хәтта уйларга да куркыныч.

— Сугыш башланганда сезгә унөч яшь булган, шулай бит?

— Әйе...— дип сузды актер һәм уйга калды. Дәһшәтле иртәне күз алдына китерде, күрәсең.

— Ул чакта без Саба районының Мәңгәр авылында тора идек.— Актер каршындагы көзгегә карап алды, аның зәңгәр күзләрендә мин сугыш башланган иртәнең чагылышын күргәндәй булдым.

...Шәүкәт дүрт классны тәмамлый. Мәктәп директоры булып эшләгән этисе Хәсән Зарипович кечкенә кызы Гөлназ белән малаена Казан күрсәтеп кайтмакчы була. Балалар өчен бу зур бәйрәм.

Шулай 22 июнь иртәсендә этиләре станциягә барыр өчен ат сорарга бригадир янына китә. Әмма буш кул белән кайта, кыяфәте борчулы. Артсыз урындыкка килеп утыра да, балаларын үз янына чакырып алып, Казанга барып булмаячагын әйтә. Сугыш башланган. Балалар берни дә сорашмыйлар, алар кинәт

житдиләнеп калалар, чөнки күңелләре белән тормышның икенче якка борылганын сизенәләр.

Әтиләре Мәскәүдән һәм Ленинградтан күчеп килүчеләрне урнаштыру белән шөгыльләнә. Балалар да аңа булышалар. Авыл халкы килүчеләр өчен ипи, сөт, бәрәңге, йомырка китерә, өйләреннән урын бирә.

Шәүкәтнең әнисе хат ташучы булып эшли. Малай да аңа булыша, күзләре начар күргән карт-корыга хатларын укып бирә. Ә хатларда — фронт хәбәрләре... һәм 1942 елны әтиләре дә фронтка китә. Киткәндә әнисенә малайны укытырга куша. Малай күрше авыл мәктәбенә йөреп укый, ә җәйләрен колхозның бозау көтүен көтә.

1945 елны әтиләре исән-сау килеш әйләнеп кайта. Малай исә Җиңү көне 9 майны Казанда каршылый — бу көнне ул театр училищесына имтихан бирә. Сугыш вакытында артистларның күбесе фронтка китә, кемдер ятып кала, кайберләре имгәнеп кайта. Театрлар кадрларга мохтаҗлык кичерә. Шуңа күрә училищеда, көзне көтеп тормыйча, укучылар кабул итә башлыйлар. Тормыш шулай куша.

Шәүкәт Хәсәновичның грим сала торган өстәлендәге кечкенә афишаларга игътибар итәм. Ул уйнаган спектакльләр анда карандаш белән билгеләнгәннәр: А. Островский — «Бирнәсез кыз», Т. Миңнуллин —«Монда тудык, монда үстек», Г. Камал — «Банкрот», Г. Ибраһимов — «Татар хатыны ниләр күрми», Л. Леонов — «Ябырылу», Т. Миңнуллин — «Моңлы бер җыр», Р. Батулла — «Кичер мине, әнкәй», М. Горький — «Һаваларда йолдыз» һ. б. Ул һәрвакыт эштә — репетицияләр, телевидение һәм радиога язылулар... Байтак спектакльләрдә ул үзе генә уйный, димәк, авырып китәргә, арырга да хакы юк. Шулар өстенә, җәмәгать эшләре, гаилә мәшәкатьләре. Болар барысы да зур хезмәт, түземлек, сәламәтлек сорыйлар. Ә ул барысын ничектер шаяргандай башкара шикелле — шуның белән ул бәхетле дә.

***

Сугыш вакытында ил өстенә килгән бәлане үз күзе белән күргән, бер өлешен үзе дә татыган кечкенә Шәүкәт, һәр совет кешесе кебек үк, сугышның булуын теләмәгән, әлбәттә. Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасындагы 91 яшьлек Әлмәндәр карт та сугышка нәфрәтләнеп карый. Сугыш белән үлем аның төп дошманнары.

Әлмәндәр карт язмышында ил язмышы чагыла. Ул Ватанны үлемнән саклаган, ә үлем, үкчәсенә басып, аның артыннан йөргән. Беренче тапкыр үлем белән ул 1905 елда, япон сугышында яралангач очраша. Ул вакытта Әлмәндәр әле яшь, таза, көчле була һәм үлемнең тырнагыннан ычкына. Икенче тапкыр үлем аның янына 1915 елда сазлыкта ятканда килә. Әсирлектән качып, бу юлы да Әлмәндәр аннан котыла. Өченче тапкыр үлем белән ул 1930 елны, колхозлар төзеп йөргән чагында очраша: аны сәнәк белән кадыйлар. Күрше авыл русы Евстигней аны коткарып кала һәм гомерлек дустына әверелә. Ә 1941 елны сугыш аның дүрт улын тартып ала...

Сугышны ничек куралмаса, шул кадәр үк тормышка гашыйк Әлмәндәр карт. Бу дөньядан киткәндә ул үзенең дәвамы итеп күрше малаен, аның җырларын отып алган малайны калдыра. Ул да дөньяда сугышны булдырмау турында хыяллана.

Шәүкәт Хәсәнович Әлмәндәр карт образы турында менә нәрсә ди: «Әлмәндәр үткәнгә түгел, киләчәккә китә. Аның иң зур хыялы — җир йөзендә үзеннән соң җыр калдыру. Шул җырны җырлаганда аны да искә алуларын тели ул».

***

Мәскәүгә, СССР Верховный Советы сессиясенә килгән саен Шәүкәт Хәсәнович, өйрәнелгән гадәт буенча, Ленин тауларына күтәрелә, анда уйланып утырырга ярата. Моннан карап торуы рәхәт, күп нәрсәне ачыграк күрәсең.

Ул чыннан да бәхетле кеше икән бит, аңа үз театры сәхнәсендәге Н. Погодинның «Баһадирлар» пьесасындагы Ленин образын уйнарга туры килде. Роль халык тарафыннан инде кабул ителде, хупланды, аның буенча эшләүне бәлки туктатырга да вакыттыр. Әмма Шәүкәт Хәсәнович Биктимеров өчен юлбашчы образы әле һәрвакыт киләчәктә кала бирә. Актерны ул алга өнди, якты йолдыз кебек юл күрсәтеп тора. Ленин аның өчен һәр яктан үрнәк, үзенең уй-хисләрен, тормышын ул шулай кат-кат тикшереп карый, идеалына якынлашырга тырыша. Шуның өчен дә һәр кичне яраткан театрының сәхнәсенә күтәрелә.

## Балыгы башында икән

Буш вакыты чыктымы, Тажи Гыйззәт балык тотарга йөри икән. Бервакыт ул театрда бутафор-рәссам булып эшләүче Сөләйман Мортазин белән кармак салырга бара.

— Тажи абый, чиертә бит, калкавычыгыз батты бит! — дип кычкыра Сөләйман.

Т. Гыйззәт кармагын тартып ала, ләкин кармакта балык та, җим дә булмый...

— Тажи абый ул кармак салырдан, балык тотардан йөрми ахрысы,— дип сөйли соңыннан Сөләйман Мортазин.— Кармак салганда да ул пьеса язып утыра бугай.

Чыннан да, шулай бервакыт буш кул белән балыктан кайтып килгәндә, Тажи Гыйззәттән сораганнар:

— Кая бардың, Тажи абзый?

— Балыкка,— ди Тажи Гыйззәт.

— Эләктердеңме соң?

— Эләктердем! — ди драматург.

— Балыгың кая соң, Тажи абзый?

— Менә монда! — дип башына күрсәткән Т. Гыйззәт.— Пьесага бик шәп бер сюжет каптырдым!

## Сафалар, Вафалар, Гаталар

Радиодан Сөләйман Йосыпов башкаруында «Ай, Сафа, вай, Сафа» җыры еш яңгырый иде. Бу җыр — гомер иткән хатынын аерып, яшь хатынга өйләнгән Сафа исемле бер бичараның җәфалары турында.

Көннәрдән бер көнне радиога бер кеше килеп керә дә бик каты үпкә белдерә:

— Сөләйман Йосыповны күрсәтегез миңа! — дип кычкыра әлеге кеше.— Нигә ул, панимаешь, кешедән көлеп җырулар чыгарып ята монда? Дөрес, мин Сафа! Дөрес, мин хатынны аерып, яшьне алдым. Дөрес, яшь хатын минем бик тыңлаучан булып чыкмады. Хәзер бөтен авыл миннән көлә. Кая ул Сөләйман Йосыповыгыз? Мин аны, панимаешь, за публичное оскорбление судка куям!

Ярый әле эш судка кадәр барып җитми. Имештер, әлеге Сафага Сөләйман Йосыпов киләчәктә «Вафа» дип җырларга вәгъдә иткән, диләр. Әмма «Вафа» турында җырлагач, тагын берәү С. Йосыпов өстеннән жалу белән йөри башлаган. Бу Вафа да хатын аерган, яшь хатынга өйләнгән булып чыга. Шуннан соң С. Йосыпов бу җырны «Гата» дип җырларга вәгъдә иткән, имеш.

...Гата исемле кеше дә жалу белән килмәс дип кем кистереп кенә әйтә ала?

«Кызыклы хәлләр»не журналга
**Роберт Батулла** әзерләде.

## *Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары*



### Әхәт Мушинский

Әхәт Хәй улы Мушинский — рус телендә иҗат итүче прозаик. Ул 1951 елда Казанда туган. Казан энергетика техникумын, Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлагач, Совет Армиясендә хезмәт итә. Аннары төрле промышленность предприятиеләрендә, «Комсомолец Татарии» газетасында корреспондент һәм җаваплы секретарь булып эшли. 1982 елдан — Татарстан Язучылар союзында әдәби консультант.

Яшь язучының беренче хикәя һәм повестьлары «Казан утлары»нда дөнья күрде. 1984 елда аның беренче китабы басылып чыкты.



### Эльмира Шәрифуллина

Эльмира Мөхәммәт кызы Шәрифуллина 1947 елда Мөслим районының Симәк авылында туган. Актаныш районы Зөбәер сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач, Минзәлә педучилищесында, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Мәктәптә балалар укыта, аннары «Ялкын» журналында, бүгенге көндә «Яшь ленинчы» газетасында эшли.

Аның шигырьләре «Беренче карлыгачлар», «Кызлар җыры» исемле күмәк җыентыкларда, балалар өчен чыккан «Безнең зоопарк» китабында басылды. 1984 елда шагыйрәнең «Янгыр җиле» исемле беренче китабы дөнья күрде.



### Нур Әхмәдиев

Нур Гариф улы Әхмәдиев 1946 елда Азнакай районы Әсәй авылында туган. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлагач, Азнакай районына эшкә җибәрелә. Мәктәптә укыта, ВЛКСМның Азнакай райкомында секретарь, район радиотапшыруларын оештыручы, «Азнакайнефть» идарәсенең курслап укыту комбинаты директоры булып эшли, хәзер «Татнефть» берләшмәсенең бораулау кадрлары мәктәбендә укыта.

Татарстан китап нәшрияты Н. Әхмәдиевнең «Аһәң» (1980), «Бал янгыры» (1984) исемле шигырь җыентыкларын бастырып чыгарды.

## МУЛЛАНУР ВАХИТОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

22 августта Казанның Куйбышев исемендәге мәйданында Мулланур Вахитовка һәйкәл ачуга багышланган тантаналы митинг булды.

Митингны халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе Р. Р. Идиатуллин ачты.

Һәйкәлне ачуның мактаулы хокукы СССР Верховный Советы Президиумы члены, КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усмановка, 1924 елдан КПСС члены Г. С. Баязитовка, В. И. Ленин исемендәге Казан күн берләшмәсенең алдынгы эшчесе Е. Ф. Окуневка, Питрәч районының М. Вахитов исемендәге колхозы председателе Ф. А. Сафинга бирелде.

Советлар Союзы Гимны яңгырый. Һәйкәлдәге тасма киселә, аннан япма ачыла. Тантанада катнашучылар алдына революционер-ленинчы Мулланур Вахитовның мәһабәт фигурасы килеп баса.

Сүз КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усмановка бирелә. Ул М. Вахитовның тормышы һәм революцион эшчәнлеге турында речь сөйләде.

Аннан Казан «Органик синтез» производство берләшмәсе аппаратчысы, Социалистик Хезмәт Герое Л. Е. Смирнова, Питрәч районы, М. Вахитов исемендәге колхоз председателе Ф. А. Сафин, КПССның Вахитов райкомы секретаре Ю. А. Гарпинченко, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Туфан Миңнуллин чыгыш ясап, митингта катнашучылар исеменнән күренекле революционер-ленинчы Мулланур Вахитов истәлегенә тирән ихтирамнарын, Бөек Октябрь казанышларын ныгытуда республика хезмәтчәннәренең омтылышларын белдерделәр.

Митингта катнашучылар Мулланур Вахитов һәйкәленә чәчәкләр куйдылар.

22 августта Казанда М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында Мулланур Вахитовның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды.

Мулланур Вахитовның тормышы һәм революцион эшчәнлеге турында доклад белән ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов чыкты.

Җыелышта КПССның Бауман райкомы беренче секретаре В. Н. Липужина, партия сугыш һәм хезмәт ветераны Г. С. Баязитов, М. Вахитов исемендәге Казан химкомбинаты аппаратчысы М. З. Шанукова, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты профессоры Р. И. Нәфиков, ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Д. К. Шәяхмәтов иптәшләр чыгыш ясады.

Җыелышта КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитеты һәм Казан шәһәр комитеты бюролары члennары һәм членлыкка кандидатлар катнашты.

Соңыннан тантаналы җыелышта катнашучыларга Татарстан сәнгать осталары көче белән концерт бирелде.

21 августта Казанда, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында, ялкынлы революционер-ленинчы Мулланур Вахитовның тууына 100 ел тулуга багышланган фәнни конференция булды.

Конференцияне КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире А. И. Афанасьев ачты.

Конференциядә Мулланур Вахитовның тормышы һәм революцион эшчәнлеге турында докладлар белән тарих фәннәре докторлары, профессорлар Р. И. Нәфиков, И. Р. Таһиров, М. К. Мөхәррәмов, Р. Г. Хәйретдинов, чуваш язучысы, Мулланур Вахитов турындагы китап авторы М. Юхма һәм башкалар чыкты.

Конференция эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

29 августта Татарстан язучыларының ачык партия җыелышы уздырылды. Җыелыш РСФСР Язучыларының VI съездын лаеклы каршылауда язучылар оешмасы алдында торган җитди бурычлар турында сөйләшүгә багышланган иде.

Әлеге мәсьәлә буенча Татарстан язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев доклад белән чыкты.

Фикер алышуларда Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, шагыйрьләр С. Хәким, Р. Харис, әдәбият галиме Х. Госман, язучылар Л. Ихсанова, М. Скороходов, композитор С. Садыйкова чыгыш ясап, бүгенге әдәбиятның хәл ителәсе җитди бурычлары турында сөйләделәр, эшлекле тәкъдимнәрен әйттеләр.

## ХӘСӘН ТУФАН ИСТӘЛЕГЕНӘ

Күренекле татар совет шагыйре Хәсән Туфан гомеренең соңгы елларында (1975—1981 еллар) Казанның Вишневский урамындагы 49 А йортында яшәде. 2 сентябрьдә шушы йортка шагыйрь истәлегенә мемориаль такта куелды.

Мемориаль такта ачу тантанасына республикабыз башкаласының партия һәм профсоюз оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, шәһәр җәмәгатьчелеге, шагыйрьнең туганнары җыелган иде.

Тантананы Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. А. Миңнуллин ачты. Аннары әдипләрдән С. Хәким, Ш. Галиев, Р. Миңнуллин чыгыш ясады.

Мемориаль такта ачу тантанасында КПССның Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнашты.

## АРХЕОГРАФИК ТАБЫШЛАР

Быел июль аенда Казан дәүләт университетының Археографик экспедициясе өч төркемгә бүленеп эшләде: тарих фәннәре докторы, профессор Миркасыйм Госманов җитәкчелегендәге зур төркем Әстерхан һәм Волгоград өлкәләрендә тарихи-археологик кузәтүләр алып барды. Алар күрше Ульяновск өлкәсенең Кулаткы районында археографик тикшеренүләр белән дә шөгыльләнде. Р. Шәйхиев җитәкчелегендәге икенче төркем Чувашиянең Батыр районы татар авылларын тикшерде; составында КДУның Совет чорына кадәрге СССР тарихы кафедрасы өлкән укытучысы Г. Хәбибуллин һәм журналыбызның фән бүлеге редакторы Җ. Миңнуллин булган өченче төркем Татарстанның Чүпрәле районында эшләде.

Ульяновск өлкәсендә Иске Кулаткы районының Иске Зеленый авылы тарихын, колхозлашу елларын тасвирлаган бай эчтәлекле кулъязма, шул ук районда күренекле татар шагыйре Габделҗаббар Кандалыйның моңарчы билгеле һәм билгесез булган шигырьләрен эченә алган кулъязма җыентык табылды. Чувашиянең Батыр районында авыл тарихлары, 1912 елгы Ленадагы ату турында истәлекләр һ. б. кыйммәтле ядкарьләр җыелды. Республикабызның Чүпрәле районында да җыр-бәет дәфтәрләре, юриспруденция буенча китаплар, төрле документлар тупланды. Бу төбәктә табылган кыйммәтле истәлекләр арасында элек татар халкында киң таралган «Яр-яр» исемле борынгы йола җырының күләмле нөсхәсе дә бар.

*

Күренекле тарихчы-археограф Сәет Вахидиның улы Нәзиф Вахидов Казан дәүләт университетының Совет чорына кадәрге СССР тарихы кафедрасына әтисенең китапханәсеннән калган китапларны бүләк итте. Ике дистәгә якын басма китаплар арасында Г. Ибраһимовның С. Вахидига бүләк иткән автографлы «Казакъ кызы» романының нөсхәсе дә бар. Шулай ук С. Вахидиның тормышына һәм эшчәнлегенә караган материаллар да игътибарны җәлеп итә.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм илле яше тулу уңаеннан, язучы, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Туфан Миңнуллин КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре һәм нәтиҗәле иҗат эшчәнлеге өчен шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 22 июль Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Нәтиҗәле әдәби иҗат эшчәнлеге өчен һәм җитмеш яше тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми консультанты тәнкыйтьче Гали Халит, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 22 июль Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Актив фәнни-тикшеренү эшчәнлеге өчен һәм алтмыш яше тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән гыйльми хезмәткәре, филология фәннәре докторы Әбрар Гыйбадуллович Кәримуллин, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 22 июль Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен түбәндәге иптәшләргә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 15 август Указы белән, «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде:

Әхмәтҗанов Шамил Сабировичка — Татарстан АССРның дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты.

Галимова Әлфия Әхмәтовнага — Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт филармониясе солисткасы.

Праченко Владимир Васильевичка — Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры солисты.

Совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан АССР Телевидение һәм радиотапшырулар буенча дәүләт комитетының телевидение студиясе дикторы Елизавета Зәһидуллинага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 8 июль Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет эстрада сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисткасы Анна Латыйповага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 15 август Указы белән «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

# ГОМЕР ЧИШМӘСЕ

Күп гасырлык милли яшәү рәвеше һәм үзенчәлекле халык характерлары формалашуның уңдырышлы җирлекләреннән саналучы авыл сәнгать осталарын һәрвакыт үзенә тартып торган, табигатькә якынлык, хезмәткә үзгә мөнәсәбәт һәм башка шундый үзара бәйләнешле төшенчәләрнең чагылышын калку итеп күрсәтү өчен отышлы нигез булып хезмәт иткән. Беренче буын рәссамнары быздан П. Радимов, Б. Урманче, В. Тимофеевлар ук, авылны экзотик һәм идиллик рәвештә сурәтләүдән баш тартып, тормыштагы социаль-экономик һәм рухи үзгәрешләрнең асылын күрсәтеп бирергә омтылдылар. Совет авылы тормышын төрле яклап ачу илленче һәм алтмышынчы елларда Л. Фәттахов, Х. Якупов кебек сәнгать осталары иҗатларында новаторларча үстерелеш тапты. Образларны көнкүреш үзенчәлекләре аша гәүдәләндерү, ягъни милли характерлар проблемасын яшәү рәвеше асылыннан чыгып хәл итү моннан соңгы чорда да сизелерлек яңарыш кичерде.

Җитмешенче еллар уртасында сынлы сәнгатебезне татар авылындагы «шигъри башлангыч»ны калкытыбрак сурәтләгән әсәрләргә баеткан рәссамнар дулкыны килде: Ш. Шәйдуллин, З. Гыймаев, Ф. Якупов... Шунысы кыйммәтле: алар авыл тормышына ниндидер яңа ноктадан карый беләләр һәм беркем дә кабатламаган үзгә сурәтләү чаралары белән эш итәләр. Шушы уңайдан Фәрит Якуповның «Онытылган чишмә» исемле картинасына тукталыйк.

Символик образ буларак алынган чишмә композициянең идея эчтәлеге үзәген билгели, һәм ул гыйбрәтле тормыш кичергән өлкәннәрнең гомер чишмәсе рәвешендә кабул ителә. Күзгә сары яфраклар белән каймаланган чишмәдән онытылмас хатирәләр кайнап чыга төсле. Чишмә өслеге күзгесендә, әйтерсең, гомер сурәтләре чагыла. Шушы борынгы чишмә янында үткәннәр белән бүгенге очраша. Еракта электрүткәргеч линияләре күренә, ә алдарак шәһәрчә киенгән бала уйнап йөри. Чишмә үзенең улагыннан тулып чылтырый, тормыш яшәрә-яшәрә агуын дәвам иттерә.

**Розалина ШАҺИЕВА,**

Татарстан сынлы сәнгать музее фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында классик драматург Кәрим Тинчуринның «Казан сөлгесе» пьесасы буенча куелган спектакльдән күренеш.

**Рөстәм МАНСУРОВ фотолары.**

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)